ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.1999



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ



Татар әдәбиятын үстерүдәге олы казанышлары өчен язучы **Фәттахов Нурихан Садрилман** улына **(Нурихан Фәттахка)** «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

Казан, Кремль.
1998 ел, 19 декабрь.

Татарстан Республикасы
Президенты **М. Ш. Шәймиев.**

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1999

# 1

(915)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Гасыр йомгагын төенләгәндә ..... 5

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гамил АФЗАЛ. Әллә кайда оҗмах кошлары бар. *Шигырьләр* ..... 13
Зөки ЗӘЙНУЛЛИН. Агыйделнең аръягында... *Роман-кыйсса* ..... 18
Илдар ЮЗЕЕВ. Йөрәгемә ятып ял иткәч. *Шигырьләр* ..... 66
Каим ШӘЙХЕТДИН. Кышлар узар... *Хәрби кеше язмалары* ..... 71
Рафаэль СИБАТ. Гомернең дүрт фасылы. *Шигырьләр* ..... 107
Фәнис ЯРУЛЛИН. Якты сагыш. *Хикәя* ..... 110
Рөстәм СУЛТИ. Читтә унынчы көй. *Шигырьләр* ..... 114

ӘХӘТ ГАФФАРГА 50 ЯШЬ

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Халыкчан иҗат иясе ..... 118
Әхәт ГАФФАР. Шәҗәрәм ажаганнары. *Хикәят* ..... 119

ПУБЛИЦИСТИКА

Марсель ЗАРИПОВ. Генерал булу рәхәтме? ..... 128

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Радик ФӘИЗОВ, Рәфикъ ШӘРӘФИЕВ. Туксанынчы еллар әдәбияты. *Анкетага җаваплар* ..... 145

СӘНГАТЬ

Шамил МОНАСЫЙПОВ. Урманченың рухи дөньясы ..... 151

ТАРИХ

Мәсгуд ГАЙНЕТДИН. Әдәби телебез төбендә—Алтын Урда теле ..... 167

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Рафаэль МОСТАФИН. "Өзелергә җитеп сыкрый күңелем..." ..... 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Фатих УРМАНЧЕ. Татар халык музыкасы турында җитди хезмәт ..... 181
Радик ХӘБИБРАХМАН Тарихка күпер ..... 183

Укучы сүзе ..... 186
Әз-мәз мәзәк ..... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

*Журнал выходит один раз в месяц*

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

"В преддверии нового тысячелетия"—статья главного редактора Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
"Проза и поэзия": "За рекой Белая"—роман З. ЗАЙНУЛЛИНА (начало); записки офицера—К. ШАЙХУТДИН: "Пройдет зима..."; рассказ Ф. ЯРУЛЛИНА "Светлая грусть"; стихи Г. АФЗАЛА, И. ЮЗЕЕВА, Р. СИБАТА, Р. СУЛЬТИ.
"К 50- летию Ахата Гаффара": предисловие Г. ГИЛЬМАНОВА и рассказ юбиляра "Зарницы родословной".
"Публицистика": очерк М. ЗАРИПОВА "Легко ли быть генералом?"
"Литературная критика": "Татарская литература 90-х годов". статья Р. ФАИЗОВА и Р. ШАРАФЕЕВА.
"Искусство": статья Ш. МОНАСЫПОВА "Духовный мир Урманче".
"История": М. ГАЙНУТДИНОВ. "Наш язык—наследник языка Золотой Орды".
"К 90- летию Фатиха Карима": статья Р. МУСТАФИНА "Душа готова оборваться...".
"Книжное обозрение": Ф. УРМАНЧЕ рецензирует книгу Р. А. Исхаковой-Вамбы "Татарское народное музыкальное творчество" и Р. ФАИЗОВ—книгу Ф.Латифи и Р. Якуша "След".
Слово читателя.
Забавные истории Ш. Маннапова.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: тамга-герб Казанского ханства, найденный в 1997 году вблизи г. Казани; писатель и общественный деятель З. Зайнуллин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"To the beginning of the millennium "- the article of chief editor R. FAIZULLIN.
"Prose and Poetry": ZAINULLIN'S novel "Over the White river"; the notes of officer K. SHAIKHUTDIN "The winter will be over..."; YARRULLIN'S story "The light sadness"; the verses of G. APHZAL, I. YUZEEV, R. SIBAT, R. SULTY.
"Commemorating the 50th Anniversary of Akhat Gaffar": G. GILMANOV'S preface and GAFFAR'S story "The light of the family tree".
"Publicism": M. ZARIPOV'S essay "Is it easily to be general?"
" Literary criticism ": R. FAIZOV'S and R. SHARAFEEV'S article "Tartar literature of 90 th years".
"Art": SH. MONASIPOV'S article "The spiritical world of Urmanchy".
"History": M. GAINUTDINOV "Our language is the heir of Gold Orda language "
"Commemorating the 90th Anniversary of Fatikh Karim": R. MUSTAFIN'S article "The soul is ready to break..."
"Book review": R. A. Iskhakova-Vamba's book "The Tartar national musical creative works"; F. Latifi's and R. Yakushev's book "The track'.
"Reader's word".
The funny stories of SH. MANNAPOV.
The diary of social and cultural life.
In our covers: tamga-arms of Kazan kingdom found in 1997; writer and public benefactor Z. Zainullin.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 13.01.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9019 Заказ 3-14
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

**Равил Фәйзуллин**

# ГАСЫР ЙОМГАГЫН ТӨЕНЛӘГӘНДӘ

Булсан икән ул бер Ташбалбал да, җиргә береккән килеш утыр икән Җил-Вакыт дигәннәренә исең дә китмичә. Үтсен еллар, үтсен гасырлар, ә син мәңгелеккә каккан казык кебек битараф рәхәтлектә оеп утырасың... Бакый гомер җил-яңгырларның сыйпап иркәләүләре туйдыргач, бер мәл, ниндидер илаһи кодрәт белән җанланасың, кызык өчен генә булса да, бу Күк гөмбәзе астында, Ай-Кояш яктысында Адәм балаларының мәш килеп ниләр майтарып ятканына күз саласың... Әһә, Дөнья дигән Яшәү Үзәнендә эшләр болайрак икән... Карыйсың-күрәсең, аңлыйсың-беләсең дә янәдән Ташбалбалга әвереләсең. Күпмедер ел-гасырлар үткәч тагын бер җанланып, Тормыш дигәннәренә янә күз салып, үзеңчә анализ-нәтиҗә ясыйсың...

Бу уйлар—әкияти хыял. Безгә—бер саплам җеп озынлыгында гомер бирелгән Кеше атлы Адәм балаларына мәңге яшәр таш сын да, шигырьдәгечә, "ак болыт булырга да язмаган"... Яшисең икән (бүтән чара юк!—"ирексездән туасың, гаҗәпләнеп яшисең, сагыш белән үләсең...")—уйланмый хәлең юк: борчыласың, хыялланасың, исәп-хисапларыңа муафикъ эш-гамәл кылырга тырышасың. Гадәттә, кылган эш-гамәлләр—корган уй-хыялларның бик аз өлеше генә булып чыга...

Гаме булган Җан иясе өчен уйланыплар калыр өчен җай чыгып кына тора ул. Тиздән—тагын берәр елдан Кешелек яңа гасырга аяк басарга тора. Хәер, гасырлар үлчәме—шартлы нәрсә. Миладичә быел 1999 ел булса, һиҗричә—1420 ел гына исәпләнә. Ә яһүдләр исә Кешелек тарихын 6 гасырга якын дип йөртәләр... Яшәешебез шартларына бәйле рәвештә бездә инде байтак гомерләр григорьян календаре исәптә йөри. Туу-үлемебез дә, гомер кичкәндәге төп вакыйга-даталар да шушы календарьдагы саннар белән билгеләнә.

Әйе, без "Егерме" дип билгеләгән түгәрәк санлы гасыр тәмамлануга бара. Алдагылары белән чагыштырганда җәһәтрәк, тизрәк үткәндер сыман тоела ул миңа. Җир Кояш тирәли кызурак әйләнмәгәндер, билгеле. Ә планетадагы Тереклекнең яшәү рәвеше, кеше гамәлләренең башкарылу тизлеге, вакыйгаларның үзара үрелеп агуы, ил-халыкларның бер-берсенә керешеп аралашуы ягыннан бу гасыр, һичшиксез, "тыгызрак" динамиграк булыр. Чагыштырып карыйк: бу йөз елга якын дәвердә халык бик нык үрчеде, берничә мәртәбәгә ишәйде. Кытай кебек халкы миллиардлап исәпләнгән илләр хасил булды. БМО мәгълүматләренә караганда, хәзер Җир йөзендә 6 миллиардлап кеше яши. Димәк, тыгызландык. Кояш астында тере күләгәләр күпкә артты, җирдән шуышып искән җилгә җанлы киртәләр күбәйде. Элгәрге гасырларда кешеләр үзе яшәгән җир өсте киңлекләрен биек тау башларына менеп манзара кылган булса, XX гасырда Адәми зат Җир шарын—Яшел Планета дип атап, галәм

кинлекләреннән чыгып, "читтән капшап" карады, хәтта Айга житеп, "Зөһрә кыз көянтәсен тотып кайтты". Жир-бишеккә мөнәсәбәт үзгәрде. Матдәнең "жанында" казыну көчәйде. Атомны таркаттылар. Ягъни, кеше акылы макродөньяга да, микродөньяга да тирән үтеп керә бара. Кеше яман чир кебек сырхауларны (соңгы чорда алар рәтенә СПИД кебекләре дә өстәлде әле!) дәваларга чарасыз булса да, тереклекне күпләп кыра торган атом, водород, нейтрон һәм тагын әллә нинди бомба-кораллар уйлап тапты. Жирнең өстен-астын үлем заводлары челтәрләде. Диңгез-океаннарның төпләренә кадәр бүлгәләнелде. Энергетик ресурслар—нефть, ташкүмер, газ бетүгә таба авышты. Азонлы биосфера катламы, тузган сүрү кебек, ертылырлык юка элпәгә калды. Табигать мәсхәрәләнде. Сугыш-эпидемияләрдән дә мәхшәррәк афәт—экологик афәт килде. Чын чиста сулар Арктик бозлар куенында гына калды бугай инде. Жир-Су дигәч, ирексездән күнелгә жирсү сүзе килә. Табигый Табигатьне сагынып жирсү... Гасырыбызның 50 елларында телдән төшми йөргән "Без Табигатьтән мәрхәмәтләр көтеп тора алмыйбыз, аны тартып алу—безнең бурыч!" дигән лозунг-шигарьнең икенче өлешен "коммунистларча" шәп үтәдек бугай. Кеше—нинди генә көч-куәткә, аң-зиһенгә ия булмасын, ул, иң әүвәл, Табигать баласы. Вәхшиләрчә мөнәсәбәттән Табигатьнең эчке гармониясе бозылган икән, димәк аның баласы—Кеше дә, шул дәрәжәдә үк камиллеген, игелеклелеген югалткан, дигән сүз. Миңа калса, үтеп бара торган Гасыр Кешенең кешелеген Яшәү сәхнәсендә шундый итеп сынады ки, һәм бөеклеген, һәм түбәнлеген, көзгедәге кебек, үзенә һәм жирдәшләренә бөтен нечкәлекләре белән күрсәтеп бирде. Шигырьдәгечә—"бөтен прогресслар фәкать регресс кына, кеше жаны череп таркалса..."

Меңнәрчә телләрдә сөйләшеп тереклек итүче халыклар (жир йөзендә 5 меңнән артык тел һәм шивәләр бар дип исәпләнә) яшәешендә дә, ягъни дөньякүләм ижтимагый тормышта да, Табигать-Ана кичергән хәлләргә охшаш үзгәреш-тетрәнүләр, һай, күп булды бу үткән гасырда! Гасыр яшьтәшләре булган йөзьяшәр аксакаллар (әйтик, безнең Гомәр ага Бәширов кебек олуг затлар) ул хәлләрне бөтен күзәнәкләре белән тоеп аңлыйлардыр. Әле безнең, чагыштырмача яшьрәкләрнең дә, ишетеп, укып, күреп, кичереп белгәннәре дә байтакка жыйнала.

Менә ул Тарих "капчыгыннан тырпаеп торган" кайбер тенденция-контурлар. Егерменче гасырда бик күп халыклар милли бәйсезлекләре өчен көрәшкә күтәрелделәр, күп корбаннар бәрабәренә булса да, жиңделәр, максатларына ирештеләр. Искә төшерик. Европаның төп баскынчы илләре—Англия, Испания, Франция күпме колонияләреннән колак кактылар! Африкада, Азиядә бик күп яңа бәйсез дәүләтләр барлыкка килде. Димәк, кимсетелгән, изелгән, каһәрләнгән халыкларның күз яшьле каргышы "костырды" аларны. Ә Тормыш-Яшәү дигән бөек сәгадәтнең антиподы—"ихтыяжи" сугышлар? Егерменче гасыр бу яктан күрсәтте инде күрмәгәнне! Үзеге без яшәгән Европада кайнап чыгып, аннары бөтен кыйтгаларга да таралган Беренче Бөтендөнья сугышы, янә Икенче Бөтендөнья сугышы (исемнәре генә ни тора!), булуы ихтимал өченчесе... Тфү! Тфү!

Ихтимал, Күк жәнапләреннән жибәрелгән иң зур каһәр һәм сынау—элеккеге Рус империясе, соңрак СССР, хәзер Россия дип йөртелгән жирләргә тигәндер... Инкыйлаб, гражданнар сугышы, жирне хужасыннан аеру—колхозлашу, сыйнфый дошман эзләү, искитмәле салымнар чоры, «коммунизм төзү» дәвере, "бөек" торгынлык, һәм, ниһаять, янәдән килеп байлар белән хәерчеләргә бүленү еллары... Бу гасырда Россия империясе, элеккеге Рим яки Госманлы империяләре шикелле таркалды дисәк тә була. Әлеге дә баягы шул "косу" галәмәте бит бу. Гасыр башында Польша, Финляндияләр кебек илләр мөстәкыйльлек алып үзбашка чыкса, гасыр ахырында зур тоташ кинлекләрнең кырыйларыннан кителгән язгы бозлар шикелле, хәзер шактый ук кечерәйгән территориядә ярымач, ярымжимерек,

ярымисерек Рәсәй утырып калды (шуның уртасында без...). Прибалтлар да юк, кырый-украин яклары да юк, Кавказ да, Урта Азия дә... Кояш астында алар бар: әмма алар—бүтән! Гомумтенденция: халыклар, бер яктан, икътисади, сәяси жирлектә берләшергә омтылсалар (мәсәлән, Европа илләре бердәмлеге һ.б.), икенче яктан, мөстәкыйльлек, милли аерымлык, үз йорт-дәүләтен булдыру юлын сайладылар. Моның бер ачык мисалы гасыр урталарында Израиль дәүләте оешу булды. Тел вә дин ягыннан үзара кардәш төркемнәр тәшкил иткән халыкларда да үзенчәлекле зур эволюцион үзгәрешләр туды, әлбәттә. Кемгә ничектер, миңа калса, төрки халыклар, әйтик славян халыкларына караганда, тетрәнүләрне, катаклизмнарны күбрәк кичерделәр шикелле. Гасыр башында бөтен төрки халыклар диярлек, тарихи бәйсезлекләрен югалтып, аяусыз колониаль басымга дучар ителделәр. Егерменче елларда, чагыштырмача көчле һәм мөстәкыйль булган Төркия дә бәйсезлеген югалта язып калды. Урта Азия ягы төркиләре бу гасырда мәгълүм бер тәрәккыяткә ирешсәләр дә, барыбер, инкыйлаб китергән уртак нәтиҗәләрдән, уртак әйләнештән читтә кала алмадылар. Шул ук бер идеологик максат-принциплар, шул ук тоталитар идарә итү системасы, шул ук совет халкы (дөньядагы иң алдынгы!) рәвешендә урыслаштыру сәясәте... Сүздә никадәр генә ирекле һәм тугандаш саналмасын, "бәйдә тоту" принцибы шулкадәр мөкәммәл эшләнгән иде ки, хәтта бер генә республиканың да үзендә теге яки бу төрдәге тулы производство-житештерү циклы булдырылмады. Төп деталь, двигатель бер жирдә эшләнсә, ә бер бик тә кирәкле икенче бер "шөреп" меңәр чакрым ераклыктагы бүтән бер өлкә йә республикада ясала иде... Әмма тарихи дөреслек өчен гадел булыйк: Урта Азия халыкларына бу үткән гасыр шактый ук "көн төште". Ижтимагый формацияләрнең эволюцион үсеш чоры тизләнү сәбәпле, икътисадта алар Урта гасырчылык мирасыннан шактый тиз арына алдылар. Нинди генә бәрелешләр, сугышлар, сынаулар булса да, халыкларның тарихи рухлары, нигездә, бетмәде, яшәү рәвешләренең төп принциплары сакланды, өмет-максатлары югалмады. Һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба, алар хакыйкый бәйсезлек тә алдылар. Күрәбез, беләбез: бүген алар зур икътисади кыенлыклар кичерә. Үтә торган авырлыклар бу. Иң мөһиме: "Аһ, татлы нәрсә шул ул Азатлык!" дигән шикелле, халыкның киләчәгенә гарантия булган мөстәкыйль дәүләтчелек барлыкка килде. Димәк, өмет бар!

Безнең жирлектә яшәгән өлкән һәм урта буын өчен Егерменче гасыр тарихы ул, асылда, СССР тарихы. Ә СССР—ул Жир шарындагы коры жирнең алтыдан берен тәшкил иткән галәмәт зур территория. Шушы киңлек гел генә Егерменче гасырның халыкларны "печү" полигоны булган икән дип уйлаучылар ялгышырлар. Байтак ил-халыкларга якты нур булып төшәрлек прогрессив идея-гамәлләр дә туган һәм тормышка ашкан жир дә бит әле ул Советлар Союзы. Егерменче гасырның иң авыр сынауларын кичеп тә рухлары сынмаган, талантлы халыклар яшәгән бу жирләрдә. Күп кенә бөек башлангычлар иле дә булган ул. Халкы ачлы-туклы яшәсә дә, киләчәккә иманы нык булган аның. Жаны сау булган. Конфуций әйткән, имеш: Дәүләт белән идарә итәр өчен өч нәрсә кирәк: ашар-эчәр ризык, ил сакларлык корал һәм халык ышанычы. Аннан сораганнар: шуларның берәрсе булмаса, дәүләтне тотып буламы? Коралсыз да була, дип жавап биргән ул. Әгәр шул өченең тагын берсе булмаса? Хәтта ризыксыз да була, дигән акыл иясе, кешегә, барыбер, бер үләргә туры килә, ә менә халык ышанычын югалтса, бернинди Дәүләт тә яши алмый, дип жавап биргән. Әйе, ышаныч, киләчәккә ышаныч бөек нәрсә ул! Дөрес, ышанычларның күбесе акланмаган... Халыкларның бөеклеге һәм фажигасе кардиограммасы. "Ул елларга инде кайтып булмый..." дигән шигырь юллары бар. "Сагынып кына була!" дип дәвам итә ул. Хикмәт—ностальгиядә, сагыну-сагынмауда гына түгел, әлбәттә. Әмма бүгенге кискен контрастлар, дәүләти дәрәжәдәге жинаятьчелек, эшсезлек, сәяси башбаштаклык... Әнә шулар үткәнне сагынырга мәжбүр итә. Ә сагыныр

нәрсәләр юк түгел: социаль гаделлек; хезмәткә, укуга, ялга, дәвалануга реаль хокуклар; билгеле бер әхлакый- этик нормаларның үтәлүе, канун-законнарның эзлекле ныклыгы...

Инде килеп, үзебезгә—татар кавеменә кайтыйк. Ни гамәлләр кылынды бу дәвердә? Бүген ниләр майтарабыз? Киләчәктә нәрсәләр эшләргә җыенабыз? Сорауларны бердем бирүен дә, ә җавап бирүләре, ай-һай, кыен. Яңа гасыр башланыр алдыннан бик күпләр уйлана-уйлана, кайта-кайта үзенчә җавап эзләячәк әле бу сорауларга. Шулай булгач, шул меңнәрнең берсе, бу очракта шушы гасырның икенче яртысын кичкән кеше, бүгенге әдип һәм мөхәррир буларак, үземчә фикер йөртеп карау гаепмени? Сизенәм, мөгаен, субъективлыкта гаепләүчеләр дә табылыр. Моны халык язмышы турында фикерләшкәндә бәхәсләр туу—табигый хәл ич! дип кабул итәргә кирәктер.

Иң элек күңелгә шуны киртләп куйыйк. Үтеп баручы гасырда, без сан ягыннан (рәсми мәгълүматләргә табынмаган хәлдә дә) әлләни артмадык, үрчемәдек, ишәймәдек. Бүтән төрки халыклар белән чагыштырганда бу бигрәк тә ачык күренә. Сәбәпләрен һәркем үзенчә гоман кылыр. Заманында хәзер уртак ватан саналган иксез-чиксез киңлекләргә дәгъва кылган милләт XV-XVI гасырларда каршы як милләт белән бер чамадарак булган бит ласа! Нидән бу туктап әкренәймеш? Бар булып та, бүтән халыклар мохитендә, балавыз күк изрәп "эрүебез" нәтиҗәсеме бу? Әллә сәбәп генофонд оеткысының сыекланyындамы? Әллә неомалтусчылык (күп үрчү, янәсе сыйфатка "бәрә", интеллект кимүгә китерә. Гадәттә, Африка һәм Азия илләре мисалында шулай аңлаталар) тарафдарлары булып киттекме? Әллә элегрәк прогрессив күренеш дип бик пропагандаланган катнаш никахлар җимешеме? Ни генә булмасын, факт инкяр итеп булмаслык факт булып кала. Димәк, санның сыйфатка әверелү ягыннан да без әлләни алгарышка өметләнә алмыйбыз.

Каршылыклы тагын бер сорау туа: гасыр башында татарның матди һәм мәдәни хәле ничегрәк булган? Гасыр ахырында ничегрәк? Россия империясе кысасында нindирәк урын тотканбыз да, хәзер шул ук ил-халыклар (хәзер статуслары бүтән булса да) арасында нindирәк рейтингта без? (Әлбәттә, һәр вакытка, һәр чорга чагыштырмача нисбәттә!) Без гасыр башында, бүтән халыклар белән чагыштырганда баерак, зыялырак булганбызмы, әллә?.. (Янәдән кабатлыйм: чагыштырмача). Төгәл, кистереп җавап бирү кыен. Гомумконтурны ретроштрихлар белән генә чамаларга кала. Шунысы факт: заманасына күрә Россиядә—Дума җыелышларындамы, фабрика-завод цехларындамы, прииска-шахта тирәнлекләрендәме—татар факторы шактый көчле булган. Сәүдә дөньясы турында әйтәсе дә юк. Халыкның билгеле бер катламында милли сәрмая—ягъни милли капитал тупланган булган. Хосуси кулларда булса да, бу капиталның шактый өлешен милли байлык дип тә әйтеп була. Моңа бер дәлил-меценатлык. Әгәр хәйрия оешмалары (бу хәрәкәтнең үзәгендә торган Хөсәеновлар, Кәримов, Яушев, Юнысов, Акчурин, Рәмиев кебек затларга дистә еллар аша рәхмәт!) булмаса, әйтик мәгариф өлкәсендәге казанышларга (чагыштырмача уку-язу буенча татарлар урыс туганнарга караганда гыйлемлерәк тә саналганнар әле. Бу хакта Ленин да язып калдырган) ирешелер идеме? Матбага эше гөрләп тормаса, көчле әдәбият каян килер иде? Рухыбыз дөньясында бер Тукай феномены гына да күп нәрсәне аңлата.

Ул заманда безнең халык күпләп яшәгән һәр губерниядә, һәр төбәктә татар теленә, татар китабына, милли яшәү рәвешенә табигый көчле ихтыяҗ булган. Татар китабы, гомумән, татар матбугаты, империянең дистәләгән регионнарында мул күләмдә, күп санда нәшер ителгән. Театр труппалары оешкан. Дини оешмалар һәм мәчетләр массакүләм рухи-идеологик үзәк миссиясен үтәгән... Кыскасы, рухи күтәрелеш булган. Дәрт тә, дәрман да булган.

Мәгълүм хакыйкать: һәр халыкның көчен-куәтен аның милли байлыгы билгели. Бүгенге дөнья байлыгы кайсы илләрдә һәм кемнәр кулында тупланган? Әйтәләр: кимендә 70 % мәгълүм бер халык хозурында. Ә безнең милли байлыгыбыз (республика банкларының берсендә Татарстанның да үз алтыны—фәлән килолы бер кирпеч коелмасы бар дип сөйлиләр) күпме дә һәм кемнәр кулында?.. Алга киткән цивилизацияле илләр мисалы шуны күрсәтә: әгәр байлык чын мәгънәсендә уртак милли байлык булса, чын хөкүмәт аны әрәм-шәрәм итүгә, урлауга юл куймый. Хәер, бу кадәресе хәзерге Россиягә дә, Татарстанга да карамый шикелле.

Үткәнне мактыймммы? Һич юк . Булганын искәртәм генә. Бүгенге күзлектән караганда ул заманның сәнәгатендә булсын, мәгърифәтендә, сәнгать һәм әдәбиятында булсын дөнья кадәр тискәре якларын табарга мөмкин. Ә бүгенгебез? Совет чорында чыккан йөзләгән фәнни-гыйльми саналган хезмәт-китапларны актарсак, (аларда совет чорындагы бишьеллыкларның "уңышларын", гадәттә, нигәдер 1913 елгы күрсәткечләр белән чагыштыралар иде) теге заман белән чагыштырганда йөзәрләгән, хәтта меңәрләгән тапкыр үсеш турында саннар, күрсәткечләргә юлыгырбыз. Әйтик, матбугат турында сүз чыкса, әйтерләр, хәзер бер Татарстанда гына йөзләгән нәшрият бар. Шәһәрләрдә йөзләгән татар мәктәбе. Фәлән йөз язучы, фәлән мең мәдәният сарае, клуб... Ә заводлар, фабрикалар, промышленность предприятиеләре, бигрәк тә хәрби заводлар турында сүз китсә, үсеш темпларына шаккатып тел шартлатырга гына кала. Геополитик яктан Европа-Азия казанышларына ия Татарстан фәненең казанышларын шик астына алырга теләмибез. Читләрдән караганда, чыннан да, милли аспект турында уйламасаң яки аны инкяр итсәң, без фәкать тәрәккыят аванпостында гына торабыз диярсең.

Ярый, без—каләм—иялəре, гомерләребезне багышлап, күп гасырлы зур әдәбиятыбыз бар дип, эчке куаныч кичереп яшәүчеләр, бөек рухи чыганак—Галиҗәнап Әдәбиятыбыз турында бүгенниләр уйлыйбыз соң? Өзек-төтек кенә белгән Болгар чоры, Алтын Урда, Казан чорларына кереп тормыйча, күпмедер дәрәҗәдә шаһите без булган Егерменче гасыр әдәбиятын күздән кичерик. Гасыр башы һәм гасыр ахыры чишмә башлары чыганакларын барлыйк. Кайларда туып, кайлардан килгән соң талантлар татар әдәбиятына? Әлбәттә, Идел-Урал буе—Татарстан һәм Башкортостаннан, Самара, Сембер, Пенза, Нижгардан; Әстерхан, Тобол, Сарытау, Оренбург, Троицк, Чиләбе, Курган якларыннан... Тагын дистәләгән шәһәрләрдән... Хәер, йөрәк яндырып санап торуның хаҗәте юк. Хәзерге әдәбиятыбызга әзме-күпме килеп кушылган яшьләр—үзебезнең Татарстаннан да Башкортостаннан. Калган регионнардан инде килмиләр диярлек. Мәктәпләр беткән, китапханәләрдәге рухны вакыт җилгәргән, "киткән ватан белән сөт тә китканме әллә?.." Әй, мөхтәрәм зат Закир Рәмиев—иптәш Дәрдмәнд!—ямьле Юлык буйларында нинди варисларыгыз үсә? Сыркыдыда Такташ якташлары татар китапларын укыймы? Пенза якларында Г.Коләхмәтов, К.Тинчурин, Ш. Усманов, Г.Кутуйлар рухы исәнме? Камышлы Әнвәр абый Давыдовны юксынамы? Тагын кайсы якларга карап оран салыйк? Беренче татар романнары авторы З.Бигиев (Ростов), Ш.Камал, Г. Әпсәләмов (Мордовия), К. Нәҗми (Т.Новгород), Г. Сәмитова (Ташлыяр), Х. Госман (Пермь), А. Расих (Троицк), Н.Арслан (Кызылъяр)... Театр, музыка, сынлы сәнгать дөньясыннан кайбер исемнәрне искә төшереп үтик: З.Хәбибуллин—(Орск), Л. Фәттахов (Сергач), Р.Ваһапов (Т.Новгород), Г. Кайбицская (Уральск), Ф. Туишев (Сембер)... Хәзер, кызганыч, ул төбәкләрдән мондый олуг "йолдызларны" телескоп яки төнлә күрсәтә торган приборлардан карасаң да күреп-табып булмый инде...

Әдәбият—китапсыз була алмый. Татар китабының, гомумән матбугатының бүгенге хәле күңел күгәртерлек дәрәҗәдә мөшкел. Китап кирәксез товарга әйләнде. Үзенең кирәксезлеген тою—һәр талант, гомумән һәркем өчен, иң авыр тойгыларның берсе. Мәгърифәтче шагыйрь Акмулла кебек, куларбага китап төяп ил буйлап йөрергә дә риза булыр идең дә

хәтта, әмма бүгенге яшь-җилкенчәккә син язган җыру-моңнар кирәк микән? Ә бит Егерме беренче гасырга алып чыгарлык әдәби мирасыбыз бар һәм ул әлегә өстәлеп тора! Аяныч. Мирасыбыз өчен түгел, бүгенге хәлебез өчен аяныч.

Хәзерге татар әдәбияты әлегәчә элеккеге "эч мае" хисабына (фольклор, классик мирас тәэсире, чирәмле авыл рухы, җыр-моң, балачак хатирәләре, табигый җир-су...) яшәп килде. Телебезнең бишеге булган авыл да, ай-һай, бик нык үзгәрде шул бу дистә елларда!.. Берничә буынны тәрбияләгән "Галиябану", "Агыйдел", "Йөзек кашы", "Туган ягым—яшел бишек" әсәрләрендәге каһарманнарның реаль оныклары укый микән әле бу гүзәл әсәрләрне? Шикләнәм. Кыскасы, нигезебезне—авылны югалтып барабыз. Бәс шулай булгач, сугыштан соң тирәлегебезне чорнап алган ВПК предприятиеләре, нефть промыселлары, КамАЗ, нефтехимнәрнең югары даирәдәге шәхесләре турында үз телебездә нинди югары художестволы әсәр туарга мөмкин! Базарың (бәяң мәгънәсендә) булмагач, әдипнең дә кадере юк. Кадерсез әдип үзе дә сансызлана. Бүгенге көндә югары исемнәр йөрткән, яшьләре белән 70 ләрдән узган мөхтәрәм әдипләребезнең дә байтагының интеллектын гасыр башындагы С. Максуди, Й. Акчура, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г. Ибраһимовлар интеллекты, зыялылыгы һәм затлылыгы белән чагыштыру кыен. Әмма, үзен татар дип йөрткән, үзендә милли үзаң бар, дип исәпләгән һәркем бернәрсәне онытмаска тиеш: дәүләтчелек идеясе теге йә бу формада иң әүвәл Сүздә—гыйлем ияләренең, шагыйрьләрнең, әдипләрнең язма яки басма хезмәтләрендә сакланды. Байтак гасырлар буенча. Дин, беренче чиратта милләтне таркатмаска булышса, әдәбият иң мөкатдәс хисне—Азатлык, Бәйсезлек, Мөстәкыйльлек идеясен, йә ачыктан-ачык, йә эзоп теле белән—эчтән саклап, үстереп килде. Әйе, 90 елларда беркадәр яуланган суверенитет-мөстәкыйльлегебезнең юлбашы ерактарак... Шуңа күрә дә, шул Олуг Әдәбият варисларының бүгенге көндә үз талантларына кирәк кулланыш таба алмаулары, кирәксезлекләре—ил хуҗалары, дөнья чыгырын әйләндерүчеләр өчен оят булырга тиеш.

Халык рухының ышанычлы көзгесе булган әдәбият турында сүз кузгаткач, милләтне милләт иткән бүтән компонентлар турында да берничә сүз әйтми калып булмый. Ул—туган тел язмышы, ул—милли тарих, ул—милли мәгариф системасы, ул—дин тәгълиматы... Бу олуг мәсьәләләрне бер язмада хәл итү түгел, чишелешен дөрес куя белү дә ифрат авыр. Теләгәндә дә, әзерлегем, көчем дә җитмәс иде. Кайбер күзәтүләр белән чикләнәм. Тел хакында сүзем кыска: ул—сорау гына. Ана телендә гасыр башында күбрәк сөйләшкәнме татар халкы, әллә хәзерме? Өч алфавит кичкән халык, яңа гасыр башын нинди имля белән башлар? Җавапларны укучы үзе табар. Дин өлкәсендә, кызганыч, махсус белемем юк. Шулай да, мәсьәлә артык зур булганга күрә,бу хакта һәркемнең үз фикере булу лязем. Әгәр динебез булмаса, бу 4-5 гасыр эчендә без милләт буларак күптән беткән булыр идек инде. Безне моңарчы дин, эчке иман саклап килде. Шуны аңлап дәһшәтле кара көчләр төрле гасырларда динебезне юк итәргә ташландылар да инде!

Үтеп баручы гасырда, рухка иркенрәк еллар булгаласа да, нигездә, динебез, галимнәребез бик нык каһәрләнде, дин хадимнәренең күбесе җисми юк ителде. Болары һәркайсыбызга мәгълүм. Һәм, ниһаять, гасыр ахырына таба дин ирегенә юл бирелде. Күп җирләрдә тирә-юньгә ямь биреп манаралы мәчетләр калкып чыкты (дөрес, аларның күбесе ашыкпошык, зәвыксыз һәм фәкыйрь салынды. Хәер, әлегә алары да ярап тора.). Ә халык йөриме? Ниятләнгән максатка ирешеләме? Динчеләребез әзерлеклеме? Дөресен әйтик, безгә чын мәгънәсендәге динле халык булырга ерак әле. Гади халык кына түгел, хәтта күп руханиларыбызның да гамәле, Диннең асыл рухы һәм Аллаһ индергән тәгълимат белән иманланудан бигрәк, яшәешләре, гамәлләре, асылда, ритуал йола-гадәтләрен үтәүгә кайтып кала. Дин, алда әйтелгәнчә, бөек көч. Иншалла, киләсе гасыр

дәвамында милләтне саклауда аның роле зур булсын иде.

Ә уку-укыту, гомумән мәгариф системасына килсәк, безнең өчен аеруча авыр дәвер булгандыр бу гасыр. Бигрәк тә алтмышынчы-сиксәненче еллар арасында татар мәктәбен ачыктан-ачык юк итү сәясәте алып барылды. Моннан егерме еллар элек Казан булып Казанның үзендә тулысынча татарныкы дип әйтерлек бер генә мәктәпнең дә калмавын искә алсак, бу хакта артык сүз куертуның кирәге юк. Милли мәктәпләрне үстерүдә соңгы еллардагы күтәрелеш беркадәр өметне уята-уятуын. Тик болар әлегә үсентеләр, көзге болында калкып килүче курпылар гына... Булган милли рухны кире кайтарыр өчен генә дә берничә яңа буынның үсүе зарур. Бер сөргән болында янәдән тигез чирәм—бәбкә үләне булдыру өчен күпме вакыт кирәклеген күпләр белә булыр...

Үткәнебезне өйрәнүдә дә эшләр шулайрак. Егерменче елларда татар тарихы беркадәр өйрәнелә башласа да, соңгы 50-60 елда ул партия идеологиясе басымында, бер яклы, Мәскәү тарихына кулай кушымта булып "фәнниләште". Без, дөресен әйтик, дәүләтчелегебез тарихын, үсеш дәверләрен, аның хаким-шәхесләрен, алар кылган гамәлләрнең яхшы-яманын бөтенләй диярлек белми үстек. Хәзер генә, яңа туган песи баласыныкы шикелле, күзебез ачыла башлады. Тарихыбызны оныттыру, хәтерсезләндерү—Егерменче гасырның (алдагы 4-5 гасырның дәвамчысы буларак, әлбәттә) безләргә кылган иң "саваплы" гамәлләренең берседер...

Ишеткәнем бар: янәсе, һәр гасыр башында зур социаль тетрәнүләр булып ала һәм шул нисбәттә рухи дөньяда даһилар пәйда була. Миңа калса, мондый фараз, кемнәрнеңдер чынаяктагы кофене болгатып, язмыш юравы шикеллерәк нәрсә. Әмма, халыклар язмышында (календарь тәртибе буенча түгел, билгеле) чоры-чоры белән ыргымнар, янарышлар булып тора. Безнең Татарстан мисалында да бу шулай. Соңгы 10-15 елда эчке үзгәрешләр бик күп. Җитмешенче еллардагы Татарстан обкомы чорлары белән туксанынчы еллар ахырындагы идарә системасы, элеккеге Верховный Совет белән хәзерге Югары Совет (Дәүләт Советы), элеккеге Конституция белән хәзерге Конституция арасындагы аерма аңлаган кеше өчен бик зур бит. Евразия үзәгендә Татарстан дигән республика барын хәзер бөтен дөнья белә. Бу—бик мөһим фактор һәм егерменче гасырда ирешкән зур казанышыбыз. Акча яки корбан бәрабәренә сатып алып була торган нәрсә түгел ул. Пародокс: бер яктан, ярлар тарая, ә агым көчәя генә; басым арта, бәреп чыгу дәрманы арта... Тик шунысы кызганыч—Татарстан ул әле бөтен татар халкы дигән сүз түгел шул... Гасыр башында империя кинлекләрендә татар өчен "күтәрәсе (уныш бирәсе!) чирәмлекләр" шактый иде әле. Хәзер ул чирәмлекләр тупас тәрән белән аннан-моннан сукаланган, аларга ашлама дип агу мул сибелгән (эчкечелек—шунын иң каһәрлеседер, мөгаен.) Шулай да, акрынлап булса да, иман иңдерү бара. Соңгы 7-8 ел эчендә ике тапкыр үткәрелгән Бөтендөнья татар конгресслары... Исеме генә ни тора! Тупланырга, яһүдләрдән ким булмаганча, бер-беребезгә таяныч булырга бөек омтылыш бит бу! Элек исемнәре дә, як-якка каранып, пышылдап кына әйтелә торган чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән, хәзер кулга кул бирешеп, киләчәктә ничегрәк яшәү турында иркенләп фикер алыша алабыз. Тоталитар режим балалары өчен бу да зур казаныш. Шәп, матур, тантаналы очрашулар үтә, мәгънәле генә карар-резолюцияләр кабул ителә. Делегатлар таралалар. Һәм... үз җирләрендә киләсе җыелуларны көтеп яши бирәләр. Дөрес аңлашылсын, Конгресс Комитеты эшләрен һич тә киметергә теләмим, хәл кадәри тырышалар, чит өлкәләргә чыгалар... Уяту һәм беркадәр уяну бар. Әмма, кайчак шундый уй да килә: төрле илләрдә, төрле төбәкләрдә сүнеп яткан учактагы күмерләрнең, унай исеп куйган җилдә беркавым җемелдәп алуы гына түгел микән бу олуг җыеннар?.. Әгәр татарлар ишле яшәгән җирләрдә милли-мәдәни мохтарият төзелми, федераль үзәктән, җыелган салымнар бәрабәренә, тиешле средстволар бирелми торып милли хәрәкәт

мактанырлык алга китә алмастыр.

Хәзерерактагы hәм якындагы чит илләрдә Татарстанның уннарча Вәкиллекләре бар. Алар, бәлкем, республика өчен зур эшләр башкара торганнардыр. Америка, Франциядәге кебек илләрдә дип әйтмим, әйтик, татарлар күп яшәп торган төрки дәүләтләрдә—Казакъстанда, Үзбәкстанда яшәп ятучы ул Вәкиллекләр безнең рухи байлыгыбызны—китапларны, газета-журналларны оешкан тәртиптә тарату эшенә алына алмыйлар микәнни? Татар матбугаты хәзер, нигездә, Татарстанда гына тарала. Урта Азия, Казакъстан белән бу җәhәттән аралар киселгән диярлек. Менә бит ул тараюлар каян килә! (Кайчак уйлап куясың: ул якларда милли җанлы эшмәкәрләр табылмый микәнни? Хәзерге заманда әллә нинди могҗизалар эшләп була бит. Әйтик, “Казан утлары” яки бүтән берәр басманың куен кесәсенә сыя торган бер-ике санлык дискетын ал да, шунда кәгазь табып, бастырып, таратып файдасын күр! Юк бит...).

Кулларыгызга барып ирешкән газиз (бу сүзне төчеләнмичә әйтәм, чөнки гасырның буеннан-буена диярлек халкыбызга хезмәт иткән басма hәр татар кешесенә чыннан да газиз булырга тиеш) журналыбызның 1999 елдагы беренче саны бу. Гомумисәп буенча 915 саны. Без, редакциядә эшләүче язучылар, журналистлар, гамәли хезмәткәрләр горурланып әйтәбез: журналыбыз—Егерменче гасыр татар әдәбиятының, гомумән мәдәниятының, төп учагы—елъязмачысы булды. Әлбәттә, бу олы миссия безгә тау кадәр җаваплылык та өсти. Моны без генә түгел, үзләренең иҗатлары белән журналыбызда катнашучы hәр каләм иясе яхшы аңлый булыр. Шуны ышандырып әйтә алабыз: без—редакция хезмәткәрләре—“Казан утлары” халкыбызның яңа Егерме беренче гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булып калсын өчен тырышачакбыз.

Сүзне йомгакларга да вакыттыр. Без, гасырны бераз иртәрәк төенлибез бугай. Шулай да, берле (1), hәм дә тугызлы (999) саннар белән быел саубуллашачакбыз. Аннан—икеле (2), нольле (0) саннар башланыр. Егерме беренче гасырга үз язмышына, үз тарихына hәр халык үзенчә аяк басар. Инглиз инглиз булып, француз француз булып, гарәп гарәп булып... Алар да, әлбәттә, бу үтеп баручы гасырда әллә ничаклы фаҗигалар, регресслар, тантаналар, үзгәрешләр кичергәннәрдер. Әмма милләт буларак, алар фәкать чыныгу, сынау алыпшул ук тарихлы, шул ук телле, шул ук мәдәниятлы халык-милләт булып калдылар. Ә без татарлар бер гасыр эчендә әллә нинди метаморфозалар кичереп, сыйфати, әхлакый, генетик яктан бик-бик нык үзгәрдек. Үтеп баручы гасырда безнең күбебезгә, кәлтә сланы кебек, кирәк буыннарны да өзеп (теләп яки мәҗбүр ителеп) калдырырга туры килде. Ә шулай да, күпме генә сыкранып-сыктасак та табигатьтә Бөек Хәят дәвам итәчәк. Ышанасы килә: дөнья халыклары, дөнья цивилизациясендә Татар милләте булачак. Кояш астында Татар иленең үзенә лаек урыны булыр, иншалла.

## ШИГЪРИЯТ



## Гамил Афзал

### ӘЛЛӘ КАЙДА ОҖМАХ КОШЛАРЫ БАР

### Заман шундый...

Золым, вәхшәт йөрде бу җирләрдә—
Шаһит булып олыслар ята:
Әллә кайчан атылган ирләргә
Архив тулы доноcлар ята.

«Җинаять юк, ялгышканнар» имеш,
Дәүләт чаклы дәүләт ялгышкан!
Күрәләтә, бер гөнаһсыз килеш
Кайчан котылырбыз «ялгыштан»!

Әмма шаулы дан казаныр идек,
Арсланнар белән алышсак,
Бер куркусыз, без батырлар, дидек,—
Ә ни булыр без дә ялгышсак?

Тел төбеннән хилаф сүзен сизеп,
Якасыннан борып алганчы,
«Заман шундый, вакыт кушты» диеп,
Акланырга тотына ялганчы.

### Фикер йөртүче

Кирәк бит дип, киңәшмәгә килсәң,
Озын сөйли күзлек сөртүче.
«Нигә болай» диеп сорый белсәң—
Син—кеше һәм фикер йөртүче.

Күк күкрәсен, ялтырасын яшен,
Үтеп барам упкын читеннән,
Беркемнән дә курыкмыйча яшим,
Соңгы сулышта да үкенмәм.

Җырлый-җырлый йөзгә җитсен яшем,
Туган илгә файда китереп.
Беркемнән дә курыкмыйча яшим,
Ялганның битенә төкереп.

Булсын диеп, Каф тауларына җит,
Дөнья көтү—шундый оешма,
Егыла-тора, һәр көн иҗтиһад ит,
Сыныкка сылтарга тырышма!

## Тарихи мәйдан

Киткәннәрне хурлап торабыз да,
Килгәннәрне зурлап торабыз.
Мыек борып тамак кырабыз да,
Киләчәккә план корабыз.

Төрмәләрдә үлгән бик күпләрнең
Исеме юк тарих битләрендә,
Изге эш дип кылган гамәлләре
Сөяк булды заман этләренә.

Заман безгә мәйдан әзерләде,
Иман безгә бурыч йөкләгән:
Казан ханнарының каберләре
Шушы җирдән чыгып китмәгән.

Алтын Урда таралган да беткән,
Хәзер менә Рәсәй таркала.
Бер тиран да мәңге тормый икән
Кан белән тир сеңгән аркада.

Әлләкемнәр мәкер җыеп килгән,
Әлләкемнәр пычак кайраган.
Ай нурында алтын Иман иңгән,
Бәхет юрап былбыл сайраган.

## Ак хыяллар

Мин үстем дә, үзгәрмәдем кебек
Үзгәрүчән еллар дулкынында.
Түземле бул, усал булма диеп,
Сандугач сайрады тар юлымда.

Түземле бул, явыз булма диеп,
Пәйгамбәр сөйләде мөнбәрләрдә.
Шат малайлар кебек, бүрек чөеп,
Бик сокландым үргә менгәннәргә.

Арып-талып кышка керәм менә,
Айга карап шигырь уйларга.
Ак күгәрчен булып илһам килә,
Ак хыяллар ява юлларга.

Бүрәнә йорт, сукмак, кара мунча,
Офыклардан шомлы җил исә.
Беркемнең дә сүзенә карамыйча,
Үзем булып яшим үземчә.

## Дипломат елмаюы

Дипломат елмаерга тиеш,
Дипломатның һәр бакыры—көмеш,
Ач булса да, хәерче булса да,
Аның бер дә кайгысы юк имеш.

Авыз ерып елмая бит Шомбай,
Ярдәм сорап килгәч тупсаңа.
Син дә шулай, Шомбай кебек елмай,
Серең бирмә сыртың сынса да.

Елдан-елга тормыш катлаулана,
Шыксызлана бара җир йөзе.
Җиргә, суга битарафлык кала,
Бу дөньяда кеше—берүзе.

Ераккарак, тирәнгәрәк кара,
Күпне белгән саен шөбһә арта:
Империячел мифлар төбендә
Мәкерле һәм явыз ялган ята.

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Җырлый-җырлый урап чыгарлык.
Базарларга керсәң—сызгырып кер:
Бүредән дә явыз чынбарлык.

## Мәгънәле юл

Бик озын гомерләр алданып йөрдек без,
Эчтән калтырап, тыштан ялтырап.
Ялтырап йөрүне геройлык дидек без,
Ялтыраган өчен дан сорап.

Кәгазьдә бар, гамәлдә юк хокук,
Җитмеш ел йөрдек тел тешләп.
Налог түләп, кайгы-хәсрәт йотып
Ударниклар булып эш эшләп.

Шул чагында караны ак дидек,
Хак дөреслек дидек ялганны.
Ат сөйрәмәс, җен күтәрмәс иде
Безнең җилкә күтәрә алганны.

Алданып, таланып «базарга килдек» без,
Бик авыр, бик хәтәр юл урап...
Алдаусыз, талаусыз үрләргә меник без,—
Иманлы, мәгънәле юл ерак!

## Шөрепләр бушаганда

... Заман шундый,—дисең, көлә-көлә,—
Югарыда шөреп бушады.
Мин бәләкәй кеше, белмим, димә,
Кимсенергә заман кушмады.

Танау тартып торган малай булма,
Каты куллар кирәк көрәштә,
Абына-тора алга барган юлда
Усал да бул, дустым, көләч тә.

Зур эшләр башкар да, дан сорама,
Зур эшләр эшлә дә, мин зур димә.
Әкиятләр сөйләнә, җыр җырлана,
Мәхшәр көне кебек заман килә.

Бу җирдә мең ел арыш чәчкәннәр
Киндер ыштан кигән эткәңнәр.
«Иленнән бизгән лә ир уңмас», дип,
Узгынчыларга әйткәннәр.

## Ветераннар сүзе

Без бик озак ачлы-туклы йөреп,
Агач пәйгамбәргә ышандык:
Ул бик даһи, ул бик гадел, дидек,
Әй, беркатлы инде бу халык!

Без—эшчән һәм саф күңелле халык,
Кем әйтмешли, дөнья—куласа,
Һәй, сөенер идек алга барып,
Кимсетү вә алдау булмаса.

Без бу шаулы, шомлы замананың
Бушка ашамадык икмәген,
Астан кисеп, өстен ямамадык,
Әманәткә хыянәт итмәдек.

Ярлар гына текә, таулар биек,
Йөрмә боек башың түбән иеп,
Горур яшә, башың текә чөеп,
Без—егетләр, диеп!

## Ясалма дуслык

Мөстәкыйль яшәүне сөеп,
Халыклар дулый, иркәм.
Политика кушты диеп,
Дуслашып булмый икән.

Халыкның кулы бөердә,
Мескенләнер чак түгел,
Синең кубызга биергә
Халыклар курчак түгел.

Өмете—алдау булганга,
Сәясәт ала-кола.
Католик та мөселман да
Үзенчә дога кыла.

Әдәп саклап елмаясың,
Күңелдә бушлык була:
Ясалма «дошманлык» була,
Ясалма «дуслык» була...

## Серле күлләр, горур таулар

Тора-бара шундый чиккә җиткәч,
Инде нишлим дигән вакыт килсә,
Авыр булса, таян иптәш,
Алдамас, күтәрер минем иңсә.

Синең күңелдә дә давыл уйнасын,
Көлеп кара дансыз үткәннәргә.
Ахмак заманнардан көлгән буласың,
Ә ул көлү кагыла бүтәннәргә.

Халыкара хәлләр, эһем-эһем,
Тавык чүпләп бетермәслек хәлләр.
Көлә-көлә яз килүе мөһим,
Гөрләвекләр ага, күкләр зәңгәр.

Әй, кирәкми нотык-вәгазь чәйнәү,
Купшы сүзне сөймим, күрәсең.
Сәлам әйтеп килсен яшел җәйләр,
Һәр куакта яфрак тирбәлсен.

Әллә кайда оҗмах кошлары бар,
Җәннәт бакчалары уртасында.
Төтен исе сеңгән урамың тар,
Шул урамга карап торасың да,

Олагасы килә әллә кайда,
Чәчәк исле җилләр тели йөрәк.
Шомлы шаулап торган яшел тайга,
Серле күлләр, горур таулар кирәк...

*1995—1997*

## Чәчмә әсәрләр

Зәки Зәйнуллин

# АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА...

РОМАН-КЫЙССА

## Беренче бүлек

### ЭПИЛОГ

Туган ягым Эстәрле буйлары!

Бүгенге Башкортостанның иң көньягындагы казакъ далаларына чиктәш җирләр... Көньяктан Ырынбур далалары белән тоташкан изге урыннар!.. Күпме генә җирләрне гизсәм дә мин Эстәрле якларындагы кебек гүзәллек, матурлыкны, сихрилекне күрә алмадым. Көньяк Урал тауларының Урта Сырт дип йөртелгән өлеше казакъ далаларына табан таралып китә; бик биектән булмасалар да, текә таулар өстендә дүрт-биш чакрымнарга сузылган дала сыманрак тигез җирләр җәелеп ята. Бу урыннар инде «дала туа» башлаган җирләр булыр.

Минем туып үскән авылым Эстәрлебаштан көнбатышка табанрак дүрт-биш чакрым чамасы араны узсаң, дүрт елга башланган калкулыкка барып чыгасың. Ул елгалар Эстәрле, Тәтер, Күндерәк һәм Дим дип аталалар. Шул калкулык урынның төрле җирләреннән алар чишмәләр булып бәреп чыгалар да дүртесе дүрт якка юл алып, елга булып ага башлыйлар. Дүрт елганың дүрт якка акканын беренче мәртәбә күргән кешеләр һәрчак хәйран калалар, ә Тәтер елгасының «югары якка акканын» шәйләп алгач, хәтта Эстәрле кешесе үз күзенә үзе ышанмыйча исе китеп карап тора: бу елга бит чынлап та каршы якка карап ага түгелме соң? Алай булырга тиеш түгел ләбаса. Һәм ул яр буеннан берәр агач кисәге, йә таш алып суга ташлый да... ышанырга мәҗбүр була:

—Һы! Кызык! Чыннан да югарыга табан ага икән бит бу Тәтер елгасы, Ходайның рәхмәте төшкере!

Эстәрле кешесе Тәтергә барган чакта гелән генә тау менә. Тик бер генә урында тау төшә. Әҗәл тавы дип атала ул. Елгаларның икесен ике якка агарга мәҗбүр иткән калкулык шул Әҗәл тавы янында. Аның түбәсеннән борынгы заманнарда атаклы Ат караклары сукмагы узган...

Эстәрле елгасы Ашказарга, Тәтер елгасы Димгә барып кушылалар. Ашказар да, Дим дә Ходай кушкан бормалы-бормалы озын юлларын үтеп, икесе ике урында гүзәл Агыйделгә барып баш оралар. Ә Күндерәк елгасын Урал елгасына китә, диләр.

Ах, бу Эстәрле яклары!

Ак кылганнар белән капланган текә таулар, алар өстендә сузылып киткән далалыклар; таулар арасындагы көмеш кебек саф, салкын сулы чылтыравык җырлы чишмәләр; җиләклекләр, миләшлек-баланлыклар, чикләвекле урманнар, ап-ак булып төренергә яраткан шомыртлыклар, юкә урманнары, эре-калын яфраклы мәһабәт гәүдәле имәннәр, кызлар гәүдәсенә тартым каен агачлары, куе чаганлыклар—минем күңелемнән мәңге дә китмәс!.. Берәр хәвеф-хәтәр чыгып, күңелем төшенкелеккә

бирелеп, кәеф-сафалар кырылып барган чакларда, кайда гына яшәвемә дә карамастан, мин уйларым-хыялларым белән туып үскән Эстәрле якларына юл алам. Минем өчен анда күк йөзе дә зәңгәррәк тә, биегрәк тә, һавасы да сафрак; кешеләре дә кешелекләрәкләр—аларның күңелләре киңрәк тә, миһербанлырак та, яхшырак та...

Уйларым, хыялларым белән мин турыдан менә торган сизелер-сизелмәс сукмакларыннан яисә урау юлларыннан атлап Эстәрле тауларының башларына менәм. Тауның иң биек җиренә менеп җиткәч, җир өстенә калкып чыгып торган ак, соры төстәге, азрак шадрарак «шихан ташлары»на утырып хәл алам. Тау башыннан күренгән тирә-якны барлап чыгам да, җилләр исен исним, җилләр тавышын, моңын, зарын тыңлыйм. Тау битендәге ак кылганнарның акрын гына искән җилдә ефәкчәләнеп-дулкынланып, башларын ия-ия селкенгәннәренә, җилләрне сәламләгәннәренә карап туя алмыйм. Тау башларында мин дөньяви юк-барлардан, нужа-михнәтләрдән, уй-гарасатлардан арына-арына үз-үземне, барлык вөҗүдемне онытып утырам. Искән җилләр иркенә бирелеп мин әлеге шигъри юлларны Дәрдмәнднең үз авызыннан ишеткәндәй булам:

Гарип моң бар өнендә җил-җиләснең,
Туган илләрдән искән җил димәссең.

Куе агачлыклар арасындагы ташкыяларны ярып чыгып, еллар, гасырлар буена үзләре шомарткан ташлар өстеннән чылтыр-чылтыр моңаеп аккан чишмәләрне тыңлап утырам:

Агышың, и агымсу...

Тау итәгендәге таш кыяларга ябышып, аларга тотына-тотына югарыга үрмәләгән төрле-төрле үләннәрдән, гөлләрдән күтәрелгән хуш исләрне йотлыгып иснәп, берсен-берсе уздырырга тырышып чытылдап-чутылдап сайраган Ходай кошларының тавышларын тыңлап ләззәтләнәм мин. Белгән барлык догаларымны кат-кат укып, Ходай Тәгаләгә яшәешем өчен үземнең рәхмәтләремне җиткерергә тырышам, кылган гөнаһларым өчен үземне ярлыкагыл итүен үтенәм!..

Тау араларында, тау битләрендә үскән каен, имән, усак, юкә һәм башка бихисап агачларның салмак кына искән җилләрдә шыбырдашып серләшкәннәренә дәшми генә колак салып тыңлап утырам мин...

Эстәрле якларындагы ялан-урман юлларыннан, тау сукмакларыннан, челтерәвек моңнар чыгарып аккан салкын чишмәләр яныннан, үргә күтәрелгән сукмаклардан яисә урау юллардан атлаганда, дөньяда минем өчен иң кадерле булган кешенең дә күләгәсе минем белән бергә, янәшәмнән тавыш-тын чыгармыйча гына бара кебек тоела. Миңа аның турындагы истәлекләр менә шул Эстәрле таулары, урманнары, ялан-кырлары, чишмәлекләре белән минем йөрәгемә, күңелемә, уйларыма һичвакытта да өзелмәс ныклы җепләр белән үзем дә бу дөньядан киткәнчегә кадәр бәйләгәннәр.

Аның вафат булганына инде утыз өч елдан артып китте. Ул Габдулла Тукай белән бер елны туган булган. Минем йөрәгем дә, аңым да аның юклыгы белән килешә алмыйлар, аны сагыналар, юксыналар, искә алалар. Аңардан башка Эстәрленең киң яланнарында, урман-тугайларында, ак кылганлы, таш кыялы төрле биеклектәге тауларында миңа нәрсәдер җитешеп бетми. Тау башларындагы ташкыяларда үземне-үзем онытып утырган чакларымда, кайвакытларда мин сискәнеп дертләп куям—артымда аның авыр итеп атлаган адымнары һәм салмак кына, акрын гына миңа эндәшкән тавышы ишетелә:

—... Зәки, улы-ым!!!

Шулчак инде күбесе онытылып, еллар, юллар томаннары эчендә калып барган балачакның кабатланмас сурәтләре, истәлек-хатирәләре аша мин аның азрак кына уң якка кыешрак олпат, мәһабәт гәүдәсен күргәндәй булам. Менә ул ике кулын артына куйган да, ялан юлы белән сөзәк үргә кабаланмый гына атлый. Атлаган уңаена авыз эченнән генә үзе нәрсәдер көйли бугай. Аның ягыннан акрын гына искән җил миңа табан өзек-өзек моң авазларын китергәндәй була. Өстендә тузган кәзәки, соры төстәге керле күлмәк, тез башлары, артлары ямаулы чалбар, аякларында ак йон оекбашлар белән чабаталар. Башында көрән төстәге эшләпә. Ул да инде бик искергән, кырлары салынгаланып тора. Киң маңгаен аркылыга тирән җыерчыклар ергалаганнар, җыерчыклар битләрен дә төрле тарафларга бүлгәләгәннәр. Ул җыерчыклар инде

елмайган чагында да тигезләнмиләр. Күп тапкырлар юылганнан төсен югалта башлаган зәңгәр ситса кебек сыек зәңгәр күзләр, яшь чагында сары төстә булган ап-ак чәчләр һәм очлары тәмәке төтененнән көрәнрәк сары төскә кергән мыек. Борынының сул ягында ике кечкенә миң. Борыны азрак кылычланып тора...

Көннәренең күп вакытын дәшмичә уйланып уздыра торган ул кеше минем этием Лотфулла карт иде...

Әтине мин өч яшем тулмас борын ук белә башлаганмын икән. Һәм без аның белән һәрвакыт диярлек бергә була торган идек. Мин аны, ул мине яратканнан шулай булгандыр дип уйлыйм мин хәзер.

Менә минем бала күңелемә сеңеп калган сәгадәтле иң беренче истәлек.

Без, әти белән икәү, пар-ат җигелгән, сыек ягулык тулы ике тимер мичкә салынган арбада язгы чәчүдәге «трахторларга гәрүчи алып китеп барабыз». Яланга. Арба алдында, атлар коерыгы янында ике генә кеше сыярлык урын да бар. Арба тәгәрәве уңае белән мин уң якка, әти сул якка утырганбыз. Соңыннан әтинең үзеннән сорашып белдем, бу 1936 елның язгы чәчү вакытлары булган. Димәк, минем өч яшь тулып кына килгән чаклар.

Әти чыбыркы сабы белән тәртә-тәртә күрсәтеп, миңа таулар, ялан-кырлар, чишмә-елгалар турында берсеннән-берсе кызыграк нәрсәләр сөйли. Күңеле белән дә, җаны белән дә бик тә шәп тарихчы иде ул.

—Әнә, елганың теге ягындагы, өстендә бөркет очып йөргән тауны күрәсеңме улым,—ди этием, һәр сүзенә эчке бер мәгънә салып,—аның исеме Бакыр Чагыл тавы булыр. Борын-борын заманнарда урысларның Петр Пирвый дигән патшалары тау эченнән таш чыгартып, янында мич төзетеп бакыр эреткән. Аннары шуны безнең татарлардан олаулар белән Эстәрлетамак каласына ташыткан.

Ул йөткереп куйгандай итә:

—Шул тау астындагы каенлыкны да күрәсеңме?

—Ы-ыы, ансын да күрәм, әти.

—Бакыр эретә торган мич урыны ул. Бакыр Чагыл таудан өстәрәк, ерым аша— Җомай исемле бер бабай, гомере буена тау эченнән казып таш чыгарды. Шул тау эчендә, таш казыган җирендә үлеп тә китте. Үлгәненә дә кырык елдан артыграктыр инде. Әтисе казакъ кешесе иде...

—Ния тау эчендә үлде ул, эти?

—Авыр эш эшләгәннән, улым. Таш чыгарган кеше йомран-җәнлек кебек гелән генә җир астында казына бит ул. Кәйләсен тотып. Эшли, тирли, соңра тәне суына. Шунлыктан суык тидерә. Үпкәләре авыруга әйләнә. Чөнки җир астында дымлы, һава да җитенкерәми. Эше авыр. Ташны чокырга кирәк. Җир өстенә чыгарырга кирәк. Аста, җир астында диюем, суык, дымлы, ә җир өстендә кояш, эссе...

Миңа кызык, серле, мин сабыйларча йотлыгып тыңлыйм.

—Ә Бакыр Чагылның ас ягында Миләшле тау. Анда инде бик күп булып миләш үсә. Аннан да астарак Сәхап башкорт тавы. Ул тауны менгәч, бүген үзең дә күрерсең— Локман Атрубы, Байгара яланнары башлана...

Эти миңа әнә шулай тирә-яктагы таулар, яланнар, урманнар, тугайлар, сузылган юллар турында кабат-кабат гыйбрәтле хәлләр сөйли. Кайда гына барырга чыксак та. Аңарга тыңлаучы кирәк булгандыр дип уйлыйм мин хәзер. Ә мин этине бик тә тыңларга ярата идем. Бәлки шул эти сөйләгәннәрне тыңлап, башкалар сөйләгәнне тыңлый белергә, истә калдырырга өйрәнгәнмендер. Аллага шөкер, хәтерем бүген дә зарланырлык түгел, күп вакыйгаларны исендә тота, кирәк чакта кире кайтарып искә төшерә дә белә.

Сәхап тавына менеп барган чакта яңгыр ява башлады. Эти атларны туктатты да, мине арбадан күтәреп алып җиргә бастырды. Аннары астыбызга җәйгән чүпрәк паласны алып, мине шуның белән төреп куйды, кире арбага утыртты. Үзе дә утырып, атларны кузгатты, палас аша минем аркамнан сөеп ул болай диде:

—Ходайдан теләк телә, улым:

Яңгыр яу-яу,
Ашлык үс-үс,—

диң.

Мин телим. Палас ачылып китмәсен дә, мине яңгыр юешләмәсен дип, эти

аркамнан тотып килә. Кулы авыр, әмма ул минем җаныма тынычлык бирә. Палас аша да әтинең кул җылысы аркама тарала. Әти кулы! Ул кул бар чакта миңа яңгыры да, болыты да, җиле дә—бернәрсә дә куркыныч түгел.

... 1946 елның җәендә Локман Атрубы дигән җирдә әти белән печән чабабыз. Минем бер яше яңарак кына узган, печтергән үгез җиккән фурман а[illegible] белән кырда куна яткан әти янына барышым. Кичтән төялгән йөк белән «көтү киткәнче» мин авылга кайтып җитәргә тиеш. Һәм шулай эшлим дә. Кайткач, печәнне абзар кыегына ыргытам да, «урман урларга китәм». Кичен тагын әти янына барам. Кайсы кичләрдә Күл дип йөртелгән таллар арасындагы урынга егетләр-кызлар кич уйнаган җиргә дә баргалыйм. Дөрес, безнең ише «ыбыр-чыбыр» малай-шалайны уенга кертмиләр кертүен. Хәер, анда «керүнең» безгә әллә ни кирәге дә юк, чөнки кызлар белән «нәрсә эшләргә» икәнлекне без әле яңа гына чамалый башлаганбыз, тик белеп бетермибез. Шунлыктан «өйрәнчек булып» егетләрнең кызларны тоткалаганнарын, җаен чыгарып кочаклаганнарын, чыркылдатканнарын карап, без дә «кызлар тоткаларга өйрәнәбез». Әлегә тик «күз белән генә» инде. Кызларның кайсы җирләреннән ешрак тоталар, егетләр тотканда кызлар нәрсә эшлиләр—ачуланаламы, әллә инде кыйланалар гынамы? Кайсысы чәрелди, кайсысы егетләрнең кулларына «тагын тот» дигән кебегрәк иттереп суккан була. Безнең «өйрәнчек күзләрдән» бернәрсә дә читтә, күренмичә калмый, дәрт керә башлау, бәлки, шул Күлдән башлангандыр?

Шунлыктан, кайсыбер «кызлар күзләп йөргәннән» соңгы кичләрне әти янына мин бик соңлабрак бара башладым. Сәхап тавын менеп бетү белән Локман Атрубында янган учак уты әллә каян ук күренеп тора. Мине көтеп, пешергән ашы суынмасын дип, әти учак янында кырын ятып тора. Учак утын күргәч, үгез дә атлавын тизләтә. Ул да, күрәсең, минем кебек төн караңгылыгыннан, яландагы кош-корт тавышыннан шүрли торган булгандыр. Тик минем кебек сиздермидер.

Барып җитеп үгезне тугаргач, озын муенлы чүлмәкне фурм[illegible]ән алып, учак янына куям. Чүлмәкнең авызын ябып бәйләгән чүпрәкне чишеп, әти агач кашык белән эчендәге катыкны кабып карый. Өмете киселә башлаган тавыш белән миннән сорый:

—Әниең май яисә каймак җибәрмәдемени? Бу бит сипарат сөтеннән оеткан катык кына.

—Җибәрмәде. Майны налук түләргә иттем, диде...

Әти учак утына терәп куйган кечкенә калай тасны читкәрәк өстери. Тастан бу бөркеп, арыш умачы исе килә. Мин алып килгән катыкны ашка күп итеп ката да, каяндыр бер җәймә* чыгарып миңа суза.

—Ә үзеңә?—дим мин җәймәдән күзләрне ала алмыйча.

—Мин... син килгәнче... ни... э-э... азрак капкалап алган идем инде.

—Мин килгәнче син ашамыйсың. Мине көтәсең. Аннан синең ашарыңа да беткән иде. Сындыр урталай. Яртысын гына бир миңа.

Ул җавап бирми. Сүзсез генә җәймәне урталай бөкләп бүлә дә... зуррагын миңа суза. Күзләре елмаялар:

—Сиңа, улым, үсәргә кирәк. Тот.

Зур агач кашыклар белән тас эченә тыгылабыз да, эссе арыш умачын «ташырга» тотынабыз. Ашап бетерергә азрак калгач, әти кашыгын ялый да, аны «куфайкасы» өстенә куя. Умачның калганын миңа дигәнне аңлата. Авыр иттереп көрсенә дә, мин аңардан һич кенә дә көтмәгән уйларын әйтеп ташлый.

—Мин, улым, сигез яшьтән ялланып бозаулар көттем. Унике яшьтән авыл байларына ялчылыкка чыгып киттем. Герман сугышы башланганчы егерме ел йөредем ялчылыкта. Җир юк, фәкыйрьлек бик көчле иде. Авылда иң бай, иң саран Гапкадыйр мәхдүм дигән бай бар иде. Аның Йортында бүгенге көндә милитсияләр урнашкан. Печән өстендә, урак вакытында хәтта шул саран бай да, кичен—без ялчыларына итле аш ашата иде. Чөнки эшли халык, эшчегә көч кирәк. Кичкелеккә кадак ярым ипи бирә иде өстәвенә. Ялчыларын ашатырга печән өстендә көн саен бер үгезен суйдыра иде... Җире Кара Балыклы якларында сигез йөз дисәтинәдән артык иде, ялчылары кайсыбер елларда меңнән дә артып китә торган иде.

Әти азрак дәшмичә утка карап утыра да, тәп уен чыгарып сала:

—Без крәстиянне риволүтсиядән соң алдадылар. Лилин карт та, Ысталины да.

---

* Җәймә—камыр ашы.

Җир бирәбез, дип акларга каршы сугыштырдылар. Менә хәзер крәстиянгә җире дә юк, ирегә дә юк, инде ашарга ипие дә юк. Тапкан табынганны, үстергәнне, урганны вич себереп алып бетереп торалар. Безгә хәзер арыш умачы да, сипарат сөте генә калды. Анысы да туя ашаганчы түгел. Кызыл партизан булып нигә генә сугышканмындыр инде мин. Бу сугышта Гариф улымны, киявемне бирдем. Икесе дә кайтмадылар, ятып калдылар. Ә синең инде бүгенге көндә туя ашаганың да юк. Ә бит синең самай үсеп көч утырта торган чагың. Синең гомереңүземнеке кебек ялчылыкта үтмәсен дип урманнарда, Дүлдин камандасында кызыл партизан булып сугышып йөрдем бит мин. Ә бүгенге тормыш ялчыныкыннан да начаррак...

Ә мин—пионер, шәп укучы, мәктәп гәзитәсендә рәсемнәр төшерүче, бәйрәмнәргә сырлап-сырлап коммунистик лозунглар язучы, кызыл активист. Әтигә тиешле җавабын да бирә беләм:

—Без иң беренчеләр булып коммунизм төзибез бит, әти. Чит ил пралитарийларын коллыктан коткарырга тиешбез. Аларга ярдәм кирәк. Шунлыктан түзәргә кирәк инде...

Әтинең минем белән бәхәскә керәсе дә килми.

—Шула-ай!—дип суза ул үз алдына гына.—Кирәктер бәлки анысы да. Тик күп нәрсәне аңламыйсың шул әле син. Яшьсең бик. Безне алдалаган кебек, сез яшьләрне тагын да ныграк алдалыйлар болар...

Инде мин дә картаеп барам. Иң беренче мәртәбә кешенең Совет хөкүмәтенә ризасызлык уйларын мин заманында кызыл партизан булган үземнең әтиемнән ишеттем. Локман Атрубында төнен, янган учак янында...

Истәлекләрне шушы урында туктатып торыйм. Чөнки минем төп максатым укучыма роман-кыйссамны тәкъдим итү иде.

* * *

Бу «Агыйделнең аръягында» дип исемләнгән роман өч бүлектән торачак. Беренче бүлегенең исеме «Учител тавы». Роман-кыйсса документларга нигезләнеп тә, күбрәге булган хәлләргә, риваятьләргә таянып та язылды. Харис, Харрас Тукаевлар, Мөхәммәт Шакир Тукаев, учител Мирсәет Бийишев, Хәйдәргали хәлфә, аның бигрәкләр дә фаҗигале язмышлы улы, татар халкының бөек шәхесе Мирсәет Солтангалиев, татар һәм казакъ халыкларының бөек шагыйре Акмулла, әтием Лотфулла, алты малайлы бабам Зәйнетдин Балта—барысы да җирдә яшәп киткән шәхесләр. Хәйдәргали хәлфәдән башкалары, тумышлары белән барысы да Эстәрлебашлар. Акмулла Мифтахетдин дә, шулай ук, Эстәрлебашта туып, шунда яшәп, шуның мәдрәсәсендә белем алган кеше. Башкорт авылы Туксанбайда Акмулла биш яшеннән сигез яшенә кадәр генә яшәп алган. Казакъ әтисе Мөхәммәдъяр хәлфә Эстәрлебашта үлеп җирләнгәч, әнисе Өммегөлсемне Туксанбайга Камалетдин башкортка өченче хатын итеп биргәннәр. Әнисе үлгәч, сигез яшьлек Мифтахетдин үги әтидән, ике үги әнидән качып чыгып китеп, җәяүләп Эстәрлебашка кайткан һәм мәдрәсәсендә яшәп, шунда белем алган. Акмуллада бер генә тамчы да башкорт каны юк. Казакъ белән татарныкы гына.

Эстәрлетамак каласында бүгенге көндә Мөхәммәт Шакир Тукаевның 1904 елда туган кече кызы Халимә апа яши. Ул апада Тукаевлар турында мәгълүматлар бик күп иде. Тик инде ул сукыр, чукрак. Шулай да зиһене үткер әле*.

Әйе, үзебезнең татарның фаҗигале, катлаулы, данлыклы, сатлыклы, белемле, динле, денсез, изелеп онытылган тарихын барлап, сирәк-мирәк кенә сакланып калган энҗе бөртекләре кебек истәлекләрдән керәшче, игенче, сугышчы, галим, диндар, сәүдәгәр, сәяхәтче, иманлы Казан татарларының данын, горурлыгын торгызып, үзебезне тагын бөек, көчле халыклар сафының иң алдына бастырырга кирәк.

Бу кыйссамны әтием Лотфулла бине Зәйнетдин бине Әбеннәгыйм бине Зәйнулла истәлегенә багышлыйм.

*АВТОР*

---

* Халимә апа 1998 елның июнь аенда вафат булды. Июнь аенда мин Эстәрлетамакта булып, аны соңгы тапкыр күреп фотога төшергән идем.

* * *

Көмеш сулы, гүзәл Агыйдел елгасының сул ягында яткан җирләр борын-борыннан Болгар ханлыгы биләмәләре булганнар. Монгол яулары килгәнгә кадәре заманнарда ул риваятьләргә караганда, монда безнең болгар бабаларыбыз яшәгән. Бүгенге Эстәрлебаш авылыннан Эстәрле елгасының агышы белән бер чакрым чамасы җир узсаң, Шакир Ташы дигән урынга килеп чыгасың. Бу атама борын-борын заманнардан ук сакланып, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән. Агыйдел елгасының Җиргән тирәләреннән көньякка табан кырык чакрымнар чамасы юл узсаң, шул Эстәрле елгасына барып чыгасың. Эстәрле елгасы илле чакрымнар чамасы агып килеп, Ашказар елгасына коя. Шул ике елга кушылган урыннан су агымы белән, тагын ике чакрым чамасы юл китсәң, Ашказарның Агыйделгә кушылган урнына җитәсең. Шул урында Эстәрле-тамак каласы урнашкан.

Шакир Ташы дип аталып йөртелгән ул калкулык урын Эстәрле елгасы ясаган тугайга ярымутрау булып кергән. Ул төньяктан тауга аркаланып терәлгән, ә калган өч яктан сазлыклар һәм Эстәрле елгасы белән уратылып алынган. Шакир Ташының төньягында урнашкан текә тауны Эстәрлеләр Кәҗә тавы дип атап йөртәләр. Менә шул төньяктан тауга аркаланган, калган өч ягыннан сазлык-елга белән уратылып алынган Шакир Ташы дигән урында безнең борынгы Болгар бабаларыбызның хәрби кальгасы булган. Ул кальга кыргыз-кайсак далаларыннан килә торган яу чирүләренә каршы торыр өчен салынган. Төньягында бер капка, көньягында ике капкалы, эченә таш, ком, балчык тутырылган имән бүрәнәләрдән ясалган ике катлы койма белән уратылып алынган хәрби кальга була ул. Көньяк капкалардан чыккан ике юл Эстәрле елгасы аша күперләрне үткәннәр дә, кайсак-кыргыз далаларына карап сузылганнар. Чыга торган капкалар беләктән юанрак тимерләрне бер-берсенә беркетеп эшләнгән чылтәр белән ябылганнар. Капкалар тау ташыннан салынган манаралар эчендә булганнар һәм ул капкаларны күтәрү-төшерү чыгырлар ярдәмендә башкарылган.

Кайсак далалары ягына караган ике күперне чыгып, Эстәрле елгасын үткәч, юллар ике чакрым чамасы сөзәк үргә үрмәләп тау башына менеп, шуннан соң юлчыны куе урман эченә алып кереп китәләр. Кыйбла тарафына, кайсак-кыргыз далаларына, Бохара-Сәмәрканд якларына юнәләләр. Шул борынгы болгар бабаларыбыз салган юлларның берсенең урыны бүгенге көнгәчә бар. Эстәрлеләр аның инде кайчандыр юл булганын чамаламыйча, Коры Чокыр дип кенә йөртәләр. Ул Коры Чокыр Эстәрле елгасы аша кайчандыр күпер булган урыннан башланып китә дә, теге сөзәк үрне кыеклап кыйблага табан, шул үрнең түбәсенә карап үрмәли. Хәзерге көннәрдә авыл халкы Ялгыз Каен ялаңы дип атап йөртелгән иген басуы аша уза ул Коры Чокыр. Ә Эстәрле елгасының сул ярында борынгы капкалар булган урыннар бүген дә беленебрәк тора. Борынгы заманнарда дошман бу якка һәрчак даладан килгән. Шул дошманның килү-килмәвен белеп торыр өчен хәрби кальганың өч ягында урнашкан, кальгага күренеп торган өч биек тау башында атлы каравыллар куелган. Ә тынгысыз көннәр-төннәр бу тирәләрдә ел әйләнәсенә бик күпләп булганнар. Шунлыктан ул таулар башындагы каравыллар да ел әйләнәсенә сакта торганнар. Кальгадан аз гына сулдарак, бер чакрым гына чамасы ераклыкта Күрмеш тау басып тора. Көньякта, өч чакрым ераклыкта Бакыр Чагыл исемле тау башлана. Ә инде кояш баешында, калын урман эченнән сизелер-сизелмәс кенә булып Ак Чагыл дигән тауның башы гына күренеп тора. Бу өч биек тау—Болгар ханлыгының сакчы кальгасы Шакир Ташның каравыл таулары булганнар. Һәм ул Болгар халкы сагында һәрчак уяу, батыр, сизгер торган.

...Гайсә пәйгамбәрнең туауына 1223 ел узып барган җәйдә Тын елга якларындагы далаларда, аңарга килеп кушыла торган Калка елгасы буенда

монголларның Сүбүдәй Батыр белән Җәбә Нойон кул астындагы чирүе урыс һәм кыпчакларның берләшкән гаскәрен зур бәрелештә тар-мар итеп, тоташы белән кылычтан үткәреп, чапкалап юк иткән. Әсир төшкән урыс кенәзләрен һәм атаклы кыпчак бәкләрен монголлар аяк-кулларын бәйләп җиргә тезеп салганнар да, өсләренә агачлар тезеп, шулар өстенә киезләр җәеп, үзләре шунда менеп утырып, тантана иткәннәр, тегеләрне изеп үтергәннәр. Шул сугыштан соң монголлар яңа табыш эзләп, байлыгы белән дан тоткан Болгар ханлыгын эзләп киткәннәр. Тик Болгарлар да йоклап ятмаганнар—монголларны көтеп, әзерләнеп торганнар. Җигүли таулары янында монгол чирүен каршы алып, аны таулар белән Идел арасына ымсындырып алып кереп, шунда тар урында сугышканнар. Атлы гаскәрләрен җәелдереп куллана алмаган монголлар, тиз хәрәкәт итүләреннән мәхрүм булып, үзләренчә сугыша алмаганнар. Болгарлар шул каты бәрелештә монголларны тар-мар итеп ташлаганнар. Монгол гаскәренең күпчелеген кылычтан үткәреп чапкалаганнар. Монголларның атаклы гаскәр башлыклары Сүбүдәй белән Җәбә үзләренең тән сакчылары ярдәмендә, шулар сагында гына көчкә качып котыла алганнар. Җиңелгән Хәрәзм ханлыгы җирләрендә ял итеп яткан Чыңгыз хан янына монголларның бик азы гына кайтып җитә алган. Җиңелүләренең сәбәбен Сүбүдәй белән Җәбә ничек итеп аңлатканнардыр—тарих аны бер төрле дә аңлатмый. Тик Чыңгыз хан аларның икесен дә тере калдырган. Урыннарыннан да төшермәгән. Күрәсең, аларның икесенең дә киләчәк бәрелешләр өчен кирәк буласыларын Хан алдан ук белеп торгандыр. Яхшы сугышчыларының хаталарын да гафу итә белгән бөек Хан. Алдан күрүчәнлеге дә зурдан булган...

1224 елдан алып 1236 елга кадәр монголлар белән болгарлар арасында туктамастан канкойгыч сугышлар барганнар. Болгарларның монголларга каршы тору урыннары иң башта Иртеш елгасының көнбатыш ярлары булган. Каршы торуның икенче сызыгы Җаек елгасы буйлап сузылган. Ә инде өченчесе—соңгысы, Чулман-Агыйдел елгаларын файдаланып, шунда җир-койма ныгытмалар төзеп, йөзъяшәр агачлар аударылып, җайдаклар үтә алмаслык тирән чокырлар казылып оештырылган.*

Көчленеке замана!

Калка һәм Җигүли сугышларыннан соң Чыңгыз Хан Җәбә Нойонны кытайларга каршы алып барылган сугышларга җибәргән. Ә Сүбүдәйне болгарларга яу чабачак гаскәргә башлык итеп куйган. «Карт Төлке» кушаматы алган Сүбүдәй бу юлысы Җәбәдән башка, ялгызы гына гаскәр башлыгы булган. Бер кулы сугышларда алган җәрәхәтләрдән кибеп хәрәкәтләнүдән туктаган, сыңар күзле, инде җитмешкә җитеп килгән олпат гәүдәле Сүбүдәй иягендәге сирәк сакал бөртекләрен сәрмәштереп, куанычын тышка чыгармыйча, тыныч кына Тәңресе дә, дусты да, Ханы да булган (Көрәшне егет чакта ук бергә башлаганнар), Чыңгызны тыңлап утырган. Тыңлап бетергәч, чыгып китәр өчен урыныннан кузгалыр алдыннан сыңар күзен алдындагы кымыз тулы тустаган күтәреп Чыңгызга караган да, болай дигән:

—Ханки, бер генә нәрсә өчен миңа синең рөхсәтең кирәк. Шуны синнән үтенеп сорыйм.

1223 елның җәендә Җигүли таулары янында тар-мар ителгән Сүбүдәйнең болгарларга карата ачуы һәм үч алу теләге бик тә көчле иде. Шулай булмыйни, үзенең озын һәм җиңүләргә бай яугирлек гомерендә Сүбүдәйнең бердәнбер кыйналуы ич бу. Тыштан сиздермәсә дә, аның шулай болгарлардан кыйналып мәсхәрәгә калуына Чыңгыз хан эченнән генә куанып та куйды һәм акыллы зиһене белән ул болай уйлады: «Менә кем яу чабачак болгарларга каршы!»

Моңа кадәр Сүбүдәй Батыр кушканны гына үти торган гаскәр башлыгы иде, менә хәзер үтенә ханыннан. Сорый! Сорасын! Үтенсен!

* В. Каргин. Народ богатырь.—Мәскәү, 1972.

Сүбүдәйнең шулай бил бөгеп сораячагын Чыңгызга Тәңресе әллә кайчан ук сиздереп куйган иде инде. Ул уң кулын аз гына күтәргәндәй иттерде дә, әйтте:

—Нәрсәдән тора үтенечең? Сора!

—Болгарлар акыллы, белемле, эшчән, тик бик тә батыр, сугышчан халык. Андый сугышчан халык Тәңрегә кирәгрәк. Шунлыктан болгарлар җир йөзендә яшәмәскә, булмаска тиешләр. Аларны тулысы белән Тәңре янына озатырга миңа синең рөхсәтең кирәк. Шулдыр минем үтенечем.

Чыңгыз хан уйга калып байтак утырганнан соң болай дип әйтте:

—Ә галимнәре, эш осталары? Бик маһир халык диләр бит болгарларны! Хатын-кызлары тагын?! Базарларда болгар кызлары иң кыйммәтлеләре бит.

—Безгә, монголларга каршы коралын ташламыйча, әсирлеккә бирелмичә сугышкан халыкка җир өстендә урын юк. Үтенәм синнән, рөхсәтең бир?!

Шушы сүзләрдән соң ике карт бик озак тын калып утыралар. Чыңгыз хан уйлый, Сүбүдәй Батыр аның карарын көтә. Икесенең дә һөнәрләре башка халыкларны буйсындыру да, ясак түләтү. Байлыкларының уннан берен тартып алу. Шуннан артыгын Чыңгыз хан урнаштырган «Яса» кануннары алуны тыя. Чөнки күп ясак түләгән һәм шунлыктан ярлыланган халык тынгысыз була, фетнәләр оештыра, каршы сугыша.

Ханның холкын, гадәтләрен яхшы белгән Сүбүдәй кирәк кадәре генә дәшми утырды да, башын күтәрде. Аннары уң кулын йөрәк турысына куеп урыныннан кузгалды:

—Аңладың мине, рәхмәт сиңа! Икебез өчен дә ат колаклары арасыннан, алдан тояк астына ыргылган юлларыбызның очы, кырые күренә башлады. Безнең дә Тәңребез янына китәр вакытыбыз җитеп килә. Бәлки...

Чыңгыз Хан сул кулын күтәрә биреп дустын туктатты да, моңсу гына елмаеп куйды. Бу елмаю Хан елмаюы түгел, ә бәлки гап-гади бер яугир елмаюы иде:

—Анысы кирәкми! Тәңре үзе белә булыр кайчан үзе янына чакырырга вакыт җиткәнне. Кысылмыйк аның ирегенә!

Ул билендәге хәнҗәрен кузгаткандай итеп куйды:

—Уйла! Болгар җирләренә кемне утыртабыз. Ясакны кемнән, күпме алабыз. Болгар җирләренә узган чакта, анда утыртырлык халыкларны үзең белән ияртеп кит. Ирләрен яуга ку, калганнарына болгар биләмәләрен өләшеп бир. Утырт шунда, төпләнсеннәр. Мин дә синнән калмам. Болгар калаларын бик тә күрәсем килә. Тәңрем кушса, күрермендер. Шулай да... хәзергә ... хуш Сүбүдәй. Хуш, Сүбүдәй Батыр!

Урыныннан авыр кутарылды Хан, авырлык белән Батырына табан атлады. Аның килгәнен көтмичә. Батырга зур дәрәҗә күрсәтү иде бу. Аны ике куллап кочаклап алды. Ныклап кысып-кысып кочакларга да теләде, әмма кулларында элекке көче юк иде шул. Хан, хәлсезлеген сиздермәскә тырышып, уң кулының киң учы белән Сүбүдәйнең аркасыннан сыпыргалады. Сүбүдәй таза иде әле. Сынар уң кулы белән Ханын сакланып кына кочаклады. Икесенең дә күңелләре кузгалган иде. Күп җирләрне гизгән, күп орышларда булган яугирләр йөрәкләре белән дә, акыллары белән дә аңладылар—Җир йөзендә алар башкача очрашмаячаклар!

—Ир-егетнең елгыры булдың, орышларның иң батырысың! Инде бөкрәя башлаган картка әйләнеп барасың. Тәңре сине ияр өстеннән кулына корал тоткан хәлендә ала күрсен! Атлар теге дөньяда да барлардыр. Ә сугышлар анда юктыр инде. Булмаса, Тәңренең атларын көтәрбез! Хуш!

—Хуш, Тимучин! Теге дөньяда көрешергә язсын безгә! Бәлки атларны да бергә көтәргә насыйп кыйлыр!

Ә Болгар җирләре тоташы белән синеке булыр. Болгарларсыз! Моны мин әйтәм, Сүбүдәй Батыр!

Батыр салмак, авыр адымнар белән чыгып китте. Болгар халкына зур фаҗига алып чыгып китте ул. Чыңгыз Хан Батыры чатырдан чыгып киткәнче урыныннан кымшанмыйча, аның артыннан карап калды...

Тоташ каннан, уттан гына торган яулап алу еллары башланалар иде...

1233 елның җәендә, яшел үлән ат авызына ныклы эләгә башлаган көннәрнең берсендә Бакыр Чагыл тау түбәсеннән капылт кына өч төтен баганасы күтәрелеп китте. Чөнки тау башындагы каравыл бер генә мизгел элек шундый ук өч төтен баганасын Ак Чагыл тау башында күреп алган иде. Дошман явы килә! Даладан дошман килә!

Кальга эчендә чаң суктылар. Чаң суга башлаганга күп тә үтмәде, дала ягына караган ике капка ачылып китте дә, аннан байтак олаулар чыгып, Эстәрле елга күперләрен үтеп су агышы белән түбән таба юыртып киттеләр. Арбаларга таза-таза ирләр утырганнар, берничә олауга кирәк-кәйләләр, талдан үрелгән ике тоткалы кәрҗиннәр төялгән иде. Куе әрәмәлек аша узган юл белән чакрым чамасы юыртып баргач, атларны туктатып арбалардан төштеләр. Алдан ук нәрсә эшләргә кирәклеген белгәнгәдер, күп сөйләшеп тормыйча, бердәм булып эшкә керештеләр. Һәм хәстәрен күреп әзерләп куелган кызыл мәте, кырчын, ком-таш, кызыл балчык түши-түши ярты көн дигәндә Эстәрле елгасын буып та куйдылар. Тагын берәр тәүлек үтәр үтмәстә кальганың дала ягына чыккан ике юлы да, күперләре дә, яшел тугай да тоташ су астында калдылар. Кальганың тауга терәлеп торган ягыннан кала башка өлешләрендә су дәрьясы җәелеп ята иде...

Өч көн узуга дала тарафыннан кара саранча булып, офыкны тоташ каплап, монголлар чирүе күренде. Атлылар бераз тау сырты буйлап тезелеп килделәр дә, соңра ниндидер боерыкка буйсынып аска, үзәнлеккә табан җилдертеп чабып киттеләр. Монголларның атлары карсак буйлы, кырыкмыш тайдан аз гына калку, үзләре бик тә йөнтәсләр иде. Бераздан бөтен кыр-ялан, тау итәкләре, су буйлары сөңге, калкан, кылыч белән коралланган, очлы башлы, өч колаклы, бүрек, тун кигән сугышчылар белән тулды...

Кальга өчен туктамастан унике көн буена сугыш-кырылышлар барды. Тик кальганы бер яктан да алырлык түгел иде. Монголлар кальгага тагын җиде көн һөҗүмнәр оештырып карадылар. Шуннан соң гына Эстәрле елгасының буылган җирен табып алдылар, буаны ерып җибәрделәр. Тик су китсә дә кальганың өч ягы да, дала ягына сузылган ике юл да сазлыкка әверелгәннәр иде инде. Кальга ягына дивар вата торган дөмбеләрне тартып китерерлек түгел иде. Монголлар баскычлар, арканнар ярдәмендә кальга эченә үтәргә тырышып карадылар. Тик кальга эчендәге болгарлар нык торды: алар диварга сөйкәлгән баскычларны сугышчылары-ниләре белән кирегә әйләндереп ташладылар, этеп аудардылар, очларына тимер ыргаклар бәйләп ыргытылган каен, кыл бауларны балталар белән чаптылар, озын сапка утыртылган чалгы-пычаклар белән кистеләр. Баскынчылар өстенә эретелгән сумала, кайнар су сиптеләр, ташлар белән бәрделәр, уклардан аттылар...

Җиденче көн сугыш барган чакта Сүбүдәй кальганың төньяк диварына чыгарга юл эзләп көне буена ат өстеннән төшмәде. Һәм тапты ул юлны.

Ак Чагыл тавына житмәстән ике текә тау арасында үскән юан имән, каен, карама, юкә агачларын кисеп, дивар ваткычларга юл салырга боерды. Бу эштә әсирләр белән берлектә монгол сугышчылары да катнашты. Тик алар әсирләр белән аралашмыйча, аерым-аерым эшләделәр. Дүрт көн дигәндә киселгән агач төпләрен ком-җир белән күмеп, тигезләп юл салып куйдылар. Вакытны әрәм итмичә әзер була барган юлдан ваткычларны атлар, үгезләр җигеп өстерәтә бардылар. Кальга эчендәге болгарлар сизмәсен өчен кальганың калган өч ягыннан аз-азлап һаман диварларга менәргә азапланган булып һөҗүм иткәләп тордылар...

Төньяк капканың ике ягына ике ваткыч куеп, өч көн, өч төн

туктамастан кальга диварын ваттырдылар. Шул вакыт эчендә кальга капкалары өч мәртәбә ачылды; аны саклаучылар җимерткечләрне юк итәргә теләп, һөҗүмнәр оештырып карадылар, тик балта-кылыч, ук-җәя белән коралланган бер генә болгар сугышчысы да ваткычлар янына барып җитә алмадылар, монгол укчылары аларны ваткычлар өстеннән уклар атып юк итә тордылар.

Ниһаять, җимерелгән диварларның ташларын, агачларын таптый-таптый монгол сугышчылары кальга эченә ыргылдылар һәм сөрән салып орыша-орыша урамнарга, тыкрыкларга, ихата-сарайлар арасына төркем-төркем булып таралыштылар. Кальга эчендә урам сугышы, суеш башланды.

Иртән, канга манчылгандай кып-кызыл булып кояш тугач башланган урам сугышлары икенче көнне таң атканчы туктамастан барды. Монголлар инде кальганың кешеләрен кырып-суеп бетердек дип орыштан туктый башлаганнар иде, әмма ул да булмады, ишек алларыннан, сарайлардан, янган өй эчләреннән, йорт базларыннан «Аллаһ әкбәр!»—дип сөрән салып, җәрәхәтләр алган яугирләр кабат һөҗүмгә ташландылар, сәнәк-балталар күтәргән хатын-кызлар, картлар, аларны сырып алган эреле-ваклы малайлар, сабыйларын җитәкләгән, Коръән сүрәләрен кычкырып укыган карчыклар, алар артыннан елый-елый калмыйча йөгерешкән кызчыклар—барсы да монголларга ташландылар. Кеше суеп, күзләрен кан баскан монголларның бу дәрәҗәдәге каты сугыш-суешларны, каршы торуларны моңарчы күргәннәре юк иде әле. Кальга эчендәге сугыш барышын Кәҗә тавыннан карап торган Сүбүдәйдән боерык килде. Аны берничә быргыны бергә акыртып белдерделәр,

—Сугышны туктатмаска! Һәр йорт эчен, сарай-каралтыларны, базларны карап-барлап чыгарга! Табылганнарны, урыннарында суеп бетерергә! Хатын-кызларга тотынып көчне, вакытны әрәм итмәскә! Әсирләр алу тыела!

Суеш, үтереш менә шулай бер көн, бер төн барды. Иртән, таң атып яктыра башлагач, үзләре эшләгән вәхшилектән монголлар үзләре дә тетрәнеп киттеләр: урамнарда әрдәнә-әрдәнә булып болгарларның һәм монгол сугышчыларының үлек гәүдәләре аунап ята иде. Кайсысы башсыз, кайсысы аяксыз-кулсыз, кайсыларының корсак-күкрәкләре кылычтан телгәләнгән, сөңгедән актарылган. Кальга уртасыннан Эстәрлегә табан сузылган уйсулыктан шарлавыклар ясап, елга булып кеше каны ага. Андасанда яралыларның һәм үлеп бетмәгәннәрнең ыңгырашу-ялварулары ишетелә. Өйләр эченнән сабый балаларның илереп-илереп елаулары кальга эчендәге шомны тагын да ныграк арттыра. Һавага кан, тир, тузан исе таралган. Таң кызарып атып килгән чакта аягында басып тора алган кальга халкы тоташы белән суелып бетерелгән иде.

Күп сугышлар үткән, күп үлемнәр күргән, инде картаеп, үзенең дә әҗәле якынлашып килгән Сүбүдәй Батыр, алмачуар аргамакка атланып, кальганың үзәк мәйданындагы биек манаралы таш мәчет алдына килеп туктады. Атыннан төшмичә генә, сул җилкәсе аша азрак артына борылгандай итеп боерык бирде:

—Елаган болгар балаларын туктатыгыз!

Тапыр-топыр килеп, камыт аяклы монголлар сабый балалар елаганы ишетелгән йортларга карап йөгерештеләр. Сабыйларның җанын алырга күрәсең монгол сугышчыларының да куллары күтәрелмәгәндер. Үз балалары да бар бит... Берничә йортта сабыйларның ачыргаланып кычкырганнары ишетелде дә... урамнар тынып калды...

Сүбүдәйнең җил-яңгырда, кояшта янып каралган йөзенә масаюлы канәгатьләнү билгесе җәелде, ул чыгып килгән кояш ягына борылып карады да, карлыккан тавыш белән боерык бирде:

—Йортларны, каралтыларны тагын бер кат тентеп, карап, барлап чыгыгыз! Бер кешене дә тере калдырмаска! Алтын-көмеш, җәүһәрләрне бирегә, мәчет алдына ташыгыз! Исәбен алыгыз, мәчет эченә тутырып сак куегыз!

Шулчак мәчетнең олы ишегеннән читтәрәк уелган кечкенә ишек шыгырдап, авырлык белән ачыла башлады. Бар да, сискәнеп, шул якка карадылар. Ишектән башта ике кул кочаклаган озынча ак төргәк һәм аның өстенә иелгән зур чалмалы баш күренде. Төргәкне сакланып кына кочаклап тоткан бер карт акрын гына атлап килеп чыкты. Ул ап-ак сакал-мыеклы, кара кашлы һәм шундый ук кара күзле иде. Чыккан уңгайга уң кулы белән кочагындагы төргәкне салмак кына сыйпап, акрын гына яратып суккалагандай итеп куйды. Картның кулындагы төргәктә берничә айлык кына сабый бала иде. Бабай мәйдандагыларны чем кара күзләре белән сөзеп карап чыкты да, ат өстендәге Сүбүдәйгә җинелчә генә баш какты:

—Әссәламегаләйкем, Сүбүдәй Батыр!

Сүбүдәй сәламне алмады, кырыс кына сорап куйды:

—Син кем?

—Ошбу мәсҗетнең имамы Мөхәммәт Закир бине Габдулла булам мин.

—Ә кулыңда нәрсә?

—Сабый бала. Өченче ай белән киткән сабый.

—Әнисе кая?

—Синең аргамагыңның тояклары астында ята әнисе.

Карт, уң кулына кылыч тотып, ат тояклары астында калган, кылычлар белән чапкаланган яшь кенә хатынның гәүдәсенә табан ымлап күрсәтте. Хатынның башы яртылаш кылыч белән чабылган, бакыр төсендәге җирән чәчләре канга буялган иде. Ачык күзләре зәңгәр күк йөзенә гаҗәпсенеп карап тукталып калганнар.

Сүбүдәй артындагы яраннарына ишара ясады:

—Алыгыз бу картны да, кулындагы баласын да алыгыз! Чапкалагыз болгарларны!

Имам Мөхәммәт Закир уң кулын аз гына өскә күтәрде:

—Син, Батыр, кабаланма! Синең ханың булган Чыңгызның әйткәне ныклы: гыйбадәтханәләргә һәм дин әһелләренә тимәскә, дип фәрман бирде ич ул. Син, Сүбүдәй, без болгарларны бетерү ниятендәсең. Мине һәм бу сабыйны калдыр, үтертмә...

—Чыңгыз ханның әйткәненә сез болгарлар кермисез...

—Бәлки, шулайдыр. Мин сиңа шушы бала гомере өчен кальганың хәзинәсен тапшырырмын. Шул хәзинәнең күмелгән җирен күрсәтермен...

Сүбүдәй, йөзен кыйшайтып, көлеп куйды:

—Мин синнән ул хәзинәнең кайдалыгын ут белән әйттерермен. Иң башта кулыңдагы баланы утта тотып, яндыртып. Малаймы ул бала?

Карт җавап урынына уң кулын тиз генә куенына тыкты да, аннан, кояшта ялтыратып, кечкенә хәнҗәр тартып алды:

—Бу малайны тере көенә сезгә бирү юк. Ә мине яндыр, кис, ат коерыгына тагып өзгәлә—миннән син бернәрсә дә белә алмассың...

Карт хәнҗәр тоткан кулын күтәрә башлады:

—Онытма минем болгар икәнлегемне, Сүбүдәй!!!

Сүбүдәй, ияреннән картка табан иелеп, аптыраганрак тавыш белән сорады:

—Ә сабый үтерүеңнең гөнаһын кая куярсың?

Карт имам канда таптанган ат тоякларына ымлады:

—Ә син кеше үтереп, кеше талап ясаган гөнаһларыңны кая куярсың? Теге дөньяда Тәңренә нинди җаваплар бирерсең?

Карт имам Сүбүдәйдән курыкмый иде. Сүбүдәйнең йөзе дертләп куйды. Ат өстендәге олпат гәүдәсе тагын да алгарак иелә төште. Ул сыңар күзе белән сабыена хәнҗәр күтәргән карт хәзрәткә тишәрдәй итеп карады. Тик Мөхәммәт Закир урыныннан кымшанмады, күзләрен Сүбүдәйнең сыңар күзеннән алмады. Батыр ияре өстендә кузгалып куйды, гәүдәсен турайтты:

—Күрсәт алтыннарыңны!

—Юк! Башта безгә тимәм дип, ирекккә җибәрәм, дип сүз бир!

—Кая барасыз инде сез икәү?! Барлык җирдә без—монголлар. Ә бу кальганы без юк итеп китәбез. Барыбер үләсез сез.

—Елга агышы белән өстәрәк чишмәләр бар. Алтаулар. Урман эчендә. Без шунда китәрбез улым белән...

—Ярар. Синеңчә булсын. Курка белмәгәнең өчен. Мин риза. Күрсәт байлыгыгызны. Алтын-көмешләрегезне. Икегезгә дә тимәбез. Җибәрербез ирекккә...

—Капканы чыккач, чишмә янына сукмак төшә. Төшеп житәрәк сукмакның соңгы борылышында, уң якта өч таш утырыр. Шул ташлар астында кальганың... хәзинәсе...

Ә миңа мәсҗет эченнән өч китап алып чыгарга рөхсәт ит, Батыр?

Сүбүдәй гаҗәпләнеп елмайды. Бу юлысы елмаюы җылырак кебек иде:

—Кальганың хәзинәсен тулысы белән безгә бирәсең. Ә үзең китап дисең. Нәрсәгә инде ул китаплар сиңа хәзер? Хәерчесең бит инде!

—Батыр! Дөньяда китаптан да зуррак хәзинә юк! Анда бит иң асыл затларның, галимнәрнең фикере язылган. Үзеңнең дә укып караганың аз булмагандыр ул китап хәзинәсен...

Бу юлысы карт имам ялгышты—Сүбүдәй Батыр укый да, яза да белми иде. Бернинди телдә дә...

—Ал өч китабыңны!—диде Сүбүдәй.—Калганнарын бүген ут ашаячак. Китап соранып һаман шул болгарлыгыңа барасың инде син!...

* * *

Монгол чирүе кальганы алганнан соң ике көн ял итте дә, Болгар каласы урнашкан якка юл алды. Кальга урынында көл-күмер һәм янып бетмәгән төтенләп яткан кисәү өемнәре генә торып калды. Җимерелгән мәчет-манаралар, урам тулы мәетләр, янган йорт-каралтылар, улаган этләр калды...

Тагын берничә ел узгач, кальга хәрабәләре каршына берничә кәҗә ияртеән, кечкенә малай житәкләгән, ап-пакъ чәчле, ап-пакъ сакал-мыеклы бер карт килеп туктады. Бу Мөхәммәт Закир хәзрәт иде. Өстендәге иске, ямаулы чапанын салып, яшел үләнгә җәйде. Намазга ниятләде. Урынны элекке мәчет каршында сайлады. Камзулын салып чапан кырына җәйде дә, аның өстенә малайны утыртты. Картка ияреп килгән әрсез кәҗәләр яшел үләнгә дә, анда-санда үсеп чыккан агач куакларына да тимичә, бер урынга өерелешеп тын гына басып тордылар. Җирдән һаман да кан исе килә иде әле...

Имам намазын озак укыды. Ходае белән сөйләшеп жаны белән ял итте, күңеле белән пакъләнде. Камзул өстендә утырган малай да бабасына ияреп намаз укыгандай итте. Бабай белән бергә сәҗдәгә киткәләде дә... берсендә, тормыйча, камзул өстендә ятып йоклап китте. Хәзрәт намазын тәмамлагач та, үләнгә җәелгән чапаны өстендә бик озак утырды. Ул арада малай да йокысыннан арынып торып утырды да, бабасының урыныннан кузгалганын сабыр гына көтә башлады. Бала чыннан да бик сабыр иде, ахрысы, тавыш-тын чыгармыйча, бабайга караштыргалап, тыныч кына камзул өстендә утыра бирде. Имам азрак янтаеп уң кулы белән малайның җирән чәчле башыннан сыйпады. Аннан соң малайның кырында яткан түбәтәен алып башына кидерде, аркасыннан сөйде. Шуны гына көтеп утыргандай, малай арты белән шуышып килеп бабасына якынлашты да, аңарга сыенып тынып калды.

—Сине ышанычлы кулларга тапшырырга кирәк, адаш улым минем. Хан каны ага синең тамырларыңда. Хан каны! Болгар ханы кальга ныгытмаларын карап киткәннән соң җарияbездән туган олан бит син.

Әниең гүзәлләрнең гүзәле иде. Яшь иде, бөркет кебек батыр йөрәкле иде, мәрхүмә. Без синең белән анаң кабере янында утырабыз.

Болгар халкының киләчәге өчен, яшәеше өчен син исән-имин калырга, сау-сәламәт, таза булып үсәргә тиешсең. Ир-егет булып, ханыбыз булып яшәргә тиешсең син. Болгар көтә синең үскәнне хәзер! Болга-ар!

Карт ишан эре буынлы бармаклары белән тагын акрын гына малайның аркасыннан сыйпап куйды. Аның җыерчыклар каплаган, мәрхәмәт нурлары балкыган бите буйлап бер-бер артлы эре яшь бөртекләре тәгәриләр иде. Алар ап-ак сакалыннан тәгәрәп төшеп, ямаулы ак күлмәген чылаталар иде.

—Болгарга кайтыйк, әйиеме, улым. Болгарга! Ике кәҗәне суйыйк. Итләрен киптерик. Бавырларын киптереп төйик. Кәҗәнең иң сөтлесен үзебез белән җитәккә алыйк. Безгә юлда сөте булыр, үзе юлдаш булыр. Арысаң, аз-маз атланып та барырсың. Мөгезләренә тотынып. Мин җитәкләрмен кәҗәне. Китик, улым, Шәһри Болгарны эзләп...

Мөхәммәт Закир имам үзалдына сөйләнүен дәвам итте:

—Монгол явы үтеп китте инде. Давылдан соң кап урталай сынган агачлар да яңара, яшәрә, яңа ботаклар җибәрә. Исән калган орлыклардан яңа агачлар чыга җир йөзенә. Тере калганнар булыр Болгар җирендә. Ә аларга үзебезнең хан кирәк. Болгар ханы. Сине илтеп тапшырыйм мин ышанычлы кулларга. Булыр андый куллар, табылырлар. Иншалла, тере калырсың, улым. Хан улы бит син! Хан улы!..

Монгол Сүбудәй күпме генә тырышса да суеп бетерә алмады болгар халкын. Монгол яулары да, кара күмер белән көл генә калдырып үтә торган урман янгыны кебек, Болгар җирләре аша үтеп, урыс җирләренә кереп китте. 1223 елдан алып 1236 елның кара көзенә кадәр Болгар халкы үзен-үзе аямыйча, җанын да кызганмыйча монголларга каршы сугышты. Болгарлар кебек туктамастан үндүрт ел буена монголларга каршы сугышкан бер генә башка халык та юк җир йөзендә. Берничә гасырлар узгач, ярты ел эчендә монголга бирелеп беткән урысларның тарихчылары күз дә йоммыйча Аурупага яраклашу өчен язачаклар әле: «Русь спасла Европу от монголов». «Без—урыслар булмасак, сезне басып алырга хәзер монголлар килеп җитәчәк. Без генә тотып торабыз аларны Аурупага кертмичә!»

Күн иләп эшкәртүне, чуен коюны уйлап чыгарган болгарлар, гыйлемгә хирыслыгы, эшкә зур сәләтлеге белән, монгол аяк астында торып калса да, үзенең болгарлыгын иткән. Динен алмаштырмаган, гореф-гадәтен онытмаган, белемен югалтмаган, җирен эшкәртеп иген үстерүен туктатмаган, мал үрчетүен тагын да ныграк арттырган. Яңадан аякка баскан болгар, ханлыгын торгызган һәм аңарга яңа исем биргән: Казан ханлыгы!..

Шул Казан Ханлыгын безнең бабаларыбыз Алтын Урда таркалган чакларда борынгы Болгар ханлыгы җирләрендә төзиләр. Һәм яңа ханлыкта болгарлардан калган акыллылык, эшчәнлек, үҗәтлек белән яшәп, сәүдә итеп, иген игеп, кәсепчелекне, һөнәрчелекне үстереп, тагын баеп, көчәеп китүгә мөмкинчелек китереп чыгаралар...

Тик...

Язмыш, язмыш!

...XVII гасыр урталарында Иван Грозный Казанны алып яндырганга йөз еллар чамасы узган бер вакытта урыска башбирмичә тартышкан Казан Каргалысы дигән карьяда яшәгән бертөркем кыю татарлар башкорт ягына күченеп чыгып китәләр. Утызлап арбага җигелгән яхшы ашатылган, авыр юллар үтәргә өйрәтелгән атлар ару-талуны белмичә юл ярып узалар. Олауларның алдында—билләренә кәкре кылычлар таккан ир солтаны егетләр. Барысы да җылгыр атлар менгәннәр. Болар инде олауларны сак астында алып баручылар. Арбалар эче тулы мут күзле малайлар, чыркылдык

кызлар, буй җиткергән сылулар, яшь киленнәр, хатыннар, ирләр, бабайлар, ирләргә сиздерми генә, аларны үзләренә кирәкчә эшләтә-яшәтә белгән акыллы карчыклар. Тезелеп юл башлаган олауларның иң уртасында пар-ат җигелгән, өсте киез белән ябылган җинел тәгәрмәчле арбада ап-ак чалма-чапанлы, кырма-кара сакаллы утыз яшьләр чамасындагы бер мулла утырган. Аның да чапаны билбау белән буылган. Биленда—кылыч, хәнҗәр. Исеме—Монасыйп мулла. Яшь булса да, гыйлеме бик тә зурдан. Кабаланмыйча гына, һәрбер сүзен уйлап, аны тиешле урынына куеп сөйли белүе белән, салмак йөреше белән, төпле итеп, китап сүзләрен кулланып биргән киңәш-уңашлары белән Казан Каргалысы дигән карьяда зур ихтирамга ирешкән мулла иде ул. Авылны чукындырырга килгән солдатларны җитәкләгән әфисәр белән, озын, юылмаган чәчле, тик карадан гына киенгән поп белән дә урысчалатып үзе сөйләште мулла. Урысларга буш вәгъдәләрне күпләп-күпләп бирде. Чөнки кяферне алдау, анарга вәгъдә итү коръән тарафыннан тыелмый. Урыс бит ул безнең җиребезне басып алган, динебезне бетерүне үзенең төп максаты итеп куйган кяфер. Шунлыктан урыска каршы тору, аны алдау гөнаһ саналмый, ә тик савап кына. Чукынуга әзерлек үткәрү өчен ун көн вакыт сорады Монасыйп мулла урыслардан. Вәгазь укып, сөйләшеп халыкны урыс диненә күчүгә ризалаштыру өчен. Шул ун көн эчендә үзем үгетләп православиега күчәргә күндерермен халыкны, дип сүз бирде мулла. Озын чәчле поп әйтте муллага:

—Авылыгызда үзең поп булырсың. Үзем өйрәтермен сиңа «Отче наш» дигән изге догабызны. Шул җитеп торып ике-өч айга. Мәчет башындагы ярымайны алып аның урынына тәре куярбыз. Тәрене мин үзем алып килермен.

—Латны!—диде, Монасыйп мулла ризалашты.—Ходай кушканнан узып булмас инде, иншал...

«Иншалласы» ялгыш ычкынып китте инде китүен. Соңгы авазларын чыгармыйча тиз генә попның сыек зәңгәр, эренләгән күзләренә карап алды. Попның күзләре хәмердән тоныкланганнар, баш мие мулладан ялгыш ычкынган «иншалла»ны әләктереп алырлык түгел иде. Шулай да мулланың күңеленә шик килеп керде: «Ул-буны сизмәдеме бу айгырныкы кебек яллы, тәре таккан нәмәстәкәй?»

Сизенмәде поп.

Урыслар киткәч, икенче көнне өч мәхәлләле авыл халкы зур, таш мәчет янында җыйналдылар. Өйлә намазына кадәр урамда бәхәс барды. Нәрсә эшләргә? Чукыныргамы, чукынмаскамы? Чукынмасак, кая барырга? Бәхәс куерганнан куера, кызганнан кыза барды. Кызу канлыраклар берберсенең күлмәк, кәзәки якаларына, изүләренә ябыша башладылар. Карт хәзрәтнең сөйләгәнен, әйткәнен аңламас дәрәҗәгә барып җиттеләр. Мәйдан, аерган чактагы умарта корты кебек, гүләп тора башлады. Шулчакта мәйдан уртасына, тәкбир әйтеп, Монасыйп мулла чыгып басты. Мәйдан тына башлады.

—... Раббин галәмин... Тынычланыгыз, җәмәгать! Тынычланыгыз!

Мәйдан тәмам тынычланганны ул сабыр гына көтеп алды һәм сүз башлады:

—Исегездәдер, мин узган ел җәен Агыйдел буена кымызга барып кайттым. Юрматы башкортларына. Максатым кымыз эчү генә түгел иде. Башкорт аксакаллары янына киңәш-уңашка бардым мин. Әгәр без, Казан Каргалысы татарлары, сезнең якларга яшәр өчен күченеп килсәк, безгә утырырга җир, эчәргә су, төзелеш өчен урман бирерсезме, дип сорадым мин алардан...

Мәйдан тып-тын булып тыңлады үзенең яшь мулласын. Чөнки хәзрәт иң кирәклесен сөйли иде бүген.

—Урыс безне чукындырып бетермичә туктамас. Чөнки урыска—аңарга—ат кебек эшли торган, аның тамагын туендыра торган, вә ләкин юаш халык кирәк. Без татардан, чуаштан, маридан, мукшыдан шундый халыклар ясарга омтыла урыс. Чукындыра алса, үзенең Христосы белән

безне куркытып, үзенә буйсындырып тотмакчы. Ә без татарлар үзебез эшләп тапкан белән урысны ашатып яшәтергә тиеш түгелбез. Шулай бит!!!

Мәйдан бердәм җавап бирде:

—Шулл-ла-ай!!!

Әйе, мәйдан, зур җан иясе кебек, ухылдап-шаулап тын алды. Монасыйп мулла кабаланмый гына, үзенең уйларын сүзләргә әйләндереп, мәйданга сала барды:

—Шулай! Шулай булгач, китик чыгып. Монда чукынып яшәгәнче, башкорт, кайсак-кыргыз мөселманнар янына җыелышыйк...

Халык арасыннан берәү кычкырды:

—Урыс анда да килеп җитсә?

—Каршы торырбыз. Көч җитмәсә, даланың тагын да эченәрәк кереп китәрбез. Кыргыз-кайсак арасына...

Хатын-кыз елаша да башлады:

—Туган, үскән якларыңны ташлап чыгып кит инде-е...

—И-и-и, бар икән күрәселәребе-ез!...

—Бәлкем, тимәсләр әле. Урыс та кеше бит инде-е...

Хатын-кыз гадәтенчә, үзенекен тормышка ашырырга тырышып, елап ирләр күңеленә шом сала башлады. Монасыйп мулла сүзен болай дәвам итте:

—Җәмәгать! Авылдашлар! Мөселманнар! Урыс атаң булса, билеңдә балтаң булсын, ди безнең халык. Һәм ул дөрес тә! Китик чыгып. Урыс астында яшәргә теләгәннәр калсыннар. Җаны теләгән, елан ите ашаган! Кала торганнар, калсыннар. Тик сезне барыбер чукындырып урыс ясаячаклар. Озакка сузарга безнең вакыт юк. Ике көннән кузгалырга кирәк. Кояш белән бергә. Ике көн, ике төн безнеке. Үзегез белән нәрсә алырга—һәркем үзе чамаласын. Тик иң кирәге өч әйбер булыр. Шуны онытмыйча эш итегез, җыйналганда. Иң кирәге китап сүзе, сука-сабан һәм хуҗалык, җир-эш кораллары булыр. Чалгы, көрәк, балта-сәнәк, палас суга торган стануклар һәм дә башка эш кораллары... Киңәш итегез, кайтып... Иртәгә иртәнгә, минем белән юлга чыгарга теләгәннәрегез белдерегез миңа шул хакта...

Монасыйп мулла, сөйләвеннән туктады да, өстәде тагын:

—Безнең белән китмичә авылда калганнарга бер үтенечем бар. Монда калабыз дип, урыска яраклашып, безнең китәргә ният иткәнне аларга җиткерергә тырышмагыз. Зинһар, дип үтенеп сорыйм. Гозерем шул! Авыл тирәсендәге юл-сукмаклар хәзердән үк ябылган булачаклар. Берәрсе тотыла калса, үпкәләмәсен. Безнең яктан кызганып тору булмаячак...

Халык тынып калды.

* * *

Авылдан чыгып китеп тугыз көн үтте дигәндә, утызлап олау Көньяк Урал таулары арасында, Агыйделдән еракта түгел утырган Мәксет дигән башкорт авылына килеп керделәр. Юллар тыныч, коры, тигез булганлыктандыр, мөгаен, төнен мул вә сутлы үләнгә туенган атлар күңелле генә юырталар иде. Олаулар авылдан чыгып киткәч, дүрт егет, яшеренеп, Казан юлын саклап яттылар. Өч көн, өч төн буена. Урысларга хәбәр салырга ашыгучы булмады. Урыс карамагында калсалар да, авылдашлары сатлык юлга чыкмадылар. Аллаһега шөкер! Шөкер, иншаллаһ!.. Догада булыйк!..

Мәксет башкортлары татарларның киләсен алдан белеп-көтеп торганнар иде. Манарасы кыйшая башлаган кечкенә мәчет алдында утыз чиләк керешле борынгы бакыр казанда бытыр-бытыр кайнап, тәмле, хуш исләр чыгарып сарык ите пешә. Бу хуш исләр авыл очларына ук таралган. Әйтерсең лә инде килгән кунакларны каршы ала. Ике көн генә элек

олауны куып житкән дүрт егетне Монасыйп мулла юл өйрәтеп алдан башкортларга озатты. Бермекләп-бермекләп өйрәтте юлны:

—Шушы юл сезне Агыйделгә алып чыгар. Шулай да, сораштыра барыгыз, ялгышып-нитеп читкә кереп китә күрмәгез. Әйтәм, Агыйделгә барып чыккан җирдә, Ишембай дигән җирдә унлап кына йорттан торган бер башкорт авылы булыр. Шул Ишембай авылыннан нәкъ кояш чыгышына карап китсәгез, Мәкъсет дигән тагын бер авыл булыр. Башкортлар аны Ишембайдан унсигез чакрымнар, диләр. Тик белегез—башкортның чакрымы безнең татарныкыннан озынрак. Дала ягы ич, башкорт ул чакрымны атыннан төшмичә генә үлчи. Ияр үлчәме белән. Мәкъсеткә барып җитү белән, авылы мулласына сәлам ирештерегез. Миннән килгәнегезне әйтегез. Тагын ике көннән мөселман татарлары урыстан качып килеп җитәчәкләр, дигез. Килгәннәрнең туксан икесе үсеп җитмәгән бала-чага дип белдереп куегыз. Килүчеләргә йорт саен бүлеп урын әзерләп куйсыннар. Башкорт җәйләүдә инде ул бүгенге көнне. Чакырып кайтарсыннар, дип үтенде Монасыйп мулла, дигез. Габделгани абзый үзе татардан. Җәйләүгә чыкмый, барып кына йөргәли. Яшәеше татарча, авылда. Хәерле юл, ак юл сезгә, егетләр! Юлларыгызда уяу-сак булыгыз!

* * *

Атлар бердәм кузгалды.

Мәкъсеткә килеп хәл алгач, дүрт башкорт егете, вә өч татар җайдагы юл чыгарга ниятләделәр. Ишембай авылы янына җитәрәк, атларын йөздереп, үзләре көймәләргә утырып Агыйдел елгасының сул як ярына чыктылар. Агыйдел елгасы буйларында мондыйдагы гүзәллекне, матурлыкны бу мөһаҗирләрнең беренче тапкыр күрүләре иде. Яшел урманнарга төренгән текә-текә таулар ераклларга кадәр тезелешеп басып, күгелҗемләнеп күренәләр иде. Көмеш сулы Агыйделнең төрле зурлыктагы ташлар белән капланган су төбе якын гына булып күренеп ята. Кулыңны суга тыксаң, шул ташларны тотып алырга да булыр кебек. Суы саф, салкын һәм шунлыктан исеме дә Агыйделдер аның.

Елганың сул ягына чыккач, атларына атландылар да, кояш баешын азрак ундарак тотып, дала катыш таулар арасына кереп киттеләр. Кояш баер алдыннан яшел кылган каплаган тау башына килеп чыктылар. Тау бик биектән булмаса да текә иде.

—Ошо инде һезгә дигән ерзәр!—диде Миңлегол башкорт, уң кулындагы камчысын еракта күренгән таулар ягына сузып.—Кай тирәһе ошай—шунда ултырыгыз. Менә был, без башында тукталган таузың исеме Бакыр Сагыл. Боронго заманнардан калган исем тизәр. Эсендә бакыр ташы бар икән. Әнә-ә тегендә урман эченнән башы гына агарып күренгән таузың исеме Ак Сагыл.Ошо Бакыр Сагыл тау астындагы яландарзы Гөмбәз яландары тип йөретәбез. Елгаһы ла, әнә тау астында агып ята—Гөмбәз елгаһы. Һыуы бә-әк тә тәмле, үзе һыуык—тештәрзе камаштыра эскән сакта...

—Ә ни сәбәпле бер генә авыл да юк бу якларда?

Миңлегол карт, олпат гәүдәсен иярдән арткарак каера биреп, иркенләп көлде:

—Теге, киң битле, кысык күзле кайсактар менән бәхәс һанала был ерзәр. Әллә кайларзан йәйләүләргә тип килеп беззең башкорт еренә нәфселәрен һузалар. Шунлыктан без дә был яктарга йәйләүгә мал куабыз. Авылдар һалганыбыз юк. Кайсак-кыргыззар туздыралар беззең ауылдарзы. Без аларзыкын. Ә ер—беззеке. Башкорттыкы. Беззең ата-бабанан калган ерзәр был яктар...

Түземсезләнеп тапанган атының муеныннан шапылдатып сөйде:

—Тәк кенә тор, алмасуаркай! Тәк кенә-ә! Карагыз, һөрегез! Кай

урын охшай—шунда һалыгыз авылыгыззы. Ирек һезгә. Аксаһын тыләрһегез. Алтын-көмеш аксалар менән. Хакын әллә ни киммәттән алмабыз. Безгә лә, һеззәге күек уку кәрәк. Һез татарзар укымышлы халык...

—Мәдрәсәләр булыр, агай!—диде Монасыйп.—Торырга азрак урын әтмәлләсәк, мәчет-мәдрәсәгә тотыначакбыз. Ныклап торып! Иншаллаһ!..

—Шулай булырмы?—диде башкорт.—Әйдәгез, мин һезгә өс елга бергә кушылган урыннарзы, шул яктагы шишмәлектәрзе, тугай-әрәмәлектәрзе күрһәтәйем әле. Зирекле елга, Карамалы елга, Имәнле елга кушылган бик тә матур, асыл урын бар. Текә тау астында ул урыннар...

Камчысы белән Ак Чагыл тау ягына төртте:

—Әнә-ә, урман өстеннән аз гына агарып тора Ак Сагыл. Ән-нә-ә, бөркет осоп йөри тау өстеннән. Әнә, шул бөркет осып йөрегән якка карагыз! Әнә-ә! Шул Ак Сагылдың был ягында, өс елга кушылган урында, бик зур бер күл бар. Ул каз, ул үрдәк күлдә—исәбе юк. Елгаларында күлендә балы-ык. Ул ажау, ул шамбы, ул бәрде! Суртандар беләктән озондар, үззәре бүрәнәләй юандар. Куян, төлке яландарза, урман тулы бурһык, поши. Бүреһе дә бар тунга, толопка, бүреккә...

Башкорт шәп сунарчы иде, ахрысы...

Көн кичкә авыша башлаган бер чакта инде, төнгелеккә тукталдылар. Урынны кунарга башкорт сайлады. Атларны тышаулап, учак яккач, Монасыйп мулла елгага төшеп тәһарәт алды да, аяк-кул язып, берунайдан намаз да укып алырга дип, якындагы кечкенә тау башына табан атлады. Тауның итәге, башы билгә тиклем җиткән яшел кылган белән капланган иде. Кояш баешына карап, Кыйбланың кайдалыгын билгеләде дә, яшел кылганны аяклары белән азрак тапаштырып, чапанын җиргә җәйде. Намазга керешә...

—Ният кылдым...

Сәҗдәгә китәргә дип тезләнгәндә, уң аягының тезе чапан астындагы, җирдән азрак чыгып торган ниндидер каты әйбергә тиеп, авыртып куйды. Хәзрәт намазын бүлмәде, тик тезен генә азрак читкә шудырды. Намазы тәмамланып, чапанын җирдән алган чакта, тезен авырттырган нәрсәгә күзе төште. Инде карая төшкән кылган төбеннән бер таш күренеп тора иде. Шул ташның читендә сызыгы да бар. Хәзрәт, иелә биреп, ташны бармаклары белән сәрмәде. Тирә ягына каранды да, кул учы зурлыктагырак бер таш кисәге табып алды. Шул таш белән тезенә бәрелгән ташның тирәсен казый башлады. Таш, җирдән ачылып, ул инде уч киңлегендә иде. Монасыйп мулланың йөрәк тибеше көчәйде. Байтак казына торгач, ташның түгәрәкләнгән башы җирдән күренә башлады. Монасыйп мулла ташны тоткалап, аны туфрактан, комнан арындырды һәм аңлады—бу кабер ташы иде! Тагын байтак казый торгач, ташның күп өлеше күренә башлады. Монасыйп бармакларының бите белән ташның яссы өстен сыйпап карады да—сискәнеп китте. Ташта гарәп хәрефләрен чамалап алды мулла. Тик укый алмады. Еллар тәэсире астында ташка кисеп язылган хәрефләр үзләренең язылыш сызыкларын югалтып бетерә язганнар иде. Шулай да мулла бер сүзне укыган кебегрәк иттереп чамалый алды. Ул сүз «мәдфүн» дигәнгә охшаган иде. «Мәдфүн? Мә-фү-үн?!» «Күмелгән!» дигәнне аңлата бит бу сүз: Күмелгән! Димәк, бу мөселман кабере булырга тиеш!..

Миңлегол башкорт Монасыйп мулланың мөселман кабере турында сөйли башлаганына кул гына селтәде:

—Әллә кайчангы боронгы замандарза ошо урында кальгаме шунда, авылмы инде булган бугай. Олатайым шулай тип һөйләй торгайны. Мангул яуы килгән замандарда булган ул кальгаме шунда, әллә авылмы. Олатайым шулай ти торгайны. Мангуллар килгәнсе булган инде бу хәлләр. Уныһы хак. Был урын Шакир Ташы дип атала. Кем белһен инде нәмәләр булганын ул замандарза. Дала башлана бит ошо ерзәрзән. Дала-а! Дала кылганы астындагыһын кем генә белеп бөтерһен инде-е?!

Алар Эстәрле елгасына табан сузылган үзән кебегрәк җирдә

туктадылар. Төнне шунда уздырдылар. Иртән торып, тәһарәт алып намаз укыганда да, иртәнге чәйгә утырганда да Монасыйп мулланың йөзендә ниндидер авыр уйларның күләгәсе чагылып, кәефе чамалы күренә иде. Егетләрнең берсе саклык белән генә сорады:

—Хәзрәт! Әллә төнлә белән йокың тынычсызрак булдымы? Ике мәртәбә ыңгырашып та алгандай иттең. Йоклаганда.

Мулла моң һәм уй тулы күзләрен егеткә текәде:

—Нилектән алай дип сорыйсың Мөхәммәт Гарифулла? Берәр нәрсә сиземәме әллә йөземнән?

—Сизелә бугай инде. Битең гадәти алсулыгын югалткан бүген. Азрак көл төсе кергән димме шунда...

Миңлегол башкорт сүзгә кушылды:

—Юкты һөйләмәссәле-е! Нәмәкәй инде бында! Бер-ике тустак кымыз эс тиһәк, бар еребеззә урынына утырасак. Хәз-зер!...

Миңлегол янындагы каен тузыннан ясалган, ярыйсы гына зурлыктагы ябык савытка үрелде.

—Төнгелеккә шишмә һыуына батырып куйгайным. Һалкын кымыз бик тә тәмле була эсәргә...

—Туктап тор, Миңлегол агай! Мин сезгә бер нәрсә турында сөйлим әле.

Монасыйп, юлдашларын барлагандай карап чыкты да, авыр итеп көрсенде:

—Без йоклаган бу урын бик тынгысыз булырга охшаган. Кичә кичтән мин әнә теге кечкенә калкулык башында, намаз укыганнан соң бик борынгы кабер ташына тап булдым. Ул урында мөселманнарның каберлеге булганга охшаган. Ходай Тәгалә белдерде бу турыда. Намаз укыган чакта, сәҗдәгә киткәндә тез башына туры килде шул кабер ташының баш өлеше. Аз гына чыгып тора икән җирдән. Кич йокларга ятканда догалар укып ялвардым Ходайдан: «Нинди урын бу? Кая булганнар монда көн күргән, дөнья көткән мөселман бәндәләрең? Авыллары булганмы? Төш аша булса да хәбәр ит мин колына?»...

Сүзләрен сөйләүне туктатып ул байтак утырды. Башкортның түземлелеге бетә башлады. Аның кымыз эчәсе килә иде. Урыныннан кузгалып куйды:

—Шуннан?—дип сорады.

—Шуннанмы?

—Әй-йеме.

—Төне буена йокылы-уяулы ятып чыктым. Йоклагандай булып онытылып кына китә башлыйм, шунда ук колагыма җан биргәндәге кебек ачыргаланып елаган, кычкырган сабыйлар тавышы ишетелгәндәй була. Яткан урыным җайсыз кебек, тын кысыла, сулыш алырга һава җитешми. Тиргә батып уянып китәм, аннан соң йоклагандай булып тагын онытыла башлыйм. Атлар кешни ачыргаланып, кылычлар чыңлыйлар бер-берсенә бәрелешеп, кемнәрдер җан биргәндәгедәй авыр итеп ыңгырашалар кебек. Тагын уянып китәм, тагын онытылам...

Җиргә төбәгән күзләрен күтәрмичә тагын болай дип өстәде:

—Мин уйлыйм—әле без утырган урында бик күпләр булып безнең мөселманның каны аккандыр. Кабер ташы булгач—зираты да булгандыр. Зираты булгач, аңарга мәет бирүче авылы, яисә кальгасы да булгандыр. Бу урын кеше торак төзеп яшәр өчен бик кулай урындыр. Чишмәләре бар, сулары тәмле,үзе текә елга ярында. Өч яктан су белән, сазлыклар белән уратып алынган. Җире кара, уңдырышлы булырга охшаган. Бу җирдә тереклек итүчеләр көч белән, кылыч-сөңге белән юк ителгән булырга тиешләр. Бик күпләп кан коелгандыр бу җирдә. Һавасы авыр сулар өчен. Кан исе килгән кебек. Авыл салырга җир алсак, без урынны су агышы белән өстәнрәк карап алыйк. Күлнең теге ягына, урманга якынрак ягын карыйк...

Миңлегол башкорт телгә килде:

—Ысыннан ла был тирә игелекле түгел шул. Йәисә ат аягын һындыра, бия колонлаһа—колоно үле туа, йәисә бүре малдың бугазын өзгәләй. Шишмәләре һыуыннан әллә ниндәй тәм килә. Әйзәгез, мин һеззе арырак алып китәйем. Анда, текә тау астында алты шишмә сыгып ята. Тик урыны таулырак инде, бындагы кебек тигез ер түгел. Илләмә, һыуы ла һыуы инде шишмәләрдең. Әйберзәр ошонда калып торһондар. Бындан ерак түгел ул урын...

Атларга атланып, тау сырты белән чакрым-ярым чамасы ара уздылар. Аннан соң юан-юан агачлар белән капланган ике тау арасыннан, җәнлек сукмагы белән аска төштеләр. Ачыграк урыннарда ямь-яшел кылган өзәнгеләргә житеп үскән иде. Тауларны яртылаш диярлек төшкәч, чылтырап агып яткан чишмәлеккә килеп чыктылар. Алар, атларыннан төшеп, соклануларыннан байтак кына сүзсез калып тордылар. Чишмәләрнең челтерәп аккан тавышына агачлар арасында сайраган сандугачлар тавышы кушыла иде. Бу тавышлар атларыннан төшеп басып торган бәндәләрнең киләчәккә өметләрен кузгата иде: «Ходай кушып, бары да иминләнеп китәр! Йортлы-җирле булырбыз, иншалла!»

—Сөбхәналла!—дип акрын гына пышылдады хәзрәт.—Сөбхәналла! Булса да була икән җир йөзендә оҗмахка тиң урыннар! Бик тә гүзәл итеп яраткан икән бу урынны Ходай! Азрак аскарак төшеп тәһарәт алыйк та, намазга басыйк, мөселманнар! Шушыдыр безнең урыныбыз. Мең рәхмәтләр Ходайга! Сулыш алуларым иркенәеп китте. Ошбу урында булыр авылыбыз да, зиратыбыз да. Иншалла! Яшәрбез! Яшәр өчен урын эзлибез! Без колларыңны кайгырттың Ходаем! Рәхмәтләр яусын сиңа!

Минлегол кулы белән каршы тау ягына селтәде:

—Ошоннан турыга менһәң, тагы ла бер шишмә бар. Етенсеһе шишмәләрзең тау башына менеп етәрәк бер сокорзан бәреп сыгып ята. Һыуы бында хәтлем төшәп етә алмай—ага-ага комга һеңеп бөтә. Һыуыкымыз күек эсеп туйгыһыз...

* * *

Чишмәләр чыгып яткан шушы урында күченеп килгән татарлар авыл сала башлыйлар. Аллага тапшырып! Ташлап киткән авылларының истәлеге итеп, авылга Каргалы дип исем кушып карыйлар. Тик, ни сәбәптәндер, ул исем авылга ябешеп китми. Чөнки бу урынны башкортлар үзләренчә Өс Төрле Елга Башы дип йөртәләр. Соңрак, «елга»сы төшеп калып авыл, Өс Төрле Башы булып кына аталмыштыр. Шуңардан килеп чыга инде авылның исеме дә—Эстәрлебашның исеме. Ә елгалар чыннан да урманнан өчәү агып килеп чыгалар—Зирекле, Имәнле, Карамалы елгалары. Елга ярында нинди агач күбрәк үскән—елганың исеме дә шуңардан. Өч елга ярты чакрым арада бергә килеп кушылалар да, берничә текә тауларны сул як ярда тотып, инде Эстәрле елгасы исемендә Ашказарны эзләп агып китәләр. Эстәрле елгасы ике чакрым чамасы узгач, зур гына Камышлы күлгә килеп керә. Елгалар агышы белән уң яктан күлгә тагын бер елга килеп коя. Анысыннан да исеме ярларында тоташ булып үскән ак каеннардан алынган—Каенлы Елга. Җирнең күбрәк өлеше кара туфрак, текә тауларның эче тулы каты таш, кырчын. Ә инде калынлыгы аршиннан артык кара туфракны казып төшсәң, кызыл балчык катламы башлана. Балчыктан соң ком катыш вак кына таш. Бу якларның шундый ком катыш вак ташын кырчын диләр икән. Тау эчләрендәге каты таш катламына кәйлә белән китереп суксаң, ул юка-кисәкләргә ярылып китә, яссы ташка әверелә. Анысы инде йорт-кура тирәли таш койма ясарга, келәт-абзарлар салырга бик тә жайлы таш.

Күченеп килгәннәр Каенлы елганың ике як яры буйлап сузылган, гасырлар буена сабан күрмәгән чирәмне сөреп, килгән елны тары гына чәчтеләр. Чөнки яз үтеп беткән иде инде. Күзгә котырып үскән тарыга

карап килгәннәрнең Ходайга рәхмәтләре иксез-чиксез булды. Ул елны кыш буена тары боткасы, тары өйрәсе, тары коймагы ашап чыктылар...

Килеп утырганнарына егерме еллар чамасы узгач, Текә тау астындагы алты чишмә янында башланып киткән татар авылы Эстәрле елгасы ярларына җәелеп, мәчетле, мәдрәсәле, салам башлардан торган төрле зурлыктагы йортлары булган матур бер авылга әйләнгән иде инде. Авыл иплe, эшчән, гыйлемле, сәүдәгәр, игенче, ташчы, балта остасы, аяклы мал кадерен белүче татар ирләреннән һәм ашка-суга оста, исән-имин балалар таба белә торган, матур паласлар, тулалар суга торган чибәр татар хатыннары белән дан ала башлады.

Беренче еллар авыр булдылар. Килеп утырганның икенче җәй башында ук авылга баштан-аяк коралланган атларга атланган йөздән артык кайсак килеп керде. Кайсак-кыргызлар Тургай далаларыннан икәннәр. Анысы соңрак ачыкланды. Көпе туннар, ике яңагын, җилкәсен каплап торган өч колаклы малахайлар кигән, киң битле, почтык борынлы, кысык күзле кайсаклар, авылга килеп керү белән алтын аен кояшта ялтыратып утырган мәчет янына юырттылар. Монасыйп мулла аларның килүеннән хәбәрдар булгандай, мәчет алдындагы мәйданда каршы алды.

—Хуп киләсез, кайсак кунаклар! Әс-әлам-мәгаләйкүм-үм! Хуп киләсез! Мәчеткә үтегез! Намаз вакыты житеп килә. Ният итеп намаз укып алыйк!..

Кайсакларны, тәһарәтләндереп, мәчет эченә намазга алып керделәр. Намазга маһирлыклары сайрак икәнлеге күренеп торса да, мөселман татарлар аны-моны сиздермиләр. Намаздан соң кайсакларны йорт саен бүлешеп алып, ныклап кунак итеп сыйлыйлар. Һәр йортта салынган мунчаларны ягып-булдырып, далада мунчаны үз гомерләрендә күрмәгән кайсакларның ләүкәдә, каен себеркесе белән чабып юындырдылар. Юка мунчаласы, ак күбекле сабын белән күпме генә ышкып юсалар да, килгән кунакларның тән каралыгы бер тамчы да кимемәде. Тик кара-кучкылланып кызарды гына. Ышкып-ышкып юып та кайсакларның тәнен агарта алмагач кына мунчалы татарлар анлыйлар—кайсакларның тумыштан шундый карарак төстә икән тәннәре! Ходайның кеме генә юк жир йөзендә, сөбханалла!

Мунча кертеп чыгаргач, әче бал белән сыйладылар. Ике тустак балдан соң кайсаклар ат иярennән чишеп алган думбраларын алмашлап чиртә-чиртә, дала жырларын—үләң әйттерергә тотындылар...

Икенче көнне иртән мулла-ишаннар кунакларга кечкенә мәдрәсәнең паласлар җәйгән идәнендә тезелешеп утырган, барысы да китап тоткан утызлап малай-шәкертләрен күрсәтеп мактандылар.

Кайсаклар тагын икене кунып кунак булдылар. Көн дә мунча керделәр. Аларга иң ошаганы эссе ләүкә белән каен себеркесе булды. Өч көн узгач, кунаклар китәргә ният иттеләр. Уникедән үргән каеш камчысы белән күн итегенең балтырына шапылдатып суккалап, Учакбай исемле иң гаярь кайсак әйтте шунда:

—Бу яктагы жирләр борын-борыннан сез болгарлар белән без кайсаклар арасында низагъ чыгаручы урыннар булганнар. Мангул батыры Сүбүдәй шушы жирләрдә яшәгән болгарларны тоташыгыз белән суеп бетереп юк иткән. Борынгылардан калган истәлекләргә караганда, шушы тирәләрдә болгарларның бик зур кальгасы булган. Сүбүдәй аны алган, талаган, юк иткән. Тик бер карт мулла белән бер ир баланы гына тере калдырган. Үзләренең жаннары өчен теге карт мангулларга кальганың хәзинәсен күрсәткән, диләр. Безнең кайсаклардан ул карт белән малайны күрүчеләр булган. Мангуллар Агыйделнең теге ярына Тобол елгасы буеннан Табын ыруы башкортларын күчереп утырткannaр. Ул ыруның иң зур батыры Майкы бәй булган. Шул батыр Чыңгыз ханга курайда уйный торган булган. Майкы бәйнең ыруы Болгарларга каршы Чыңгыз гаскәренә кушылып сугышкан. Агыйделнең теге ярында ныклап төпләнгәннәр башкортлар. Болгар жирләрендә. Ә Агыйделнең бу як ярына чыгып

авыллар салырга җөрьәт итмәгәннәр. Без кайсаклар көчлебез. Шунлыктан бу дала-кырлар болгар белән кайсакның уртак җире санала. Без кайсаклар шулай уйлыйбыз. Шунлыктан без кайсаклар сезне хуп күрәбез. Авылыгыз матур, житеш мәдрәсәле вә... мунчалы...

Учакбай елмаеп куйды.

—Сез татарлар китаплы, гыйлемле халык. Мәдрәсәле, укымышлы барыгыз да. Мәдрәсәләрегезне зурайтыгыз. Безнең балаларга да белем, гыйлем бирерсез, аларны да укытырсыз. Үзегезнекеләрне укыткан кебекләр итеп. Укытуны оештыруны без кайсак-кыргызлар әлегә булдыра алмабыз. Бохара, Сәмәрканд якларындагы мәдрәсәләр безгә кулай түгел. Үзбәкләр белән безнең арада җир өчен, су өчен тартыш бара. Борын борыннан ук. Өстәвенә, алар бездән көлергә яраталар. Без яратмыйбыз аларны, алар— безне. Ә сез инде солых белән, сәүдә белән килегез безгә, без сезгә килербез. Без кайсак-кыргызлар бик күп дала эчендә. Сезнең авылдан алып, Кытай диварына кадәр җәйләүләрдә күченеп яшибез без. Дала тоташ безнеке...

Ул Монасыйп мулланы кочакларга дип кочагын җәйде:

—Хуш иттек!

Кочаклашып саубуллаштылар. Аерылганда татарлар бу җирләрне әҗәргә алган өчен башкортларга алтын-көмеш белән хак түләгәннәрен әйтеп тормадылар. Түләнгәнне башкорттан кире алып булмый бит инде. Аннан, иң авыр чагында, башкорт киң күңеллелек күрсәтеп, сиңа утырырга җир күрсәткән икән, шуңарга каршы рәхмәттән башка нәрсә булырга тиеш ди инде?! Яңа җирләр, авыл тирә ягындагы табигать, тау-яланнар монда туган балаларга Туган Як, Туган Ил булачак бит! Аллага мең шөкер! Аллаһү әкъбәр!!!

* * *

Унҗиденче гасыр азагында Эстәрлебаш инде йөздән артык йортлы, Чишмә урамына салынган зур агач мәчетле, мәдрәсәле татар авылы булып ныгып китә. Мәхәллә ишаны Монасыйп мулла Эстәрлебашның үзендә дә, ул салынганнан соң гына бар булып, аны уратып утырган татар, башкорт авылларында да зур абруйга ия була. Эстәрле елгасының агымы белән өч чакрымдагы җирдә, аңарга Кайраклы елгасы килеп кушылган урында, татар авылына елышып, Агыйделнең уң як ярында урнашкан юрматы башкортларыннан булган Мәкъсет авылы башкортлары күченеп утыралар. Алар яңа авылга да үзләренең элекке авылларының исемен кушалар. Шулай итеп, Эстәрлебаш авылында кыргыз-кайсак шәкертләре күбәйгәнне күреп, башкортлар кыргыз-кайсак далаларына киткән җирләрдә авыллар тергезә башлыйлар. Мәкъсет авылына нигез салынганга өч ел вакыт үтте дигәндә, авыл уртасына бәләкәй генә агач мәчет тә салып куялар. Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укып гыйлем алган Заһретдин исемле татар шәкертен мулла иттереп тәгаенлиләр. Озакка сузмыйча, буй җиткәреп килгән Гөлбикә исемле бер башкорт кызын яшь муллага абыстай итеп, туйлап яраштереп тә куялар.

Монасыйп мулла инде җитмешкә җитеп килсә дә, егәре вә һәм дә байлыгы җитәрлек булганнан, өченче мәртәбә өйләнеп, бабасы йортында яшь кияү булып йөри. Туй көннәре үтеп, яшь абыстайны ике хатыны өстенә өченче абыстай иттереп төшереп йөргән чагында, Эстәрлебашка көтелмәгән олаулар килеп чыгалар. Казан каласы артында, Малмыж өязендәге Салавыч дигән авылдан Бохарада сабакташы булган Урманай мулланың Тукай исемле улы җитәкләгән була ул олауларны. Атлар тугарылып, арбадагы юлчылар йортлар саен бүленеп урнаштырып куелгач, Монасыйп мулла Тукайны мәчет янындагы үз йортына алып китә. Шунда Тукай карт муллага Салавычтан алып килгән зарын җиткерә.

—Петр патша фәрманы буенча безне көчләп чукындыра башладылар. Алты авыл берләшеп каршы тордык, чукынмадык. Урыс солдатлары туплар белән килгәннәр иде, барыбер безне җинә алмадылар. Тупларын юк иттек, үзләре качтылар. Тик әтиебез Урманай туп кыйпылчыгы тиеп каты җәрәхәтләнде дә, җан тәслим кылды. Шәһит китте. Үләр алдыннан мине янына чакрып алып, Эстәрлебашка юлны өйрәтте. Сине үзенең дусты диде. Монасыйп хәзрәт белән без Бохарада бергә укыдык, бер киез өстендә, бер юрган астында йокладык, яхшы дусларбыз, диде. Ул сиңа ярдәмчел булыр диде...

Хәзрәт яшь егетне ихласлык белән тыңлады. Тавыш-тынсыз гына чәй ясаган яшь абыстайга караштыргалап Тукайны сыйлады һәм әйтте:

—Аша, улым! Юл белән килеп ачыккансыңдыр. Озакламый мунча өлгерер, Алла боерса. Исән-имин килеп җиткәнсез, Ходайга мең шөкерләр. Монда төпләнерсез, яшәрсез, балалар үстерерсез, үрчерсез. Иншалла. Бик уңдырышлы бу якның җирләре, һавасы шифалы, җилләре саф, кышкы суыклары исәнлеккә файдалы. Таулар, иркен елан-кырлар җитәрлек. Кош-корт та бик күп. Хәтта кайсыбер елларда аю да килеп чыккалый. Иген бик тә уңа, мал нык үрчүчән бу якларда, иркенлек зур. Башкортлар турында да начар сүз әйтеп булмый һәм әйтәсе килми дә. Киң күңелле, юмарт халык алар. Комсызлык юк аларда. Көнчелек дигән нәрсә дә сизелми үзләрендә. Тик нилектәндер игенчелеккә хирыс түгелләр. Азрак җир эшенә ялкаураклар димме инде шунда. Барлык эшкә ризалар, тик җир генә сукалатма инде син аңардан. Иң яраткан эшләре—ялан-кырда мал көтү. Аннан инде умарта асрау, кымыз эчү, гыж-гыж китереп курай тарту. Илләмә анысын яраталар инде. Осталар шул курайга үзләре. Әллә нинди моңнар чыгаралар инде. Кызулыклары да бар. Безнең татар кебек төптән, озак итеп уйлап эш йөртә белмиләр. Суктым-үптем—эшлиләр дә ташлыйлар. Аннан соң гына уйлыйлар: «Нәмә эшләп болай килеп сыкты һуң әле был?»—дип...

Монасыйп үзенең сөйләгәненнән үзе елмайды да, азрак уйланып утырды. Аннан соң гына сорады:

—Күңеленә авыр алма, улым, дөнья хәле бит. Сорыйм әле. Атаңнан калган сәмәнең бармы соң? Акча, алтын-көмеш диюем.

Тукай җитди итеп җаваплады:

—Бар. Тик күпме икәнлеген белмим. Барлык акча, алтын-көмеш олы әнидә. Төрле-төрле кыйммәтле ташлардан хатын-кыз бизәнү әйберләре дә байтак бар бугай. Сорармын.

—Сорашма. Кирәкми анысы. Үзе белгәч җиткән. Безнең йорттан Эстәрле ярына кадәр буш урын бар. Кирәге чыгар, вакыты белән үзе авыл уртасы булачак дип тота идем. Шунда утырырсың. Урын күп анда, мул итеп уратып ал. Шунда йорт-кура житештерә башла. Иманле Үр дигән җирдән агач кисәрсең. Ташырга якын, авылга хәтле бер генә бәләкәй үре бар. Юлы әйбәттән санала. Эшләгән халыкка хакын кызганма. Юмарт икәнеңне авыл халкы да тирә-як авылларда да белсеннәр. Соңыннан бише белән кайтыр. Очсызның арты тынычсыз, диләр.

Ике ел узгач яшь бичәсен, алты айлык улы Биктимерне әнисе карамагына калдырып Тукай бине Урманай зур укуга, гыйлем эстәргә дип ерак сәфәргә, Бохара Шәрифкә юл тотты. Бохарада биш ел укыды. Шул гомер эчендә авылга тик ике генә мәртәбә кайтып торып китте. Абыстае да уңганнардан булып чыкты: Тукай-шәкерте кайтып кунак булып китүгә, тәгаенлы вакыты килеп җитү белән, дөньяга чибәр-чибәр балалар китерә торды.

Бохара Шәрифтән дин укуын тәмамлап кайткач, картаеп инде ныклап йончыган Монасыйп мулла урынына, аның фатихасын алып, Эстәрлебаш мәдрәсәсенә Тукай бине Урманай мөдәррис итеп билгеләнде.

Шул рәвешле Казан губернасы, Малмыж өязе җирендә урнашкан Салавыч исемле кариядән чукынудан качып чыгып киткән Тукай бине Урманайдан кыргыз-кайсакларның иксез-чиксез далалары башланып киткән

җирдә салынган Эстәрлебаш кариясендә иң зур мәдрәсәләрнең берсен тотучы Тукай бабай нәселе бар була. Ике йөз елдан артык Эстәрлебашның мәдрәсәсендә мөдәррис, мәсчетендә ишан булып Тукай бабай нәселеннән чыккан асыл затлы шәхесләр торалар. Тукай бабайдан соң аның улы Биктимер мөдәррис-имам була. Аннан соң оныгы Нигъмәтулла. Анысыннан соң Нигъмәтулланың уллары Харис белән Харрас. Һәм Харисның улы, Эстәрлебашның атаклы мәдрәсәсенең соңгы мөдәррисе, Дәрдмәнднең һәм Риза Фәхретдиновның дусты Икенче Дәүләт Думасы депутаты, галим үтә дә фаҗигале язмышлы Мөхәммәт Шакир Тукаев була. Ул 1917 елгы революция зилзиләләрен үткәреп, 1923 елда Эстәрлебаш мәдрәсәсе ябылгач, НКВД тарафыннан Оренбургка күчерелә. Һәм шунда фәкыйрьлектә, хәерчелектә, юклыкта яшәп, 1933 елгы ачлыкта үлә. Кабере билгесез. Урыны оҗмахта булсын!

* * *

Харис хәзрәт белән Харрас хәзрәт икәүләшеп 1867 елның көзендә фаэтоннарына пар ат җиктереп, Казан шәрифкә дип юлга чыктылар. Максатлары мелла Шиһабетдин бине Баһаветдинне күреп, аның белән сөйләшеп, дөньяви хәлләр турында мәгълүматлар алу иде.

Эстәрлебаш мәдрәсәсенең мөдәррисе Харис бине Нигъмәтулла заманында Казанда да, Бохарада да укып белем эстәп йөргән затлардан. Урыс падишасы Александр II гә ярдәм итеп, аңарга каршы сугышкан кыргыз-кайсакларга барып вәгазь укып, аларның урыска каршы булган фетнәләрен туктаткан Харис хәзрәт ул. Тынычландырган тегеләрне, ак патша белән солых төзеткән. Бары тик үгет-нәсихәт белән генә эш иткән. Ак патша, үзенә эшләгән шул файда өчен, Харис хәзрәткә тархан дәрәҗәсе биргән— аны татар дворяны иткән.

Тархан Харис бине Нигъмәтулла бине Биктимер бине Тукай бине Урманай берәр яры барырга дип юлга чыкса, җигелгән пар атның дугасына өч кыңгырау тактыра торган булган. Юлда ишетелгән шул кыңгырау тавышына каршы очраган барлык олаулар, ат менгәннәр, җәяүлеләр юл читенә чыгып, тукталып тарханга юл бирергә тиеш булганнар. Заманында бабасы ишан Биктимер бине Тукай кулга корал тотып та, баш белән уйлап та урыс җәфасыннан котылу юлларын эзләгән. Ә инде аның әтисе Тукай бине Урманай Казан губернасының Малмыж өязендәге татар халкын урыстан азат итү өчен, чукындыруга каршы корал тотып сугышкан Тукайның әтисе Урманай хәзрәт шул сугышларда һәлак булган. Тукай улы Биктимер мөселман халкына Пугачев яуларына кушылырга кирәк дип язган өндәмәсен дусты, мәшһүр Кинҗә Арслановка биргән. Арсландай йөрәкле бик күп егетләрнең кулына кылыч алдырган ул өндәмә.

Менә инде шул Биктимер ишанның ике оныгы Харис белән Харрас атаклы Казан каласына җитеп киләләр иде. Харис хәзрәт кучеренә исеме белән дәште:

—Әбеннәгыйм энем! Атларга азрак ял биреп ал, биң кума. Казанга барып кергәч инде атларны да, үзеңне дә күрсәтеп алырсың. Безне дә онытып китмә, фаетунның өстен ачарсың.

—Ярар, хәзрәт! Барысын да эшләрмен,—диде калын, көр тавыш белән кучере.—Дер селкетербез Казаннарын. Белсеннәр Эстәрлебашлар килгәнне...

Харис хәзрәт көлеп куйды:

—Тик син инде Казанга кергәч сызгырып җибәрә күрмә. Югыйсә узган ел Ырымбурга кергәндә, сызгырып палисискины куркыткан идең бит. Аннан бүрегеңне басыбрак ки инде. Теге бакыр төсле чәчләрең бик күренеп тормасын читә яннарыңнан. Чәчеңнән таныш табарлар үзеңне аннан соң...

Харис ишан кучеренә һәр чак сокланып карый. Әбеннәгыйм кучер

китап күчереп язучы Госман бабайның оныгы. Әтисе Зәйнулла кырыкка да житмичә агач астында калып һәлак булды. Ятим калган малайны китапчы Госман үзендә асрап үстерде. Чөнки киленен Әнәч авылы мулласы икенче хатынлыкка соратканда, малайның артык икәнлеге беленде. Әнисе кияүгә ике кечкенә кызын ияртеп киткәч, малай Госман картта калды. Тик бабасы күпме генә тырышса да, оныгын үзенең һөнәренә—китап күчереп язуга өйрәтә алмады. Әбеннәгыйм дөньяга килгәндә, ана алтмышы туларга ике генә ел калган иде инде. Оныгы булгангадырмы, әллә инде нәселләрендә бердәнбер малай булгангамы, жирән чәчле ул балага Госман карт бик тә йомшак булды. Кул күтәреп сугу түгел, оныгына каты иттереп тә дәшә белмәде. Шунлыктан, малайны үз иркендә үстерде. Ә малай туганда ук ат жене кагылган бер жан булып чыкты. Арба кендеге кебек чагыннан ук, зурларның ярдәмен дә көтеп тормыйча аждаһадай ажгырып торган айгырларга да менә башлады. Сикерә биреп атның ялыннан ике куллап эләктереп ала да, аягының баш бармагы белән имән бармагын тырпайтып аера биреп атның ботына ябешә. Күз ачып йомганчы ул инде ат өстендә була. Атлары да шул орчык буйлы, жирән чәчле малайны тыңлап кына торалар бит әле. Сука-сабанга да һичкенә дә исе китмәде. Аңа тик ат кына булсын. Унбиш яшеннән яхшы атлы авыл байларына, сәүдәгәрләренә ялланып күчер булып эшли башлады. Инде менә хәзер утыз өч яшендә Эстәрлебаштагы иң тәвәккәл, иң шәп ат белгече, иң дәртле һәм... иң башсыз күчер булып санала. Өч ел гына элек Харис хәзрәтне Уфага алып барырга юлга чыга Әбеннәгыйм. Карадан пар ат жигелгән фаэтон белән. Дугага тарханлык билгесе иттереп өч Валдай кыңгыравы тагылган. Бозаязга житәрәк дугасына дүрт кыңгырау тактырган Уфа губернаторын куып житәләр болар. Губернаторда тройка ат. Әбеннәгыйм, куып житәргә бик аз гына калгач, артына борылып ишанына карый. Анысында да Тукай бабай каны бит, сүзсез генә баш кага. Дилбегә белән генә каккалап, Әбеннәгыйм губернаторны узып та китә. Узып барганда, губернаторның ак пирчәткә кигән йодрыгының һавада селкенгәнен чамалап калалар. Губернаторны саклап, артыннан ат менеп килгән алты казак куа чыга боларны. Харис хәзрәт артларыннан һавага аткан тавышка борылып карый да, көлеп жибәрә:

—И-и, Әбеннәгыйм! Миңа тархан булганлыктан тимәсләр инде. Илләмә сиңа казак камчысы эләгә бит инде!

—Һи-и, хәзрәт! Нык тотын! Төшеп кала күрмә! Хәз-зер беренче үрдә үк ташлап китәбез аларны. Бисмилланы укы да, ныклап тотын да карап кына бар. —Алты чакрымга якын казаклар белән булган араны арттырмыйча да, киметмичә дә тота күчер. Казаклар һавага атып кына туктата алмаганнарын аңлап, фуражкаларының каешын ияк\u0301ләре астыннан кияләр дә, ияр\u0301ләрендә алгарак иелеп утырып атларын камчылый башлыйлар. Әбеннәгыйм астына тыгып куйган каеш чыбыркысын кулына алып, аны шартлаткалап кына, атларын тик дилбегәсе ярдәмендә генә чаптырта. Губернаторның кибиткасы, кучерның атларын чыбыркылавына карамастан бик нык артта кала. Алты казак жепкә тезелгән кебек бер-бер артлы атларын камчылый-камчылый фаэтонны куалар. Тик араларын кыскарта алмыйлар, шулай да исәпләре фаэтонны күздән югалтмыйча Уфага хәтле куу була, ахрысы. Калага кергәч барыбер эләктерәчәкләр. Тар урамнарда иркен ялан юлындагыча чаба алмаслар!

Озын, сөзәк үргә житәләр. Шул өч чакрымга сузылган үргә житкәч Әбеннәгыйм, урыныннан азрак калкынып артына карый да, хәзрәтенә әйтә:

—Бик ныклап тотын хәзрәт абзый! Бу кара йөрәкләргә күрсәтим әле мин татарларның йөгерек шонкарларын!

Әбеннәгыймнең колакларны авырттырганчы ярырлык иттереп сызгырып жибәргәненә ике кара чаптар очкан карлыгачлардай үргә ыргылалар. Фаэтонның тәгәрмәчләре жиргә әллә тия, әллә юк. Атлы казаклар атларын камчылый-камчылый кара тиргә төшереп үрне менеп

житкәндә, татарларның фаэтоннары ерактагы борылышта тузан уйнатып аз гына күренә дә юкка чыга. Юлны ике яклап каплаган урман юлында юк була. Казаклар атларын күпме генә куып карасалар да, тегеләрдән җилләр искән була. Казак урядныгы губернаторның авызыннан ыргылып чыккан өч катлы урыс матын «честь» биргән хәлендә тыңлый. Ачуыннан уртын чәйни-чәйни. Сүгенеп азрак эчен бушаткач, губернатор бите тирләп чыккан урядникка боерык бирә:

—Барлык полицияне аякка бастырырга. Уфаның астын өскә китереп тентергә. Бу тархан Тукаев Харис.Табарга. Ике атны шәһәр файдасына конфискацияләргә! Кучеренә Ратуша мәйданында утыз камчы сугарга.

Урядник бик тырыш казак санала. Җаваплый:

—Слушаюсь, ваше превосходительство! Сам буду бить гололобого Мамая. Сам!

Тик губернаторның боерыгы үтәлмичә кала. Бик тырышып карасалар да. Шул көнне үк Уфадан чыккан барлык юлларны ябып, үткән-сүткәнне тикшерүләр башлана. Уфа эчендә шәһәр урамнарының чатларына кылычлы жандармнар бастырып куялар. Тентүләр китә татарларның йортларында. Өйләргә кереп иснәнеп йөрүчеләр дә күбәя. Тик тырышулары бушка була.

Губернаторны мәсхәрәләп үтеп киткәнгә ике көн дигәндә, ап-ак пар ат җигелгән бердәнбер тарантас Уфадан чыгып, Эстәрлетамак юлы белән келтер-келтер тавышлар чыгарып тәгәри. Кара төстәге ике атны конфискацияләргә боерык алган полиция офицеры ул ак атлар җигелгән тарантасны туктатып та тормый. Өстәвенә, салам эшләпә кигән кучеренең чәчләре дә кап-кара, ә бакыр төсендә түгел. Кучер атларын кабаланмый гына юыртып үтеп бара. Үзе тыныч. Татарга ошамаган да. Битендә бер бөртек сакал-мыекка дигән йоны да юк. Евнух кебек бернәрсә шунда. Офицер иренеп кенә шундый уйларга бирелеп озатып кала тарантасны.

Эстәрлетамакны үтеп Кала Утары дип йөртелгән утарга житәрәк күчер татантаста утырган урысчарак иттереп киенгән хуҗасына борыла:

—Туктыйк, хәзрәт, Эстәрлесу буенда. Син чапан-чалмаларыңны киенеп, тәһарәтләнеп намазыңны укыганчы, мин атларны үз төсләренә кертеп алыйм инде. Югыйсә авыл халкы көләр бездән.

Харис хәзрәт тарантастан көлә-көлә төшә. Үзенә ярдәм иткән Әбеннәгыймнең бөеренә йодрыгы белән шаяртып төртә:

—Шайтансың дисәм, коерыгың юк, Әбеннәгыйм энем. Ай-һа-ай! Бу ике көн эчендә минем йөрәкне әллә нәрсәләр эшләтеп бетердең бит син. Синең коткыга бирелеп, ул губирнатырны узарга ризалашкан мин дә юләр инде. Бала-чага кебек бит икебез дә. Ул атларны катыкка буяп, төне буена киптереп, ак төстәге атлар итәргә ничек башыңа керде синең, ә?

—Мин уйлап чыгарган нәрсә түгел инде. Ат каракларының ысулы ул. Тик алар кыш кулланганнар бу ысулны. Буйый барганнар, туңа барган. Артларыннан куа килгәннәргә каршы юлга чыкканнар да, үткәннәр дә киткәннәр. Без киптереп байтак азапландык шул...

Үзе сөйләнә-сөйләнә атларын тугарды да, бер-бер артлы елгага алып кереп мунчалалап юарга тотынды. Атлар актан карага әйләнә башладылар. Харис хәзрәт киная белән тагын көлде:

—Мунчаласын каян алдың инде тагын?

—Синең дус Галләметдин байның ишек алдын караучы Ибраһим абзый минем дус бит. Шул тыкты юлга дип. Аның белән икәү буядык та инде атларны төне буена катык белән.

—Ә чәчеңне кай арада буяп өлгердең инде?

—Анысын инде Ибраһим абзыйның хатыны Миңлебәһәр җиңги басма белән буяп каралтты. Көзгегә карагач куркып киттем үземне күреп—гөрҗи дә гөрҗи, мин дә тач шул гөрҗи инде. Бүген кайту белән кырдырам чәчне. Иң шәбе үземнең бакыр төсе—чәч өчен дә, сакал-мыекка да...

Барлык Уфа губернасына тарала тархан Харис Тукаев белән аның җирән чәчле күчеренең даннары. Елга якын кеше теленнән төшмиләр:

«Әстәрледән Уфага барганда Харис тархан губернаторны куып житкән дә, күчеренә губернаторны узып китәргә кушкан. Тегесенә шул гына кирәк тә бит инде. Харис хәзрәт әйткән тегенәргә: «Узып китеп, кугач тоттырмасаң, бер сыерлык акча сиңа!» Узып киткән дә, ташлап та киткән тегеләрне. Губернаторны озатып барган бер взвод казак куган, тик житә алмаганнар. Уфадан чыгу юлларын бер атна саклаганнар, качкыннарны эләктерү максаты белән. Атна узгач, Эстәрлебаштан Харис хәзрәт губернаторга хәбәр иттергән: «Безнең кайтканга бишенче көн тулды инде»,—дип. Ә ай тулуга Харис тарханга губернатордан полиция приставы килеп төшә. Озын чибәр мыегын бөтерә-бөтерә тарханга губернаторның теләк-боерыгын житкерә:

—Губернатор галижәнапләре атларыңны сатып алырга боерык биреп мине жибәрде. Сат. Әгәр сатмасаң, сәүдә эшләреңә губернатор комачау ясаячак.

Хәзрәт озак уйлап тормый, Әбеннәгыймне чакыртып кертә. Приставның ни өчен килгәнлеген сөйләп бирә. Ишек төбеннән узмыйча гына тыңлаган күчер кулын селтәп кәлә генә:

—Сат, сат хәзрәт! Миннән саттыр. Хакын шәп каерырмын мин аның.

Моңарчы урысчалап кына сукалаган пристав саф татарча әйтеп ташлый:

—Губернатор күпме генә сорасагыз да, шуны түләргә кушты.

Елмаеп өсти:

—Бик гарьләнгән губернатор. Тархан булмасаң бетергән булыр иде, тик сиңа көче житми.

Хәзрәт белән күчер приставны авыл уртасындагы Таш күпер янына кадәр озата чыгалар. Пристав үзе ияртеп килгән дүрт полицейский белән сулга борылып кала юлына чыгып күздән югалгач, Әбеннәгыйм хәзрәтенә әйтә:

—Син хәзрәт бурлы бия белән бер трантасыңны бир инде миңа. Акчаны да яхшы гына иттереп бир. Мин китим чыгып казакълар ягына. Тургай далаларына. Тагын ике йөгерек ат алып кайтыйм. Тегеләреннән дә шәбрәк булырлар. Бәлки төсләре карадан булмас, иллә мәгәр йөгерек булырлар.

Атлар сатылганга ике ай чамасы вакыт үтүгә, жирән сакал-мыек баскан, казакъ якларында ит ашап, кымыз эчеп шомарып тазарган Әбеннәгыйм ике алмачуар ат алып кайта. Икесе дә печтермәгән өч яшьлек айгырлар. Пошкырганда, борын тишекләреннән ут көлтәләре очкан кебек булып биеп торалар. Үзләре оча торган шоңкарга охшаганнар. Ат жене күчереннән хәзрәтенә дә күчә башлаган. Атларны күргәч, Харис тархан өнсез кала. Атлар тирәсендә байтак уранып йөргәч кенә телгә килә:

—Сөбханалла, Әбеннәгыйм энем! Сөбханалла! Тфү-тфү. Күз тия күрмәсен—ялларына кызыл чүпрәк бәйләп куй. Бисмилла иррахман иррахиим! Ходай Тәгаләгә биргәненә мең шөкерләрем. Жинел аяклары белән, игелекле булып керсеннәр бу йортка, хәйванкайлар...

Айгырларны печтереп, жәрәхәтләре төзәлгәч Әбеннәгыйм аларны көзен, кышын яхшы иттереп парлап фаэтонга, жиңел чанага жигеп йөрергә өйрәтте. Икенче жәйне Эстәрлетамакта бер атна яшәделәр губернаторның килгәнен көтеп. Көткән, морадына житкән, ди. Губернатор, Эстәрлетамакка килеп өч көн узгач, тагын Уфага кайтырга чыга. Тархан утырган фаэтон тагын губернаторны узып китә. Губернатор тарханнан алган ике кара ат жигелгән сыгылма рессорлы бик купшы тарантаска утырган була. Әбеннәгыймне казакъ урядникгы танып ала да, губернаторга әйтә:

—Ваше высокоблагородие! Опять этот рыжий шайтан с новыми лошадьми на обгон идет.

Губернатор жавап бирми. Тарханның фаэтоны үзен узып киткәндә, юлның икенче ягына карап кала губернатор. Атларын сатып алырга дип икенчегә татарча сукалаган приставын да жибәрми...

... Шул ике алмачуар алаша җигелгән фаэтонда Эстәрлебаш авылының ике хәзрәте Казанга килеп керделәр. Түгәрәк кара кырпы бүрек, җилән кигән ике чибәр хәзрәт утырган, пар алмачуар җигелгән фаэтон Казан каласыннан таш урамнары буйлап тәгәри. Заманында икесе дә Эстәрлебаш мәдрәсәсеннән соң икешәр ел Казанда белем алганнар. Аннан соң шәкерт булып Бохара Шәрифкә сәфәр кылып, шунда белем эстәгәннәр. Бохараи Шәрифтә дәрес алган остазлары бер үк галимнәр—Габделмөэмин Хуҗа, Мелла Хәсән, Ниязетдин һәм Мелла Фазул әл-Гиҗуанилар хозурында гыйлем заһир алып шөгыльләнгәннәр. Харис хәзрәт Шиһабетдин хәзрәтне якыннан күреп, сөйләшеп утыру бәхетенә беренче тапкыр ирешәчәк. Ә энесе Харрас Шиһабетдин хәзрәтне яхшы белә. Хәзрәтнең бер туган энесе Садретдин белән Кабан күле мәдрәсәсендә ике ел бергә укыганнар. Кабан күле мәдрәсәсеннән соң Бохарада да бергә булганнар. Бохараи Шәриф мәдрәсәсен тәмамлагач юллары аерыла. Садретдин Казан каласына, ә Харрас Эстәрлебашка кайтып китә.

Абыйсы Харис та, энесе Харрас та икесе дә галим-голәмә булып, зур гыйлемгә ия булып, илләрендә ихтирам казандылар, дөньялары киң, шәкертләре күп булды. Башкорт ягындагы хәзрәтләрнең бәяләве буенча, Харис хәзрәт тә, Харрас хәзрәт тә гыйлем ягыннан аталары Нигъмәтулла хәзрәт дәрәҗәсендә иделәр.

Казанның урамнарын узып, Кабан күленә якынлаша башлагач Харис хәзрәт үз алдына гына сөйләгәндәй әйтеп куйды:

—Казан бик нык урыслашкан кала шул. Татарлык, мөселманлык Кабан күленең теге ягында гына инде, Татар бистәләрендә генә...

Шиһабетдин хәзрәт тә, энесе Садретдин да Башкорт ягыннан килгән кунакларны ачык йөз, юмартлык күрсәтеп каршы алдылар. Шиһабетдин хәзрәтнең ике катлы зур йорты Кабан күленә якын ук салынган. Аскы каты кирпечтән, ә өске каты юан карагай бүрәнәләрдән бик оста иттереп эшләнгән. Ике катында да, урам якка да һәм ишек алдына да караган бишәр тәрәзә уелган. Өске катның тәрәзәләре аскы катныкыннан зурраклар. Өй эчендә өч мич. Бүлмәләре зур—якты, яшәр өчен бик җайлы итеп эшләнгәннәр. Бүлмәләр саны алтаудыр. Җиденчесе, аш пешерә торганы, беренче катта кергән уңайга ук бүленеп куелган. Шунда ук тәһарәт ала торган бер почмак чыбылдык белән бүленгән.

Шиһабетдин хәзрәт үзе дә яхшы балта остасы икән һәм йортын салган вакытта үзе дә кулына балта тотып күп көч сарыф иткән булган.

Атларны урам аша урнашкан ике катлы йортка куйдылар. Күчер Әбеннәгыйм дә шунда яшәде. Йорт хуҗасы Мәүлетдин исемле урта кул сәүдәгәр икән. Мәүлетдин йортыннан такта койма белән аерылып, Шиһабетдин хәзрәт мөдәррислек иткән ике катлы кирпеч мәдрәсә урнашкан. Анда йөз илледән артыграк шәкерт белем алалар икән дә, шунда ук яшиләр дә икән. Шул мәдрәсәдән ерак түгел, Кабан күленең ярында утырган тагын бер мәдрәсәне карадылар. Дәресләрдә булдылар. Ул мәдрәсә дә җыйнак, шулай ук кирпечтән ике катлы итеп салынган, эче якты-иркен, шәкертләре тыйнак, укуга хирыс күренделәр.

Казан мәчетләрендә, мәдрәсәләрендә, кичләрен татар байларында ашта йөреп өч көннәре үтте. Шуннан соң Шиһабетдин хәзрәт Харис белән Харрасны татар балаларын урысча укыта торган Учителски школа дигән уку йортына алып китте. Аны татарлар ышкул диләр икән. Шунда килеп кергән уңайга ук бер татарга тап булдылар. Чандыр гәүдәле, кырма сакал-мыеклы, азрак озынчарак йөзле, бик ныклы дикъкать белән тынлый белә торган зат булып чыкты. Шиһабетдинне күргәч, аның йөзе яктырып китте. Сәламләде:

—Әссәламмәгаләйкем, Шиһабетдин абзый! Исәнлек-иминлек телим сезләргә! Сөбханалла, таныш түгелләр кунакларммы әллә?!

—Вәгаләйкем әссәлам, Каюм энем! Үзең исән-иминсеңме соң?!

—Аллага шөкер! Сезләрнең хәер-фатихасы белән яшәп ятабыз әлегә. Киләчәге бер Ходай кулында!

Шиһабетдин кунакларга әйтте:

—Таныш булыгыз, Каюм Насыйри дигән галимебез була. Бик тәүфыйклы, бик тә белемле, тырыш зат. Татар халкына белем бирүдә, аны зыялы итүдә бик ныклап көч сарыф итүчеләрнең берседер...

Аннары Каюм Насыйрига борылды:

—Бу затлы кунаклар башкорт ягыннан. Мәшһүр Урманай әл-Салавыч токымыннан. Икесе дә. Шуның улы Тукай бабай оныгы Нигъмәтулла ишан уллары. Нәселләре белән бик укымышлылар. Олысы Мөхәммәт Харис хәзрәт, энесе Харрас хәзрәт. Олысы Эстәрлебаш мәдрәсәсендә мөдәррис, кечесе мәчетендә ишан. Икесе дә Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыталар. Харис хәзрәт патша галиҗәнапләре тарафыннан тарханлык алган зат...

Бергәләп ышкулның уку бүлмәләрен карап йөределәр. Бер бүлмәдә кәләпүшле ике татар малае алмашлап, бик тә тырышып урысларның Лев Толстой дигән графларыннан балалар өчен язылган «Дуб и орешник» дигән хикәясен укыдылар. Китапларын ябып куеп, укыганнарын урысчалатып сөйләп тә бирделәр. Тик берсе азрак сакаурак кына иде. Ләкин ике хәзрәтнең дә урысчалары чамалы иде шул. Шунлыктан ят телдә укый да, сөйли дә белгән татар малайларына икесе дә сәерсенеп тә, гаҗәпләнеп тә, бу урыс укуы без татарга нәмәстәмә хаҗәт инде дигән уй белән карап, дәшми-тынмый гына утырдылар.

Ышкулдан чыгар алдыннан Шиһабетдин хәзрәт, сөйләшәсе сүз бар дип, Каюм Насыйрине дә үзенә чакырды. Дуртәүләшеп, үзләренең дәрәҗәләрен белеп хәзрәтнең өе тарафына атладылар.

Кайтып җиткәч, дуртесе дә тәһарәт алып, ният кылып намазлыклар өстенә бастылар. Намаздан соң озак кына гәп корып утырдылар. Харис хәзрәт Шиһабетдин белән Каюмга үзен нык борчыган сорауны бирде:

—Хәзрәтләр! Сез инде икегез дә зур гыйлемле, баш белән эш итеп тормышта күпне җиренә җиткереп яшәгән затларсыз. Менә без энем Харрас белән бергәлектә, сезгә ияреп, мөселман-татар балаларын урысча укыткан ышкулга бардык. Укуларын сөйләгәннәрен бик үк аңлап бетермәсәк тә тыңладык та, карадык та инде. Хәзер инде уйга төштек: урысча уку белән безнең мөсел балаларына башка төрле, кяферләрчә тел ачкычы биреп, аларның... э-э-э... теге ялан ботлы марҗалары белән аралашып, урыслашып китәргә без үзебез ярдәм итмибезме икән?..

Мөхәммәт Харис хәзрәтнең сөйләгәнен табында зур игътибар белән тыңладылар. Садретдин сак кына хәрәкәт итеп чәй ясый. Харис хәзрәт эчтәге борчылуын тышка чыгармыйча гына дәвам итте:

—Урыс марҗасы бар җирдә пөхтәлек, әхлаклык бетә. Иман бетә, тыйнаклык юкка чыга. Тән күрсәтеп, мөселман ирләрен аздырырга марҗалар бик тә маһирлар. Гасырлар буена хәмер чөмергән урыс ирләренең җенси яктан көч-дарманнары бик зәгыйфь, безнең мөселман ирләрендә булган җенси куәт аларда юк дәрәҗәдә. Аллага мең шөкер, ул шулай булып калачак та. Ә марҗалар урысча укырга, сөйләшергә өйрәнгән татарлардан урыс ясаячаклар. Аларга җенси яктан көчле татарлар кирәк бит. Менә шундый шик туды бездә.

Монысы бер булды. Икенчедән. Урысча уку безнең ислам дине буенча гөнаһ ясау түгелме? Мин менә тыңлап утырдым ике баланың урысча укыганын. Колакка ятышлы тел түгел инде. Сүзләренең әйтелеше дә, яңгыравы да. Урысның гореф-гадәтләре, аларның яшәеш кануннары безнең мөселманнарның дөньясына басып керүе бик ихтимал. Инде урыс астында өч йөз елдан артык иза чигәбез. Кистеләр дә безне, астылар да, суйдылар да безне, чукындырдылар да безне. Җиребезне тартып алдылар, динебезне тыйдылар. Әле дә шулай бара. Без менә энем Мөхәммәт Харрас белән, килгәч-килгәч карап чыгыйк дип, каланың бик матур бер бакчасына керергә булдык. Кичәгенәк. Кылычлы, итекле, мыеклы җандар кертмәде бакчага безне. Этләргә, татарларга кала бакчаларына керергә ярамый икән дә, губирнаторларының боерыгы шундый икән Казанда...

Шул дөрес буламы инде?! Ә?

Шиһабетдин җавабында болай диде:

—Дөрес сөйлисең хәзрәт! Урыс кертми безне бакчаларга. Анынча, кертмәү дөрес була. Ул басып кергән бит безнең җиргә. Ул гаспадин...

—Соң, шулай булгач?! Ул гаспадин булган урыс теленең безгә нәрсәгә хаҗәте бар. Сез монда, Казанда яшәп, урыс белән аралашып, дөньяви хәлләрне бездән ныграк беләсез, яхшырак аңлыйсыз. Безгә, туган яклардан аерылып башкорт ягында яшәгән татарларга аңлатып бирегез әле—нәрсәгә безгә ул кяферләр теле?

Шиһабетдин белән Каюм бер-берсенә карашып, аңлашып алдылар.

—Син сөйлә инде, Шиһабетдин абзый! Синдә ышандыра белү көче ныграк.

—Ярар алайса!—диде хәзрәт ялындырмыйча.—Аңлатып карыйк сезләргә.

Ул сакал-мыегын сыпыргалап алды, акрын гына йөткергәндәй иттереп тамак төбен кыргалады да сүз башлады.

—Бөтен Аурупада, Әмирикта бик нык итеп фән белән шөгыльләнәләр. Кеше хезмәтен җиңеләйтә торган төрле-төрле эш кораллары җитештерәләр, тукымалар ясый торган махсус корылмалар уйлап чыгаралар. Аларны машиналар, стануклар диләр. Әмирикләрдә ат җигеп тарттырып иген чәчәләр, үсеп өлгергәч шулай ук ат көче белән уралар, пар белән эшли торган машина ярдәмендә көлтәләр сугалар. Машина, стануkларны җитештерү сәнәгать дип атала. Җир өстеннән сузган ике тимер өстеннән тәгәрәп йөри торган арба уйлап чыгарганнар. Миче дә шул тимер юл өстендә, тәгәрмәчле арбасы да. Кешеләр шуңа утырып ерак юлга чыгалар икән. Сезнең кебек ат җигеп чыкмыйлар. Шул нәстәне урысча паравыз, диләр. Тукыма суга торган стануклар бик күп эшләнә аларда...

Харрас кыска гына итеп көлеп куйды:

—Аларның паравызы безнеңчә пәрәвез дигән кебек бит...

Шиһабетдин уң кулын күтәрә бирде:

—Суда йөзә торган караблары да пар белән эшли торган машиналар ярдәмендә йөриләр. Ишкәк тә кирәкми, җилкән дә кирәкми, караб җилгә каршы да йөзә, агымга каршы да йөзә. Урыс хәзер Аурупадан өйрәнеп завод фабрикаларын күпләп сала. Фәнгә ия була, көч ала.

Яңа заманалар килә, яңа көчләр туа башлады Дөньяда. Без татарлар да шул дөньяви таләпләрдән артта калмаска тиешбез. Һәм ислам дине безгә алга барышта комачау итмичә, ярдәм итәргә тиеш. Ходай Тәгаләнең кодрәте киң, көчле. Ә без татарлар гыйлемгә бик тә хирыс халык. Вә ләкин без урыс тарафыннан яулап алынган, ирегебездән мәхрүм ителгән халыкбыз. Үзебезнең дәүләтебез дә, патшабыз да, ханыбыз да, элекке замандагы кебек чын бәкләребез дә, морзаларыбыз да юклар. Бүгенге көнне булганнарының күпчелеге сатлыклар. Татар халкының язмышы урыс кулында. Дөрес әйттегез—урыс хәмерче, ялкау. Эшне дә бик яратып, өнәп бетерми. Вә ләкин...

Шиһабетдин хәзрәткә сөйләве авыр иде. Ходай тарафыннан бирелгән зиһене, акылы белән бу зат әллә ничәмә-ничә миллионлы мөселман дөньясында бер генә кеше дә аңламаганны иң беренче булып аңлап, шуны татар халкына җиткерү теләге белән яна иде. Кадим карашлы мулла-ишаннар ахун-шәехләр, Коръән Кәрим аятьләренә генә таянып, теш-тырнаклары белән Шиһабетдин хәзрәтнең яңа карашларына каршы чыгып, аны мәдрәсәсез, мәчетсез калдырып, безне урыска сата дип исемен пычратып, үзен юк итеп бетерә яздылар. Татар халкына гомере буена аңбелем биреп, аның акылын агартуда армый-талмый эшләр башкарып, бик күп авырлыклар күргән шәхес иде хәзрәте Шиһабетдин Мәрҗани. Дингә акча эшләү, мал табу кәсебе итеп кенә карап, сәдака акчасы җыйнап байлык туплаган мулла-ишаннар яңача фикер йөртеп, шуны халыкка җиткерү юлында куркуны белмичә вәгазьләр укып, урыс телен татар тормышында корал итүдә күп эш башкарган хәзрәт, ерак араны

якын итеп килгән кунакларга үз фикерләрен житкерергә тырышты.

—Синең фикерләвеңдә дөреслек бар, Харис хәзрәт. Урысча белгәннәр маржалар белән сөйләшеп аралашачаклар. Вә ләкин инсафлы, тәне дә, күңеле дә пакь, үзе эшчән татар кызы белән маржаны чагыштыру һәрчак безнең мөселман кызлары файдасына булачак. Һәм без үзебез дә, олы яшьләрдәге бабайлар, карчыклар, муллаларыбыз, ишаннарыбыз, ата-аналар шул хакта сөйләргә, яшьләргә житкерергә, аңлатырга тиешбез. Урыс кул астында яшәп, татар булып, мөселман итеп халкыбызны саклап алып калу өчен безгә дә урыс белгәнне белү фарыздыр. Кылган зур гөнаһларыбыз өчен, үзебезнең ханнарыбызны санга сукмыйча: читтән ханнар китерткәнебез өчен, узара уртаклык таба алмыйча низагъ белән яшәгәнебез өчен, морзаларыбыз халыкны урыска каршы сугышка әйдәү урынына, шул ук урыска сатылганнары өчен, Ходай Тәгалә безне урыс карамагына биргән дә инде. Үзегезчә, мөселманча матур итеп яши белмисез икән, кяфер кул астында, кяфердән калганны гына ашап, аның искесен генә киенеп яшәп карасын әле бу татар мөселманы дип, карар кылгандыр Ходай. Хәзерге көннәрдә дә бездән өметен өзеп.

... Инде урысча уку хакында. Мөхтәрәм кунакларым Казан каласын алырга дип килгәндә урысларның дарылары да күп булган, туплары да безнең туплардан камилрәк булганнар, мылтыклары да күп булган. Дошманга каршы сугышыр өчен синең коралың аныкыннан шәбрәк булырга тиеш. Һич югында аныкы кебек булсын...

Харис хәзрәт сорады:

—Син хәзрәт урысны әле дә дошман дип уйлыйсың булыр...

Шиһабетдин кашлары астыннан тиз генә Харискa карап алды. Сөйләү юлын үзгәртте.

—Безнең төп бурычыбыз халкыбызга аң-белем биреп, аның зиһенен эшләтүдер. Бу дошман, теге дошман түгел дип фикер йөретү диндарлар эше түгел. Кеше үзе ачыклап үз акылы белән белер дошманын да, дустын да. Соравың җавапсыз калмасын өчен мин шуны әйтәм сина: бер туктаусыз хәмер белән мавыгып, эштә ялкаулык күрсәтеп яшәүче халыкның киләчәге караңгылыкта, наданлыкта, хәерчелектә узачак. Урыс халкы барлык башка халыкларга караганда да иң бәхетсез халык ул. Сәбәпләре күп аның шулай булуында. Шулар арасында, минемчә, өчесе иң мөһимнәрдәндер. Беренчедән, урыс хәмерне бик күпләп һәм көн саен эчә. Шунлыктан аңарда табигать биргән кешелек дигән сыйфат бозыла. Без мөселман аны иман дибез. Урыста андый сүз юк та ул. Кабан күленең, Болакның теге ягына чыгып, Суконный дип аталмыш урыслар яшәгән урамнарны кичкырын йөреп чыгып, карап кайтыгыз. Садретдин энем алып барыр, алып кайтыр. Анда яшәгән урыслар беләләр аны. Шунлыктан тимәсләр сезгә. Анда исерекләрнең нindиләре генә юк! Сүгенү, акыру-бакыруны, сугышуны-әйткән дә юк! Баштан ашкан алар анда. Сүзләрен аңлап бетермәсәгез дә, сүгенүләренең әшәкелеген, сасылыгын ишетерсез, иснәрсез.

Икенче сәбәбе. Урысларның православие дип аталмыш диннәре безнең Ислам дине кебек саф, пакь түгел. Православие динендә булган кеше дип әйтик инде, хәтта баю максаты белән дә башка берәүне үтереп ташлады ди. Баеды да ди. Диннәре буенча шул гөнаһын бетереп юк итә ала ул...

—Ничекләр иттереп?

—Чиркәүгә бара. Бик зурдан шәм куя. Чиркәү эчендә сатып алып. Попка акча түли дә, үзенең нинди гөнаһ эшләгәнен аңарга гына әйтә. Поп шул гөнаһын кичереп дога укый. Монысы аңа акча түли. Теге гөнаһсыз булып чиркәүдән чыга да, тагын кеше үтерә. Тагын бара чиркәүгә. Тагын шәм куя, попка акча тоттыра. Пакьлана, гөнаһы бетә...

—И-и, бик ансат икән алай булгач урысларга яшәүләре!..

—Без, Казан мөселманнары өч йөз елдан артык урыс астында яшәп динебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне, эшчәнлегебезне югалтмаганбыз икән, иншалла, вакыты житәр—котылырбыз бу коллыктан. Авылларыбызда,

иншалла, мәчет-мәдрәсәләребез бик тә ишәйделәр. Балаларыбыз гарәпчә хәреф кулланып, татарча укый-яза беләләр. Әнә шул мин әйткән өч төп сәбәп һәр сәгатьне, һәр көнне безнең файдага эшлиләр. Кылган гөнаһларыбыз өчен Ходай Тәгалә тарафыннан без колларына тәгаенләнгән җәза вакыты үтеп китәр. Әнә шул заманда инде без үзебезчә дә, аларча да аңбелемле, гыйлемле, сөйләшү-аңлашу өчен кимендә ике телле халык булырга тиешбез. Татарча да, урысча да һәм тагын да Аурупадагыларнын да бирәр телен, әйтик, инглиз телен белергә тиешбез. Ипи-тозлык кына булса да.

Абыйсының холкын, гадәтләрен яхшы белгән Садретдин аңарга кайнар чәй ясап бирде. Кунакларны да карады, онытмады. Харис белән Харрас ишеткәннәрен башларына сыйдыра алмыйча утыралар иде. Аларда чәй кайгысы да онытылды. Шиһабетдин хәзрәт елмаю тулы күзләре белән икесенә дә караштыргалап алды да, сорады:

—Харис абзый! Сезнең Тукай бабай нәселенең башкорт ягында җир-байлыгы бик зурдан дип ишетәбез. Шул чынмы?

—Ходайның биргәненә мең шөкер. Бар җирләребез. Җитәрлек дияргә ныклы итеп әйтеп була.

—Безнең хәбәрләр буенча сезләр бик күпләп каты бодай үстереп, шуны карабларга төяп Агыйдел, Кама елгалары белән Иделгә чыгарып, Сары Чин шәһәренә ташыйсыз икән. Аннан соң Дон елгасына олаулар белән күчереп, Ростовта тагын карабларга төяп итальяннарга озатасыз икән, шулай бит?

—Шулай. Дөрес бар да.

—Менә шул чакта, Эстәрлетамакта баржыларга төйи башлаганнан алып, Ростов каласында итальян сәүдәгәрләренә сатканчы татарчадан урысчага тәрҗемә иткән тылмачларга күпме түлисез?

—Күпме түлисез дип инде, алай уптым санаган юк. Илләмә дә күп каералар инде. Сәгатьләп түләтәләр.

—Шулай да, чама белән булса да әйтеп кара инде.

—Көнләп ялласаң, көненә бер яхшы гына ат алырлык акча китә. Ә инде теге урысчалап язып кыягазлар тутырырга булса, тагын да күбрәк.

—Ә үзебезнең татар прикашигың урысча яза белсә, сөйләшә белсә?

—И-и-и, андыйны каян аласың инде аны безнең авыл җирендә. Юк бит алар!

Мәрҗани хәзрәт шатланып елмайды:

—Үзегез укытыгыз!

Харис хәзрәт күңелсез генә кул селтәде:

—Үзем белмәгән урысчаны мин ничекләр иттереп укытыйм инде?

Шиһабетдин хәзрәт белән Каюм Насыйри бер-берсенә карап елмаештылар. Каюм да сүзгә катнашты:

—Менә сез бүген урысчага укыткан ышкулны күрдегез инде. Шуны тәмамлап, урыс-татар арасында тылмач булып йөргән берничә егетебез дә бар инде безнең. Алар безнең татарга урысча укыту кирәклекне башлары белән дә, йөрәкләре белән дә аңлап эш кылалар. Шулай арасыннан берсен Эстәрлебашка барып яшәп урысча укытырга күндереп булыр дип уйлыйм мин. Урысча мәктәп оештырыр да, укытыр да. Син, хәзрәт, ничек уйлыйсың?

—Минеке билгеле инде,—диде Шиһабетдин.—Шуның өчен көнтөн Казан муллалары арасында ызгыш-талаш бара да бит инде. Хуплыйм сүзләреңне, Каюм энем. Табарбыз урысча укыта торган егетне. Тик менә кунаклар нәрсә әйтерләр бит әле. Авылларында урыс ышкулы ачу турында диюем.

—Соң без нәрсә дибез инде. Сезнең уйларны, фикерләрне тыңлагач, баш нәрсә уйларга да аптырап тора. Шулай да яңа уйлар туа бугай. Чыннан да яшәеш өчен дә, сәнәгать өчен дә, сәүдә өчен дә урыс теле бик нык кирәк безгә. Ул турыда бәхәсләшеп торуның кирәге дә юк. Тик менә безгә бара торган егетегез риза булырмы икән дә, безләргә аны күреп сөйләшү мөмкин булырмы икән?

—Ә авылыгыздагы мулла-хәлфәләрегез, авыл-мәчет картлары нәрсә әйтерләр ул турыда? Аны да уйлагыз. Безнең Казанда булып Казанда да бик каты каршылыклар белән бара әле урысча укыту.

—Арттан быкылдаучылар булыр анысы булуын. Тик безгә, Тукайларга каршы чыгучылар булмаячак. Безнең абруй мәдрәсә-мәсчетләрдә дә, халык арасында да бик зурдан. Ә кара, укымаган халыкка аңарга барыбер. Ул ышкулны күрмәс тә әле ул. Тамак кайгысы көчле аңарда. Ә авылнын ярлы-ябагае безнең жирләрдә иген игеп, мал үрчетеп, эшләп тамак туйдыра. Шунлыктан холкы тыныч. Аллага мең шөкер, эшләсен дип сәләт вә көч биргән безнең халыкка. Укытырга тәгаен кешегез белән очрашыйк, сөйләшик. Байлыгыбыз бар, ул урыс ышкулын тота алырбыз без. Үзебезнең балалар өчен бит. Татар өчен, сәүдә өчен...

* * *

Гайсә пәйгамбәрнең тууына 1891 ел дигәндә килгән кыш үзе белән зәмһәрир суыклар һәм ачлык алып килде. Кара яздан алып, жәй буена чат аяз күк йөзеннән бер генә тамчы яңгыр да төшмәде. Жир өсте тоташы белән көйде. Гыйнвар азакларында татар авылларында ачлык хөкем сөрә башлады.

Эстәрлебаш кешесе авылча, Зәйнетдин Балта базардан кайтты да, ишек төбенә сөялеп куелган челек себеркесе белән чабаталарындагы карны суккалап, себереп төшерде. Билбавына кыстырган балтасын кулына алып, өй ишегеп ачты. Бу тирәләрдә февраль-март бураннары башланса, авыл урамнарын, йорт-каралтыларны, читән-коймаларны кар көртләре басып китәләр. Күп вакытта ул кар көртләре өйләрнең түбәләренә кадәр менеп житәләр. Шунлыктан өйдән ишек алдына чыга торган ишекләр барысы да эчкә ачыла торган иттереп эшләнгәннәр.

Нечкә генә бүрәнәләрдән салынган кечкенә өй жылыны начар тота. Шунлыктан Зәйнетдин көздән үк өйнең нигезен салам китереп жылыта, кыш көннәрендә котып ягыннан искән жилләрдән аз гына булса да ышык булсын дип алар өстенә карлар өя. Ә өй эчендә жылы барыбер начар саклана. Аннан соң утын яклары да бик мулдан түгел.

Кергән иренә хатыны Мәрфуга күтәрелеп карады да, кулындагы тегүен сәкегә куеп урыныннан торды.

—Өшегәнсендер инде, әй! Тизрәк чишен дә, әнә, мичкә арканны терәп сәкедә утырып тор. Син алып кайтмаган булсаң, ашарга бернәрсә дә юк. Бетүгә табан барабыз инде, әй Алла!

Зәйнетдин хатынына жавап бирмичә генә куеныннан ирләр түбәтәе хәтлек кенә кап-кара төстәге түгәрәк ипи чыгарды. Утыру өчен көйләнгән түмәрне сәке астыннан тартып алып, ипине балтасы белән чабып икегә бүлде.

—Тукта, пычак белән кисик. Балта белән ипигә чабу гөнаһ була бит,—дип Мәрфугасы мич янына пычак алырга ашыкты.

—Туңган ипи ул. Пычак алырлык түгел аны. Турмайдан Насыйр абзый алып килгән—сату итә. Алабута белән арыш көрпәсе, элмә агачы кайрысы кушып салган ипи икән. Үзе дәште миңа. Зәйнетдин энем, ди, мә берсен ал, ди. Акчаң юктыр инде, бирәр жае чыккач бирерсең әле, дөнья бит, ди. Алдым инде, нәрсә эшләмәк кирәк. Яхшы кеше үзе бирел торгач. Түләрмен, иншалла.

Үзе сөйләгән арада ипине чапкалап ваклады да, өч кисәген алып, мич башыннан карап яткан малайларына табан борылды. Мич башында, чыбылдык кебегрәк иттереп асып куелган чәчкәле ситса чаршау астыннан өч малайның башлары күренә иде. Малайларның ач икәнлеге күзләренә чыккан. Тик сабыр гына, дәшмичә әтиләренә караган килеш, түземсезлек күрсәтмичә карап кына яталар. Зурысы сигез яшендә. Исеме—Хәйрулла. Аннан ике яшькә кечерәге Лотфулла. Иң кечесе, өч яшьлеге, Гатаулла

исемле. Аталарыныкына ошап Хәйрулла белән Гатаулланың чәчләре бакыр төслеләр. Күзләре дә әтиләренеке кебек коңгыртлар. Ә Лотфулла әниләренә охшаган—акка тартымрак сары чәчле, кылыч борынлы, зәңгәр күзле. Борынының сул ягында, танау тишегеннән аз гына өстәрәк, нәкъ әнисенеке кебек кечкенә бер миңе дә бар. Зәйнетдиннең дусты, күршеләре Әхмәт Кадыйр аңардан көләргә ярата:

—Син, дус кеше, хатының Гөлмәрфуга белән эшегезне җайга салып алдыгыз! Малайларны берәү аша аралаштырып әле берегезгә, әле икенчегезгә охшатып дөньяга китерәсез. Берсе җирән, берсе сары.

Үзе җылы көнчелек белән янган күзләрен кызыл, сары чәчле малайлардан ала алмый. Үзенең «авырткан җирен» аз гына күршесенә күрсәтеп тә куя:

—Минем хатын кыздан башканы таба белми. Шул хәтлекләр тырышып карыйм малай булсын, дип. Юк кына бит. Тапкан берсе үзенә охшаган кыз була да куя. Өстәвенә үзләре усаллар, үзләре күп ашыйлар...

Зәйнетдин дустының күңелен тынычландырырга уйлый:

—Юкка кайгырма, күрше. Аның караве кияүләрең күп булыр!

—Шула-ай!—дип суза күршесе.—Малай оныклар кияүләрдән булачак бит инде. Минем нәсел бетте дигән сүз бит инде ул. Мин бит әтинең бердәнбер малае. Башкалар бар да кызлар бит...

Әхмәт Кадыйр Зәйнетдингә сорау катыш өмет тулы күзләре белән текәлә:

—Сиңа рәхәт сөйләүләре. Кызыл, сары башлы булсалар да синдә малайлар үсә. Ә мин? Ул малайлар ясауның сере нәрсәдә соң. Бер-бер киңәш бирер идең? Күрше бит син!

Зәйнетдин борау белән агач тишкәндәге кебегрәк, вак кына иттереп кетердәтеп көлә:

—Йокларга ятканда түшәгең астына балта, өтерге, бораулар салып куй. Шуннан соң гына тотын хатыныңа бисмилләңны әйтеп. Шул барлык булган сере. Калганы инде... Ходайдан тора...

—Көләсең инде син! Салуын салган бар ла ул. Ба-ар! Тик минем балта-өтергеләр синекеннән үтмәсрәкләр, ахрысы...

—Киресенчә, үткеррәкләрдер. Арттырып җибәреп, кисеп ташлыйсыңдыр иң кирәк җирен...

Зәйнетдин өч кисәк ипине өч малаена тоттырды. Чүпрәкне ябып малайлар туң ипине кимерергә тотындылар. Күп тә үтмәде, өч яшьлек Гатаулла кычкырып елый башлады.

—Нәрсә булды тагын?—дип сорады әнкәләре—нигә елатасыз энегезне?!

—Ипи туң бит, кимерә алмый Гатау. Теше каный,—диде Хәйрулла.—Тукта, җылама!

Берне биреп тә алды, ахрысы, Гатаулла тагын да ныграк акырырга тотынды.

—Тимә балага!—диде әниләре мич янына килеп. Чыбылдыкны ача биреп Гатауллага эндәште:

—Кая, балам, ипиең? Бир җылытып бирим учакта. Бир!

Тик ач бала ипиен бирмәде. Шыңшый-шыңшый кимерүен белде. Җайлап елавыннан да туктады.

Зәйнетдин малайларына ипи таратып тоттыргач, бишмәте белән колаксыз түгәрәк бүреген салып ишек янагындагы чөйгә элде. Колакларын, муенын суыктан саклар өчен ураган хатынының чәчкәле яулыгын да чишеп шунда ук элеп куйды. Бүкәнгә утырып, иске тула оегы өстеннән ыштыр урап кигән чабаталарын салды. Мич аралыгына кереп, чабата, оек чуын җылы урынга киптерергә куйды. Каешланып каткан түбәтәен салып куеп, көз көне генә Мәрфугасы тегеп биргән кара кәләпүшен тәрәзә янагындагы чөйдән алып башына киде. Сәкегә утырып дога кылды да, җайлап кына самавыр яңартып болашкан хатынына сөйләп китте:

—Әти кайткан. Мөхәммәт Шакир мәхдүмне алырга дип Уфага киткән

иде бит. Хәзрәт үзе белән бергә бер бәндәне дә ияртеп алып кайткан. Теге Чуаш тавы астындагы урыс ышкулында укыткан карт хәлфә Казанына кайтып киткән икән. Әҗәлемне Казанымда каршы алып, каберемнең шунда булуын телим, дигән киткән чагында. Һәркемнең үз иле бит инде. Аның да, күрәсең, үз Казаны Казандыр инде. Миңа калса, безнең Эстәрлебаш авылыннан да гүзәлрәк, матур урын юктыр җир йөзендә.

Шакир мәхдүм алып кайткан бәндә шул урыс ышкулында укыта торган кеше икән инде. Урыс хәлфәсе икән дә, урысчалап әйтсәң, исеме Учител була икән. Шакир мәхдүм шул Учителгә Чуаш тавына менәр алдыннан, Чуаш тыкрыгын чыккач сул яклап, Ваһап карт кырыннан йорт салырга чамалый икән. Әти хәзрәт белән бурасын миннән буратырга сөйләшкән инде. Миңа әйтә, син иртәгә өйлә намазына зур мәчеткә кил, ди, Мөхәммәт Шакир хәзрәт белән сөйләшербез, ди. Икәүләшеп инде...

Мәрфуга сәкегә ашъяулык җәйде. Ире алып кайткан ипине көчхәл белән кискәләп табынга куйды. Самавыр камфаркасына менеп кунаклаган ак чәйниктән кыршауланган ике чәшкегә мәтрүшкә катыш, чия чәе ясады. Мич янындагы диварга элентән кара төстәге шкафның әллә кайсы бер тартмасыннан тыгылып, бик зурдан булмаган сары төстәге бер шакмак шикәр алды. Иренә тоттырды. Зәйнетдин, пычак сыртына уң кулының кыры белән суккалап, шикәрне бишкә бүлде. Өч кисәге кечерәкләр иде. Шуларны алып барып, мич башыннан «әтисе белән әнисенең чәй эчкәннәрен» карап яткан өч малаена тоттырды. Шикәр кисәкләре эләккәннән малайларның шатлыклары зурдан булды.

Хатыны тавыш-тынсыз гына, бүлдермичә ирен тынлый. Чәйгә азазлап кына кашыклап кәҗә сөте өсти. Чәйне иренең алдына ук китереп куйды...

Өч малайлы бу гаиләдә барлык кылган эшләр, гамәлләр хатыны Мәрфуга тырышлыгы белән баралар. Өйләнеп бер ел чамасы яшәгәч, Зәйнетдин хатынына үзе әйтте:

—Син, карчык, мине яхшы итеп тыңла. Минем эшем балта эше инде. Үзең күреп торасың. Бик авыр да, ныклап йончыта да торган һөнәр. Шунлыктан син, Мәрфуга, йорттагы барлык эшләрне, сатыпалуны, өс-башны карауны, акча тотуларны үзең алып бар. Бик бай яшәмәбез, тик ач-ялангач итмәм мин сезне, иншалла. Соранып кеше бусагасына да йөретмәм. Миннән зур эшләргә генә рөхсәт сора. Алары әллә ни күп булмаслар. Вак-төяк көндәлек юк-барны миңа әйтеп тә торма...

Мәрфугасы елмаеп сорады:

—Син шулай дисең лә ул. Ә эшнең зурмы, бәләкәйме икәнен мин аерып белеп бетермәсәм? Мин башбаштакланып, зур эшләрне дә бәләкәйгә санап, үз белдегем белән майтарып ташласам? Син нәрсә әйтерсең аннан?

—Аңлык кына башың бардыр. Белмәсәң, әнә, алып килгән китапларыңнан ачып кара. Шул хәтлек калын китапларда бар да язылгандыр дип уйлыйм мин. Шул сиңа.

Гөлмәрфуга күрше Яңгырчы авылының мөәзин кызы. Дүрт балалы әнисе яшьли тол калып, ялгызлык, ярлылык михнәтендә үстерде балаларын. Кызы Мәрфуга дүрт бала арасында иң зурысы. Кияүгә чыкканда, күн тышлы, кулдан язылган, әтисеннән калган борынгы өч китап күтәреп килде. Пөхтә ак киндергә төреп. Кышкы озын кичләрдә шул өч китабын укырга бик тә хирыс Зәйнетдин Балтаның хатыны Гөлмәрфуга. Китапларның берсе дарулар китабы. Анда нинди үлән, нинди чиргә каршы кулланыла—шул язылган. Үләннәрне нинди урыннардан, кайсы вакытларда җыярга икәнлеге язылган. Икенче китап кешенең сырхаулары хакында кайсы авыруга, нинди өшкерү догалары кирәклеге әйтелгән. Өченче китапның нәрсәгә кирәклеген белә алмады Зәйнетдин. Хәер, белергә бик үк теләмәде дә бугай. Шулай да бер мәртәбә ачкалап, укып караган иде каравын. Тик нинди китап икәнен аңлый алмады. Сихер китабына

охшатып «бисмилласын» әйтеп япты да, башкача ул китапларга тотынмады. Китап укып көн уздыра торган кеше түгел Зәйнетдин, балта остасы. Шунлыктан исеме дә Зәйнетдин Балта. Инде менә өч малайлары булды. Өйләре ике диварда кечкенә икешәр тәрәзәле, салам башлы йорт. Хатыны кул остасы. Туннар, бүрекләр, толыплар, такыя-түбәтәйләр тегә. Икесенең кул көче белән көн күрәләр. Иген игәргә, мал тотарга җирләре юк. Зәйнетдиннең әтисе Әбеннәгыйм гомере буена байларда, ишан-муллаларда күчерлектә гомерен үткәргән бер бәндә. Картайса да яраткан һөнәрен ташлый алмый. Яраткан хәзрәте Мөхәммәт Харис вафатыннан соң, аның энесе Харрасны йөретте. Инде хәзер Харис хәзрәтнең улы Мөхәммәт Шакир мөдәрристә күчерлек итә.

Биш ел элек Зәйнетдиннең әнисе вафат булып куйгач, Әбеннәгыйм Күчер икенчегә яшь бичә алып, өр яңадан яңа оя корып, гаилә белән яшәп ята. Бүгенге көндә улы Зәйнетдиннең Гатаулла исемле улы белән бер яшьлек малае бар. Фәйзрахман исемле малай ул.

1894 елның көзе бик каты пычрак булып килде. Кыйбла тарафыннан агач башларына эләгә-эләгә язып түбәннән генә агылган кургаш-соргылт тыгыз болытлар җир өстенә вак һәм куе яңгырлар алып килделәр дә, юлларны, ялан-кырлары кара боламыкка әйләндерделәр. Ул салкын, тәүлекләр буена туктамастан яуган яңгырлардан авыл урамнары өшеп күшектеләр. Җәйге кичләрдәге кебек, көтү белән авылга кайткач «кәсепкә» йөрергә яраткан сакаллы, әрсез кәҗәләр дә, үз йортларын таба алмыйча бертуктаусыз бакырып йөргән ангыра сарыклар да юклар салкын, юеш урамнарда. Тик сирәк-мирәк кенә, юешләнеп суыктан кәкрәйгән, бөрешкән, урам аша йөгерүче мескен этләрнең гәүдәсе генә күренеп кала да, шунда ук юкка да чыга.

Ләкин көзлектәге туклыкка килеп җиткән авыл, барлык өметен инде тау ягыннан киләсе суыкларга баглап, кыстыбый-коймаклар, пәрәмәчләр пешереп гомер итә. Халык белми әйтми: «Синтәбердә син дә бер, мин дә бер!» Чөнки көзге җыйналган уңыштан бай да, ярлы да коймак-кабартма, тары, карабодай боткасы пешерә ала. Хәленнән килә.

Гаиләләр Ходайга рәхмәтләр укый-укый бербөтен табын булып ашъяулык тирәсендә тезелешеп утыралар да, әниләре таба белән китереп куйган эссе кабартмаларга әтиләренең үрелгәнен көтәләр. Әтиләре бисмилласын әйтеп, кабаланмый гына кабартманы ала да, ашый башлый. Аның артыннан кызыл-сары чәчле малайлар җитешәләр. Аннан соң әниләре. «Ә», дигәнче зур таба бушап, «ялт» итеп кала. Тагын бер таба килә. Инде малайлар бу табаның астынарак, майлырак җиренә төшәргә тырышалар. Анысын да, озакка сузмыйча, бушатып куялар. Куллар, иреннәр, битләр майлана, туенганнан күзләр туклык пәрдәсе белән капланалар. Шуннан инде...

Урамга чыгып чабар идең—юк шул! Анда тездән баткак. Өй эчендә качышлы, ясисә бастырышып уйнар идең дә матчага кыстырып куелган талчыбыгы хәзер әниләр кулына күчә. Шул ирек бирми. Бармак белән ышкып тәрәзә пыяласын шыңшытыр идең—әлеге шул талчыбыгы синең арка буйлап чыжлап китәргә генә тора. Көзге урамга чыгып уйнарга өстенә кияре булмаган авыл малае өчен ел әйләнәсендә иң күңелсез вакытлар әнә шул көзге пычрак урамлы, яңгырлы көннәр дә инде. Андый күңелсез, караңгы көннәрдә малайларның гомере, тизрәк кыш килсен иде дип теләк теләп үтә.

Көткән—морадына җиткән! Бер кичне әтиләре бишмәтен иненә генә салып, түгәрәк бүреген башына киеп, «тышка чыгып китте.» Байтак торып кергәч, бишмәтен ишек янындагы «әтинең чөе»нә элгәндә, азрак көлемсерәп әйтеп куйды:

—Малайлар! Ак Чагыл тавы уфыллый анда, тышта. Өч көннән суыклар башланыр, Алла кушса. Сорагыз Ходайдан!

Малайлар сагаеп калдылар. Алар беләләр—әтиләре Зәйнетдин Ак Чагыл дигән тауның уфылдавын тыңлап, кайчан яңгыр, кайчан кар явасын,

буран чыгып котырасын әйтә белә. Берничә көн алдан әле өстәвенә! Улларын да өйрәтә шул тау «уфылдавын» тыңларга. Малайлар әтиләренең бишмәтен кире кидерәләр:

—Әти-и! Әйдә инде без дә тыңлыйк әле Ак чагыл уфылдаганны. Син әйтеп кенә тор, уфылдый хәзер дип. Без дә өйрәник тыңларга. Өч малай, бар да яланаяк, кулмәкчән генә әтиләренә ияреп тышка, ишек болдырына чыгалар. Әтиләре аларны, аякларына кигән булсалар өскәрәк, тыкрык башынарак алып барыр иде, тик малайлары яланаяклар шул. Фәкыйрьлек көчле! Малайларының аяклары астына өстеннән бишмәтен салып җәеп куя:

—Бишмәткә басыгыз да, тыныгыз да чыкмасын! Шауламагыз!

Малайлар тынган кебек булалар.

—Борыннарыгызны тартудан, сызгыртудан туктагыз!—ди әтиләре пышылдап кына. Малайлар әтиләре алдында бер-берсенә сыенып баскан хәлдә тынып калалар. Һәм...

Бикмәт тавыннан да арырак урнашкан Ак Чагыл тау ягына колакларын торгызып тыңлап тора башлыйлар. Тагын бераз көткәч, әтиләре пышылдый:

—Әнә, ишетәсезме?

Тып-тын һаваны этеп кузгаткандай иттереп, гүләгән тавыш ишетелгәндәй була. Һәм ул тавыш көчәя барып, каты авыру кеше сулыш алгандагыдай бер иңрәүгә әйләнә:

—Гү-ү-ү-уу-уфф-фф-фаһһ-у-у!...

Тавыш тына. Малайлар да, тын алырга да онытып, тып-тын басып торалар. Тагын көтәләр тавыш килгәнне. Иң бәләкәйләре, уртада басып торган Гатаулла аяк бармакларын кузгаткалый. Өшиләр. Шулай да кечкенә малай түзә. Өши дип әйтә башласаң, әтиләре өчесен дә куып өйгә алып кереп китәчәк. Ә анда кергәч, мич башында ике абыйсыннан да «эләгә» бит инде! Шунлыктан түзә малай. Аннан соң тагын бер генә тапкыр булса да ишетәсе килә бит әле ул Ак Чагыл уфылдавын. Әтиләре тагын пышылдый:

—Тыңлагыз!

Ак Чагыл көттерми:

—Гүү-у-у-у-уф-ффауууаһһ!!!

Өйгә кергәч, малайлар бер-берсен бүлә-бүлә әтиләреннән сорашалар:

—Әти, нигә алай «уф»ылдый ул Ак Чагыл?

—Әти, әллә ул тауның пәриләре бармы? Шулар уфылдыймы?

Әтиләре кабаланмый гына аңлата:

—Котыптан, Себер якларыннан килгән җилләр Урал тау сырты белән безнең якларга хәтле килеп җитәләр. Яңгыр-карлар әле юлда вакытта ук һава агымы алданрак килеп Ак Чагылга бәрелә. Ул тау җилләрнең уза торган юлына каршы, аркылы басып тора. Менә шул һава агымы уфылдый да инде Ак Чагыл тауга бәрелеп. Минем картәтинең әтисе, Госман бабай шулай дип сөйләгән Әбеннәгыйм бабагызга. Ә ул миңа сөйли торган иде малай чагымда. Шул, буран, кар-яңгырлар буласын алдан белеп, искәртеп тора да инде безне, Ходай бәндәләрен, Ак Чагылкай дигән тау. Безне салкын, карлы бураннарда адашып үлүдән саклый ул. Язын, җәен яңгырлар киләсен алдан әйтеп тора. Безгә, ярлы халыкка ярдәме зур ул тауның улларым...

Малайлар Ак Чагылның «уфылдаганын» тыңлаганнан соң өч көн үтүгә, авыл урамнарындагы баткаклар, Эстәрле елгасы шыкраеп туңдылар. Каткан баткактан атлавы кыен булса да урамнарда кешеләр, эре малтуар, кәҗә-сарыклар күренделәр. Атна үтәр-үтмәстә ыжгырып, суык буранлап, карлар куып кыш килде. Урамнар, бакчалар, тау битләре ап-ак булып кар белән капланды. Читән, койма буйларында, чибәр кар сырынтылары, көртләр өелделәр. Тауга карап үрмәләгән тыкрыкларда, яр буйларында чаңгы-чаналы малай-шалайлар күренделәр. Аларга ияреп, төрле зурлыктагы, кәкре койрыклы этләр чабыштылар.

... Төрек Төхфәтулла йортыннан соң тауга терәтеп салынган мәдрәсә эчендә урыс дәресе бара. Урысча укытучы Мирсәет исемле Учител татар балаларына беренче урыс хәрефен өйрәтә. Әлегә татарча сөйли:

—Менә балалар сезгә урысча «А» хәрефе. Аның исеме «Азъ». Тынлагыз, исегездә калдырыгыз исемен: «Азъ».

Һәм Мирсәет Учител кулындагы катыркада байбичә кебек юан, симез бер хәреф күренә. Ә зурысы аска каратып куйган баскыч кебек. Тик аркылысы гына берәү. Бәләкәй хәреф юанлыкка юан, тик башы бөтенләй юк!

—Ягез әле, балалар, кабатлагыз әле: «А-аазъ!

Малайлар гөрлиләр:

—А-а-а...

—Аз ... аз ... аз... а-а-а...

Урыс ышкулына укырга йөргән малайлар сигез яшь белән унике арасында булып, күбесе Тукай бабай нәселеннән чыккан ишаннар, муллалар, хәлфәләр балалары иде. Шулар арасында авыл байларының, сәүдәгәрләренең, мәдрәсә хәлфәләренең малайлары да барлар.

Урысча дәресләр алып барган Учител дигән абыйларының чын исеме Мирсәет икән. Фамилиясе—Бийишев булып чыкты. Ул абзый чыгышы белән Казан каласының үзеннән булып, әллә кайлардагы урысларның Мәскәү, Питербург, Мәкәрҗә дигән калаларында да булганы бар икән.

Авыл халкы өчен урысчага укытучы ул кеше башта бик сәер тоелды. Ул Эстәрлебашка килгәннең икенче көнендә үк авыл урамнары буйлап аның турында имеш-мимешләр таралды:

—Шакир мәгъзүм авылга урысча укыта торган бер кеше алып кайткан икән. Теге урысча укыткан карт хәлфә урынына. Учител дип әйтәләр икән үзен. Үзе япь-яшь егет икән дә, башында кара Казан кәләпүше икән. Үзем күрмәдем күрүен дә, Югары очның Гршавай Хәмденисасы күргән. Шул сөйләде...

—Ы-ы! Шулай диләр шул. Аның исеме Учител икән шул. Казаннарында әллә нинди исемнәр була икән аларның. Ул Учител исеме безнең яклардагы кебек бер дә колакка ятышлы түгел бит. Кемчә икән инде ул Учител дигән исем. Тегесе бит үзен мөгаллим дип кенә йөртә иде. Исеме дә безнеңчә, Габделхак абзый иде. Балалар бик яраталар иде үзен.

—Теге Төрек Төхфәтулла янындагы мәдрәсәдә диләр укытуын...

—Бетермәгәч бетермиләр бит шул урысча укыта торганнарын. Безнең мөселманга ул урыс укуы ни нәрсәмә хаҗәттер инде ул...

—Ы-ы, мөселманга урысча уку гөнаһ бит инде ул. Гөн-на-а-аһ! Кит инде, ничекләр иттереп ул урысчаны укымак кирәктер инде?!

—Әй, Шакир хәзрәт үзе белә булыр гөнаһмы, түгелме икәнен. Урысча уку ул чучка ите ашау түгел инде. Кирәккәдер. Шәяхмәтулла сәүдәгәр, әнә, бөтен урыс калаларын айкап сәүдә итеп йөри. Мәкәрҗәләренә ел саен бара. Шушы ышкулда урысча укып өйрәнмәгән булсам, мин Эстәрледән чыгып киткәч телсез дә, саңгырау да булган булыр идем, дип сөйли геләннәр генә. Урысча сөйләшү минем өчен чүп тә түгел ул. Иркенләп сөйләшәм, иркенләп алдыйм сәүдәдә урысларның үз телләрендә. Кяферне алдау гөнаһ түгел ул, аны китап та рөхсәт итә, дип әйтә икән.

—Укырга-язарга гына өйрәтсәләр, аның әллә ни гөнаһы булмас инде ул булулыкка. Тик урысның яман гадәтләренә генә өйрәтә күрмәсеннәр...

—Урысча укыткан ул нәмәстәкәйләре мәчеткә йөри бит. Мөселман башы белән нишләп инде урысның начарлыгына өйрәтсен, ди. Сөйлисең тагын сүз итеп...

—Учител дигән исем гарәптән чыккан икән ул. Аларда бит Гамәл, Камал, Галиәкбәр, Габделбәр дигән исемнәр бар. Монысының да тулы исеме Габдел-Учител икән дә, укытучы бәндә дигәнне анлата икән,

әйгенәкәйем...

—Ә-ә-ә, шулаймыни? Бу дөньяда Ходай Тәгаләнең әллә кемнәре бар инде. Ул Учител дигән исем учле дигән сүздән килеп чыкмадымы микән диюем әле минем. Шулайдыр ул, ахирәт...

Ай тулар тулмаста авылда тагын яңа хәбәрләр таралды.

—Теге Төрек Төхфәтулласының тау ягында урнашкан, башы дранча белән ябылган мәдрәсә тоташы белән урыс ышкулы икән хәзер. Дин дәресләрен башкача анда укытмыйлар икән инде. Ышкул дигәннәре безнеңчә мәптек дигәнгә туры килә икән...

—Карале, әхирәт! Ул урысча укыганның, укытканның гөнаһларын каялар гына куеп бетермәк кирәк ди. Түбән очның Кәшәфетдин әйтә, ди, Харис хәзрәт үзе дә, малайлары да урыс белән, итальян белән сәүдә итә-итә, урыс-итальян булып беттеләр инде дип әйтә, ди. Алардан мәчет-мәдрәсәләрне тартып алырга кирәк, мөфти хәзрәтләренә өсләреннән шикаять язып, авыллар буйлап имза җыярга кирәк, ди икән.

—Ул Кәшәфетдин Харис хәзрәт белән гомерләре буена тартыштылар бит инде. Хәзрәтнең яшь бикәчен үзең беләсең бит, теге елны урак өстендә Хәмбикә яланында...

—Эй, Ход-дай-йым! Әстәгыфирулла! Әстәгыфирулла! Шулай диген син! Үз күзең белән күрмәгәнне сөйләмә берүк! Гөнаһы зурдан булыр, сөйли күрмә кеше сүзен!

—Мин ышануын ышанмыйдырыем ла. Болай булгач дөрестер, ахрысы. Ничәмә ничә еллар узып китте, һаман үч алу бара, дигән сүз бит инде бу болайга киткәч.

—Шул шул менә! Харис хәзрәт мәчеттә вәгазендә әйткән, ди: «Безнең падишабыз—ак патша! Аны узып без Рәсәй мөселманнары бернәрсә дә кыла алмыйбыз Ата-бабаларыбыз бик күп еллар буена көч сарыф итеп, бик күп кан коеп, асыл улларыбызның җаннарын кыйганнар. Күпме генә корал тотып сугышсак та урысны җиңә алмаганбыз. Максаты юк бүген, түгелгән канның. Көчленеке замана! Иелгән башны кылыч кисмәс! Инде безгә ак патшага буйсынып, аның әмерләрен үтәп гомер итәргә калды. Шунлыктан урыс астында исән-имин, тере яшәр өчен, безгә Русия мөселманнарына ак патшаның телен белеп, урыс белән аралашып, солых вә мәслихәт белән сәүдә-кәсеп итешеп яшәргә генә кала. Ә аның өчен урыс телен белү фарыздыр. Урыс Казан каласын басып алгач, безне җиңде. Шунлыктан аның барлык кылган эшләре җиңүчеләр телендә—урыс телендә алып барыла да инде. Һәм ул шулай алып барылачак та. Без, җиңелгән халык буларак тулысынча үзебез теләгәнчә яши алмыйбыз. Халкыбызны, динебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калыр өчен урыска ераклашып, аның телен белеп, патшасын тыңлап яшәү фарыз безгә, дигән».

... Уку башланганның беренче көннәреннән үк Мирсәет Бийишев укытуны урысларның «Букбар» исемле китабыннан башлап алып китте. Андый китабы бишәү иде аның. Шул китапларны пөхтәрәк киенгән бай малайларына таратты. Берсе Нигъмәтулла хәзрәт оныгы Хәйбуллага эләкте. Ул Тукай бабай нәселенә хас зур колаклы, кара-кучкылрак йөзле (кыргыз каны катыш дип тә сөйлиләр), укуга бик тә хирыс һәм сәләтле малай иде. Китап тирәли җыйналып, кабаланмый гына битләп актарып карарга тотындылар. Учител биргән «Букбар» дигән китапның эче тулы сурәтләр иде. Моңа кадәр малайлар күргән гарәп хәрефләре белән язулы китапларның берсендә дә сурәт төшерелмәгән иде. Коръән Шәриф рөхсәт итми икән җан иясенең сурәтен төшерергә. Теге дөньяга баргач сурәт үзен төшергән кешенең җанын сорар, ди, миңа бир җанымны дип.

Малайлар китапның битен сакланып кына, берәрләп кенә ачалар һәм китап битләрендәге сурәтләргә карап бераз тын гына карап торалар. Аннан тавышларын бик каты чыгармыйча гына гөрләшә башлыйлар:

—Карале, куяннар, әй! Берәү, икәү, өчәү, дүртәү. Епәрәләр генә кар өстеннән...

—Монаусы песәй бит, карале! Тычкан бастыра. Тота инде ул аны, күр дә тор...

—Аты да аты, әй! Койрыгын карале! Гапкадыйр абзыйның Шешенгән исемле айгырыныкы хәтлек бар...

—Атка атланганының киемнәре әллә тоташ тимер инде? Башындагы бүреге очлы...

1894 елның кышы азрак соңлабрак килсә дә, каты суыклар белән башланып китте. Башта тымызык кына иттереп атна буена кар яуды. Туктамастан. Җиле юк иде. Аннан соң җайлап кына буран кузгалды. Җил, эш тапканына куана-куана, йомшак, вак карларны һавада куып йөретеп таш койма, читән, такта рәшәткә, сарайлар-йортлар, мунчалар ышыкларына сыртлап-сыртлап, көртләр итеп өяргә тотынды. Тыкрыклар, урамнар, кое яннары җигүле чаналар, мал тояклары, чабаталы-пималы кеше аяклары белән тапалдылар. Тагын карлар белән капландылар, тагын тапалдылар. Ындыр табакларында, көзен куйган кибәннәрне ачып, ашлык сугулар башланды. Шап та шоп китереп суккан чабагаш тавышлары, тешле таш тарттырган атларны куган кеше тавышлары, чыбыркы шартлаулар, шатлыклы хатын-кыз, бала-чаганың көлүләре—барысы да ындыр табакларына ямь бирәләр иде.

Авылда Төрек Тыкрыгы дип исемләнгән, арбалы ике ат кара-каршы очраганда эләгешә-тартыша көчкә аерылып уза алган тар гына урамда чана тарткан малайлар кайнашалар. Төрек Тыкрыгында чана шуу Эстәрле авылы бала-чагаларының иң күңелле урыны һәм шуучылар иң күп җыела торган җир. Базар урамыннан Чуаш ягына үрмәләгән ул тыкрык менгән саен тауга күтәрелә. Кар төшкәннән соң ике-өч көн дә үтми, малай-шалай тыкрыктагы карны таптап-шомартып, шуар өчен үзләренә бик шәп тау ясап алалар. Төрек Тыкрыгында чанада шуу авылда ата-бабадан калган бер йолага әйләнеп, ел саен кабатлана тора. Базар урамыннан таякка таянып мәчеткә барган ил картлары да бу тыкрыкта малай чакларында чанада шуганнар. Барган җирләреннән туктап, инде соңгы елларын яшәп яткан берничә карт шау-шу килеп чана шуган малайларга карап үзләренең малай чакларын исләренә төшереп озак басып торалар. Бу көн саен диярлек кабатлана торган бер манзара. Аннан соң кузгалган күңелләрен намаз укып басар өчен кабаланмый гына мәчеткә карап атлыйлар. Уза-а гомерлә-әр!...

Ә картаю турында әле башларына китерә дә алмаган малайлар төркеме, тыкрыктагы ат юлын таптый-таптый, чана белән шуа-шуа тауның өстенәрәк күтәреләләр. Тора-бара Төрек Төхфәтулла бабай йортын узып, урыс ышкулы янына менеп җитәләр. Тагын берничә көн узуга, ышкулны да үтеп, кинәт кенә кискен иттереп текәләнеп киткән тауга үрмәли башлыйлар. Анын да карын, башта пималы, чабаталы аяклар белән таптап, икешәр-өчәр булып чаналарга төялеп тау түбән элдертәләр. Тау шуарга әйбәт, шома булсын өчен малайлар барлык ысулларны да кулланалар. Килгән бер малай, очкыр белән бәйләп куелган чалбарын чишеп, тапалган карга ... сиптереп сияргә фарыз. Монысы да кайчандыр борынгы заманнарда шулай ук малай булган бабайлардан калган йола. Үтәмичә хәлең юк. Шулай эшләмәсәң, тауда өстенлек иткән берәр малай бәргәләп алырга да күп сорап тормый...

Чана шууда Мирсәет Учител дә катнаша. Атнага бер көнне Төрек Төхфәтулласының ат чанасын сорап ала да, аның тәртәләрен алып ук куя. Урысча укый торган барлык «учиникләрен»—шәкертләрен чана шуарга алып чыга. Чананың ике ягыннан бәйләнгән ике сүс арканга аларны тигез иттереп бүлеп куя. Чанага бәйләнгән шул ике аркан белән малайлар эченә күп итеп печән тутырылган чананы тауга өстериләр. Мирсәет Учител, дәрәҗәсен саклап, чана артыннан гына атлый. Бай, ишан, хәлфә малайлары авылның игенче, малчы, балта остасы, ташчы малайларыннан бер генә тамчы да аерылмыйлар монда, барысы да тигез хокуклы. Алар да чын малайлар була беләләр. Мышный-мышный тартып, тау уртасында

азрак бүлтәеп чыгып торган урынга алып менеп җиткерәләр ат чанасын. Шул җирдә инде Учител Мирсәет тә аларга ярдәм итә—бергәләшеп чананы тау түбәненә каратып борып куялар. Иң беренче булып ваграк малайлар, аннан эрерәкләре чана эченә тула башлыйлар. Мирсәет Учител белән, һәрчак аның уң кулы булган Лотфый мәгъзүм чананың башы янынннан, икесе ике яктан тотып торалар. Чана кузгалып китмәсен дип. Малайлар этешә-төртешә чана эченә тулып беткәч, Мирсәет: «Аллага тапшырдык!—дип, чана эчендә үзенә урын чамалап тиз генә итеп утыра. Лотфый мәгъзүм дә анардан калышмый. Ул да малайлар өстенә тәгәри. Чана дертләп куя да, кузгала. Җәйнең хуш исләрен алып калган ямь-яшел печән өстендәге малайларның башта тыннары да чыкмый. Ә малайлар белән эче тулы ат чанасы тизлеген арттырганнан-арттыра бара. Колак янында җил уйный башлый, каршы килгән һава дулкыны тынны кысып каплый, күздән яшьләрне бәреп чыгара. Шул чакта чана эчендәге берәр малайның чыдамы бетеп, эчендә туа башлаган очу теләген авазга әйләндереп кычкырып җибәрә:

—Иh-hа-аhа-hа-hа-а-а!

Беренче тавыш чыгу белән, чана эчендәге барлык малайлар да яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып акырырга, сызгырырга тотыналар. Каршыга искән һава агымына кайсысыныңдыр бүреген очыртып алып китә, кемдер этешкән-төртешкәннән чанадан ычкынып, юлда мәтәлләп төшеп кала. Әнә, капкасы төбендә, бабасыннан истәлек булып калган чикләвек таягына таянган, сул якка кыеш гәүдәле Ваһап Пәрәү бабай күзгә чалынып кала. Ул да әле нужа кайгысы күрмәгән, чыйнаган-сызгырган вак-төяк малай-шалайның шатлыгына ак сакал-мыеклы, җыерчыклар баскан битен балкытып басып тора. И-иэх! Бар иде бит шундый малай чаклар! Әнә, кече базарга бер кадак кына симез ит алырга чыгып барган Буйдак Һидият олпат гәүдәсе белән көрт эченә кереп баскан. Әле һаман өйләнә алмый йөрсә дә ул да кайчандыр малай булган кеше бит! Чана чыжылдап үтеп барганда капка асларыннан этләр амалап килеп чыгалар да, азга гына булса да ияргә тырышып өтәләнә-өтәләнә өреп чабалар...

Ә ат чанасы такыр юлдан җилдертепме җилдертә! Очыпмы оча! Тыкрыктан атылып Базар урамына килеп чыга да, күз ачып йомганчы аны аркылыга кисеп, Галәветдин байның таш келәтен сулда калдырып, Мөкейләр тыкрыгына кереп китә. Ул кыска тыкрыкны выжылдап уза да, Эстәрле елгасының текә ярыннан елга бозына очып килеп керә. Икенче яры да текә Эстәрленең, чана каршы ярның яртысына менеп җитә дә туктый. Туктаган чанадан каршыга искән җилдән битләре кызарган, күзләре очкынланган малайлар коела башлыйлар. Мирсәет Учител дә алсуланган битен балкытып елмая:

—Төшегез, бурлаклар! Тотыгыз арканнарны, җигелегез чанага! Киттек менеп. Шуарга яратасыз икән, әйдә, чанасын да тартыгыз!

«Бурлаклар», чананы борып елга бозына төшерәләр, арканнарга ябешәләр, иелә төшеп тартып елга ярына үрмәлиләр.

Мирсәет Учителнең урысча укыган шәкертләре белән ат чанасына төялеп таудан шуганын карарга һәр шимбә көнне авыл кешеләре җыйнала. Тамаша, бушка! Базар урамына, Чуаш-Төрек тыкрыгы чыккан урынга бала-чага, кыз-кыркын, хатын-кыз, ирләр, карчыклар, картлар җыйналып, тезелешеп басалар. Чана тыкрыктан чайкалып чыйнап килеп чыгуга кайсы кая йөгерешеп аңарга юл ачалар. Кычкырыш-көлеш, этеш-төртеш, йөгереш, егылыш, елаш...

Икенче көнне базар була. Таудан зур урамга килеп чыгып, шуу юк. Чөнки базар урамы сату-алу, алдау-алдану белән мәшгуль. Ул көнне таудан шуып килеп чыккан малайларның колагын бору, аларны кар белән уу тиешле. Кып-кызыл булганчы! Йөремә базар көнне чана шуып! Ат тоягы астына эләгүең бар! Менә сиңа! Еламагаең—күзең кара, йөрәгең таза булыр! Хуш иттек шуны!

Дүшәмбе көнне тагын дәресләр башлана. Өйлә узу белән мәдрәсәдән кайтып ашап алган малайлар «урыс дәресләренә» җыйналалар. Инде алар өйләдән соң шәкертләр түгел, ә учиниклар. Тотыналар урысчалатып сүзләр ятларга:

—Вода—су була...

—Уха—балык шулпасы...

—Рыба—балык...

—Лушыт—ат була...

—Заес—куян...

—Русак—үр куяны.

—Биләк—урман куяны.

—Кошка—песи була.

—Чилавик—кеше.

Бүлмәдә җылы, рәхәт һәм дәресләргә генә хас булган гүләү ишетелә. Татар малайлары тырыша-тырмаша урысча өйрәнәләр.

—Вода течет—су ага.

Урам якка караган тәрәзә янында утырган Лотфи мәгъзүм тәрәзәгә йодрык янаты. Ертылаш туң тәрәзәдән түгәрәк кара бүрек кигән бер малай башы күренә иде. Ике зәңгәр күз зур кызыксыну һәм гаҗәпләнү белән бүлмә эченә карап торалар.

—Кем ул?—дип сорады Учител, малайның башын күреп.

—Лотфулла исемле малай ул. Зәйнетдин Балтаның икенче улы.

—Нәрсә карый инде монда?

—Мөкиләр тыкрыгында торалар алар. Яр башында. Сыңар мөгезле кәҗәләре генә бар. Хәерчеләр алар. Өстенә киярга бишмәте дә юк аның. Үзләре гел малайлар...

Учител нәрсәдер әйтергә теләп тәрәзәгә караган иде, анда инде малайдан җилләр искән...

* * *

Шул көннән соң ике-өч көнгә бер тәрәзәдә теге малайның башы күренеп китә торган булды. Кышкы суыклар башлануга карамастан малайның тәрәзәгә килүе өзелмәде. Малай сигез яшьләр чамасында иде. Кайчан карасаң да ул гел күлмәкчән була иде. Башына кигән түгәрәк бүреге колакларын тоташ каплап тора. Кашлары сары, күзләре зәңгәрләр. Суыкта өшегән бите тулы кызыксыну. Тәрәзәгә килүе ешайгач, беркөнне Мирсәет аның килү вакытын чамалап, малайны өйалдында көтеп алды. Малай килеп җитеп, тәрәзә пыяласына бите белән елышуга, куркытмаска тырышып акрын гына эндәште:

—Үскәнем, кил әле болайга! Сөйләшик.

Малай тавыш килгән якка тиз генә борылып карады да песи тизлеге белән тәрәзәдән читкә сикерде. Өстендә тез башлары, артлары ямалган буйлы ыштан, соры төстәге юылган күлмәк, ялан аякка киелгән агач каталар. Ул тиз-тиз йөгереп азрак барды да, шома юлдан түбән табан шуып төшеп китте. Агач ката табаннары таудан шуа-шуа яхшы ук шомарганнар иде, ахрысы. Азрак алга табанрак иелгән кечкенә гәүдәсе зур тизлек белән түбән таба оча. Малай җитез һәм тизлектән курыкмый иде. Тыкрык очына җитәрәк малайның гәүдәсе турайды. Ул, артына борылып, Мирсәет басып торган якка карап алды да, йөгерә-йөгерә Базар урамын аркылы чыгып, Мөкиләр тыкрыгына кереп күздән югалды. Учителнең ул зәңгәр күзле малайның кем икәнен беләсе һәм аның белән сөйләшәсе килә иде...

Кышкы көннәрнең берсендә мәктәп ишеге катында авыл мәдрәсәсенең Хәйдәргали исемле хәлфәсе күренде. Мирсәет башлап үзе сүз катты.

—Әйдүк, хуш киләсең, Хәйдәргали абзый!—диде ул ачык йөз белән.—Түрдән үт әйдә!

—Әссәламәгаләйкум, Мирсәет энем! Килгәч үтәрбез инде. Шуңа дип килү бит. Үтәрбез! Ай-һай суык тышта, куырып алып бара. Юлда йөргәннәргә Ходай ярдәм бирсен!

—Әй-йе!—диде Мирсәет.—Бу якларда суыклар катырак икән Казан тарафларына караганда дип әйтүем. Бураннары да бик каты булалар икән. Күз ачкысыз...

—Бердән—казакъ далалары якыннар. Аннан Эстәрлебаш Урал тауның Урта Сырты Казакъ далаларына кереп киткән җирдә утырган бит. Җилләр котыптан Урал таулары өстеннән очып киләләр дә, шул якның суыгын да, карын да бу тирәләргә ташыйлар. Аннан кире казакъ якларыннан әйләнеп киләләр. Менә шул әйләнеп килгән бураннар бик каты булалар нилектәндер. Шул бураннарда адашып үлүчеләр дә байтак була...

Хәйдәргали хәлфә Мирсәеткә карап алды:

—Укытуыңны бүлдем бугай?

—Бүлдем дип инде?! Бүлмәдең. Зурлар арифметикадан мисаллар чишәләр, бәләкәйләре язалар. Син болай гына йөри торган кеше түгелсең—керүеңнең берәр сәбәбе бардыр, мөгаен?

—Бар иде шул, Мирсәет энем. Бар. Көлсәң көл, еласаң ела, дигәндәй, мин сиңа бик зур гозер белән кердем бит әле. Син ныклап кына, башыңа алып тыңла мине, зинһар.

—Әйдә, түргәрәк узыйк. Утыр. Аннан соң әйтерсең гозереңне. Дога да кылып алыйк.

Аягындагы пималарын салып, Хәйдәргали хәлфә алга узды.

Дога укып алгач, Хәйдәргали тырышып-тырышып нидер язып утырган малайларга сокланып та, көнләшеп тә карап алды.

—Сөбханалла! Шулкадәрле дә бирелеп укыйлар бит. Карап торулары күңелгә бер рәхәтлек бирә. Болардан кеше чыгар болай булгач.

—Дөрес әйтәсең, хәлфә! Шуңа дип тырышабыз бит.

—Без, булмаса, алгы бүлмәгә чыгыйк. Малай-шалай ишетә торган түгел минем сүз.

Күрше бүлмәгә чыккач, Хәйдәргали хәлфәнең чибәр, кырыс йөзе нурланып, эчтән чыккан йомшаклык белән яктыра башлады.

—Ни бит әле, энем Мирсәет. Мин теге елны алып барып чыгара алмаган эш белән тагын сиңа килдем бит әле.

Учител аңарга азрак каушый биреп карады:

—Әллә инде?!

—Соң?!—диде хәлфә, Мирсәетнең аңлый башлаганына куанып.—Син мине кире укырга ал инде? Туксан беренче елның ачлыгын үзең беләсең нинди булганын. Шуңа өстәп малай туды. Нужа өстенә нужа, юклык өстенә юклык. Гаилә ишәеп китте—алып барып чыгып булмады. Урысча укуны ташлаган идем бит. Ныклап булмаса да, аз-маз сукалыйм. Ырынбурга барган идем, урыс гәҗитләре алып, кич буена укып утырдым. Белемнең чиге юк икән, үземә кайбер нәрсәләр алган кебек булдым. Хөрмәтем бик зур сиңа, энем Мирсәет. Шунлыктан улыма да синең исемеңне куштым. Мирсәет дип!

—Беләм. Ул бала үскәндер инде. Күрмәгәнемә дә елдан артыктыр.

—Соң үсми тагын! Инде өче белән китте. Урамга чыкса, алып керәм димә. Үзе гәүдәгә бәләкәй генә, ә үзе бер сугыш чукмары. Үзеннән дә зуррак малайларга үрелә менә. Дүрт-биш яшьлекләргә хәтле.

Хәйдәргали хәйләкәр генә елмаеп алды да, күзләрен Учителгә текәде:

—Мин килим инде укырга, энем?!.

Мирсәет азрак дәшмичә уйланып утырды да, әйтте:

—Килүен килерсең. Тик сиңа баштан ук яңадан кабатларга туры килер инде. Ташлаганыңа өч елга якын бит. Аннан соң мәдрәсә мөдәррисе Мөхәммәт Шакир хәзрәт белән сөйләшеп, аның ризалыгын ал. Авыл бит—гайбәттән арына алмассың.

—Укыганга нинди гайбәт булсын ди инде тагын?! Кит аннан, юкны!

—Син мине тыңла. Урысча укыгач, урыс булырга хәзерләнә икән диячәкләр, әнә, теге елны күпме сүз йөрде. Авылда анламый торган халык та байтак бит әле. Хәзрәтнең фатихасын алсаң, авылга тәтен таратырбыз. Фатихасы бар, дип. Шул җитәр. Ә болай үзе мин каршы түгелмен. Кил, укы. Баштарак авыр булыр, малай чагың түгел бит. Мәдрәсәдә дә укытырга, монда да укырга туры киләчәк ич.

—Авыр булуы билгеле инде аның. Тик минем телләрне яхшылап өйрәнеп, балалар укытасым килә. Укыган баланың күңеле була аның, нур өләшәсем килә. Синең кебек иттереп... Шакир мәгъзүм фатихасын бирер ансы. Атасы кебек укуның тәмен белә торган зат ул. Синнән алда укыткан Ярмөхәммәт абзый Мәрҗани хәзрәт шәкерте булган. Казандагы учителски ышкулда укып чыккан зат булган. Аны беләсендер бит?

—Беләм. Аллага шөкер, исән-сау. Казанның Яңа Бистәсендә яши. Тик күзләре генә начарланган.Шунлыктан укытуны ташлаган. Базарда аз-маз сәүдә итә икән. Тереклек итәргә кирәк бит. Узган ел барып таптым мин аны. Яңа бистәдә, Таш мәчет янында кечкенә бер йорт сатып алган. Эстәрлене бик сагынам, ди. Ул таулар, чишмәләр төшемә керә, ди.

—Кере-ер! Эстәрлебашның суын бер тапкыр эчкән кеше барыбер кайта ул әйләнеп.

—Ярар, энем Мирсәет! Аллага тапшырып, мин киләсе атнадан укуны өр яңадан башлыйм инде. Бик күптән булдыра алмам, шулай да кулдан килгәнчә түләргә дә тырышырмын инде.

—И-и Хәйдәргали абзый! Миңа түләвең шул булыр—укы син! Укы, туктама башкача!

Чыга башладылар. Күрше бүлмәдә «Кем сукты»лы уйнап малайлар «ду» киләләр иде инде. Кереп килгән Учителне күргәч, шыбырдашып өстәл араларына тула башладылар. Хәйдәргали көлебрәк сорады:

—Талчыбыкларың һаман күренмиләр?..

—Тыңлаучаннар алар. Гыйлемгә сусаган малайлар.

Ул кинәт сүзеннән бүленеп, Хәйдәргалигә акрын гына дәште:

—Син тәрәзәгә карале, абзый! Көн саен диярлек менә шушы тәрәзәгә бер малай килә. Чакырам—керми. Чыга башласам, тау түбән шуып төшә дә китә. Әнә, тагын килгән...

—Безнең күрше Зәйнетдин абзыйның икенче малае ул. Исеме Лотфулла. Кая, мин чыгып карыйм әле. Күрше малае бит.

Күп тә үтмәде, ул малайны ияртеп кире керде. Хәйдәргали абзый бусагада туктап калган малайның аркасыннан сөйде:

—Төш, улым, бусагадан, курыкма. Учител Мирсәет абзаң бик әйбәт кеше ул.

Малай курка торганнардан түгел иде. Ул алга таба бер адым атлады да, сәламләде:

—Әссәламмәгәләйкүм!

—Вәгаләйкем әссәлам!—дип сәламен алды Мирсәет Учител.—Үт болайрак! Якын кил!

—Үтмим!—диде малай көр тавыш белән.—Каталарның кары эрер дә, идәнегезне юешләр. Ярамый үтәргә.

—Сал каталарыңны!

—Салмыйм!

Мирсәет каталарга күз салды—оекбашлары юк иде малайның.

—Исемең Лотфулла бугай?

—Әй-йе.

—Син нәрсә, гелән генә тәрәзәгә киләсең, ә үзең чакырсам да кермисең? Ә?

—Һы! Кызык бит.

—Нәрсәсе кызык?

—Урысча укыганны карау кызык.

—Син әллә урысча беләсеңме?
—Кайбер сүзләрен генә беләм.
—Нинди сүзләр алар, әйтеп кара әле.
Малай тезеп алып китте: кушка—песи, вада—су, зимлә—җир, нибы—күк йөзе, палкы—таяк...
—Сөбханалла-а!—дип куанды Хәйдәргали абзый.—Каян белеп бетердең син бу сүзләрне?
—Мәхдүмнәр ятлаганнан. Урам буенча кычкырып ятлап кайталар ич алар. Ә мин арттанрак ияреп килеп тыңлыйм да, алар артыннан эчемнән генә кабатлап, исемдә калдырам.
—Кемнәр алар, мәхдүмнәр дигәнең?
—Лотфи белән Гобәйдулла инде, кем булсын! Башкалары ятламыйлар.
Мирсәет гаҗәпләнеп карап торды—гади генә малай булмаска тиеш бу.
—Энем, сиңа бер гозерем бар. Хатыным, Сара апаң кибетләргә, йә базарга-мазарга чыгып киткәндә ике улым янында калып торырга иптәшкә бер малай кирәк иде. Мин үзем укыту эшендә, малайларны карарга вакытым җитешми. Бергә уйнап торырга. Син шуңа риза булмассыңмы?
—Еламасыннар дипме?
—Әй-йе шул.
—Мин үземнең энем Гатаулланы гелән карыйм. Уйнасаң еламый. Тик еш-рак пес кенә иттерергә кирәк. Аннан киреләнә башласа, азрак биргәләп аласың инде.
—Тыңлыймы соң?
—Биргәләгәч, тынламый кая барсын ди. Тыңлы-ый! Якын килә башласаң, кача башлый.
—Кача аламы соң?
—Кая качсын ди инде. Бәләкәй бит әле. Бар белгәне шул сәке астына кереп китү инде.
—Шуннан эләктереп аласыңмы?
—Ю-ук! Азрак утыргач, сәке астыннан башын чыгарып: «Абый!—дип акыра. Анда караңгы бит. Хәзер күтеннән җен-пәри эләктереп ала, дим. Атылып килеп чыга. «Абый», дип торгач тимим инде аннан соң.
Мирсәеткә малай ошады.
—Син көн дә кил монда. Өйләдән соң. Сара апаңа ярдәм итәрсең. Малайларны карашырсың. Әгәр инде Сара апаңа кирәк булмасаң, менә бу бүлмәдә, ишек янындагы өстәл артына утырып укырга өйрәнерсең. Укуга сәләтең бар күренә.
—Мәдрәсәдә иң тырыш шәкерт мин. Гобәйдулла хәлфә шулай ди.
Дәшми генә тыңлап торган Хәйдәргали дә сүзгә кушылды:
—Бергә утырырбыз. Күршеләр бит...
Мирсәет, сөйләшкән арада, Лотфулланың өс-башын карап алган иде. Чыгып китте дә, бер чалбар белән бер күлмәк тотып керде:
—Әниеңә алып кайтып бирерсең. Сүтсен дә, таманлап тектерсен. Миннән бүләк сиңа. Үземнекеләр. Бик иске дә түгелләр әле.
—Безнең әни үзе тегә,—диде малай, ерылган авызын җыеп ала алмыйча.—Рәхмәтләр яусын, Учител абый!
—Бетең юкмы?
—Юк. Күрше Габделхавас бабайларның мунчасына ягабыз. Атна саен. Утын алардан, су белән ягу бездән. Абый белән икәүләшеп фантаддан су ташыйбыз. Шулай булгач, бет була димени.
—Ярар, алайса! Бар кайт! Ике көннән кил. Аңладыңмы?
—Аңладым!
—Зур үс, туганым!

* * *

Шул сөйләшүдән соң Лотфулла мәдрәсәдән тыш урыс ышкулына да йөри башлады. Әтисе пәке белән кырып чәчен алды. Әнисе исә Учител биргән чалбар белән күлмәкне сүтеп юды да, таманлап, улына чалбар белән күлмәк тегеп кидерде. Әниләре кул белән тегеп утырганда, бәләкәч Гатаулла анның янынннан гел китмәде. Озак кына карап утыргач, сабыйларча куанып әйтеп куйды:

—Бәләкәй абый бу күлмәктән үсеп чыккач, ул аңа бәләкәйләнгәч миңа кала инде, әйеме әни?

—Шулай балам, шулай. Аңа кадәр тузып бетмәсләр.

Гатаулла анысына да җавап тапты:

—Әни, син бәләкәй абыйга әйтеп кидер инде, туздырмыйча ки, диген. Гатауллага да калсын диген...

Ярлылык бик көчле иде шул Зәйнетдин Балта гаиләсендә...

Лотфулла Мирсәет абыйсының хатыны Сара апасы кушкан йорттагы вак-төяк эшләрне караштырды, вак-төяк йомышка йөрде, чанага ныгытып бәйләнгән тәпән белән «фантал»дан су ташыды; «фантал» дигәннәре җиргә казып утыртылган зур гына бер чан иде. Башы җир өстенә чыгып тора. Йорт башы ябылган кебек тимер белән ябылып, яшел төскә буялган. Шул түбә уртасындагы багана башына җиздән ярымай куелган. Чанга су тау итәгендә чыгып яткан чишмәләрдән эче куш агач торбалардан агып килә. Фанталлар Гайсә пәйгамбәр туганга 1835 ел булганда салынганнар. Шундый фанталлар авылның өч урынында урнаштырылганнар. Шуның өстенә Тукаевларның җимеш бакчаларында тагын шундый ук өч фантал бар. Эстәрлебаш халкы фанталдан кул пешкәге ярдәмендә чишмә суы алып, шуны эчеп яши. Фанталлар янында атларны да, башка мал-туарны да эчерергә ярамый. Мал өчен һәр урамда агач улакны, кыршауланган зур агач чиләкле, сиртмәле, эчләренә имән бура төшерелгән коелар бар. Кешеләргә дә, мал-туарга да эчә торган суга бай авыл Эстәрлебаш.

Лотфулланың төп эше, Сара апа авыл арасына чыгып киткән чакта, ике малайны карау. Малайларның арасы яшь ярым гына. Гәүдәгә икесе дә бер чамалар. Икесе дә сакаулар. «Ш» һәм «Р» авазларын әйтә белмиләр. Тәүге көннәрдә нәрсә сөйләгәннәрен аңлау кыенрак иде, аннан соң бар да аңлашыла башлады. Малайлар тыңлаучан, үзләре иркә түгелләр иде.

Эш юграк чакларда Лотфулла, тавыш чыгармаска тырышып, ышкулга бара да ишек төбенә якынрак куелган өстәл артына, хәлфә Хәйдәргали абзый янына кереп утыра. Өстәлләрнең, утыргычларның барысын да Хәйдәргали абзый ясаган. Куллары оста, белмәгән эше юк.

Укый башлаганның икенче көнендә Хәйдәргали хәлфә Лотфуллага ике дәфтәр белән бер каләм бүләк итеп бирде. Каләм искитмәле иде. Лотфулланың андый каләмне беренче мәртәбә күрүе иде. Төкерекләсәң, гүшни төс чыгарып яза икән. Төкерекләмәсәң, мондый каләм кебек кенә яза үзе.

Беренче көннәрдән үк Лотфулла Мирсәет Учителнең сөйләгәннәрен, өйрәткәннәрен бик зур игътибар белән тыңлый башлады. Хәйдәргали абзый белән икәүләшеп бер китап өстенә иелеп укырга өйрәнәләр. Лотфулла имән бармагы белән китап битенә язылган сүзгә төртә. Хәйдәргали укый башлый:

—Р...рр..рре..ек... Рек-к-кка...

Икәүләшеп тырыша торгач, теге сүзне укып чыгалар: «Река» дигән сүз икән дә, татарча «елга» икән. Китаптагы сурәткә карасаң, елга икәнлеге күренеп тора «река»ның. Тагын укырга тотыналар:

—Е-ел-ль—дип укыйлар икесе бергә.—Ель!

—Ерш!—дип укый Лотфулла.

—Шыртлака дигән балык ул,—дип аңлата Хәйдәргали.—Лайла гына, тотып та булмый. Безнең татар ашамый аны.

—Андый балык булмый!—дип ризалашмый Лотфулла.—Алабуга дигән

балык бала, ә син әйткән балык булмый.

—Бар ул, бар!—ди Хәйдәргали бәләкәй дустына.—Минем үземнең дә тотканым бар аны.

—Ә нигә безнең Эстәрле елгасында юк? Шамбы да бар, алабуга да бар, чабак та бар. Хәтта чуртан да бар. Ә җәеннәр менә мондыйлар...

Ул ике кулын бер-берсеннән ярыйсы гына аерып күрсәтте.

Укулар бер җайга бардылар да бардылар. Ишек төбенә куелган өстәл артында Хәйдәргали хәлфә белән кечкенә Лотфулла, икесе бер җан булып дигәндәй, «урысча сукалап» утыралар. Учител Мирсәет аларга игътибарны бик биреп бетерми—башкалар белән күбрәк мәшгуль.

Укучы балалар арасында һәрчак төрлесе була. Сәләтлесе дә, сәләтсезе дә, тырышы да, ялкавы да, шаяны да, сабыры, тынычы да. Шунлыктан тиз аңламаганнар белән, артта калганнар белән күп шөгыльләнә Учител. Мирсәетнең холкы сабыр, беркайчан да тавышын күтәрми, малайларга кычкырмый, аларга сукмый. Ачуы килгән чакларда әйткән иң авыр сүзе: «Мөртәт!» Шаярса, яисә дәресен белмәсә, ул малайны өстәле янына чакырып ала да, иптәшләренә каратып бастырып куя. Озакка сузмыйча вәгазъ укый:

—Син бит туган, мөртәт түгелсең лә инде. Тамагың ачмы? Ач булсаң, болай шаярмас идең. Түгел бит?

—Түгел,—ди малай бик үк исе китмәгәнне күрсәтергә тырышып.

—Әллә бозау булдыңмы?

—Нигә-ә?

—Нигә, имеш! Ник җиңеңне чәйнисең?

Иптәшләре көлешә башлыйлар. Учителгә шул гына кирәк тә инде. Урысчага күчә:

—Дай слово. Что больше так не будешь.

Монысына инде белсәң-белмәсәң дә, теләсәң-теләмәсәң дә урысчалатып җавап бирергә кирәк. Малай аркасында, ике калак сөягенең нәкъ урта бер җиреннән тир тамчысының аска табан юл ярып төшә башлаганын баскан җиреннән сизеп тора. Анысы артыннан икенчесе, өченчесе. Ә татарча уйлаган баш, урыс сүзләрен искә төшерми. Малай уйлана-уйлана баш миенең сыеклана башлаганын сизеп, баскан җирендә тораташ кебек катып тик тора. Шуннан, көчәнеп уйлый торгач, җавап таба бугай. Сөенеченнән күзләренә җан керә башлый. «Урысчалый» бу:

—Бул-ллше-е ни бу-уди-ишш!!!

—Как, как? Повтори правильно!—дип җилеккә үтә Учител. Малай да төшеп калганнардан түгел, тавышына көрлек өсти дә кабатлый:

—Булше ни будеш маяныкы!

Мирсәет тынып калган малайларга карый:

—Кем дөрес иттереп урысчалап әйтә ала: «Сүз бирәм, башкача кабатламам!»—дип. Ягез әле эшләтегез башыгызны.

Малайлар күзләрен өстәл такталарына тегеп дәшмиләр. Иң арттагы өстәл артында утырган Хәйдәргалинең тавышы ишетелә:

—Кая, энем, мин әйтеп карыйм әле?

—Энем түгел, ә гаспадин учитель!

—Гаспадин учител!

—Прашу минә прастит. Булше ни буду баловайт. Читайт буду книга.

—Вот ичмасам, молодец, Солтангалиев. Ә син әйткәннең иң дөресе менә болай ишетелергә тиеш...

Учител кабаланмый гына Хәйдәргали әйткәнне кабатлый:

—Прошу меня простить, больше не буду баловаться. Книгу читать буду. Понятно теперь?

Үзләреннән сорамаганга куанган малайлар дәррәү акыралар:

—Панятна-а!!!

—Повтори, Султангалеев!

Хәйдәргади абзый урысчалап, дөрес итеп кабатлый. Мирсәет күңеле булып елмая:

—Хәзер инде урысчалатып рәхмәт әйт!

—Ыспачиба!

—Дөрес итеп әйтергә кирәк. Менә болай итеп: Спа-аси-ибо! Урысның ул сүзе ике сүздән килеп чыккан: «Спаси» һәм «Бог». Алла коткарсын дигәнне анлата—спасибо! Әйдәгез әле барыбыз да бергә шул «спасибо»ны әйтик. Бер-ик-ке: «Спа-а-а»...

Бүлмә урысчалатып акыра: «Спа-а-си-и-бо-о!» Үзен «онытканга» куанып өстәл янында иптәшләренә йөзе белән борылып басып торган теге малай да кушыла. Иң кәчлесе аның тавышы инде. Учител Мирсәет малайның кәләпүше астындагы ялтыратып кырылган «татар башына» елмаеп карый да аңарга урынына утырырга рөхсәт итә:

—Бар урыныңа. Шаярма башкача алай. Шаярсаң да башкаларга да күңелле булырлык итеп шаяра бел. Иди, садись! Не балуй больше!

Кайсебер көнне ишек аз гына ачыла да, анда Сара апаның чибәр елмаюы күренә:

—Акыллы-ым!—ди ул пышылдап кына Лотфуллага.—Чык әле бирегә-ә! Малай сораулы күзләре белән Учителгә карый. Тегесе тавышсыз гына баш кага: «Бар, чакыргач!» Шулай да Лотфулланың дәрестән чыгып китүен Мирсәет Учител өнәп бетерми. Чөнки ул күреп тора—ишек ачыла башлаганда шыгырдаса, малайның йөзендәге нуры сүнә. Бу баланың ярлылыкта, хәерчелектә, ялангачлыкта узган көннәрендә шушы урысча уку дәресләре аның өчен бердәнбер шатлык. Моның шулай икәнен, Учител яхшы белә, шунлыктан Лотфулланы кызгана, аның укуын тели иде дә...

Лотфулла уку әсбапларын әнисе тегеп биргән корама букчага тутыра да, акрын гына атлап чыгып китә. Анда инде аны түземсезләнеп Сара апасы көтә.

—Мин зур абыстайларга ашка барам,—ди ул. Аның өстендә йомран тиреләреннән тегелгән йөнтәс тун, башында ике каз канаты куелган йөнтәс җирән хатын-кызлар гына кия торган бүрек, аякларында тезләренә җитеп торган матур Казан итекләре.

—Гомәр белән Вәлиәхмәтне яхшы кара. Егылмасыннар, еламасыннар. Гомәр Вәлине җәберләмәсен. Тегесе абыйсына сукмасын. Уенчык бүлешеп тартышмасыннар, сугышмасыннар. Мин бик озак булмам анда. Күрше Минзаһида апага йөгереп кереп кенә әйтеп чык, бер коянтә генә фантал суы китерсен. Чәйгә. Кече агач табакка тутырып бәрәңге әрчеп куй. Аңладыңмы, акыллым!

—Әй-йе! Аңладым, Сара апа!

Сара апасы яшь кәҗә кебек вак-вак кына атлап, тыкрыктан тау түбәненә төшеп тә китте. Чибәр Сара апа. Үзе беркайчан да әрләмәс, тавышын күтәрмәс. Лотфуллага эшне күп иттереп кушкан чакларында да тик «акыллым» дип кенә эндәшә. Үзләре белән табынга утыртмаса да, көненә берәр мәртәбә, кайчак икешәр рәт тә әле утыртып ашата. Олы гына берәр ипи кыерчыгы да бирә, берәр җомаяк токмачлы куе аш сала. Ашы итле дә була әле кайчакларда. Ә Лотфулла бик тырышып эшли шуның өчен дә, акыллым дип дәшкәне өчен дә. Кичә кичен ышкул каравылчысы Гыйбәт бабай кисеп ярган утыннарны да кертеште аңарга. Бабай да мактады үзен, Сара апа да. Идәнен дә себерә, базга төшеп бәрәңге, кишерен дә алып менә. Сара апасы кер юганда, су ташый, юынтык суларын чыгарып түгә. Шулар арасында Лотфулланың иң төп эше—ике ташбаш малайны карау. Олысы—Гомәр исемле. Ул—дүрте тулып бишкә китте. Ә кечесенә ике генә яшь әле. Бертуктаусыз такылдый үзе. Сара апа малаеның шатыр-шотыр иттереп кара күмер ашаганына көенә.

—Лотфулла-а! Акыллы-ым! Тагын күмер ашый бит. Вәлине тотыйк инде.

Бүлмәне урап-урап йөгергән малайны тотып алалар да, акырта-акырта авызындагы күмерне алырга тырышып карыйлар. Малай тешләрен нык иттереп кыскан, ике куллап авызын япкан да, аны ачмыйча гына кычкыра:

—М-м-м-м!...

Авызына бармак та тыгып карыйлар. Ачмый барыбер.

—Ач авызыңны! Ач, дим мин сиңа! Ач!

Сара апа чибәр, нечкә-озын бармаклары белән малайның түгәрәк ике битеннән тотып селкеткәли. Малай барыбер авызын ачмый. Әнисе артына сугарга үрелгәндә, тиз-тиз генә берничә мәртәбә күмерен чәйнәп тә ала. Ә малайның әтисе, Мирсәет абыйсы малайның күмер ашаганына бик тә тыныч карый:

—Нигә тиясез инде аңарга! Ашасын! Вөҗүденә кирәктер, шуңа ашый да ул. Җибәрегез минем үскән улымны иреккә. Ашасын күмерен!—ди.

Лотфулланың көннәре урыс ышкулында үтүгә әтисе дә, әнисе дә каршы түгелләр. Бигрәкләр дә әнисе куана:

—Ходайга шөкер! Бер юнен биреп тора ул шулай! Лотфулламның тамагы да тук, өсте дә азрак бөтенәйде.

Әтисе башкачарак итеп әйтеп куйды:

—Эшлә, улым! Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен! Сорамыйча бер әйберләренә дә кагылма. Кешенеке икәнне һәр чак хәтереңдә тот. Малайларына сукма—сабыйлар бит алар. Эләккәндә укып та өлгер.

Эшенә иренмәде Лотфулла. Чибәр апа нәрсә генә кушса да, барысын да җиренә җиткереп эшләп куйды. Йомышына да йөгерде, суга да барды, бәрәңге дә әрчеде, кар да көрәде, теге ике шук малайны да карады. Алар белән качышлы, атлы уйнады. Тик Лотфулланың да бай малайлары кебек ышкул эченнән чыкмастан утырып, Мирсәет абыйсы укып, тәрҗемә иткән урыс хикәяләрен, әкиятләрен тыңлыйсы килә иде. Эштән аз гына арынса да, ул уку бүлмәсенә ашыкты.

Рәхмәт төшкере Хәйдәргали абзыйга. Лотфулла юк чакта үтелгән дәресләрне, ул керүгә бер урынга җыеп, әзерләп куя. Кайсыбер көнне ышкулдан да бергә кайткалыйлар. Тик Лотфулла Хәйдәргали абзый унаена атлый алмый—суыкка түзә алмыйча, күлмәкчән генә көенә алдан йөгереп кайтып китә. Аның өстендә бишмәте юк. Йомыш-юлга гына булса да кул арасына кирә торсыннар дип, әтиләре ике малаена агачтан каталар ясап бирде. Өтерге белән сөян агачын чокып. Чокып бетергәч, каталар эченә кызу күмер тутырып тигезләде. Ком белән ышкып шомартты.

Тәүге көннәрдә дәрес тыңларга дип, катасын кигән көенә керде Лотфулла. Чөнки катасы эченнән кияргә бернинди оекбашы да юк иде. Тик менә Учител Мирсәет абый аның каталарын тиз салдырды.

—Син Лотфулла каталарыңны тышта ук салып кер. Югыйсә, кары эреп иданне юешли. Ә бит идәндә учениклар оекбаштан гына йөриләр. Аяклары юешләнә. Яхшы түгел. Шунлыктан ярамый ката белән керү.

Шул көннән соң ике агач ката тышта, болдырда кала башладылар. Тик...

Берничә көн узгач, Лотфулла кайту исәбе белән болдырга чыкты да, кияргә дип каталарына үрелде. Каталарга тотынгач ук сизде—алар нилектәндер гадәттәгедән авырлар иде. Иелеп карады. Әңгер-меңгер, караңгы төшеп бетмәгән чак иде әле. Кичнең соңгы яктылыгында Лотфулла күреп алды—ката эчләре сарырак төстәге боз белән туп-тулы иделәр. Шул чакта, артта, өй алды ишеге артында берничә малайның «пск-пск» килеп көлешкәннәре ишетелде. Һәм аерым-аерым сүзләре дә ишетелеп киттеләр.

—Хәйбулла бит... ката эченә...

—Ә?... нишләгә-ән?

—... сигән... туңган инде... менә-ә!

Лотфулла эчләре сидек белән тулган ике катаны кулларына алды да, ялан аяк килеш ышкул тыкрыгындагы бозланып каткан, шомарган кышкы юлдан томырылып кайту ягына йөгерде. Аның артыннан «һай-һу»лап акырган, сызгырган тавышлар ишетелеп калдылар. Тик күлмәк-ыштан гына кигән ярлы балтачы Зәйнетдиннең улы Лотфулла алдын-артын карамыйча җан фәрманга җил белән ярышып чаба иде...

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ



**Илдар Юзеев**

**ЙӨРӘГЕМӘ ЯТЫП ЯЛ ИТКӘЧ**

## Таулар күкрәгеннән чыккан җыр

**Гомерем буе таугa—Күккә ашып,
Түбән төшә-төшә ялыктым.
Тукталдым да Урал итәгенә,
Йөрәгемә ятып ял иттем.
Ишетелде шул чак серле бер җыр,
Ардым инде, талдым дигәндә:
"Төшсәң дә син Җиргә—бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә..."
Табигатьне, йөрәгемне айкап,
Яшәртте җыр Җирне-Күкләрне.
Таулар күкрәгеннән чыккангадыр,
Ул мине дә биек күтәрде.**

## Илдә җырлар җыеп йөргән чакта...

*Башкорт шагыйре Рәми Гариповка*

**Бик-бик теләсәм дә, соңга калдым,
Рәхмәт әйтәлмәдем Рәмигә.
Илдә җырлар җыеп йөргән чакта,
Ямадыга кергән әнигә.
Әнкәйдән ул үз улларын сагынып
Язган шигырьләрен сөйләткән.
Безне тирбәтүче бишек җыры
Агылгандыр арган йөрәктән.
Әнкәй дә юк хәзер, Рәми дә юк,
Ә җырлары һаман җылылар.
Миндә генә түгел, Рәмидә дә
Әнкәйләрнең сагыну моңы бар...**

## Без үзебез...

Читтәгеләр,
Туган телебездән
Сез еракта—алыс тордыгыз.
Ник, нигә сез газиз әнкә телен
Чит бер телгә алыштырдыгыз?

Мондагылар,
Сез бит туган телнең
Үзәгендә генә тордыгыз.
Ник, нигә сез җанга якын телне
Ерак телгә алыштырдыгыз?

Туган телнең әткә-әнкәләре...
Без ул—ерак, алыс торганы.
Күреп, карап, сизеп, түзеп тордык
Бала—телен алыштырганны...

## Китәм, диден...

*Фасил Әхмәткә*

Хәсрәт-сагыш тулы тавыш белән
Шылтыраттың миңа бүген дә:
"Фатир алу өчен китәм, диден,
Яшим ич мин ишек төбендә".
Күңел тартты гел-гел югарыга—
Хыял җитмәс Илаһ күгенә.
Фатир сораганда төштек инде
Түрәләрнең ишек төбенә.
Ничә гасыр газап чигәбез без,
Һич күнегеп булмый бүген дә...
Туган телебез дә, үзебез дә
Түрә телнең ишек төбендә.
Ераккарак, йөрәккәрәк китик
Түрәләрнең ишек төбеннән,
Күпме генә аска тартсалар да,
Төшмәдек без иҗат күгеннән!
Аңлыйм, дускай, авыр—бу тормышның
Кырыс җилләр искән үрендә.
Юк, китмәбез, без яшәрбез әле
Үзебезнең өйнең түрендә!

*12.10.97.*

... Китеп бардың кайтмас мәңгелеккә,
Симфония булып күкрәргә.
Син яшисе фатир көткән икән
Таң йолдызың янган Күкләрдә...

*10.09.98.*

## Тимер ташкын килә...

Хәтеремдә:
бала чагымда,
авыл урамында
Абый чыкты мине кулдан тотып.
Сизми калдык:
Ике нәни җанны куркытып,
Тыкырыкта бер ат күренде.
Кулдан ычкындырган Нил абый.
Ат астында калдым мин-сабый.
"Беттем..."—дисәм,
Мин—исән...
Атның дүрт тоягы тими үткән икән.
Кара дуга
ал офыкка китеп күмелде...
Сикереп тордым.
Җанда курку хисе сүрелде.
Куллар Нил абыйга үрелде.

... Тимер ташкын килә
урамнарны йотып:
китәр сытып,
аждаһадай килә куркытып.
Чыктым юлга оныгымны тотып.
Тимер ташкын килә каршыма.
Сак булыгыз, шәһәр оныклары!
Онытмагыз, шәһәр картлары:
Ал офыкка китеп күмелделәр
Авыл атлары...

## Су анасы монологы

*Казандагы Тукай мәйданы каршындагы*
*Су анасы сынындагы таракны каерып алганнар.*

Озак-мәңге хыял-экияттә—
Су астында ятып кем чыдар...
Аңладылар, Казан урамына
Алып кайтты мине сынчылар.
Озын чәчләремнең таң җилендә
Тараласын, ахры, тойдылар:
Рәхмәт инде, алтын булмаса да,
Тимер тарак алга куйдылар.
Әкияти бер хозурлык сиздем
Яшьләр миңа карап узганда.
Чәчләремне тарыйм әле диеп,
Тарагыма кулны сузганда,—
Казан караклары тарагымны
Кулларымнан тартып алдылар,
Бирмәскә дип күпме тырышсам да,
Каерып һәм ватып алдылар.

Берни булмагандай, салкын гына
Узгалыйсыз миңа карап сез...
Әкият тә, урам гүзәле дә—
Мин берни дә түгел тараксыз.
Әнкәләре тәрәзәсен ачмас,
Минем арттан "һау!"лап эт өрмәс.
Бу экият түгел, башка дөнья,
Тарагымны беркем китермәс.
Нишләдең? Син—мине-экиятне
Үзең иҗат иткән халык бит!
Мәйдандагы Тукай абыем-җаныем,
Зинһар тизрәк моннан алып кит!
Тузган чәчләремне күрсәтмичә,
Кара төнгә яшереп үтәм мин.
Гүзәл булу сездә мөмкин түгел,—
Су астына кире китәм мин...

## Бәхет әле синнән ерак йөри...

“Беттем, сүндем, артык түзә алмыйм,
Яшәү—бигрәк ямьсез, авыр бик...”
Күтәр башың, энем, кара күккә:
Күкләр нинди серле, матур бит!
Төн. Караңгы әле. Ай күренми...
Әмма Кояш барыбер калкыр бит.
Көнне каршылавы—үзе шатлык!
Таң йолдызы нинди матур бит!
Бәхет әле синнән ерак йөри,
Кайчан булса да ул калкыр бит.
Бу яшәүнең һәр мизгеле—бүләк,
Җир гөлләре бигрәк матур бит!
Юллар ярам. Бәхетемә барам.
Ул еракта, кайчак якын бик.
Җанда нәни генә өмет яна:
Яшәмәскә минем хакым юк!
Тукталабыз кайчак башны иеп:
Гомер итүләре авыр бик...
“Бу тормышны матурайтам! “ диеп
Яшәүләре—үзе матур бит!

• • •

Рәсемеңне ясыйм хыялымда:
Күзләрең—диңгез,
Чәчләрең—дулкын,
хисләрең—ташкын,
карашың—упкын.

Ни булса да түзәм юлларымда:
күзләрем—маяк,
чәчләрем—җилкән,
тынычлан, диңгез,
мин киләм, иркәм...

## Август чәчәкләре

Август чәчәкләре, кайчан гына
Балкып-көлеп яна идегез.
Көз салкынын сизеп, боектыгыз,
Башыгызны түбән идегез.
“Вакытында су да сипмәде” дип,
Рәнҗемичә генә корыгыз.
Мин беразга гына калам әле,
Мәңгелеккә бара торыгыз.
Якын дус-ишләрем арасында
Яшәсәм дә уйнап-көлеп мин,
Ялгыз калган чакта бик тә уйчан,
Август чәчәкләре кебек мин.
Дусларыма кереп барам әле
Яшьләремне тыеп көләргә.
Кышларыма кереп барам әле
Яшьлегемне коеп җилләрдә...

## Тагын бер дәрәҗә тактылар

Мулла нәселе дә җиткән иде,
Тагын бер дәрәҗә тактылар:
Шәҗәрәмдә—бик эзләнә торгач,
Морза икәнемне таптылар.
Иске-москы Ямадыда туып,
Шул тормышка риза булганмын,
Черек кәлҗәмәләр капканда ук
"Чабаталы морза" булганмын.
Ничә еллар кагылып та сугылып,
Морзалыктан китә барганмын,
Авызымны ачсам, бер чакрымнан
Күренеп тора һаман бәрәңгем.
КГБга рәхмәт, ул елларда
Табалмаган кат-кат тикшереп.
"Сыйнфый дошман" диеп, Себерләргә
Озатырлар иде "өшкереп".
Халык малын талап баеганнар,
Кайсы булсагыз да берегез
Үзегездән арткан коттеджны
Юзи хәзрәтләргә бирегез!
Кайтарыгыз мине морза бабам
Гомер сөргән сарай, утарга.
"Тот капчыгың!" диеп әйтсәгез дә,
Капчыгым да юк шул тотарга.
Еллар мине юлга чыгардылар,
Чабатадан күчтем итеккә.
Әмма ямаулардан котылмадым
Ямадыдан ерак китеп тә...
"Саумы, Юзи морза? Хәлең ничек?"
Язмыш минем белән шаяра.
Ачы яшькә, канга ямеренеп
Дәшә миңа боек шәҗәрә.
Мөлкәт-байлык миңа кирәк түгел,
Сарайларда рәхәт күрегез.
Сабыйларча бер мактану өчен,
Титулымны гына бирегез!
Әтрәк-әләм, ялкау теш кайрарлар,
Морзадашлар, бәлки, үз күрер,
Әмма теге заман кире кайтса,
Җиде әбиемне өшкерер.
Нәсел газаплары искә төшкәч,
Дөресен генә әйтим, шүрлимен.
Шагыйрь булу гына җитмәгәнме,
Морзалыкка нигә үрлимен?
Киеп шигъриятнең чабатасын,
Килә минем көн-төн чабасым,
Килә милләтемне баетасым:
Рәмиевләр Дәрдмәнде кебек,
Уй-моң алтыннарын табасым...

*1996-1998*

## Чәчмә әсәрләр



# Каим Шәйхетдин

## КЫШЛАР УЗАР...

ХӘРБИ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Телефон төребкәсе юрган астыннан сузылган кулга эләккәнче кыңгырау тавышы үзенекен итте: аның ачы чылтыравы өйдәге төнге тынлыкны юкка чыгарды.

—Тыңлыйм,—диде Шәймәрдәнов карлыккан тавыш белән.

—Беренче номерлы әзерлек, иптәш подполковник!

—Аңладым, хәзер килеп житәрмен!—Ул төребкәне урынына куйды.

Йокының эзе дә калмады. Өстәл өстендә яшел күзен ялтыратып торган электрон сәгатькә күзен ташлады Кадим: төнге өч туларга уникe минут иде. «Тревога» хәбәре армия штабыннан булса, ике минут чамасы вакыт үткән. 15 минуттан ул полкның команда пунктында булачак.

Әйе, полк командиры подполковник Шәймәрдәнов бер дә юкка гына КПга якын урындагы йортка күчеп килмәде. Дөрес, хатыны Халисә озак кына тукыды: балалар турында уйлыйк, күчми торыйк, әллә кайда шәһәр читенә диде, анда мәктәп тә начар, имеш, укытучылар да тегеннән моннан җыелганнар, яхшы белем ала алмаслар балалар ул мәктәптә... Кадимнең мондый сүзләрне беренче ишетүе түгел. Бу сүзләр күбесенчә, тар карашлы офицер хатыннары арасында йөри. Халисә белән озак сүз көрәштермәде, кыска гына әйтеп куйды: «Шулай кирәк, Халисә! Хезмәт шуны таләп итә». Аннан соң, бераз вакыт үткәч, инде күчеп китәр алдыннан, сүз уңаен китереп, хатынын юатты: «Менә дигән саф һава анда. Тирә як—урман. Трамвайлар дыңгырдамый, завод трубалары төтен очырмый, һаваны агуламый. Мәктәбе дә яхшы анда. Хәер, мәктәпнең яхшылыгы, начарлыгы үзәктә яки читтә урнашканга карамый ул. Шәһәренә дә карамый. Мәскәүдә әнә бәлки бөтен мәктәпләр дә безнең мәктәпләрдән яхшы якка аерылып торадыр да, ләкин яхшы укучылар анда дип уйлыйсыңмы? Ялгышасың. Бөтен атаклы кешеләрнең уннан тугызы перифириядән чыккан. Шуны онытма». Халисә дә инде бу күченүгә эченнән ризалашкан иде инде, шуңа күрә: «Анысы шулай инде, атасы,»—дип кенә куйды.

Менә, озакламый ел тула күчкәннәренә, бөтен эшләр ярыйсы: хезмәт тә, мәктәп тә, өйдә дә.

---

Каим ШӘЙХЕТДИН (1936)—*отставкадагы подполковник. Матбугатта аның «Вьетнам язмалары», «Яшерен сәфәр», дигән повестьлары «Маршалның имән таягы» дигән хикәясе дөнья күрде. «Казан утлары»нда беренче тапкыр басыла.*

Кадим полкка килеп тә житте.

Кизү офицер КППның тышкы ягына ук чыгып тора. Командир бу юлы рәсми рапорт алып тормады, тик: «Гадәттәгечәме?»—дип сорагач, «Нәкъ шулай, иптәш подполковник,»—дигән җавапны алды да, ашыгып узып китте.

Команда пункты имәнлек уртасына, җир астында урнашкан. Аннан кырык-илле метр чамасы ераклыктагы кызыл кирпечтән салынган бер катлы бинада—казарма. Агачлар арасына эчкәрәк керсәң, төрле хуҗалык корылмалары, уң якта радиолокаторлар урнашкан. Шул тирәдә үк җир астына яшереп куелган электростанция. Радиолокаторларның антенналы кабиналары өеп эшләнгән калкулыкларга куелган, алар әллә кайдан ук күренеп тора.

Шәймәрданов биеклектә урнашкан үз урынына узганчы, элемтә буенча кизү сержантның рапортын алды, кулын биреп күреште. Гадәттәгечә оператив залны хуҗаларга хас булган караш белән айкап чыкты: операторлар, планшетларда эшләүчеләр, элемтәчеләр—һәммәсе үз урыннарында иде. Барысы да эшкә әзер. Залда тып-тын диярлек, тик әллә каян, ишетелер ишетелмәс кенә вентиляторлар эшләгән тавышны шәйләп була. Димәк, аппаратура кабызылган. Өскә күтәрелеп эш урынына утыргач, экраннарга, дисплейларга, таблоларга күз ташлады. Зәңгәр, кызыл, ак сигнал лампалары ялтырый. Локатор экранында ялтыравык сызык, антенналар хәрәкәтен кабатлап, әйләнә бирә. Ул һавада, җирдә булган нәрсәләрдән чагылып кайткан радиодулкыннарның хәбәрен язып бара. Дисплейда саннар, хәрефләр, сүзләр җемелдәп-җемелдәп берсе артыннан берсе алмашынып тора. Каршыдагы зур планшеттагы электрон сәгать 2.59ны күрсәтә иде.

Кадим, кирәкле кнопкаларга басып, дивизиянең оператив кизү офицерын чакырды.

—Тыңлыйм,—әллә ничә йөз километр ара үтеп килгән тавыш рәттән басып торган кешенеке кебек ишетелде. Бу—подполковник Калашниковның тавышы иде.

—Шәймәрданов сөйли. Хәерле иртә, Алексей Михайлович. Мин урынымда. Полк сугышчан әзерлеккә китерелә. Вакыт бар әле, бераздан кизү офицер тулысынча җиткерер. Килештекме?—Бераз көтеп торып җавап ишетмәгәч, сорады:—Сез мине ишеттегезме?

—Ишетәм, бик яхшы ишетәм, Кадим Каюмович. Син, гадәтенчә, бик тиз килеп җиттең. Хәлләр шундый: өстән сезне генә күтәрделәр, күршеләрең барысы да рәхәтләнеп йоклап ята әле.—Илле яшьләргә җитеп барган подполковник Кадимгә дә «син» дип сөйләшергә ярата иде. Дәрәҗәсенә мазар карап тормый ул, үзеннән яшьрәк теләсә кемгә «син»—яраткан сүзе.

—Аңладым. Яңалык булса кичектермәгез, мин үз урынымда.

«Ни сәбәпле безне генә күтәрделәр икән?»—дигән сорау Кадим күңелендә тотылып калды. Моны хәзергә бер кем дә белми әле, чөнки югарыдагы командирлар урыннарына да килеп җитмәгәннәрдер. Хәер, җитсәләр дә сиңа шалтыратып аңлатып утырырга вакытлары булмас, һәр кешенең мондый вакытта үз кайгысы кайгы.

Кулына телетайп кәгазе тотып кизү офицер капитан Коновалов килеп керде һәм кәгазьне сүзсез генә командир алдына салды. «Полк командирын ашыгыч рәвештә үз урынына чакырып китерегез. Килү белән телетайп буенча зенит-ракета гаскәрләре башлыгы генерал-майор Елисов белән турыдан-туры элемтәгә керсен. Армиянең оператив кизүе полковник Петровский».

Шәймәрданов урыныннан торды. Дулкынлануын капитан Коноваловка күрсәтергә теләми иде, әлбәттә. Буйсынган кешегә командир үзенең каушап калганын да, икеләнгәнен дә сиздермәскә тиеш. Мондый вакытта буйсынган кешеләр синең тәвәккәллегеңне һәм кыюлыгыңны гына күрсен. Шуларны күреп, үзләренең командирларына ышанып эш иткән солдатлар

һәм офицерлар сугыш вакытында үзләрен җыйнак, тәвәккәл тоталар, каушамыйлар һәм җиңүгә ирешәләр. Шәймәрдәнов моны китаплардан укып та, тормышның дистәләгән мисалларын күреп тә үзләштергән иде инде. Тик аны белү белән эшкә ашыру арасы җир белән күк кебек ерак шул. Бөтен хезмәт юлында Кадим шул ерак араны якынайтырга тырышты.

Күп юллар үтте подполковник Шәймәрдәнов, нинди генә кешеләр белән очрашмады, күптөрле гаризоннарда хезмәт итте. Хәтта ерак Вьетнам җирендә бер елдан артык чын дошманнар белән сугышып йөрде. Анда чакта ничәмә мәртәбә бомба астында калды. Һәммә җан иясенә хас булган курку, шикләнү кебек нәрсәләрдән барыбер бөтенләй үк арынып булмады. Шулай да күпкә ирешә Кадим. Менә әле дә аның йөзеннән-чыраеннан, хәрәкәте-кыланышыннан капитан Коновалов тәвәккәллек һәм үз-үзенә нык ышанган кыю командир гына күрде, аңа карап сокланды, ул нинди боерык бирсә, шуны гына үтәячәк иде ул.

Телеграфчы солдатка ымлап кына утырырга кушып, Шәймәрдәнов аның кәнәфие артына басты да, аппаратка төбәлде. Йомшак кына әйтте:

—Дулкынланмаска, бернинди хатасыз эшләргә! Булдырырсыңмы, Егоров?

—Тырышырмын, иптәш подполковник.

—Тапшыр: полк командиры подполковник Шәймәрдәнов аппарат янында. Генерал-майор Елисовны, аның боерыгы буенча, туры элемтә көтә.

Телеграф аппараты хәтәр тыкылдый башлады. Лентада Кадим әйткән сүзләр тезелеп китте. Солдат, тапшырып бетергән һәр җөмләсеннән соң, командирына борылып карады. Янәсе, ничек, булдыраммы?

15-20 минут барган элемтә вакытында менә нәрсә ачыкланды.

Безгә дус булган бер ил үзенең һава киңлеген бозып керүчеләрдән саклану өчен ракеталарга мохтаҗ икән. Шул илгә ярдәм йөзеннән берничә көн эчендә (вакыт бик-бик тыгыз) фәлән кадәр ракета әзерләп, самолетларга төяп җибәрергә кирәк. Ракеталарның бүтән өлешләре төрле төбәкләрдән китереләчәк, ә иң үзәген, аның төп өлешен, Кадим полкы урнашкан шәһәрнең бер заводыннан алырга. Бөтен эшләр яшерен эшләнергә тиеш, бер кем дә күрмәсен дә, сизмәсен дә! Белгечләр, ярдәмчеләр бүген үк килеп житәчәк. Бу җаваплы эшне башкарып чыгу бөтен армиягә зур бурыч итеп куела.

Сөйләшү вакытында Шәймәрдәновның күп сораулары туды, алган җавапларның күбесе канәгатьләндермәде. Ләкин ул вакланмады. Үзенә, солдатларына, офицерларына ышана иде, шуңа күрә кыска гына әйтеп, башлыкны юатып куйды: «Барысын да вакытында эшләрбез».

Оператив залга чыккач инде килеп җиткән урынбасарлары, штаб башлыгы белән кул биреп күреште, үзенең эш урынына менеп утырды. Дивизионнар белән элемтә тота торган микрофонны кулга алгач, сугышчан әзерлекне күрсәтеп ялтыраган дисплейны карап чыкты, башка экраннарга, таблоларга күз ташлады. Шушы берничә секунд эчендә Шәймәрдәнов зиһенен җыя барды, бөтен уйларын бер ноктага туплап бетерде—бөтен башкарасы эшләр, кыласы гамәлләр күз алдында иде.

—Исәнмесез, иптәшләр! Күрәм, барыгыз да вакытында сугышчан хәлгә килгәнсез. Рәхмәт.—Берничә секунд пауза.—Бүген без бик зур бурыч алдык. Хәзер сөйләп тормыйм. Бер сәгатьтән монда килеп җитегез, шуннан соң сөйләшербез. Бүгенге күтәрелү вакытында житешмәүчелекләр булса, кирәкле кисәтүләр ясагыз. Ә хәзер техник дивизион һәм КПдән башкаларга—отбой.

Шәймәрдәнов калган барлык офицерларны оператив залга җыйды, аларның бурычларын кыскача гына аңлатты.

—Штаб башлыгы! Тәүлекләр буе эшләр өчен расчетлар төзегез. Бөтен офицерлар казарма хәленә калдырыла. Тәэмин итү хезмәтенә ашау-эчүне полкта оештырырга. Нинди сораулар бар?

Сораулар күп иде. Тик Шәймәрдәнов кайберләренә генә җавап

бирде дә, калганнарын кинәшмәдә чишәрбез, дип, кешеләрне таратты.

Сәгать дүртенче яртыны узган. Сентябрь төне караңгы иде, салкынча. Күк аяз. Йолдызлар ун, йөз мең еллар элек ничек җемелдәгән булса, шулай җемелдиләр. Анда, киң галәмдә, күрәсең, үзгәрешләр безнең тормыштагы кебек түгел, бик акрын бара. Кеше аны сизми. Ул бала чагында отып калган күк күренешләре һич үзгәрми, ай да, кояш та бер алган юлларыннан йөри бирә. Һәм алар без картайгач та, үлгәч тә шул юлларыннан йөриячәкләр. Иртән җирне яктыртып кояш чыгачак, кич җиткәч баеячак. Ай бүгенге кебек үк йолдызлар арасында йөзәчәк.

Кеше гомере бик кыска шул. Ай, кояш, йолдызларныкы кебек озын түгел, бик кыска. Шуңа күрә дә инде бүгенге көн иртәгәсеннән ай кояштан аерылган кебек аерылып тора. Хәтта көннең иртәнге өлеше дә кичкесенә охшамый. Җирдә кешенең тормышы бөтерелеп, ашкынып аккан тау елгасы кебек, болганып тора. Аның агымын рәткә салу бик кыен, моның өчен күп көч һәм тырышлык кирәк. Ялгыз кеше бөтенләй көчсез бу тормышта.

Кадим сигарет чыгарып кабызды, тынычланырга тырышты. Ялгызлык һәм әкрен генә искән салкын җил тынычланырга бераз ярдәм итә кебек. Килеп чыккан ситуацияне тагын бер тапкыр анализлап чыгарга булды Шәймәрдәнов.

Хәзер аңлашыла инде: Израиль белән күрше гарәп илләре арасында барган сугыш әле ялкынланып китә, әле сүрелеп тора. Менә безгә дә килеп төртелде аның шаукымы! Турыдан туры Шәймәрдәновка, полкына килеп төртелде бит, әй! Төн уртасында тәмле йокыдан уятты... Ни эшлисең бит, Советлар Союзы белән килешүдә торган гарәп илләрен, андагы кешеләрне язмыш иркенә ташлап булмый. Шуннан чыгып эш итәргә кирәк. Башкача түгел. Сүрия бу, дип фаразлады Кадим. Ул инде бөтенләй диярлек тынычланды! Уйлар әллә кайларда йөгерсәләр дә, аның йөрәге инде тигез ритм белән тибә иде.

... Инде ике тәүлек буена хәрби аэродромда зур эш бара. Бертуктаусыз килеп төшкән, күтәрелеп киткән самолетлар, тегендә-монда чапкан машиналар, кырмыскалар кебек әш-мәш килеп кабаланган солдатлар-офицерлар, барысы да бер эш белән мәшгуль—ракеталар әзерлиләр.

Монда бөтен нәрсә уйланган: хәрби-транспорт самолетлары кайда төшәргә тиеш, кайда туктарга, бушату, төяү урыннары—барысы да билгеләнгән, бөтен эшләр хисапланып барыла, бөтен җирдә тәртип. Һәр офицер, һәр солдат үзенең вазифасын нык белә: нәрсә эшләргә, кайчан ашарга, кайчан ял итәргә. Ангарлар арасында палаткалар корылган. Палаткалар эчендә эш кайный. Ракеталарның компонетлары җыела, махсус арбаларга салынып берсенә берсе беркетелә, тикшерелә. Бөтен эшләр белән җитәкләүче штаб та палатка эчендә урнашкан.

... Шәймәрдәнов инде өченче тәүлек буена борып җибәрелгән уенчык кебек бөтерелә. Ял юк, юньләп ашау юк. Йомшак мендәргә ятып йоклау турында башка да керми инде. Заводка ике мәртәбә барырга туры килде: ни өчендер ашыкмадылар анда. Директор да, баш инженеры да: «Безнең төп эшебез бар, аңа зыян китерә алмыйбыз, күпме көчтән килә, шуның хәтле эшләрбез» кебек сүзләрне генә кабатладылар. Заводтан туп-туры өлкә комитетына китте Кадим. Анда ракеталар әзерләү турында беренче сәгатьләрдән үк беләләр иде. Административ бүлек мөдире Мухин Кадим сөйләгәннәрне тыңлап та бетермәде, беренчегә кереп китте. Өч-дүрт минуттан, беренче секретарь завод директоры белән «сөйләшә» иде инде.

Инде бөтен нәрсә җайланып китте дигәндә генә, Себер ягыннан самолет белән китерелүче ракетаның беренче баскычын кабыза торган шартлаткычлар килми башлады. Бик ашыгыч рәвештә Мәскәү вәкиле белән ике имза куеп, Себер заводына һәм Үзәккә шифротелеграмма җибәрергә туры килде. Күп вакыт та үтмәде, шартлаткычлар килеп төште, ләкин самолетта килгәндә, биеклектә һава басымы аз булганлыктан, алар

янчелгәннәр иде. Ракеталарны җибәрү тагын тукталды. Хәзер бер генә чара бар иде: шартлаткычларны полк запаслыгыннан алырга кирәк. Югарыдан рөхсәт сорарга дип торганда армия командующие генерал-полковник Гурин үзе килеп төште. Ул сүзне озакка сузмады, «китер боерык проектыңны»,—диде. Шунда ук штабта әзерләнгән боерык кәгазенә кул да куйды.

Бөтен эш урыннарын җентекләп карап чыкты командующий. Бик канәгать булып, аның белән бер адым да калмый йөргән Шәймәрдәновка борылып елмайды.

—Гафу ит, подполковник. Сине полкка билгеләгән вакытта бик шикләнгән идем. Теге, сиңа кадәр булган полковниктан соң мондый тәртипне күрермен дип көтмәгән дә идем. Беләм, безнең күршеләр әле һаман бер генә ракета да җибәрә алмаганнар. Ә бездә эшләр менә дигән бара икән. Шулай ерып чыксаң, подполковник, күкрәгеңә орден көт! Татар халкының бөек улы син!

Кадимнең бу сүзләрдән соң күзеннән яшьләр атылып чыгардай булды. Менә бит ул, ә?! Полк командиры итеп куйганнар, ә үзләренең тулы ышанычлары булмаган. Ә «татар халкының бөек улы» дигәннән соң калтыранып китте. Җавап бирми калдыра алмады:

—Никак нет, иптәш командующий! Татар халкының бөек улы түгел, ә бөек татар халкының гади бер улы.

—Нинди бөек татар халкы тагы?..

—Безнең бабайлар ун елдан артык монгол яуларын урыс җирләренә кертми торганнар. Ә үзара ызгышып, сугышып яшәгән урыс кенәзләре Бөек Болгар дәүләтенә ярдәмгә килмәгәннәр. Һәм болгар халкы ялгыз калып, кан коеп, җиңелгәннән соң, үзләре дә монгол астында калганнар. Менә шул халык чыннан да бөек булган. Соңгыларының, болгарларының, башкаласы да Бөек Болгар дип аталган.

—Мм... Татар-монгол яулары рус халыкларын өч йөз елга якын үз табан астында тотмаганнар булып чыга инде синеңчә, ә?

—Анысы соңыннан. Өлешчә дөрес.

—Син турыдан-туры әйт, булганмы мондый хәл, юкмы?

—Булган. Тик бу тирән тарихка кереп китү инде. Сүз кайсы халык бөек, кайсы бөек түгел дигәннән башланды. Билгеле инде, һәр халык үзенчә бөек. Күп санлымы ул, аз санлымы.

—Бөтенләй дөрес түгел. Бөек халык тарихта үзенең тирән эзен калдыра, ә кайбер халык турында без ишеткәнебез дә юк. Шулай түгелмени?

—Шулаен шулай ла ул. Эзләр кала. Тик кайбер «бөек» халыкның эзе ифрат канлы шул.

Командующий, үзе дә сизмәстән Шәймәрдәнов белән бәхәскә кереп китүен шәйләде инде, шуңа күрә ялгыш ычкындырган сүздән башланган диалогны бетерергә булды.

—Ярар, без еракка кереп киттек бугай. Бәхәсне башка вакытта тәмамларбыз.

—Гафу итегез, иптәш командующий, авыз йомып кала алмадым, сүзегез нечкә кылларыма тиде.

—Менә, менә! Моңарчы әллә кайда яшеренеп яткан милләтчелек кылларына кагылды диегез,

—Мин алай димәс идем...

—Ну, житте, подполковник. Аңлашырбыз әле...—диде Гурин һәм авиация генералы Митрохинга борылды:

—Бәлки безгә әбәт ашап алырга вакыттыр, ә?

Шәймәрдәнов «нәрсә әйтер инде Митрохин», дип күзләрен дивизия командирына текәде. Минем полкта ашау өстәленең әзер икәнен белә торып, очучылар ашханәсенә чакырыр микәнни, дип борчылып уйлап алды. Юк, алай итмәде аның өлкән күршесе. Командуюший полкка килеп тә, күрше частьтә ашап киткән дигән сүз таралса, җир тишегенә

кер дә кач! Дивизия командирының йөзендә елмаю чаткылары күренде. Ул әле генә булып алган сөйләшүдән туган киеренкелекне оныттырырга тырышу иде.

—Сезнең өчен әзерләнгән аш өстәленә полк командиры Шәймәрдәнов мине дә чакырган иде, иптәш командующий. Әгәр рөхсәт итсәгез...

—Киттек, алай булса,—диде Гурин.

Өстәл янында озак кына утырдылар. Ашыкмыйча гына ашлар ашагач, генералның кәефе күтәрелеп китте. Моңа тәмле итеп пешерелгән ит һәм балык шулпасы да, украинча пешерелгән борщ та һәм башка, һәм башка ит, балык, сөт ризыклары, төрле үләннәр, яшелчә-җимешләр сәбәп иде, әлбәттә. Пешекче Овчаренконың сыйлау алымнары да, авиация генералы Митрохинның очучылар тормышыннан сөйләнгән анекдотларын да өстәсәк, Гуринның кәефе күтәрелми калмаска тиеш иде инде, әлбәттә.

Өстәл янында утырганда Шәймәрдәнов үзе башлап сүз сөйләмәде. Кирәк чакта гына сүз кыстырды, җавап кайтарды. Аэродромда сөйләшүдән калган киеренкелек үтмәгән иде әле. Армия командующиена каршы сүз әйтүче кешене гомерендә беренче мәртәбә күрүчеләр Шәймәрдәновка сокланып карап тордылар. Генералның төймәләре ычкындырып җибәрелгән шинель эченең кызыл төсе башка вакыттагы кебек игътибарын тартмады Кадимнең. Командующий машинага таба атлагач, аның артыннан дивизия командиры, Шәймәрдәнов һәм тагын берничә офицер иярде. Машина янына җиткәч, Шәймәрдәнов:

—Нинди боерыкларыгыз булыр, иптәш командующий?—дип сорады. Гурин дәшмәде, ул әле генә ашарга килеп җиткән офицерларны күзәтә иде.

—Чакырып китерегез якынрак,—диде. Тегеләр җыелгач, кыскача гына бурычлар куйды, полкка ярдәмне азагына хәтле җиткерергә кушты.—Ә полк командирын (ул иптәш Шәймәрдәнов та, иптәш подполковник дип тә әйтмәде) ачы теле һәм миңа каршы сөйләшкәне өчен мактый алмасам да, эшләгән эше, куелган җитди бурычны яхшы сыйфат белән эшләп торуы өчен рәхмәт әйтми булдыра алмыйм... Самолетка хәтле озатып йөрмә, эшеңне кара.

Ике генерал машинага кереп утырдылар һәм машина кузгалып китте.

Тиешле санда ракеталар әзерләнеп бетте. Алар махсус арбаларга беркетелеп, хәрби транспорт самолетларына төялеп китә торды. Әйләнеп кайткан экипажлар белән Шәймәрдәнов ара-тирә очрашып, сөйләште. Сүриядәге хәлләрне белеште. Әллә ни күп түгел иде ул яңалыклар: Дәмәшкнең аэропорты белән генә чикләнәләр иде безнең очучылар. Башкала аэропортына төшкәч, бик ашыгып кына ракеталарны безнең офицерга тапшыралар икән дә, аның имзасын куйдырып, тиз арада һавага да күтәрелеп китәләр икән. Сүрия күгендә бик күп ракеталар шартлавын да күргәннәр...

Югары штаблардан килгән хезмәткәрләр һәм инженерлар үзләренең вазифаларын үтәп бетереп, кайтып китә башладылар. Әллә ни ярдәмнәре булмаса да, кирәксә кирәкмәсә, эш барышына тыгылып, комачаулык китерүчеләр дә булмады түгел. Әрсезрәкләре Кадим янына килеп, нинди зур эшләр башкарып чыктык, моны билгеләп үтик, утырып алыйк, дигән булып, аптыратып бетерделәр. Вакытым юк ич, әнә үзегез күрәсез бит, ни хәтле эшләр кала сез киткәч, дип Кадим мондый тәкъдимнәрне кире какты.

* * *

Армия политбүлеге начальнигының урынбасары полковник Петров башкалар белән бергә кайтып китмәде. Нииндидер эшләр табып полкта кала бирде ул: Полк политбүлеге начальнигы Швалев белән

бөтен подразделениеләрне йөреп чыктылар кебек. Нинди эшләре табылгандыр, бу турыда кызыксынырга Кадимнең вакыты юк иде әле. Һәм, ниһаять, йөрүләре бетте бугай—полковник Петров Кадимне чакыртып алды. Ул Швалев бүлмәсендә бер үзе генә утыра. Йөзе бик кырыс. Әңгәмәне рәсми генә тотарга уйлый иде шикелле.

—Утырыгыз, иптәш Шәймәрдәнов. Сөйләшәсе сүзләр бик җитди. Мин, политработник буларак, бу әңгәмәне кичектерә алмыйм. Үзем белән үк сезнең командующий белән сөйләшкәндәге кыланышыгыз турында материаллар алып китәргә тиешмен.

—Нинди кыланыш турында, иптәш полковник? Мин аңламыйм сезне!—диде Кадим, нәрсә турында сүз барасын аңлап алып, әмма әле белмәмешкә салышып.

—Нинди кыланыш имеш... Безгә күптән ишетелә иде инде сезнең милләтче икәнегез турында. Сез һәрвакыт үзегезнең татарлыгыгызны күрсәтеп йөрисез. Менә хәзер ачыкланды инде ни өчен сез үзегезнең тирәгезгә татарларны туплаганыгыз...

—Ничек? Мин үз тирәмдә татарларны туплыйммыни?—Кадим түзә алмады, полковникны кискен бүлде.

—Шулай шул. Шулай килеп чыга. Машинагызны йөртүче—татар, бер урынбасарыгыз—татар, ике служба начальнигы, икесе дә капитан,—татарлар. Эзләп карасаң тагын бардыр әле...

—Соң, сез әйткән өч офицер мин монда килгәнче үк үз урыннарында хезмәт итәләр иде бит. Миңа хәтле булган полк командиры полковник Мешков татар түгел, ләбаса! Кем туплаган соң аларны, минем киләсене белепмени? Алай булса да мин гаепле түгел монда, яла якмагыз миңа! Әгәр командующий, уйламыйчарак, «шаярып» җибәргән икән, мин аңа үземнең фикеремне әйттем. Һәм тагын кабатлап әйтәм, рус халкын гына бөек халык дип атау ул—Совет илендә яшәгән башка халыкларны түбәнсетү. Рус халкы вәкилләре үзләренең мондый сүзләре белән башка милләт кешеләреннән көлмәсеннәр иде.

—Син нәрсә монда миңа дәрес биреп маташасың әле?! Бу барыбызга да билгеле: тик бөек рус халкы гына милли азчылык булган халыкларны азатлыкка алып чыкты.

—Белмим, азатлыкка алып чыкты микән, әллә юк микән? «Азатлыкка» чыккан халыклар ни өчен үзләренең телләрен югалтып бетереп баралар соң? Әллә русификация политикасын бик ятратканга дип уйлыйсызмы?

—Так, так! Менә ничек аңлыйсыз икән сез безнең партиянең политикасын. Ничек сез шул партия сафында тора аласыз, оят түгелмени? Кем сезгә рекомендация бирде? Шушы көнгә хәтле мондый милләтчене партия сафында тотабыз—без дә инде...

—Лаеклы кешеләр бирде миңа рекомендацияләрне! Ә партиядә мин менә шундый уйларымны ачык итеп ярып салыр өчен торам. Мин милләтче түгел, сезнеңчә аңлаган мәгънәдә милләтче түгел! Киресенчә, мин—интернационалист. Сез үзегез менә—шовинист, бөекмилләтчел шовинист! Рус теленнән башка берәр тел беләсезме? Ә-ә, шулаймыни? Димәк, сез башка халыкларны ихтирам итмисез!

Петровның битләре кып-кызыл булып бүртенеп чыкты, ул булдыра алса, Кадимне бер сугуда юк итәргә әзер иде. Ләкин аның алдында болай гына юк итәрлек кеше түгел иде шул.

—Ну, бетте! Мин барсын да аңладым! Синең белән парткомиссия телендә генә сөйләшеп булачак. Әйе, парткомиссия карары сезне тиз вакытта партиядән куу турында булырга тиеш! Политбүлек мөдире кая карап торган? Нигә мондый карашлы командир белән эшләп яткан? Аннан да сорарбыз парткомиссиядә. Мондый командир полк алдында куелган бурычларны үти аламыни?

—Ә сез, политработник, бер генә дә хәрби профессия белмәгән кеше, ничек минем эшләремә бәя бирә аласыз, ә?!

—Алырбыз, алырбыз, кайгырмагыз!

—Мин кайгырмыйм, сез үзегез баш ватыгыз... Дөрес, сез хәзер моның өчен бөтен көчегезне бирәчәксез. Тик бу гаделлек булырмы соң? Сез үзегезне гадел кешеләр дип саныйсыз, шул турыда теләсә кайда сөйләп йөрисез, шулай дип бөтен армияне тәрбиялисез...

—Без—политорганнар, армиядә партия вәкилләре! Безгә шундый җаваплылык йөкләнгән һәм без партия куйган бурычларны тулысынча үтәп чыгачакбыз.

Кадим башын читкә борды, йөзен чытты һәм үзалдына көлемсерәп куйды. Мондый сөйләшүне дәвам итүдә бернинди файда да юк иде. Моны Петров та аңлады.

—Минем башка әйтәсе сүзем юк...

—Минем дә!—дип өстәде Кадим һәм рөхсәт тә сорамыйча кабинеттан чыгып китте.

Кабинетына керәп утыргач кына ни булганын аңлады Шәймәрдәнов. Менә сиңа, мә! Бу бит чынлап та парткомиссиягә барып җитте бугай! Үзеңне болай тотсаң, партбилетыңнан да, бөтен дәрәҗәләреңнән дә колак кагасыңны көт тә тор. Шулай да ул күңелендә үкенү сизмәде. Петровка әйткән сүзләрен ул теләсә кем алдында әйтә ала, чөнки алар Кадимнең йөрәгендә туганнар, ул аларның дөреслегенә ышана. Ә дәрәҗәләр... Дөрес, дәрәҗәләр яулап алына һәм аларны югалтырга да була. Тик нәрсә соң ул дәрәҗә хәзерге вакытта? Тормыш баскычының бер басмасымы, урынымы? Әйе, шулайдыр. Нәрсәгәдер бөтен күңелең белән бирелү, ышану, хаклыгыңны аңлау, көчеңә ышану нинди дер бер вакытлы урын белән чагыштырып караганда өстенрәк түгелмени? Ярый, әйткән сүз—аткан ук, инде аны кире кайтарып булмый! Онытыйк бу вакыйганы вакытлыча. Хәзер якындагы мәсьәләләрне чишәргә кирәк. Әле солдатлар, офицерлар, техниклар үз урыннарына кайтып бетмәгәннәрдер... Аларга ял бирергә, техниканы рәткә китерергә кирәк. Чыгымнарны исәплисе дә бар, кирәк нәрсәләргә заявкалар бирәсе... Эшләр күп әле.

* * *

Кабинетка бик ашыгып полкның штаб начальнигы килеп керде. Аның йөзе борчулы иде.

—Ни булды, Евгений Андреевич?

—Эшләр хәрти, Кадим Каюмович. Икенче дивизионда бер яшерен кулланманы югалтканнар. Сез беләсез инде аны: кызыл катыргы тышлы китап. Ни эшләргә дә белмим хәзер!

—Корпустан бер офицер килгән иде түгелме соң, штабтан? Китеп өлгерде микән?

—Юк әле, китмәде. Майор Яковлев ул.

—Кайчан югалган инде ул?

—Югалганын белгәннән башлап ике сәгатьтән артык вакыт узды инде.

—Таба алмасак баштан сыйпамаслар. Сез хәзер үк теге майорны табып, аның белән киңәшеп алыгыз. Үзегезнең кабинеттан корпус штабы начальнигына шалтыратыгыз. Шул вакытта Яковлев сезнең белән рәттән булсын. Шифротелеграмма да бирегез. Генерал Фонотов аңа да күрсәтмәләр бирергә теләр. Яковлев бит штабның режим белән шөгыльләнгән бүлегеннән.

—Аңладым. Китәргә рөхсәт итегез?

—Әйе.

Көн үтте, ике көн узды, әмма югалган кулланма табылмады. Калын гына китап бит ул. Кесәгә дә сыярлык түгел. Аннан соң дивизионда һәр кешенең нәрсә эшләгәне күз алдында. Хәтта офицерлар торган йорт та шәһәрчек эчендә, КППны узмыйча беркая да китеп булмый, бөтен тирә як тимер чыбык белән әйләндереп алынган.

Шәймәрдәнов тикшерү, эзләү эшләрен үз кулына алды. Кулланма монарчы читкә китмәсә (ә ул китмәскә тиеш, чөнки шушы арада һичкем дә беркая да чыкмаган), кайдандыр табылырга тиеш. Эзләү шул хәтле җентекле бара ки, карамаган, тикшермәгән бер урын да калмаган инде.

Корпус штабы начальнигы генерал-майор Фонотов икенче көнне үк үзе килеп төште. Димәк, хәзер бу турыда Мәскәүдә дә беләләр.

Инде бөтенесенең дә башлары әйләнеп бетте. Тагын, тагын бөтен җир тикшереп чыгылды. Эзләнүләр шул хәтле җилətте, бу эшне кылган кеше табылса—урлаганмы, яшергәнме, шаярганмы ул—аннан ничек үч алу турында сөйләшүләр таралды. Ашау юк, йокы юк бит...

Командующий һәм политбүлек начальнигы урынбасары белән булган вакыйга бөтенләй онытылды кебек. Иң мөһиме—хәзер кулланманы табу. Күп кеше белән Кадим үзе сөйләште, калганнары КГБ вәкилләре, штаб хезмәткәрләре тарафыннан сорау алынуга дучар булдылар. Мондый сорау алулардан теге кулланманы күрмәгән-белмәгән кешеләр дә туеп бетте. Чираттагы киңәшмә вакытында шул ачыкланды: инде бөтен карарлык урыннар каралып бетте, тик казармадан 40-50 метрлар чамасында урнашкан тышкы бәдрәф берничек тә тикшерелмәгән икән әле. Өлкә үзәгендәге гарнизоннан махсус машина чакырттылар. Эш озакка сузылмады: тирән генә чокырдан бөтен булган нәҗес суыртылып беткәч, иң төптә кызыл тышлы китап күренде...

* * *

Халисә эштән кайтып керде. Тиз-тиз генә киемнәрен салып, халатын киде дә, кухняга ашыкты. Берәр төрле күптән ашамаган, сагындырган нәрсә пешерергә уйлады ул бүген. Кадимнең яраткан ризыкларын искә төшерә башлады. Өчпочмак, пәрәмәч, ит бәлеше, кыздырылган бавыр? Тагын нәрсәләр ярата соң әле ул? Бала чагыннан ук яратып ашаганы, авылда пешерелә торганы кирәк. Озак уйланды Халисә. Берсе ошамады, икенчесе. Ә-ә, ачы камыр да юк икән бит әле. Суыткычын берничә мәртәбә ачып карады. Бер нәрсәгә дә туктала алмыйча озак кына изалангач, пилмән пешерергә булды.

Уйлап карасаң, инде ничә ай үтеп китте. Карлар төште, салкыннар житте, ә өйдә әллә нинди күңелсезлек. Әллә кая китте күңелле кичләр, көлүләр, шаярулар. Кадим хезмәтеннән соң кайта, балалар белән бераз гына сөйләшеп ала да, ашап, үз бүлмәсенә кереп китә. «Нигә болай бик боек күренәсең?»—дигән сүзләргә: «Бик арытты, Халисә, гафу ит инде син мине»,—дип сүзне бетерә. Юк, алай ачуын күрсәтми, кай чакта шаян сүзләр дә әйткәләштерә. Әллә нәрсә булды Кадимгә. «Әллә шул югалткан китап өчен шелтә бирделәрме сиңа»,—дип тә сорап карады. «Юк ла инде, табылды ич ул»,—дип кенә куйды Кадим. Отпуск та бирмиләр, ичмасам. Инде декабрьнең яртысы житте. Ялгызы гына булса да берәр таба—санаторийгамы шунда—барып кайтса, башына төшкән кайгыларыннан арыныр иде, җилләнеп кайтыр иде. Шул бетмәс-төкәнмәс эшен, хезмәтен беразга онытып торыр иде. Иренә: «Нигә син шундыйга әйләндең, миңа сәбәбен әйтмисең, нигә кара болыт кебек йөрисен?» дип, Халисә сагыз кебек ябышмады, түзде. Алай эшләү, җавап таләп итү Кадимгә бөтенләй кире тәэсир ясыйсын белә ул. Шуңа күрә, башка юллар эзләп, иренә ярдәм итәргә теләде. Әгәр сәбәбен белсә Кадимгә үзенең ярдәм итә алачагына ышана иде. Шуңа күрә бүгенге гади генә эш көнендә тәмле ашлар пешереп, ничек булса да иренең күңелен күреп, серен ачарга исәбе иде Халисәнең.

Мәктәптән балалар кайтты. Мараты да, Халидәсе дә тиз-тиз юынып, кухняга чыктылар. Әниләренең пилмән эшләп торганын күреп бер-бер артлы «нинди бәйрәм бүген», дип, шатлана-көлә төпчәнә башладылар.

—Ә? Нинди бәйрәм?—Халисә балалар өчен берниңди бәйрәм турында

да уйлап куймаган иде шул, әйтте:—Менә әтиегез кайтыр, шул вакытта күрерсез нинди бәйрәм икәнен. Ә хәзер тиз генә миңа булыша башлагыз. Марат, син өстәлгә эскәтер җәя тор, савыт-саба куй. Аннан соң кибеткә йөгерерсең, каймак алып кайтырсың. Ә син, Халидә, ки алъяпкычыңны, миңа монда булышырсың. Әтиегез тиз генә кайтмаска ошый. Әшенә шалтыратырга кирәк булыр, соңламасын.

Балалар ярдәме белән бөтен ризыклар әзерләнеп, куясы өстәлгә, көтеп торасы суыткычка урнаштырылды. Балалар үзләре эшләгән эшкә сокланып, һаман өстәл тирәсендә әйләнә-бөтерелә: кашыклар үз урыннарындамы, дөрес куелганнармы, янәсә.

Халисә күзләрен сәгатькә юнәлтте. Әстәгыфирулла, сәгать җиде тулып килә ләбаса! Кадимнең кайтып керүе ихтимал, мин үземнең өс-башымны да рәткә китерергә өлгерә алмам, дип, ваннага, көзге янына ташланды. Аш-су әзерләү белән мавыгып чәчләр бераз таркалган, ләкин шулай таркалган көйгә дә алар кухня җылысында кызарып киткән биткә бик килешеп торалар иде. Халисә башын унга, сулга борды, үзенең кыяфәтеннән канәгать калды: утыз өч яшьлек хатын би-ик чибәр иде. Үзенә карап соклanудан туган елмаюы аны тагын да матурландырды, мөлаемландырды. Халисәгә бер мизгелдә уңайсызрак булып китте: ах, син, матуркай, чиктән тыш масаеп китмә тагын! Бу уй аны көзгедән барыбер аера алмады. Ул алъяпкычын салып ташлады. Ике бала тудырып, ир белән ничә еллар гомер кичергән хатын булуына карамастан, һаман балкортыныкы кебек нечкә калган билләренә таянды. Гәүдәсен алга-артка борды, күкрәкләрен сыйпады. Борын, бит очларына бармагын төртеп (Кадим иркәләгәндә гел шулай итә), алмадай пешкән йөзен тагын тикшереп чыкты. Килешмәгән, житешмәгән җирен тапмады. Күз төпләремдә җыерчыклар чыкмаганмы, аллам сакласын, дип, бит тиреләрен алай-болай тарткалап карады. Юк инде, юк, бөтенесе дә урынында, артыгы да, җитешмәгәне дә юк! Иремне дә, балаларымны да яратам. Яраткан эшем дә бар. Бөтенесе дә бар! Бәхетле мин, бәхетле, дип сөенде Халисә. Баштан шушы уйлар үткәч, ул тагын матурланды, тагын балкыды.

Сәгатьләр, минутлар бер-берсен алмаштырып бер секундка да туктап тормый торган вакытны санийлар. Инде тугызынчы ярты да килеп җитте. Ни сәбәптән болай соңарды Кадим? Кичеккән вакытларда алдан ук шалтыратып куя иде. Халисә телефон трубкасын күтәрде. Кабинетына шалтыратыйм микән? Юк, анда түгелдер ул... Юк, кабинетында түгел ул, анда булса инде әллә кайчан хәбәр биргән булыр иде. Әллә КПгамы? Юк инде, туры телефонны борчымыйк. Телефон трубкасын кире куеп Халисә залга узды. Аннан соң кухняга чыкты, кабинетка да кагылды. Болай да әйбәт кенә торган әйберләрне төзәткәләде, гөл савытларын күчерде, яфракларын сөрткәләде. Балалар инде әллә ничә мәртәбә үз бүлмәләреннән башларын тыгып әниләренә караштырып алдылар, аның бер сүзсез фатир буенча йөрүен күреп, аптырадылар. Шулай да сүз катмадылар, карыннары ач булуга карамастан, түзделәр. Әтиләрен көттеләр. Ә ул һаман кайтмый. Халисәнең көзге алдында бөтерелгәндәге чибәрлеге юкка чыккандай булды. Күзләрендә әллә сизенүдән туган кайгы пәйда булды, елмаю һәм канәгатьлек эзләре әллә кая китеп югалды. Борчылу шәүләсе аның йөзен болыт кебек каплап алды, йөзе агарды. Хисле хатын-кыз йөрәге шундый ул, еракган сизә—иренә әллә нәрсә булды! Нәрсәдер булды!

Халисә балаларына җитәрлек кенә итеп пилмән пешерде. «Әтиегезнең бүген эше күптер»,—дип аларны ашатты, йокларга яткырды. Үзе берни капмады, тамакка үтми иде. Балалар йокларга яткач, залга чыгып телевизор алдына утырды. Тик экрандагы вакыйгалар башка кермәде. Борчулы күңел иренең хезмәтендә килеп чыккан үзгәрешләренең сәбәбен эзләде. Нинди сәбәп соң моңа? Мин гаепле түгелдер бит? Ни хәтле генә тырышса да җавап таба алмады. Халисә Кадим белән бергә торган бөтен елларын искә төшерде, аерым вакыйгаларны баштан кичерде. Бәйләнерлек нәрсә

таба алмады. Алар танышып очраша башлаган көннәрдән үк диярлек Халисә үзен җаваплы тотарга мәҗбүр итте. Бу үзеннән-үзе килеп чыкты, чөнки ул беренче танышудан ук Кадимгә мөкиббән китте, аны үлеп яратты. Инде аның киләчәк тормышы Кадимгә багышланасы билгеле иде. Шуннан башка бернинди уй да, омтылыш та булганы юк. Халисә иренең хыяллары, максатлары белән уртаклашты, кылган гамәлләре белән яшәде. Кадим үзе дә шулай итте һәм алар шуңа күрә бик бәхетлеләр иде. Халисә Кадимгә бөтен күңеле белән бирелгән, аңа тулысынча ышана, һичкайчан да шик тотканы юк. Ә хәзер, бүгенге көндә? Сәгать унбер тулып килә, ә иренең кайда икәне билгеле түгел. Әллә?.. Кит, китегез башымнан мондый уйлар! Нинди пычраклык бу минем бәгыремдә, балаларымның атасы турында шундый уйларны башка кертү!

Ниһаять, уникенче егерме минутта машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Халисә утырган урыныннан сикереп торып ишеккә ташланды, ишекнең ачкычын борды, әмма ишекне ачмады. Йөрәк доп-доп тибә. Кадимме бу, әллә икенче кешеме? Тик әкрен генә басып килгән аяк тавышлары ишек янында сүнгәч, Халисә ишекне ачып җибәрде. Аның каршысында фуражкасы кыйгайган, йөзләре салынып төшкән, күз карашлары сүнгән Кадиме басып тора иде! Бөтенләй аның иренә охшамаган кеше бу... Шулай да бу—Кадим... Алар бер-берсенә ләм-мим сүз дәшмәделәр, тик бер-берсенә ташландылар һәм шул килеш ачык калган ишектән өйгә шуышып кергәндәй керделәр. Кочаклашкан килеш шулай бер мәл торгач, Кадимнең бөтен авырлыгын үз иңнәрендә тоя башлагач кына, Халисә аның лаякыл исерек икәнен сизеп алды. Кадимнең аяклары гәүдәсен тотмый башлады һәм ул үзенең бөтен авырлыгы белән хатынына асылынып калды. Халисә ничектер тырышып үзенең бөтен көчен җыеп караса да көч җитмәде. Иренең гәүдәсен иплэп-иплэп җибәрә төште. Кадимнең аяклары бөгелеп киттеләр һәм ул коридор буенча сузылып яткан келәмгә җансыз капчык кебек авып төште, хәрәкәтсез калды. Ул йоклый иде.

Бераз вакыт үткәч Халисә бик зур кыенлыклар белән Кадимне уятып, чишендереп, урынына яткырды. Төне буе керфек какмады. Вакыты-вакыты белән Кадим гырылдый башлый иде (гомерендә беренче мәртәбә). Аның гырылдавы Халисәдә шундый көчле нәфрәт тудырды—Кадим янына йокы бүлмәсенә кереп яңакларына тондырасы килде аның. Халисә уйлавынча, Кадим ят хатын яныннан кайткан иде.

Хатын залда кәнәфидә урын алды. Ул һаман уйлана, һаман елый. Әллә ничә мәртәбә кухняга чыгып тынычлану өчен дарулар эчте. Йокы качты, тынычлык кайтмады. Тагын үткән тормышларын искә төшерде. Аның башына сыймый иде: ничек инде аны, элек яраткан хатынын, балаларын ташлап, чит хатыннарда йөрергә мөмкин?

Икенче көнне Кадим урыныннан тормады. Иртәнгә таба уянып, Халисәдән салкын су сорап эчте дә, тагын бөркәнеп ятты. Гафу ит димәде, кайда йөргәнен әйтмәде, бөркәнде дә ятты. Аның болай кылануы инде Халисәне бөтенләй чыгырыннан чыгарды. «Әгәр шул чит хатыннарда йөреп кайткан булса, Кадим минеке түгел, китәм кайтып, бер көн дә аның белән тормыйм»,—дигән карарга килде. Шул уйлардан соң бераз тынычлана төште—карар кабул ителде!—кухняга чыгып балаларына җылы аш әзерли башлады.

Әллә савыт-саба тавышыннан, әллә йокысы туеп, Кадимнең торып йөргән тавышы ишетелде. Киенде булса кирәк, ваннада озак кына юынды, кырынды. Аннан соң берни булмагандай кухняга килеп керде.

—Хәерле иртә, Халисәкәй. Әллә бәйрәм әзерлисең инде?—Аның йөзендә көлемсерәү эзе күренеп китте. Битләре кызарган, күз төпләре шешенгән иде. Халисә дәшмәде, аның сүз әйтерлек әзерлеге юк иде әле. Борылып кына карады да, эшләгән эшен дәвам итте.

—Ир кеше бик соң кайткач, җитмәсә исереп кайткач, әллә нәрсә уйлап бетергәнсеңдер инде. Аңлашыла. Син мине бераздан аңларсың,

матурым. Гафу ит, соң кайтырмын дип уйламаган идем. Телефон булмады!

Ул суыткычны ачып нидер эзләде, таба алмагач, якынрак килеп утырды да дәвам итте.

—Мин, беләсеңме, кайда булдым? Башыңа да китерә алмассың: Амангельды Туганбаевта кунакта булдым мин! Исеңдәме, бервакыт безгә кереп чыккан иде? Казакъ малае, колхоз председателе. Исеңдәме? Әй, ярар бу турыда. Бу—иң мөһим нәрсә түгел. Ушны алырлык яңалык шул: мине армиядән куалар.

Халисәнең токкан кашыгы төшеп китте, йөзе кыйшаеп калды.

—Ничек? Нигә куалар? Ни өчен?

—Үзем дә аңламыйм шул, Халисә. Әмма бу—факт. Инде приказга Мәскәү кул куясы гына калган.

—Ниләр эшләдең соң? Нигә миңа бер сүз дә әйтми йөрисең?! Нинди җинаятьләр эшләдең? Кемнәр, нинди хатыннар белән бәйләндең?—Халисәнең сөйләве елау катыш иде. Ул куларын күкрәгенә кушлап кысып урындыкка утырды, ватылып-коелып төшкән чынаяк сыман, таркалып китте, башка сүз таба алмыйча, үксеп елап җибәрде.

—Юк, Халисә! Үземнең намусыма, офицер намусына каршы килгән бер нәрсә дә эшләгәнем юк. Теге кулланманы югалткан идек. Таптык. Тагын бар инде җитешсезлекләр. Вак-төяк. Менә шунысы гаҗәп шул, минем үземә дә аңлашылмый. Моңа минем бөтен күңелем каршы, шуңа күрә үземә урын таба алмыйм. Әллә нинди кара көчләр басты юлыма. Һичкая атларга ирек бирмиләр. Атлау гынамы соң—кыймылдарга да форсат юк!

—Ә син кичә... кичә чит хатын-кыз янында булдыңмы соң? Кадим, җаным, әйт дөресен!..

—Нәрсә сөйлисең, хатын, әллә акылыңнан кузгалдыңмы?

—Кузгалдым шул! Кузгалырсың да бу хәлгә калгач...

Бераздан Халисә иренә таба борылды, күз яшьләре аркылы ягымлы караш төбәде. Елау белән елмаю катышлы йөзендә кызару төсләре күренде. Көчсез кулларын сузды.

—Ярар, ярар, елама инде! Барыбер, берсенә дә ялынып барачак түгелмен! Көтмәсеннәр!

Халисә ашыга-ашыга күз яшьләрен сөртеп алды. Балалар бүлмәсеннән сәгать чылтыраган тавыш ишетелде. Балалар торыр вакыт җиткән икән ләбаса...

Кадим бүген эшкә бармады.

* * *

Теләр-теләмәс кенә, дәртсез генә Кадим хезмәтенә йөри бирде. Иртән вакытында торып, гадәттәгечә күнегүләр эшләде. Халисә пешергән ашларны ашады. Һичнинди үзгәреш юк кебек бер караганда. Боткаларны да, эремчекне дә ашады. Хатынына мактау сүзләре әйткәләде. «Бик файдалы ризык»,—дип, эремчекне бик ук яратып бетермәсә дә ашады, хатынының күңелен күрергә тырышты. Вакытында китте, вакытында кайтты. Полктагы үзгәрешләр турында Халисәгә сөйләмәде. Ә бу вакытта армия һәм корпус политбүлекләре тарафыннан Шәймәрдәновка каршы шәхси эш ачылган иде инде. Шаккатты Кадим: әле күптән генәме бик якын булып йөргән кешеләрнең күбесе читләшә башлады, элекке кебек фикер алышулар бетте, бергәләп эшләгән уртак эшләр онытылды. Гүя алар бөтенләй дә булмаган. Полкның политбүлек башлыгы Швалевка да килеп чыккан хәлләр ошамый иде кебек. Швалев белән сөйләшеп алырга кирәк, дигән фикергә тукталды Кадим. Әмма ничегрәк? Кабинетка чакырып алыргамы, үзе янына керергәме?

Швалевны күптән белә иде ул. Әдәпле, намуслы офицерларны теркәп-санап үткәндә, алар исемлегенә Швалевны кертмәс иде ул.

Фамилиясе генә ни тора—«шваль» сүзеннән килеп чыккан бит! Ә урыс фамилияләре күпне әйтә алар. Тышкы кыяфәте, холкы да фамилиясеннән күренеп тора. «Кара, кара, Кадим, майор Быков тач үгез бит, ә?»—ди торган иде бергә хезмәт иткән башкорт малае чын күңеленнән исе китеп. Кушаматлар кешене бер сүз белән тасвирлап бирә бит. Ә урыс фамилияләре үз вакытында кушаматлардан язылганнар алар. Билгеле, аннан бирле күпләр үзгәргән инде, үзенең фамилиясенә тәңгәл килгән сыйфатлар да үзгәргән. Ә Швалевлар үзгәрмәгәндер, күрәсең. Эчкерле кеше иде ул. Башкаларга начарлык эшләү аның өчен, урыслар әйтмешли, бер төкерү генә иде. Үзенең карьерасы өчен үз анасын сатарга әзер иде. Уңмаган командир белән өскә үрмәләп булмаганны да яхшы аңлый Александр Прокопьевич. Кадим командир булып килгәч ул бик шатланды. Бу командир белән полкта озак утырмам дип шатланды. Командирга охшарга теләде, эшендә дә тырышты инде, моны инкарь итеп булмый. Күп кенә файдалы эшләр дә эшләп ташлады. Дөрес, күз-колак булмасаң, азып, чыгырдан чыгып киткән чаклары да булмады түгел. Хатынына, командировкага китәм, дип, төннәрен чит хатыннар янында йөргәне дә билгеле иде полк командирына. Ярата иде Швалев ят мендәрләрне! Хатын-кызлар булган урыннарда аның күзләре уйнап, һич үз урыннарында тора алмыйча, атылып чыгарга тора иде.

Швалев белән сөйләшү нәтиҗә бирмәде. Алар бергә хезмәт итә башлаганнан бирле булмаган нәрсә килеп чыкты: политотдел башлыгы командирга нәсихәт укый башлады. Элек моңа базмый иде ул. Ә хәзер укытучы булып кылана, тәртипсез укучыны тәртипкә утыртамыни! Син мондый, син тегенди! Ничек мин, политбүлек башлыгы буларак, күрми торганмын, имеш.

—Тукта, тукта әле, Александр Прокопьевич! Кай арада үзеңнең карашларыңны үзгәртеп өлгердең соң әле? Ник башкалар сүзен кабатлыйсың попугай кебек? Нигә миңа нахак сүзләр әйтәсең, яла ягасың?—диде Кадим, аның сүзен бүлеп. Кызып китте тегесе, һич сөйләшү мөмкинлеген калдырмады. Күренеп тора иде: моны «өстәгеләр» шундый хәлгә җиткергәннәр! Шулай, шуңа ошый, башкача түгел. «Моңа, бу хайванга, бүгенге көндә сүз күндереп булмас. Мантыйк дигән нәрсә бу очракта көчсез», дип уйлап алды Кадим һәм кискен борылып чыгып китте.

Кадим уйлаганча булып чыкты: Швалевны өстәгеләр Кадимгә каршы чыгарга бөтенләй көйләп бетергәннәр иде инде. Свердловск шәһәренә чакырып алдылар. Армиянең политбүлеге каршындагы парткомиссиядәге утырыш вакытында Швалевның чыгышы искитәрлек иде. Бу адәмнең икейөзлелеге һичнинди калыпка сыймаслык булып чыкты. Үзе белгән, үзе ишеткән бер генә булган хәл белән дә чагыштыра алмады моны Кадим! Үзенең урынын, дәрәҗәсен саклап калу өчен, өстәге түрәләрнең сүзләрен рас итеп күрсәтү өчен, алар алып барган юнәлешнең «Дөреслеген» «исбат итү» өчен тирән итеп уйлап, әзерләнгән эш иде бу. Иң аянычы шунда, партия комиссиясендә катнашкан, Кадимгә кагылган эшне тирәннән белмәгән кешеләр моңа ышандылар. Бу чыннан да шулай икән, дип, Швалев ягына тайпылдылар. Утырыш алдан төзелгән сценарий буенча үткәрелде. Ә Кадим сөйләгән сүзләргә инде игътибар зур булмады: әһә, менә ул ничек акланырга тырыша! Юк, синеңчә килеп чыкмас, сиңа һичнинди гафу юк! Җәзаның иң катысы аңа! Менә шундый рухта үтте парткомиссия.

Утырыш беткәч үк штаб бинасыннан тышка чыгып китте Кадим. Монда аңа һава җитми иде. Сәгать икенче киткән, штабта әбәт вакыты. Штаб хезмәткәрләре ашханәгә юнәлгәннәрдер, коридорларда бер таныш та очрамады. Ә монда танышлар байтак. Бергә укыганнар да бар. Гадәттә, элек килеп йөргән вакытларда, аларның барысы белән дә диярлек, бүлмәдән бүлмәгә күчеп, хәл-әхвәл сорашып, сөйләшеп-күрешеп йөри иде ул. Бүген андый мөмкинлек тә, теләк тә юк. Штабтан чыгып киткәндә

кизү офицер бүлмәсе янында торган берничә хәрби зат Кадимгә табан борылып честь биреп сәламләп калдылар. Белмиләр иде шул бу яшь офицерлар парткомиссия бүлмәсендә нәрсә булганын! Шуңа да карамастан, Кадим күз карашын тиз генә читкә борды. Оялгандай булды ул. Әллә үзенең «гаебен» таныган кебек тойдымы, әллә болай гына, очраклы уйлар йөгереп уздымы баштан. Контроль пунктында да солдатлар, кинәт сөйләшүләрен бүлеп, аягүрә бастылар. Кадимне кызганган сыман, йөзләренә җитдилек, кайгыга төшкән сыйфат чыгарып озатып калдылар. Әллә беләләр инде болар, «штаб күселәре», дип уйлап куйды Кадим. Ә чынында исә офицерларны да, солдатларны да Кадимнең язмышы кызыксындырмый иде. Соңгылары ул килеп керер алдыннан гына үткән төнне контроль пункты янына килгән җиңел тәртипле кызлар турында сүз алып баралар иде, шыркылдашып көләләр иде. Ә чырайларын инде алар ничек кирәк шулай ясарга күптән өйрәнгәннәр, командирларын алдау өчен бу өлкәдә артистлардан да уздырып җибәрәләр иде.

Урам искиткеч матур. Ара-тирә очраган кешеләр ашыкмый гына каядыр баралар. Машиналар бөтенләй юк диярлек. Тирә-як яшеллеккә чумган. Һава чиста. Күңелне тынычландыра торган бер урыны иде бу дөньяның. Кадим дә адымын әкренәйтте. Ашыгасы юк, кунакханәгә кайтып Швалев белән очрашасы килми. Аларга бер үк номерга урнашырга туры килде, чөнки башка урын тәкъдим итмәделәр. Йөрәк тибеше бераз басылгандай булды. Бакчага кереп озак кына йөрде Кадим, аллеялар буйлап. Җир шарының әллә кайсы төбәкләреннән кайтарып утыртылган агачларга карап йөрде. Уйлар болганчык, аларны баштан чыгарып ташлап булмый.

Көз көннәрендә кояш күктә озак йөрми ул, инде баю ягын карый. Менә шунда гына, кояш шәһәр йортларының түбәләренә якынаеп, күләгәләрне шактый озынайткач кына, Кадим үзенең әбәт ашамаганлыгын исенә төшерде. Каядыр барып ашказанының «ялваруын» басарга кирәк иде. Көне дә салкынайтты кебек. Әле перчаткалар кимәгән кулларын угалап, җылытып торырга туры килә...

Свердловскига чыгып киткәндә Кадим бу шәһәрдә яшәгән танышларын искә төшергән иде һәм күреп-күрешеп чыгарга ниятләгән иде. Монда аның ерак туганнары да бар. Кереп чыксаң шәп булыр. Авылны, бала чакларны, таныш-белешләрне искә төшереп алсаң күңелгә үзе бер ләззәт, дару була, дип уйланган иде теге вакытта. Ә хәзер ни өчендер дусты, классташы Назиф торган урамга борылмады, турыга китте. Бүгенге изүдән соң авылдашлары белән уртак сүз таба алмас кебек тоелды. Авыз салындырып, әрнегән йөрәк белән йөрмиләр инде кунакка. Назифка барып керсәм, анда барыбер бөтен белгән-белмәгән якташлар җыелачак. Кадим килгән, Кадим килгән!—диячәкләр. Үзләре генә түгел, хатыннарын, балаларын ияртеп йөгерәчәкләр. Чөнки авылда мине, минем әтине генә түгел, бөтен нәселне ихтирам итәләр. Күрешеп, сөйләшеп, чәй эчеп утырасы килә килүен... Ләкин бүген булмый. Күңел сыкрый. Булмый бүген...

* * *

Мәскәүгә барып дөреслек эзләп кайту турындагы уй инде күптән борчый иде. Билгеле бит, бөтен нәрсә командующий Гурин белән, аннан соң армиянең хәрби совет әгъзасы, политбүлек башлыгы урынбасары Петров белән бәрелешүдән башланды. Корпус командиры, штабы, политбүлеге ягыннан нindидер претензияләр юк. Шулай булгач, Кадимне армиядән җибәрү инициаторы бер генә: армия политбүлеге. Командующий үзе түгел, билгеле. Ул аңа бара торган кеше түгел икәнне күпләр белә. Мәскәүдәге даирәләр аңламасмыни? Ятып калганчы атып кал, диләр. Нәрсә югалтам барып кайтсам, дип уйлады

Кадим. Барыбер бөтен хезмәт юкка чыкты. ПВО башкомандующиена керергә иде. Ә моның өчен зенит-ракета гаскәрләре командующиен үтәргә кирәк. Армиядә баскычның һәр басмасына басмыйча беркая да үтеп булмый. Башкача булмый, устав шулай куша. Астагы басмаларны үтмәсәң, өстәгесендә синең белән беркем дә сөйләшеп тормый.

Илнең зенит-ракета гаскәрләре командующие итеп күптән түгел генә генерал-полковник Гуринны билгеләделәр. Шәймәрдәновны армиядән җибәрү турындагы кәгазьгә нәкъ менә шул Гурин кул куйган иде бит Мәскәүгә күчкәнче. Үзенең имзасын кире алырга теләрме ул? "Мәскәү күз яшьләренә ышанмый" дигәнне дә онытмаска кирәк. Бәлки башыңны иеп барып та йөрмәскәдер? Азакка хәтле горурлыгыңны саклап калыргадыр?

Генерал-полковник Гуринны Мәскәүгә ничегрәк билгеләү турында бер таныш полковник сөйләгән иде. Пенза шәһәрендә бергә командировкада булганнар алар. Кич кунакханә номерында кәеф күтәреп утырган вакытта булган бу сөйләшү. Мәскәү белән телефоннан сөйләшү. Гуринның кәефе бик яхшы иде ул кичне, ди. Мәскәүдән сөйләгән кешесе генералга яхшы таныш икәне күренеп тора. Башта бик күңелле генә итеп сәламләштеләр, көлешеп алдылар, ди. Берникадәр вакыт сөйләшкәннән соң Гуринның йөзе күренеп үзгәрә башлады, болай да кызыл битле кеше чия кебек булды, ди. Аңлашыла инде, Мәскәүдәге танышы Гуринга маршал Батицкийның карарын җиткерә: сине илнең ЗРВ командующие итеп билгеләргә. Телефон трубкасын куйгач, Гурин бүлмәнең ишегеннән түренә туктаусыз сәгать буена йөренде, ди. Сукранды, төкеренде, ди. Юньсез сүзләрнең берсен дә калдырмады, ди. Шулай булмый соң! Аерым ПВО армиясендә командующий Гурин—тулы хуҗа. Аңа авиация дә, зенит-ракета гаскәрләре дә, башкалары да буйсына. Шәхси самолет, кайда тели шунда оча. Элемтә даими тәэмин ителә, җирдә дә, һавада да: телефон, радио, шифр элемтәсе һ. б. Ә ЗРВ командующие? Мәскәүдә утыруына карамастан аның иреге ташка үлчим, көче дә чамалы гына. Бөтен гамәле дә күз алдында бит әле. Ә моны начальство яратмый. Бер сүз белән әйткәндә, кәрт колодасындагы "алтылык" инде. Батицкий ни әйтсә, шуны эшләргә туры киләчәк.

Шулай килеп чыкты да. Гуринны илнең ЗРВ командующие итеп билгеләделәр. Мондый вакытта "мин бармыйм бу урынга" дию юк. Баш тартсаң сиңа армиядә урын калмавы һәркемгә дә билгеле.

Кадим Шәймәрдәнов Мәскәүгә самолет белән барып төште. Гурин янына кереп тормаска булды, чөнки ул анда яклау таба алмам дип уйлады. ПВО башкомандующие маршал Батицкийның кайда икәнен белешеп, электричка белән шунда китте. Кулда командировка юлламасы юк иде. Документсыз булганга күрә, озак кына КПП да көттерделәр: чакырылмаган кешене Батицкий кабул итми. Шулай да, озак кына ялынганнан соң КПП башлыгы телефоннан шалтыратырга рөхсәт итте, кирәкле телефон номерын бирде. Озак аңлатырга туры килде Кадимгә үзенең үтенечен. Ә үтенече аның маршалның үзе белән очрашу иде. "Көтегез, сезнең янга чыгарлар",—дигән сүзләрне ишеткәч, Кадим бераз тынычлангандай булды, азмы-күпме өмет туды.

Озак көтәргә туры килде. КППга килгән полковник Батицкийның кабул итү эшләре белән шөгыльләнгән махсус бер хезмәткәре икән. Петлицаларында юстиция хезмәте билгеләре. Полковник Шәймәрдәновны аерым бүлмәгә алып керде. Каршысына утыртып сүзен бүлми генә тыңлады. Берничә сорау да бирде. Полковник Кадим турында күпне белә икән, димәк, документларны карап чыгарга өлгергән. "Бу турыда кабатлап тормагыз, мин моны беләм",—дигән сүзләре шуны аңлата иде.

—Сез сөйләгәннәрне, үтенечегезне мин Главкомга җиткерермен,—диде полковник, сөйләшүне йомгакларга теләп. Кадим бу сөйләшү белән генә канәгать булмавын, Главкомның үзе белән очрашырга теләвен, моннан башка чара калмаганлыгын катырак сүзләр, таләп итү тоны белән әйтергә мәҗбүр булды.

—Минем бернинди гаебем юк. Хезмәттә житешсезлекләрем юк иде, гел мактау кәгазьләре, бүләкләр алып тордым. Нинди нигезләүләр бар соң мине армиядән куарга? Җинаятьче түгел ич мин! Хакым бармы минем үземне үзем якларга? Устав буенча иң өске инстанцияләргә барып дәгъва итәргә хокукым бар. Нигә миңа мондый мөмкинчелек бирмиләр?— Шулай катгый куйды Кадим таләбен. Полковник моны аңлый иде кебек, әмма, ни өчендер, Батицкий белән очрашып сөйләшүгә гел каршы килә. Алдан ук бу турыда карар кабул итеп куелганмы? Әйе шул, сизелеп тора бит инде!

—Кайчан, кайда көтим мин Главкомнан җавапны?—дип сорады Кадим.

—Көтегез, мин сезне эзләп табармын...

Кадим Мәскәүдән кайткач ук, хәрби госпитальга ятты.

* * *

Менә шундый ул тормыш! Көтмәгәндә, уйламаганда үзгәрә дә куя. Арба тәгәрмәче кебегрәк—әле генә тигез җирдән салмак кына әйләнә иде, бак: чокырга килеп төште дә, бәрелеп ватылды.

Кадим госпитальдән чыкканда приказ килгән иде инде. Хезмәткә чыгып йөрисе дә юк. Тиешле акчаңны ал да, сыпыр: синең хәзер армия өчен хаҗәтең калмады. Утыз җиде яшьтәге ир менә шулай беркемгә дә кирәкмәгән кеше булды да калды! Тормыш бөтенләй тукталып калды кебек. Мондый хәлгә калмаган адәмнәргә аңлау һич мөмкин түгел. Гражданкада эштән алыну, икенче эшкә күчү ул—гадәти нәрсә. Ә Кадим өчен—бөтен гомерен унҗиде яшьтән үк хәрби хезмәткә багышлаган кеше өчен—бу коточкыч нәрсә икән ләбаса! Бөтен дөнья аяктан башка басты да куйды. Инде ни эшләргә? Кая барырга? Ничек көн күрергә—менә шундый зур проблема килеп чыгар дип кем уйлаган?! Дөрес, Кадимнең яшьләй армиядән китүчеләрне очратканы бар иде барын. Әмма аларның күбесе армия сафыннан китүләрен алдан ук белеп тора, әзерләнеп тора иде бит. Аларга җиңелрәк булгандыр. Ә Кадим моңа әзер түгел иде. Дөресен әйткәндә ул моңа ышанмады да. Инде полк командиры дәрәҗәсендә калмавы билгеле булгач та, бөтенләй армиядән китүенә ышанмады. Түбәнрәк урын табып, башка шәһәргә күчерерләр дип уйлады. Юк, алай түгел икән шул, моның армиядә эзен дә калдырмаска булганнар икән! Менә ничек уйланып, менә ничек китереп чыгарганнар! Мөстәкыйль уй йөрткән, үзен күпме дә булса бәйсезрәк тоткан кешеләрне яратмыйлар шул армиядә.

Вьетнамда Америка самолетларына каршы сугышып йөрде, армиягә бөтен көчен, сәләтен бирде. Полк командиры дәрәҗәсенә житте—ул дәрәҗә болай гына таратылмый бит,—ә хәзер бөтенләй хаҗәте калмадымыни? Ничек болай килеп чыга соң әле бу?

* * *

Инде ике ай Кадим эш эзли. Тегендә бәрелә, монда төртелә. Танышбелешләрнең күбесе Кадимне күрүгә башларын читкә борырга ашыга. Берсе, ачык күңеллерәге: "Син мине аңла, армиядән куылган, партия буенча каты шелтә алган кешене ничек эшкә урнаштырыйм",—дип әйтеп үк салды. Өлкә комитетының оештыру бүлеге мөдире башта үтенечне кире какмады, уйларбыз, берәр урын табарбыз, бер атнадан кил, ике атнадан кил, дип, озак йөртте. Әмма берни дә эшләмәде! Кайбер предприятиеләрдә эш тәкъдим итүләр булды, ләкин алар Кадимнең үзенә ошамады, алары аның белеменә туры килми иде.

Утыз җиде яшьтә профессия алмаштыру—ул радиотехника буенча инженер ич—җинел түгел. Өйрәнчек булып та эш башлау килешмәс, шәһәрдә аны белүче кешеләр күп кенә. Халисә алдында да оят бит инде! Токарь, слесарь, шофер булып та эшләргә булдырыр иде Кадим, тик аның белеме, җитәкчелек тәҗрибәсе белән башка урында файдалырак булмас иде микән? Сизде, аңлады Кадим: безнең илдә шундый система икән. Бер кешене бетереп ташладылармы, янадан күтәреләм димәсен! Бөтенесе дә шуңа юнәлтелгән, андыйлар аякка басарга тиеш түгел. Чөнки алар бу системага ярамаганлыкларын, каршылыкларын күрсәтteләр инде. Күтәрелү юлларын япкач, кеше үзеннән-үзе бетәчәк. "Мондый метод утызынчы елларда ук сыналган иде түгелме соң? Әйе, шуна охшый",—дигән нәтиҗәгә килде Кадим.

Көннәрнең берсендә, инде бүген кайда барып карыйм микән, дип үзлегенә уйланып утырганда, өйдә телефон чылтырады.

—Әйе, тыңлыйм.

—Шәймәрдәнов фатирымы?—көр генә ир кеше тавышы.

—Нәкъ үзе тыңлый.

—Мин—полковник Гусейнов Мамед Сурханович. Запастагы полковник. Хәзер кадрлар бүлегендә эшлим. Сезнең белән күрешәсем, танышасым килә. Әле эшкә урнашмадыгызмы?

—Юк, эшләмим әле.

—Бик яхшы! (Нәрсәсе яхшыдыр инде?) Сезгә эш тәкъдим итәргә уйлыйм.

Кадим бер мизгел ни әйтергә белми торды, мондый сөйләшүне бөтенләй көтмәгән иде. Бөтен җирдән сине этеп-төртеп торсыннар да, һәм менә кинәт кенә, сиңа, өеңә шалтыратып, эш тәкъдим итсеннәр, имеш. Ниһаять телгә килде ул.

—Сез кайдан соң? Нинди оешмадан?

—Мин ерак элемтә тәэмин итү белән шөгыльләнә торган бер предприятиедән. Штабыбыз (ул шулай дип, хәрбиләрчә әйтте) Киров урамында, почтамт янында урнашкан. Нинди эш икәнен күрешкәч сөйләшербез. Төрле эшләр бар. Ну, ничек, ризамы сез?

—Риза. Кайда күрешербез, кайчан?—Бу кешенең тавышы ошады Кадимгә. Шуңа күрә артык төпченеп тормады.

Почтамтка автобус белән барсаң, ярты сәгатьлек юл. Очрашу бер сәгатьтән сөйләшенүгә карамастан, Кадим бик ашыкты. Очып барырга әзер иде. Ләкин автобустан башка транспорт юк шул. Ул, автобус дигәне дә иң кирәк вакытта озак килми торды. Барганда да ташбака тизлеге белән барды. Шуңа да карамастан, Кадим унбиш минутка элгәрерәк килеп җитте әле.

Гусейнов озын буйлы, юка йөзле, 50-55 яшьләр чамасындагы кеше иде. Ул еractан ук елмаеп, ике кулын алга сузып, Кадимгә таба атлады.

—Исән-саумы, Кадим Каюмович? Хәрби киемсез сезне беренче мәртәбә күрүем. Шулай да, хәрби кеше икәнегез әллә кайдан күренеп тора.

—Сезнең дә, иптәш полковник.

—Мамед Сурханович дип әйтегез. Мин инде өч ел пенсиядә, полковник дип беркем дә дәшми хәзер. Эшләп йөрим гражданкада.—Ул Кадимне инбашыннан кочаклап, читкәрәк борды.—Ишеттем дә, шаккаттым. Сезне армиядән демобилизовать иткәнне, дим. Гафу итегез. Дөресен әйтсәк—куу бу армия сафыннан.

—Сез мине беләсезмени? Ничек мине таптыгыз?

—Ишетеп күптән беләм. Күргәнем дә бар. Кайсыдыр бәйрәм вакытында. Ә мин үзем мондагы хәрби училищеның начальнигы урынбасары идем. Мине дә армиядән теләгемне сорамыйча демобилизовать иттеләр. Дөрес, минем пенсия алырлык стажым бар иде. Ләкин 49 яшь тулмаган иде әле. Партиядән дә пенсиягә киткәнгә күрә генә чыгармадылар. Партия шелтәсен райкомда тикшереп кире алганчы елдан артык

эшкә керә алмый йөрдем. Яшерен күрсәтмәләр бар икән: шелтәң бар икән, эштән, хезмәттән дә дип уйла инде, чыгарылган икән, житәкче яки зуррак дәрәҗәле эшкә алмаска. Менә мин хәзер кадрлар бүлеге начальнигы була алдым инде.

Күптән түгел генә хәрби булган ике ир-ат шулай сөйләшеп киттеләр. Якындагы кечкенә бакчага керделәр. Гусейнов үзен якын кешесен очраткан кебек тотты. Аның көләч йөзе, селтәнеп-кизәнеп торган куллары, әле туктап, әле алга омтылып алга атлаган гәүдәсе Кадимнең бөтен игътибарын җәлеп итеп алды. Бу кешене тыңлау бик рәхәт иде. Ләкин Кадимнең тизрәк беләсе килде: нинди эш тәкъдим итәр икән Мамед Сурханович? Ә полковник һаман сөйли. Әллә юатырга тели? Үзенең тормышын сөйләп, Кадимнең хәзерге хәлен җиңеләйтергә тели иде бугай Мамед Сурханович. Кадим аның турында барсын да белә иде кебек. Хатыны белән генә тора икән. Ике балалары, инде үсеп, берсе кияүгә чыгып, икенчесе өйләнеп, аерылып башка чыкканнар. Илнең күп төбәкләрендә хезмәт итеп, мондагы хәрби училищега аның начальнигы булу, генералны алу максаты белән күчкән икән. Монда килгәнче хезмәт иткән урыны Рига каласы булган. Инде алтмыш яшен узган училище начальнигы аны—үзен, "төртеп" төшерергә килгән полковникны—төрле ысуллар белән пычракка батырырга булган һәм максатына ирешкән дә. Үзе һаман урынында утыра ди.

—Мин үзем ялгышлык җибәрдем. Монда килеп фатир алгач, бер ел буена Ригадагы фатирымны тоттым. Дөресен әйткәндә, фатирны саклап калырга исәп иде. Балалар өчен. Монда хезмәтне генерал дәрәҗәсендә бетереп, кире күченеп кайтырга да исәп юк түгел иде. Килеп чыкмады.

Бераз сүзсез генә атладылар. Гусейновның "Фатир манипуляциясендә" бернинди гаеп күрмәде Кадим, малае һәм кызы Ригада яшәп калганнар бит. Икесе дә студентлар. Соңгы курсларын ташлап әти-әнисе артыннан монда күчеп килергә тиешләрме соң алар? Әллә тулай торакка күчеп, фатирларын калдырып, китәргә тиеш булдылар микән?

—Аңладым, Мамед Сурханович. Миңа соң ничек ярдәм итә аласыз? Мин дә бит коммунист, мин дә армиядән куылган кеше.

—Һе, менә шул хәлеңне белгәнгә ярдәм итә алам да инде мин. Ул турыда кайгырма, безнең берләшмәнең идарә башлыгы хәрби кешеләрне бик ихтирам итә. Аның янына бергә керербез, бергә сөйләшербез.

—Ә нинди эш бирәсез соң? Бәлки ул миңа ошамас.

—Буш урыннар күп. Кайсы урынга утырсаң да эшли аласың. Синең мөмкинлекләреңне шәйлим бит мин. Үзем дә ракетчик мин. Ракетаны белгән кеше нәрсәгә тотынса да булдыра. Ике-өч елдан биек урында утырачаксың, һич кайгырма.

—Шулай да...

—Радиореле станцияләре буенча бүлек мөдире юк. Кабельләр буенча элемтә бүлегендә югары белемсез кеше утыра. Энергетика буенча да кеше кирәк. Тегесен дә, монысын да алып бара аласың. Уйланып торасы да юк. Хәзер үк идарәгә керәбез, минем эшләгән урынны карап чыгарсың.—Алар инде идарәгә табан борылганнар иде.—Бүген начальник урынында юк. Ә иртәгә иртүк аның янына гариза тотып керербез.

Магистраль элемтәләрне булдыру, шунда ук телевизион сигналларны ерак төбәкләргә житкерү эшләрен башкаручы берләшмә идарәсе өч катлы йортта урнашкан. Элегрәк, Кадим бу тирәдән узып йөргән вакытта, эленеп торган тактага игътибар иткәне юк иде. Монда менә нинди предприятие урнашкан икән! Кабель һәм радиореле магистральләре берничә өлкә территориясен кисеп үтә. Алар буенча бихисап аппаратура урнаштырылган. Кайбер пунктлар җир астында, кайберләре вышкаларда.

Бина эченә кергәч, берничә кабинетны ачып карады Мамед Сурханович. Зур гына бүлмәләрдә өстәлләр артында утырган кешеләр, ирләр һәм хатын-кызлар, бик җитдилек белән эшләп утыралар иде. Кемдер укый, кемдер яза... Ә бер ишектә "лаборатория" дип язылган.

—Әйдә кереп чыгабыз,—диде Мамед Сурханович.

Зур зал. Махсус эшләнгән өстәлләр өстендә бихисап күп приборлар һәм төрле-төрле аппаратура. Тәмле итеп канифоль, ябыштыргыч исе килеп тора. Приборлар янында ак халат кигән егетләр һәм кызлар нидер үлчиләр, бәхәсләшәләр. Залның түрендә, олы өстәл артында, китапка төбәлеп 30-35 яшьләрдәге егет утыра. “Лаборатория начальнигы”,—диде Гусейнов шул якка ымлап. Боларга әлләни игътибар булмады, алар тавышсыз гына чыгып киттеләр.

Кадрлар бүлеге начальнигының кабинеты икенче катта, баскычтан менгәч үк уң якта урнашкан. Өстәл, шкаф, зур гына сейф, суыткыч, алты-җиде урындык...

—Утыр,—диде хуҗа.—Менә сиңа кәгазь. Мин әйткәнне тыңла, каршы килмә. Яз: “Прошу принять меня старшим инженером ПТЛ”. Әйе, әйе, шул без кереп чыккан лабораторияга. Башта шуннан башласаң, сиңа файдалырак булыр. Акчасы башта, әлбәттә, бик үк күп булмас. Чөнки әле синең стажың да юк бит. Өч-дүрт ай үтмәс, бүлек мөдире итеп куярбыз. Баш инженер һәм урынбасарлар янына кереп чыгарбыз.

Кадим озак уйланып тормады. Чөнки ике ай эш эзләп тә мондый урынны тәкъдим иткәннәре юк иде әле дә. Лабораториядә бер караудан үзенә таныш приборларны күреп алды. Андый приборларны ул яхшы белә. Радиолокаторлардагы кебек бик кыска дулкынлы энергия үткәргечләрне дә шәйләде ул. “Монда эш башлау җиңелрәк булыр, приборлар арасында күнеккән эш”,—дип уйлап алды, гаризасын язып та бирде.

—Менә шулай, хәрбиләрчә,—дип, Гусейнов гаризаны өстәл тартмасына тыгып куйды.—Ә хәзер,—ул сәгатенә күз ташлады.—Әбәт вакыты җитте. Без бу эшнең башын юып та алырбыз. А то, понимаешь, иртәннән баш авыртып йөри, һич кенә дә сылтау табып булмый.

Кадим нәрсә турында сүз баруын аңлап алды, әмма бер сүз дә әйтмәде, күзәтүен дәвам итте. Әле Гусейнов кабинетына кергәч, аның авыз ачып сүз әйткәне булмады да кебек.

Шул арада Гусейнов бүлмә ишеген бикләп килде, әллә кайдагы ерак кесәләреннән эзләп, ачкыч тапты һәм сейфның авыр ишеген ачып җибәрде. Суыткычтан берсе артыннан берсе төрле ашамлыклар чыгып өстәлгә тезелә башлады. Балык уылдыгы, сыр, колбаса, шоколад, кәнфит, печенье һәм тагын әллә нәрсәләр бар. Иң азактан, өстәл эченнән рюмкалар һәм башланган коньяк шешәсе килеп чыкты.

—Әйдә, Кадим Каюмович. Салыйк берәрне, баш сафланып китсен.—Рюмкалар тутырылды.—Бергә-бергә эшләү хөрмәтенә, киләчәктә уңышлар хөрмәтенә.

Эчтеләр. Җылы коньяк тәнгә рәхәтлек таратты. Икмәк кисәгенә балык уылдыгы белән май буяп капкалап алдылар. Бүлмә хуҗасы рюмкаларны тагын тутырды, тагын эчеп җибәрделәр. Шуннан соң хуҗа үзенең хезмәт юлын сөйли башлады.

Бер үк гаскәрләрдә хезмәт иткәннәр, уртак танышлары да бар икән. Бу танышуына ул бик шат иде. Менә нинди кешеләр бар бит дөньяда, алар бетмәгән икән әле, яшиләр! Кыенлыкта калганнарга, үзләрен югалта башлаганнарга, ярдәм итәргә әзерләр. Ничә ай эш эзләп йөргән көннәрендә ул, мондый кешеләр юк икән, дигән уйга күнегеп бетә язган иде. Кайчак аның башында начар уйлар да куера иде. Чөнки армиядән башка тормышны ул белми бит. Шуңа күрә армиядән китүенә бик көенде, үземә чит бу тормышта урын таба алмам дип ышанып бара иде инде. Юк, алай түгел икән әле, бетмәгәнбез икән әле! Башта ук аңа запастагы офицерларны эзләп табарга, ярдәм сорап аларга барырга кирәк булган икән! Кадим шушы уйлары белән Мамед Сурханович белән уртаклашты.

—Юк, алай түгелдер ул, Кадим Каюмович, син ялгышасыңдыр. Гражданкада да яхшы кешеләр бар. Син алар белән очрашырсың әле. Синең моңарчы андый яхшы кешеләрне тапмавың аңлашыла—син бит хәзергәчә партия йогынтысында торган оешмалар һәм кешеләр белән генә элемтәгә кереп йөрдең. Ә алар арасында гаделлек кагыйдәләре

буенча яшәүчеләр юк диярлек. Юктыр да, бәлки. Булсалар да аларны тора-бара үзенчәлекле номенклатура тормышына буйсындыралар, өйрәтәләр, күнектерәләр. Партия һәм советлар дигән нәрсәләр алар, син бәлки моңа ышанасың да килмәс, шул хәтле череп беткән органнар алар... Без китапта укып белгән, халыкка хезмәт итүче партия һәм халык тарафыннан сайлап куйган власть түгел, киресенчә, халыкның итен сөягенә хәтле кимереп, үзләре өчен генә яшәүче бер өем, чүп өеме алар. Әмма алар кулында власть...

—Мамед Сурханович, сез бик каты бәреләсез түгелме? Партиягә яла атмыйсызмы? Бу сүзләрегезне тыңлау кыен миңа. Ничек кенә булмасын, мин партияга ышанам. Аерым кешеләр бар, әлбәттә. Менә мине политбүлекләрдәге мөртәтләр армиядән куып чыгарды. Әмма бөтен партия турында...

—Юк, юк, Кадим! Бөтен партия әгъзалары турында сүз бармый...— Гусейнов кинәт сәгатенә күз башлады.—О, о, әбәт узып бара, шешә дә бушаган. Әйдә без моннан бөтенләй шылыйк әле. Берәр аулак урын табып, иркенләбрәк сөйләшеп утырыйк.

* * *

Ике атна чамасы үтүгә Кадим бөтен нәрсәне өйрәнеп чыкты, эшне ничек алып барырга икәнне аңлап бетерде. Аңа беренче көннәрдә үк лаборатория мөдире дә, радиореле буенча начальник урынбасары да ике айга план төзергә тәкъдим иткәннәр иде. Нигә шул хәтле вакыт кирәк микән соң моңа, дип уйлап алган иде ул. Шулай да каршы сүз әйтмәде, төзеде, раслау имзалары куйдырды. Әйтелгәнчә, атна-ун көннән ул планны үтәп чыккан иде. Гусейнов һәркөн диярлек Кадим белән очраша-күрешә торды, үзенең тәкъдим-нәсихәтләрен сөйли торды: "Ашыкма син, Кадим Каюмович, нинди кинәш бирәләр, шуңа күнә бар. Монда армия түгел, ашыгыч эшләр юк. Бөтен нәрсә әкренләп эшләнә. Буш вакытында минем янга кереп йөр."—Кадим шулай итте.

Сәгатьләп, минутлап бүленгән көн тәртибендә яшәгән кешегә тормышның болай барышы бик авыр булып чыкты. Иртәнге сәгать тугызга эшкә килеп, кичке алтыда эштән кайтып китү һәркөн кабатлана... Шимбә, якшәмбе көннәрдә бөтенләй эшкә барырга кирәкми. Чакырып та алмыйлар, төннәрендә шалтыратучы юк. Гаҗәеп тормыш иде бу! Башта Кадим үзен кая куярга белми йөрде. Әлбәттә, кичләрен гаилә белән бергә үткәрү яхшы инде. Киногa, театрга йөрергә була. Элек Халисә гел генә зарлана иде: бөтен гомеребез хезмәттә үтә, театрга да йөри алмыйбыз. Менә хәзер театрга да берничә мәртәбә барып кайттык, кинога да. Балалар белән бергәләп шәһәрдә булган бөтен музейларны да йөреп чыктык. Театрга һәркөн йөреп булмый икән. Аларның репертуарлары да, мин сиңа әйтим... Бер сүз белән әйткәндә, Кадим үзенең ялсыз-нисез, һәр көн унике, ундүрт сәгать эшләп йөргән чагын бик сагына иде.

Гусейнов белән очрашулар бушка китмәде. Кадим үзенә әллә нинди яңа бер дөнья ачты. Бу, әлбәттә, аның яңа танышы белән үткәргән вакытларда, фәлсәфи әңгәмәләр, сәясәт турындагы сүз көрәштерүләрдә килеп туган яңа ачыш иде. Кадим армиядә хезмәт иткән чорда бик тар, төрле яктан чикләнгән, зәгыйфь дөньяда яшәгән икән. Бөтен укулар, алган белемнәр, бөтен мөхит, кешеләр—барсы да шул зәгыйфь, китек дөньяны барлыкка китереп, аны кемгәдер хезмәт иттерер өчен яратылган булган икән. Монда, армиядән читтәге дөньяда исә, бөтенләй икенче хәл. Дөньяга караш чагыштыргысыз киңрәк. Хәрбиләр дөньясы бу катлаулы, киң күләмле, матур тормышның бер кечкенә тармагы гына икән ләбаса! Офицерның тормышы да армиядә хезмәтне тәмамлап, пенсия алу белән генә чикләнми икән. Телисеңме, юкмы—дәвам итә икән. Яше кырыкка җитмәгән егетне дә алда тулы бер тормыш көтә!

Запаска киткән тагын берничә офицер белән танышты Кадим. Һәрберсе үзенчә тормыш корган. Әнә Богатов фамилияле майор бакча сатып алып, җиләк-җимеш, чәчәкләр үстерә. Шуларны базарга чыгарып сатып, күп кенә акча алып, "майда йөзеп" яши. Ә икенчесе, Девятьяров дигәне—урыслашып киткән татар кешесе икән үзе—зур төзелеш идарәсендә директор урынбасары булып өлгергән. "Минем эшем армия хезмәтеннән дә катырак",—дип, авызын ерып, мактанып тик йөри.

Әйе, кеше үзенең тормышын, бәхетен үзе төзи. Берсе үзе өчен генә яши, бу да аңа бәхет булып тоела. Икенчесе башка кешеләр бәхете өчен күбрәк баш вата, шуннан ул ләззәт таба, аның өчен бәхет шул.

Берничә мәртәбә Мамед Сурхановичның өендә дә булырга туры килде. Хатыны кунакка киткән иде. Әйдә кереп чыгыйк, ничек яшәп ятканыбызны карап чыгарсың, дип, көчләп диярлек, алып керде. Аның китапханәсендә бик күп китап җыелган икән. Фатирының бер бүлмәсе тик китаплар белән генә тулган диярлек. Ниндиләре генә юк монда! Тарих, фәлсәфә, матур әдәбият, техника, хокук, хәрби мемуарлар... Солженицын, Бродский, Войнович... Тагын бөтенләй таныш булмаган фамилияләр. Самиздат ич бу!

—Теләсәң сайлап ал, укы. Кешенең башына көчләп кертеп булмый. Кабул итсә—итә, итмәсә—итми. Ләкин һәр кешенең үз фикерен әйтергә дә, таратырга да хакы бар! Кеше хокуклары турындагы Пакт Берләшкән милләтләр оешмасында кабул ителгән. Укып кара, нәрсәсе, кайсы пункты ошамас? Чагыштырып кара, үтәләме безнең илдә? Нигә үтәлми? Кемгә ярамый, кемгә комачаулый?

Гусейновның күп кенә китапларын укып чыкты Шаймәрдәнов. Төннәр йокламый укыды. Нинди генә уйлар, карашлар тумады да, нинди генә каршылыклар барлыкка килмәде!

Пионериядә, комсомолда тәрбияләнгән малай булуына карамастан, Кадим тормыш җитешсезлекләре турында күптән уйлана иде инде. Ник болай ул, нигә тик шулай гына булырга тиеш? Үсә төшкәч, марксизм-ленинизм теориясе һәм практикасы белән аңлы рәвештә таныша башлагач, сораулар бигрәк тә күп туды. Эшчеләр сыйныфы алдынгы сыйныф булгач, тик ул гына илнең, дөньяның язмышын хәл итәргә тиеш булгач, ничек итеп Монголиядә, Кытайда, Төньяк Кореяда, эшчеләр сыйныфы булмаган илләрдә, социализм җиңеп чыкты? Көнчыгыш Европа илләрендә совет гаскәрләре кермәгән булса, социализм җиңеп чыгар идеме? Һәм башка, һәм башка сораулар... Социализм тәрәккый итә бару белән сыйныфлар көрәше көчәячәк дигән фараз белән малай чакта ук килешми иде ул. Юлбашчылар алмашынгач ил сәясәтенең үзгәрүе, икенчеләнүе дә күренеп тора ич. Төгәл, дөрес теорияне нигә ара-тирә үзгәртеп торырга кирәк ул? Бердәнбер дөрес теория булгач! Соңгы вакытта теорияне конкрет кешегә бәйләп ясау ап-ачык булып ярылып ята. Ә шул ук "череп беткән" капиталистик илләрдә—АКШта, Бөекбританиядә, Франциядә—ил башлыклары дүрт-биш елга бер алмашынып тора. Төрле партияләр хакимияткә килә. Тормыш һаман алга бара, чәчәк ата. Сугыш вакытында җимерелеп беткән Алмания, Япония ничек күтәрелеп чыкты? Дөрес теория белән "коралланган" эшчеләр сыйныфы бу илләрдә хакимияткә килеп, халыкларны социализмга алып китә алмады. Чынлап та, сораулар бик күп туа шул. Җавап бармы боларга? Уйланырга кирәк...

Мамед Сурханович дөрес әйтә, ә Кадим аның белән килешә... Совет-партия органнарында бер үк кешеләр дистәләгән еллар буена утыра. Өстә дә, аста да шулай... Монда кешеләр-кадрлар барсы да сайлап алынган. Өстән нәрсә әйтелсә, шуны гына эшләргә тиешләр. Бу принципны үтәмәсәң, сиңа монда урын юк. Күпләр комсомол яшеннән үк номенклатурага кандидат итеп язылa. Төрле вак дәрәҗәләрдә сынаулар үтеп, өскә күчә. "Сайлаулар" вакытында халык (ул шундый дәрәҗәгә җиткерелгән инде, мескен) бердәмлек күрсәтеп, түрәләр тарафыннан алдан ук билгеләнгән бердән-бер кандидат өчен тавыш бирә. Советларда, партия

оешмалары җыелышларында, конференция-съездларда күпме эшче, күпме колхозчы буласы алдан ук язылып куелган. Менә нинди илдә яшибез без! Шушы структурага каршы тавыш күтәреп кара—төрмәдә, яисә психбольницада башың черерен белеп тор! Чит илгә куып чыгару да аз түгел. Монысы инде башка чаралар куллана алмаганга күрә, еракларда танылып өлгергән күренекле кешеләрне шулай кудылар... Ә академик Андрей Сахаровны үз илендә тоттылар, сөргендә...

* * *

Апрель аеның бер ямансу гына көне иде. ПВО хезмәткәрләре көнен бергә үткәрик, дип, Гусейнов Кадимне тагын кунакка чакырды. Хатыны бүген дә өйдә юк икән, санаторийга киткән. Фатирда бераз гына тәртипсезлек тә сизелә. Диванында йокыдан соң җыеп куелмаган юрганы, мендәрләре ята. Кухня өстәлендә юылмый калган савыт-саба да күренә.

Кадимнең моңа игътибарын сизеп:

—Бүген генә шулай, башка көннәрдә миндә тәртип ул,—дип акланып алды Мамед Сурханович.—Әйдә, залга чыгып урнаша тор. Өстәл чиста анда. Кашык-чәнечкеләр, рюмкалар куя башласаң да ярый. Үзем хәзер суыткычта булган ашамлыкларны барлый башлыйм. Җылы аш та әзерләп алырмын,—дип, кухняга чыгып китте.

Ашыкмый гына өстәл әзерләп йөргәндә Кадимнең исенә әллә кайчан үткән вакыйгалар килеп төште. Малай чакта Кадимнең Искәндәр исемле якын дусты бар иде. Ул—укытучылар гаиләсеннән. Бик укымышлы, бик зирәк иде. Гаиләләре Кадимнәр авылына сугыштан соң килеп чыгып, тиз арада авылның үз кешеләре булып китте, халык арасында зур хөрмәт казанды. Мәктәп директоры булып эшләгән Шәриф абый беренче караганда бик басынкы гына, тыйнак кеше иде. Әмма мәктәп эшләрен шул хәтле шәп алып китте ки, бөтен район сокланып карый башлады. Яңа бина салынды, укытучылар, укучылар арасында моңарчы күренмәгән тәртип урнашты, мәктәпнең эче дә, тышы да ямьләнеп, балкып китте. Сугыш вакытыннан бирле укытып йөргән өч-дүрт кеше тавышсыз-тынсыз гына пенсиягә җибәрелде—чөнки эчәләр иде алар, халык күрә иде моны. Алар урынына яшь укытучылар килде. Авыл клубында Шәриф абый лекцияләр укыганда (шундый яңалык та килеп керде авылга), кинона, ике айга бер күрсәтсәләр, хәзер ул һәр атнада китерелә башлады. Мәктәп балалары элекке кебек кача-поса кичке кинога йөрмиләр. Дәрес беткәч, сафка тезелеп клубка китәләр, рәхәтләнеп кино карыйлар—акчасы алдан ук түләп куелган икән! Нәгыймә апа да мөлаем йөзле, ачык күңелле иде. Аның дәресләрендә—ул ана теле укытты—һәрвакыт күңелле һәм кызык. Һәркемгә ягымлы сүз таба, күңелне күтәреп җибәрә торган кеше иде мәрхүмә. Менә шушы гаиләдә еш булырга туры килде Кадимгә. Алардагы китаплар! Шул хәтле күп китапны авыл китапханәсендә дә күргәне юк иде Кадимнең. Сокландыргыч иде: нинди генә китаплар юк! Бөтенесен карап чыгасы, укыйсы килә!

Кайчакларда Шәриф абый белән Нәгыймә апа бергәләп Барда ягына сәфәр кылалар. Алар үзләре шул яктан икән. Менә шул чакларда Искәндәр белән Кадим аулак өй оештырып алалар иде. Күп итеп бәрәңге пешереләә. Ашап-туеп, бераз корсак сыйпап, идәндә тәгәрәгәч—уен китә. Шахмат, шашка, ә үсә төшкәч кәртле уйныйлар иде. Искәндәрнең энесе Робин исемле. Ул дүрт яшькә кечерәк. Иллә комачаулый иде яшьтәшләргә! Анынча булмаса киреләнә, үзенең капризларын төрлечә китереп чыгара... Искәндәр арт санына төшереп алгач елап җибәрә. Үпкәләп почмакка барып утыра да, әти кайткач барысын да сөйләп бирәм, дип, яный башлый. Әләкләшеп үзенекен итәсе килә. Бу аулак өйләргә күп вакыт күрше малайлары Рәфил белән Рәфкать тә керә, тугызынчы класста

инде кызлар да катнаша иде. Менә аулак өй килеп чыга иде ичмасам! И-и, искә төшерә башласаң...

Тукта, нәрсәдән килеп керде соң әле болар башка? Ә-ә, аулак өй дигәннән, китаплар әсирлегендә булып алганнан икән бу.

Мамед Сурхановичның тундырылган пилмәннәре дә бар, шулпасын да җылытасы гына икән.

Өстәл туп-тулы иде инде. Гусейнов сәгатенә карап алды.

—Тагын бер-ике кеше килергә тиеш иде. Әллә бераз көтәбезме соң, Кадим Каюмович?

Әзерләнгән ризыкларга карап икәүләп кенә утырмаячакларын сизәргә була иде инде Кадимгә.

—Әлбәттә, Мамед Сурханович! Нинди сүз булырга мөмкин.

Тәрәзә аша өй алдындагы кечкенә мәйданчыкта балалар өчен төзелгән кальга-шаһәрчек күренә. Әтрафе төзелмәләре коймa белән уратып алынган, почмакларында башнялары да бар. Дүрт ягындагы капкалары чын кальганыкыннан һич калышмыйдыр, тик биеклеге генә бүтәнчә. Нечкә бүрәнәләрдән җиргә казып утыртылган коймасы читтән караганда чынлап та кальганы хәтерләтә. Капкаларның берсеннән кереп, икенчесеннән чыгып өч-дүрт бала уйнап йөри. Әниләре-әбиләре, бер читтәрәк торган эскәмиядә утырып, балалары турында бөтенләй онытканнар да...

Уйларга чумып, тәрәзәгә карап, балалар тормышын озак кына күзәтеп торды Кадим.

Мамед Сурхановичның икенче кунагы да килеп керде.

—Илләә мактап кына йөрисез инде!

—Мактамыйча соң, сезнең кебек кешеләрне!

Алтмыш-алтмыш биш яшьләрдәге, ап-ак чәчле олы гәүдәле, мөлаем йөзле ир-ат иде бу.

—Сәлам асыл егетләргә!

Үткен, әмма ачык караш. Тавышы бик ягымлы. Бөтен сөйләгән сүзләре үз урынында. Кирәкмәгән сүзләр сөйләми бугай бу кеше. Гәүдә хәрәкәтләре, кул селтәүләре дә салмак кына. Аның кыланышы, сөйләшүе, көлүе, шаяруы, хәтта бер сүз әйтмичә тынып торуы да, башкаларның игътибарын җәлеп итә, үзенә бәйли иде. Таныштылар. Бу кешенең исеме Николай Палиевич Татаринов булып чыкты.

Ун-унбиш минуттан тагын бер кунак килеп кергәч, фатир эче тагын җанланып китте. Сөйләшә-көлешә, өстәлгә ашамлыклар, савыт-саба куйдылар. Ишетелер-ишетелмәс кенә музыка кабызып җибәрделәр.

—Классика дигәч—классика! —Николай Палиевич берничә кассета тартып чыгарды.—Кая әле монда мин яратканнары? Ә-ә, менә икән,—дип, кирәк төймәләргә басты.

Өченче кунакның исеме Кокурин Иван Дмитриевич булып чыкты. Ул кырык-кырык биш яшьләр чамасындагы, урта буйлы, уйчан йөзле, пеләш башлы кеше иде. Күрешкәндә бик тырышып йөзенә елмаю чыгарды да, тагын моңсу маскасын киеп куйды. Әмма, шуңа карамастан, житез генә кухняга йөгерде, шунда ук нәрсәдер алып залга чыкты, аннан балконга китте, нәрсәдер алып керде. Рюмкалар сөртте, икмәк кисте. Татаринов белән Кокуринның монда беренче мәртәбә генә килүләре түгел икәне күренеп тора иде.

Менә инде өстәлгә куясы ризыклар куелып беткән. Төрле-төрле эчемлекләр, салатлар, паштетлар, ит, балык ризыклары... Әйтерсең бу катлаулы һөнәрдә тәҗрибәле хуҗабикә үзе монда булган. Хәтта һәркем алдына кашык, пычак, чәнечкеләр белән бергә крахмалланган салфеткалар да куелган иде.

—Без монда дүртәү. Нык таныш булмасак та, бер-беребезне беләбез. Кадим Каюмович безне азрак белә, әмма зарар юк, танышырбыз! Шуны ышанып әйтә алам: монда һичнинди яшеренгән фикер калмас. Без шундый кешеләр дип уйлыйм. Күпне күрдек, күпне ишеттек, күпне беләбез. Сөйләшәсе сүзләр, проблемалар күп. Беренче тостны болай дип әйтергә

рөхсәт итегез: якын киләчәктә гаделлекнең җиңүе өчен, гаделлек хөкем сөргән җәмгыять өчен!

Менә шундый сүзләрдән башланып китте бу очрашу. Дүрт кеше очрашуы. Һәм алдан ук әйтеп куйыйк: Кадимнең тормышын бөтенләй икенче якка б о р ы п җибәргән очрашу...

Николай Палиевич Татариновның атасын, анасын кулга алган елны аңа унөч яшь тула. Әтисе индустриализация елларында ук танылган инженер булган. Ул зур-зур завод-фабрикаларны төзүдә катнаша. Әнисе дә өйдә генә утырмый. Гаиләдә бер генә бала булганлыктан, башта, иҗтимагый оешмаларда, аннан соң комсомолда эшли. Утыз бишенче елда партия эшенә күчә. Ирне яңа урынга күчергән җирдә аңа тагын комсомол, партия эшләрен йөклиләр.

Шуңа күрәдер инде ир белән хатынны утыз җиденче елны бер үк төндә кулга алалар һәм юкка чыгаралар. Ә унөч яшьлек малайны исә балалар йортына озатып, мәңгелеккә ата-ана иркәсеннән һәм тәрбиясеннән мәхрүм итәләр. Бер урыннан икенче урынга күчергәндә берничә танышыннан да аерыла бу бала. Сталинга табындыра-табындыра, әти-әнисен, "халык дошманнарын", оныттырырга тырышалар.

Күп мәртәбә "мин алардан ваз кичәм" дигән сүзләрне әйттерәләр. Коммунистлар системасының бер шөребен әзерләргә, башындагы уйларын үзләренә кирәк якка юнәлтеп, кол итәргә тырышалар. Әмма унөч яшендә әти-әнисез калган малай бернәрсәне дә онытмый.

Аның чын исеме Нурихан иде. Балалар йортына урнаштырганда ул Сафин Нурихан Галиевич дип язылган иде. Бер урыннан икенче урынга күчә-күчә ул Татаринов Николай Палиевичка әйләнде. Дөрес, Николай исемен иптәшләре такты. Урыс малайлары башка милләт кешесенең исемен әйтергә яратмыйлар, үзләренчә боралар. Аңлы рәвештә эшләнми бу бала-чага арасында. Әмма ничек кенә боргалама—урыслаштыруның беренче адымы инде бу. Аның әнисен Галя дип йөртәләр иде Мәскәүдә торганда, күрше Сәкинә апаны Сонечка дип... Ә Сафин фамилиясе ничек югалуын Нурихан абый исенә төшерә алмый икән. Татаринов дигәне, әлбәттә, кушаматтан чыкан. Аны күп вакытта "татарин" дип кенә йөртәләр иде. Галиевичны Палиевичка әйләндерү читен түгел. Берәр белемсез, игътибарсыз писарьның хатасы, шаяруы, яки башка эше булгандыр. Инде сугыш башлангач, ФЗО мәктәбендә укып йөргәндә, шул ук вакытта заводта эшләп йөргәндә, Нурихан әллә ничә мәртәбә: "Минем чын исемем Сафин Нурихан Галиевич, төзәтегез",—дип карады. Тыңлаучы да булмады. Хәтта: "Какая тебе разница? Вполне русская фамилия",—диделәр. Кырык өченче елда армияга алынганда документларда: "Татаринов Н. П., национальность русский",—дип язылган иде инде.

Сугышның соңгы елында артиллерияда хезмәт итә Нурихан. Ходай саклап исән кала. Хезмәтен кырык тугызынчы елда гына бетереп ул Мәскәүгә кайта һәм эшкә урнаша. ФЗОда өйрәнгән һөнәрләре күп була: ул токарь да, слесарь да. Кичләрен мәктәптә укый. Аннан соң институт. Әтисе кебек инженер буласы килә. Һәм ул теләгенә ирешә. Энергетика институтын бетергәч бер фәнни учреждениегә эшкә җибәрелә. Эшендә үзен яхшы яктан гына күрсәтә. Бабасы, әтисе кебек тырышып эшли—аларның геннары сакланган ич. Өйләнә, гаилә кора. Техник фәннәр докторы дәрәҗәсе ала. Хрущев заманындагы "җепшек" чорда туган-тумачаларын да эзләп карый. Әмма беркемне дә таба алмый—чөнки ул әтисе-әнисенең, аз санлы туганнарының берсенең дә исемен, фамилиясен белми, исенә төшерә алмый.

—Менә шундыйрак кеше инде мин, иптәшкәйләр,—ди Николай Палиевич. Бу сүзләрне ул берничә мәртәбә кабатлады инде. Сүзләрендә моңсулык сиздереп тә һәм киресенчә, күңелле итеп, шаяру сыман итеп тә әйтте ул. Бик катлаулы да, шул ук вакытта бик ачык кеше дә ахрысы бу Нурихан абый!

—Без дүртебез дә тоталитар режим корбаннары, егетләр. Әйе, әйе,

корбаннары! Чөнки без—рухи яктан үтерелгән кешеләр. Минем әти белән әни һәм башка миллионлаган кешеләр физик рәвештә үтерелгән булсалар, калганнары, йөз миллионнары—рухи үтерелгәннәр. Аларның алдында һичнинди киләчәк юк. Аларның хәтта изге хыяллары да юк. Бүген ашаргаэчәргә, иртәгә кол хезмәтенә барырга кием-салым, баш өстендә яңгыр-кардан яшеренерлек өй түбәсе, түшәме булса, алар, месекеннәр, үзләрен бәхетле дип саныйлар. Һәркемнең фатир алу хыялы бар, аны дистәләгән еллар буена көтү бар—менә шулардан башка бу совет халкына бүтән нәрсә бирелгән соң? "Якын киләчәк—коммунизм", дигән нәрсә ул шушы үтерелгән халыкны алдау гына бит. Киләчәк булмау, хыял, максат булмау халыкны эчкечелеккә, ялкаулыкка, алдашуга, урлашуга китерә. Бу процесс хәзерге көндә көчәя бара. Тормозы тәзек булмаган, текә тау юлыннан аска табан төшеп килгән машинага охшатам мин безнең җәмгыятьне. Тизлек һаман арта. Руленә кемне генә утыртма, автомобиль чокырның төбенә килеп житкәч, барыбер челпәрәмә килеп ватылачак. Хәзер рульдә коммунистларның бер төркеме утыра. Илне алар катастрофага алып бара. Минемчә моны күпләр аңлый инде. Аңларга вакыт житте. Бәлки ватыласы автомобильдә утырган кешеләрнең бер өлешен, күпмесен генә булса да, саклап калырга булыр әле? Моның шулай буласын күпләр большевиклар хакимияткә килгәч үк аңладылар һәм әйтеп тә чыктылар. Шул күпләр арасында чын большевиклар да бар иде, әлбәттә. Ләкин сайланган юл дөрес түгел дип әйтүчеләр күбәя башлагач, моңа каршы каты көрәш ачылды. Әүвәлге корбаннарның беренчеләреннән Мирсәет Солтангалиев булды. Дөньяда, бигрәк тә төрек, гарәп илләрендә, күптән танылган бу бөек шәхес турында без әле белмибез диярлек. Вакыт житәр, ул да тарихта үзенең урынын алыр... Соңгы елларда тавышларын дөньяга ишеттергән диссидентлар хәрәкәте дә большевиклар сайлаган юлның дөрес түгеллеген күрсәтергә тырышты. Бүгенге көндә алдынгы фикер йөртүчеләр бармы соң ул? дип сорарсыз. Әлбәттә, бар! Кулга корал тотып чыгарга әзер кешеләр дә бар! Менә безнең арада утыручы Иван Дмитриевич. Әнә, Кадим Каюмовичның армиядән куылуы һәм аның, шул вакытта үз-үзен тотуы, курыкмыйча, кыю итеп үз фикерләрен ярып салуы... Болар барсы да мин әйткәннәргә мисал. Сүз арасында гына әйтеп үтәргә кирәктер, Кадим Каюмович, утызынчы елларда сезне, полк командирын, НКВД атмыйча калдырмас иде. Елмаю монда урынлы түгел, кадерлем, чынлап та шулай итәрләр иде! Сугыш алдыннан атып үтерелгән командирлар исемлегенә өстәргә кирәк булыр иде сезне, горурланыгыз! Хәзер бераз үзгәрде вазгыять. Төрмәдән, психбольницадан кала иң каты җәза чит илгә олактыру хәзер. Бүген Мамед Сурхановичка кунакка килүегез КГБга билгеле, шикләнмәгез. Әмма алар безнең дүртәү утыруны белмиләрдер дип уйлыйм. Ярый, шулай булсын: алар сезне икәүләп кенә коньяк эчәләр дип уйлансыннар, ә без дүртәүләп чәкешик!.. —Сүзсез генә эчеп куйдылар. Әйтелгәннәргә өстәрлек сүзләр табылмады. . Тик даими рәвештә: "Менә нинди дөньяда яшибез бит!" дигән уй башта бөтерелә иде...

Бераздан сүз тегенди-мондый вак-төяккә кереп китте. Бик матур, бик кызыклы тостлар әйтелде. Анекдотлар сөйләнде. Ә өстәлдә кабымлык шәп иде, әй!

—Кадим Каюмович, ә сез татарча яхшы беләсезме?—дип сорады кинәт Николай Палевич.

—Беләм. Татар авылында үстем бит мин! Сигезенче класска хәтле татар мәктәбендә укыдым.

—Яхшы беләсезме, диюем. Әдәби татар телен беләсезме соң?

—Берничә ел татарча журналлар алдырттым. Әмма даими укып барырга вакытым гына булмады. Шуңа күрә әдәби телне белүем чамалыдыр инде.

—Шулайдыр, мин дә шулай уйлаган идем. Ә менә Мамед Сурханович үзенең ана телен бөтенләй дә белми икән. Шуңа карамастан, мин

әзербәйҗан, дип мактанып йөргән була. Ә паспортында бөтенләй “русский” дип язылган. Дөресме, Мамед Сурханович?

—Дөрес. Минем әни рус кешесе, шуңа күрәдер рус дип язганнар. Әти өйрәтергә тырышып карады, килеп чыкмады. Үзем гаепледер инде.

—Юк, син гаепле түгел, Мамед Сурханович, әниең гаепле! Гафу итегез, әниең мәрхүмә инде, җаны җәннәттә булсын. Әмма шуны әйтәсем килә: мин шундый кеше инде, әйтмичә калдыра алмыйм. Менә без дүрт кеше утырабыз. Безнең арада тик Кокурин гына урыс затыннан. Димәк, калганнарыбыз урыс түгел. Ә калган өчебезнең берсе генә татар дип язылган. Ничек килеп чыга соң әле бу? Минем канда бер тамчы да урыс каны юк. Мамед Сурхановичның әтисе әзербәйҗан. Ул да урыс булырга тиеш түгел. Карагыз борынына, чәчләренә. Кыланышына игътибар итик: охшаганмы урыска? Аңлатып бирә аласызмы?

—Аңлашыла кебек,—диде Шәймәрдәнов.—Илдә урыслар күп, дәүләт теле урыс теле. Вак халыклар урыс культурасына тартыла. Табигый хәл—күпләр урыслаша бара.

—Башка милләтләр бетү табигый хәл дип уйлыйсызмыни?

—Бөтенләй бетмәс бетүен дә...

—Ничек бетмәсен, ди! Карагыз статистиканы: инде ничә милләт беткән СССР да. Бу бит соңгы илле ел эчендә генә.

Кокурин да тамак кырып алды:

—Мин күптән уйланып йөрим бу турыда. Күп вакыт шаккатасың: ни өчен мари авылларында, ә мин үзем шул яктан, мари мәктәпләрен бетереп русча укытуга күчәләр микән? Урыс исемнәре кушалар, рус җырларын җырлыйлар. Кыскасы, үзләрен үзләре бетерәләр. Аңламыйм, валлаһи аңламыйм мин моны...—Өстәл артында бер минутка тынлык урнаша. Менә бит урыс егете дә аңламый мондый хәлне.

—Әйе. Монда бөтен нәрсә ачык, егетләр. Шундый сәясәт ул безнең илдә—урыслаштыру сәясәте. Көчләпме, ачык рәвештәме, яшерен итепме—шул сәясәт бара. Урыс халкы бөек халык, аның теле дә бөек имеш. Урта һәм югары уку йортлары тик урыс телендә генә укыта. Димәк, югары белем аласың килсә, син барыбер урыс телен өйрәнәчәксең, ә үзеңнең телеңне онытачаксың. Бу сәясәт Явыз Иван чорыннан ук каты бар. Урыс империясе советлар чорында икенче төстә генә икенче лозунглар астында гына яшәде. Ә империя—империя булып кала бирә.

Тынлык урнаша. Уйланалар...

Инде ярты төн уза. Кунаклар кайтырга җыена.

—Болай итәбез, егетләр,—ди Мамед Сурханович.—Кадим Каюмович беренче булып чыга.—Туп-туры өенә табан юнәлә. Бернәрсәгә дә борылып карама, тирә ягыңа да, артыңа да! Син салгансың, кәефең күтәренке. Сүз кушарга омтылучы табылса, кискен дәшмә—син кунактан кайтасың! Ә сез, Николай Палевич, үзегез беләсез, бераздан икенче подъезд ягыннан чыгып китәрсез. Ишекне каты япмагыз, күршеләр сизмәсен, уянмасын. Мин үзем ярты сәгатькә дворник янына киттем, кергән кешеләрнең китүен көтеп күзләре дүрт булгандыр инде.

Мамед Сурханович бишмәтенең түшкесәсенә башланган аракы шешәсен тыга, кәгазьгә төреп колбаса кисәге, ипи ала. Ул беренче катта урнашкан дворникның фатирына юнәлә. Бер-ике чокыр аракы йоткач килгән-киткән кешене күзәтеп торуны оныта дәүләт куркынычсызлыгын саклаучы...

* * *

Апрель башы. Көннәр җылы, күк йөзендә һичбер болыт кисәге күренми. Кояш нурлары юллардагы карны инде эретеп бетерде. Кешеләр дә быел иртәрәк килгән язның рәхәтлегеннән җанланды: кәефләр күтәренке, күңелдә иркенлек. Алар бер-берсенә елмаялар, көлешәләр—яз житкәч ич!

Эш вакыты үтү белән үк, сәгать биштә, җыелышлар залына халык агыла башлады. Бүген партия оешмасының ачык җыелышы. Партия әгъзасы булганнар да өйгә кайтып китәргә ашыкмый. Партия җыелышына үз теләкләре белән килгәннәр. Гаҗәп хәл бит! Шаймәрдәнов белә моның сәбәбен, чөнки ул төшке аш вакытында бюро әгъзасы булган Гусейнов белән сөйләшеп утырды. Кичә кич партбюроның утырышы булган икән. Сәгать тугызга хәтле тарала алмаганнар. Алар район комитетының партия оешма җыелышына тәкъдим иткән көн тәртибен караганнар. Элегрәк, билгеле инде, райком әйткәнне тикшереп тормыйлар, үтиләр генә иде. Ә хәзер... Каршы чыкканнар бюроның кайбер әгъзалары: безгә мондый көн тәртибе белән җыелыш үткәрергә хаҗәт юк! Көн тәртибен, кара син, ниндине җибәргәннәр: "Ленин өмәсен үткәрүдә коммунистларның бурычлары". Беренче булып идарә башлыгы каршы чыккан.

—Нигә мондый көн тәртибен тагалар безгә? Әллә безнең өмә үткәргән чакта кыенлыкларга очраган бармы? Былтыр да, өченче елны да бөтен алган планнарыбызны үтәп, рәхәтләнеп эшләп, бәйрәм кебек үткәрдек ич!

Берничә кеше шунда ук идарә башлыгын яклап чыккан: вакытны бушка үткәрү генә булачак бу! Әмма партбюро секретаре моның белән килешмәгән:

—Иптәшләр! Мондый җыелышлар бөтен партия оешмаларында да үткәреләчәк. Райком кушкач үткәрергә туры килер инде. Өстән төшерелгән күрсәтмәне үтәмичә булмас.

Киткән боларның бәхәс. Секретарь икенче бүлмәгә чыгып райкомга шалтырата икән. Райкомда кизү хезмәткәрдән башка беркем дә юк, чөнки сигез тулып бара. Кизү райком секретаренең фатирына шалтырата, анысы ни өчендер телефон трубкасын алмый. Шулай итеп берниндн карарга килә алмыйча таралалар болар. Ә иртән иртүк райкомнан инструктор килеп җиткән. Идарә башлыгы бүлмәсендә тиз генә тагын бюро җыеп алганнар. Тагын бәхәс купкан. Бюро әгъзалары бу юлы барысы да диярлек бер фикерне яклаганнар: мондый көн тәртибе белән җыелыш үткәрмәскә! Бу турыда халык белгән, әлбәттә. Шуның өчен эш бетү белән өйгә кайтып китмичә, залга җыелганнар. Йөз кеше сыярлык зал шыгырдым тулган, басып торучылар да байтак.

Доклад мазар булмагач, һәркем үзе теләгән сүзне сөйләде. Әлбәттә инде иң күнелгә тигәнен, иң әһәмиятлесен, иң актуаль булганын. Кадим чыгышларны зур игътибар белән тыңлады һәм менә нәрсә күзгә ташланды. Халыкның карашы өстән җибәрелгән карарлардан, күрсәтмәләрдән, программалардан бөтенләй диярлек аерылып тора икән. Кешеләр кыюлана, курыкмый сөйли, өстәге житешсезлекләрне ачык күрә һәм үзенең канәгатьсезлеген туп-туры әйтә. Халык киләчәгенә ышанмый, шуңа күрә бик борчыла, бигрәк тә бала-чагасы өчен кайгыра. Әгәр якын вакытта бу курс үзгәрмәсә, аны үзгәртергә кирәклеген ачыктан ачык әйтә, хәтта "алып ташларга" дигән сүзләрне дә әйтергә курыкмый.

Чыгыш ясаучылар саны егермедән артып китте. Бу алтмыш өч партия әгъзасының өчтән бер өлеше дигән сүз иде. Зал гөрләп торды, тәнәфес ясарга да оныттылар.

Кадим үзенең чыгышында өстәге партия оешмаларын тәнкыйтьләп күп кенә фактлар китерде. Мона һичнинди инкарь итәрлек сүз әйтә алмады райком вәкиле. Ничек каршы сүз әйтеп була инде бөтен кешегә билгеле булган нәрсәләргә? Халыкның чарасыздан төрле партия органнарына хатлар язуы, аларның ясалма рәвештә генә тикшерелүе, кибетләрдә күп товарларның булмавы, түрәләрнең шул ук вакытта майда йөзүе турында сөйләде Кадим. Халыкның канәгатьсезлеге чиксез түгел, диде ул... Мондый канәгатьсезлекнең хәрбиләр арасында да чыгуы күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә. Мәскәүдә бу турыда уйланулар сизелми, кызганычка каршы. Балтик диңгезе флотында бер торпеда катеры командасының баш күтәреп диңгезгә чыгуы, аннан Ленинградка юл тотып,

радио аша совет халкына, илнең дөрес юл белән бармавы турында мөрәҗәгать итү таләбе кую турында сөйләп биргәч, җыелышта катнашучылар телсез калдылар. Мондый фактлар күп нәрсә турында әйтә, әмма өстәге түрәләрнең тормышны үзгәртү турында уйлаганнары да юк бугай, без сизмибез моны. Корал эшлибез, сатабыз, амбарларга тутырабыз, җир шарының әллә кайсы почмакларындагы сугышларга катнашабыз, башка илләрнең эчке эшләренә тыгылабыз, ә халык моны телиме, юкмы, сорамыйбыз. Халык хәерче! Ә социализм чорында бит халык бай яшәргә тиеш!

Кадим, әлбәттә ераккарак кереп китүен сизеп алды, әмма соң иде инде. Кызып кителде, ни эшлисең, күңел тулган чак иде.

Җыелыштан соң Шәймәрдәнов белән Гусейнов җәяү генә кузгалды. Бер квартал да үтәргә өлгермәделәр, артларыннан килгән кара төстәге "Волга"дан берләшмә начальнигы Поповский килеп чыкты.

—Мин дә кушылсам каршы килмәссезме, егетләр?

—Әйдәгез, әйдәгез, Валерий Петрович. Саф һава сезгә дә зыян итмәс.

—Әйе, мондый көннәрдә саф һава җитмирәк.—Бераз сүзсез генә бардылар.—Нинди тәэсир калдырды соң бүгенге җыелыш?—Поповский икесенә карап алды, кем беренче булып үзенең фикерен әйтер?

—Кайчандыр күрсәтергә кирәктер бит инде райком, обкомнарга: болай эшне алып барып булмый ич! Аз гына булса да мөстәкыйльлек булырга тиеш бит партия оешмаларына. Бәлки берәр акыллы баш аңлар анда.—Мамед Сурханович шулай дип кенә чикләнде, Кадим үз фикерен әйтергә өлгермәде. Поповский:

—Ә сез, Кадим Каюмович, Балтфлотта булган вакыйга турында юкка сөйләдегез түгелме? Чынлап та булган хәлме соң ул? Минем беренче ишетүем?—диде.

—Булган хәл. Бу турыда бөтен флот, бөтен армия белә. Безнең шәһәрдә бу фетнәдә катнашкан бер егет яши. Фамилиясе Кокурин, матрос булган шул катерда,—Шәймәрдәнов кисәк борылып Гусейновка төбәлде: "Әллә Иван Дмитриевич?"—Әйе, нәкъ үзе!"

—Мин бу вакыйга турында башка җирдә ишеткән идем,—диде Кадим.

—Кайда гына ишетмә, барыбер бәйләнәчәкләр, белеп тор!—дип куйды Поповский.

Озак кына сөйләшеп йөрде бу өч кеше буш шәһәр урамнарында...

* * *

Ике-өч көн үткәч Шәймәрдәновны беренче бүлеккә чакырдылар. Берәр документ килгәндер, дип уйлады ул. Монда яшерен документлар белән таныштырырга чакыралар иде, гадәттә. Бу юлы яңа килгән документлар юк, чакырып алучы кеше берләшмәнең КГБ кураторы майор Девятьяров икән.

—Мин сезгә Кадим Каюмович үткән җыелышта ясаган чыгышыгыз буенча берничә сорау бирергә тиешмен. Беренче сорау: сез бу җыелышны әзерләүдә катнаштыгызмы? Ничегрәк планлаштырган идегез?

—Сез яхшы беләсез минем бюро әгъзасы булмаганны. Мин җыелышка хәтле бернинди планлаштыру белән шөгыльләнмәдем.

—Ә сезнең чыгышыгыз нәрсә турында әйтә, нәрсәне күрсәтә?

—Мин чыгышымда нәрсә турында әйткәнмен, шуны күрсәтә.—Берләшмә начальнигы Валерий Поповскийның җыелыштан соң кайтканда әйткән сүзләре кылт итеп искә төште.—Чыгышымда җыелыш әзерләү турында бер сүз дә булмады.

—Ә Балтфлотта булган хәлләр турында нигә сөйләргә кирәк иде? Ни өчен сөйләдегез, халыкны котырту өченме? Сездә нинди максат иде?

—Гәзитләрдә язылмаса да, бу турыда халык белә. Шулай булгач ник моны яшереп торырга? Сез үзегез беләсез бит.

—Мин... Мин белмим...

—Беләсез. Белмәсәгез соравыгызны икенче төрлерәк куяр идегез. Мин тел яздырмадым, үзегез сизми калдыгыз, белгәнегезне ычкындырып җибәрдегез.

—Ярый, мин беләм дә, ди. Ләкин бездә белгертми торган нәрсәләр дә бар бит әле. Менә, мәсәлән, без утырган бүлмәдәге документларны бөтен кешегә дә укытып булмый. Сезгә моның өчен допуск бирелгән, ә башкаларга юк. Чит ил, дошман илләр разведкалары йокламый бит, бөтен көчләрен биреп эзлиләр төрле информацияне.

—Сез, Владимир Арсланович, тегенең белән моны бутамагыз. Балтфлоттагы вакыйгалар турында "дошманнары"—радиотапшыргычлар әллә кайчан сөйләп биргәннәр инде.

—Ә сез аларны тыңлыйсызмы?

—Мин тыңламыйм. Бәлки тыңлар идем дә, ишетеп булмас—бик якын урнашкан безнең шәһәрдәге томалагыч радиотапшыргычлар. Сез дә инженер бит, аңлыйсыз барсын да.

—Шулай да әйтегез инде, кайдан алдыгыз Балтфлот турындагы информацияне?

—Берничә җирдә ишеттем. Беренче мәртәбә поездда, Мәскәү—Свердловск поездында. Аен да, көнен дә исемә төшерә алам кирәк булса. Тик кирәкмидер монысы сезгә. Командировкага бара идем. Эләктем офицерлар компаниясенә. Минем дә күптән түгел генә демобилизацияләнгәнемне белгеч, ачыктан ачык сөйләштеләр, шактый гына салганнар да иде. Сез эзләмәссез теге офицерларны, шуңа күрә сөйлим, тиренең хакы иләү хакыннан күпкә ким. Минем полкта да беләләр иде бу турыда офицерлар. Анысын инде сез үзегезнең коллегадан сорагыз, полкка беркетелгән КГБ вәкиленнән, дим.

—Шулай да җыелышта чыгып сөйләү...

—Халык белүе турында әле генә аңлаттым бит, Владимир Арсланович. Нигә миңа бәйләнергә инде?

—Мин начальствога ирештерергә тиеш...

—Бу сезнең эш, шуңа акча аласыз. Ә миңа бәйләнерлек урын юк монда. Бик күп нәрсә белән канәгать булмасам да, фетнә күтәрергә әзерләнгәнем юк. Шуны әйтегез начальствогызга. Аннан соң шуны да истә тотыгыз: мин бу бүлмәдә алган яшерен мәгълүматларны башка кешегә сөйләмәскә подписка биргәнмен. Җаваплылыгымны исемдә тотам. Дошман разведкасы миннән ала алмас аларны.

—Ярый, аңлашылды, Кадим Каюмович. Тик мин сезне кисәтеп куярга тиешмен. Төрле гайбәтләр тарату да җинаятьчелек эше кузгату белән бәйләнергә мөмкин. Нәтиҗәсен истә тотыгыз.

—Мин моны куздә тотармын!—Кадимнең бу сөйләшүне бетерәсе килә иде.

—Җыелыштан соң сез өчәүләп...

—Әллә безнең арттан күзәтү дә оештырдыгызмы? Ничек әле сезнеңчә? Тышкы күзәтүме?

—Юк ла инде. Очраклы рәвештә генә күзгә ташлангансыз. Бетте минем сорауларым, Кадим Каюмович. Уңышлар телим сезгә. Баш инженер дәрәҗәсе бик авырга туры килмәдеме соң?

—Бу соравыгыз да начальство өченме?—дип көлеп җибәрде Кадим.

—Түгел, түгел! Монысын инде үзем өчен генә сорыйм. Ничек кенә булмасын без милләттәшләр дә бит әле.

—Шулай бугай шул. Ничек Володя булып киттегез соң?

—Урыслашып барабыз бит инде. Дәүләтьяр да Девятьярга әйләнде.

—Ярый әле Дәүләтьяр бабагызның исемен онытмагансыз.

Әңгәмәнең рәсми өлеше беткән иде. Бераз тегенди-мондый сүзләр дә сөйләшеп алдылар да, таралдылар бу ике татар һәрберсе үз ягына.

* * *

Соңгы ун-унбиш елда үзен болай иркен, бәхетле хис иткәне юк иде әле Кадимнең. Туган илнең һавасы да, суы да, яңа чапкан печән һәм әле череп бетмәгән тирес исе дә—барсы да аны балалык чорына кире кайтарды. Тән дә, күңел дә чир-кайгылардан арынды, җиңеләйде. Зәңгәр күккә, ирекә оч та кит! Карлыгачлар сыман талпынып-талпынып очып йөрде шунда! Шатланып, канат кагып! Балалар әнә ни эшлиләр: аларның йөгерү-сикерүләре, шатланулары шул очып йөрү түгелмени?

Инде печән чабылып, китереп, өелеп куелды. Кышка җитәрлек утын әзерләнде. Каралты тирәсендә дә төзәтәсе, көйлисе эшләр калмады. Ә авылдан китәсе килми. Югыйсә эшкә чыгар көннәр дә якынлаша бит инде—шәһәргә алданрак кайтырга кирәк булыр. Юл уңаеннан Казанга да кагылып чыгарга иде.

Кадим авылга кайтып төшкәннең беренче көннәрендә әтисе белән сөйләшеп утырганын исенә төшерде. Бәрәңге утыртып бетергән көн иде. Кичке эңгер-меңгер вакыт. Бакча буенда өеп куелган бүрәнәләр өстенә утырдылар. Каюм абзый улы белән сөйләшәсе сүзен аулаграк урында тотасы килде шикелле, өйгә керергә теләмәде. Болыттай ябырылган черкиләргә дә игътибар итмичә, бер ноктага карашын текәп, озак кына сүзсез утырды.

—Улым, мин менә нәрсә турында сорарга булдым әле синнән.—Ул тагын күпмедер вакыт сүзсез торды.—Син ни өчен армиядән киттең? Дөресрәге, ник сине армиядән кудылар?.. Чыгардылар? Хезмәтең ал да гөл иде түгелме соң? Сөйләп бир әле шуны миңа.

Кадим әтисе кебек уйланып тормады, аның җавабы әзер иде.

—Әйе, әткәй, мине армиядән куып чыгардылар, дөрес әйтәсең. Тик минем бер гаебем дә юк монда. Бер яшерен кулланманы югалтканнар иде, дөресрәге урлаганнар иде. Ул табылды. Ләкин бу гына җитми бит армиядән чыгару өчен. Ике солдатны шәһәр сукбайларын кыйнаган өчен штрафбатка утырттылар. Ләкин болар да җитми бит әле, армиядән куу өчен! Командующий белән каты гына бәрелешкәнем бар. Әй, анысы да нинди бәрелешү инде ул—татар халкын яклап командующийга каршы сүзләр әйткән идем. Башка тәртип бозу-мазар булмады. Әмма кемгәдер кирәк булды мине куу.

—Биегрәк урынга язып карамадыңмы соң? Гаделлек булырга тиештер бит бу дөньяда... Моны мин синең әйткән сүзләреңә таянып әйтәм. Сүзләреңдә ялган булмавына ышанып әйтәм.

—Сез мине ялганлашырга өйрәтмәдегез...

—Ярар, ярар. Сүзләреңә ышанып әйтәм дидем бит.

—Гаделлекне аны бик тырышып эзләсәң дә табып булмый икән ул, әткәй. Мондый нәрсәләр бер кешенең хатасына яки җинаятьчел гамәленә генә бәйле түгел икән. Бездә, безнең илдә әллә нинди үзгәрешләр бара. Ул үзгәрешләр ни өчендер гел кире якка тарта.

—Сүзең бүлим әле, улым. Син менә командующий белән эләгешкән идем, диден. Сәбәбе шул түгелме соң?

—Ул миңа "великий сын татарского народа" дип әйтте. Бәлки шаярыбрак та әйткәндер. Ә мин аңа: "обыкновенный сын великого татарского народа", дип әйтеп җибәрдем. Шуннан, бераз тарихка кереп китеп, сүз көрәштереп алдык. Башка нәрсә турында эләгешү булмады. Дөрес, соңыннан аның янындагы куштаннар мине милләтчелектә гаепләп маташтылар. Анысы булмады түгел, булды.

—Менә, менә! Аларча иң зур гаебең шунда булган инде синең!

—Милләтчелек дисеңме?! Нинди милләтчелек булсын ди инде монда? Үзең беләсең инде минем милләтчелекне! Мин татарның яхшысына—яхшы, начарына—начар! Бер халыкны да өскә куймыйм. Тирә ягыңа татарларны җыйгансың, дип маташтылар. Бусы бөтенләй ялган тагу иде.

—Ярый, аңладым. Сөйли башлаган сүзеңне бетер.

Кадим бераз зиһенен җыеп сүз башламый торды.

—Илдә эшләр алга бармый, дигән идек бугай...

—Әйе, моны барыбыз да сизә . Ләкин кем гаепле соң мона?

—Минем уемча бөтен эш җитәкчелектән тора. Халык шуңа күрә пассив. Аерым кешеләрнең фикерләре кысыла. Сүз әйттермиләр!

Каюм абзый уйлана иде. Ул малае әйткән сүзләрнең очына чыгарга тырыша иде кебек.

—Син, минем өчен кайгырма, әткәй. Гражданкада тормыш күнеллерәк икән әле ул! Бәлки армиядән китүем хәерлерәк тә булгандыр. Шушы еллар эчендә инде ике баскычка дәрәҗәм күтәрелде. Хәзер мин—ерак элемтә буенча территориаль берләшмәнең баш инженеры. Кулга алган эш хакым полк командирыныкыннан ике мәртәбә артык. Миңа ике машина беркетелгән: җәйгә дә, кышка да аерым...

—Анысы бар икәнен беләбез белүен. Тик менә халык арасында төрле имеш-мимешләр йөри. Шуларга җавабым юк.

—Ушың китмәсен, әткәй. Игътибар итмә син андый сүзләргә.

—Ничек игътибар итмичә яшәргә мөмкин?! Булмый шул алай. Күрше-күләнгә булса да аңлатып бирәсе иде. Миңа хәзер аңлашыла кебек тә соң... Юк, барыбер аңлашылмый. Әнә, безнең күз алдындагылар. Мәсәлән, колхоз рәисен алып ыргыттылар ди. Икенчесен китереп куйдылар. Аңлашыла инде: йә эшен җайлый алмады—оештыру сәләте җитми, йә зур урында башы әйләнеп китеп, тәкәбберләнде, кәпрәйде... Йә җаваплы эшне күтәрә алмыйча, эчкегә салышты. Мондый хәлләр райком секретарьлары белән дә, прокурорлар белән дә булып тора. Күз алдында бит, күрәбез! Ә син—икенче. Полк хәтле полк белән командовать итсен әле Каюм малае! Аңлатып кара син халыкка “ул хәзер зуррак урында—гражданкада командовать итә”, дип! Аңламый ул моны, аңларга теләми!

—Бөтен сүзең дә дөрес, әткәй. Тик безнең халыкка илдә булган хәлләрне минем сүзләр белән генә аңлатып булмас шул. Үзең әйтәсең ич, аңларга теләмәс, дип. Гәзитләр, радио, телевизор бер төрле сүз сөйли, ә чынлыкта исә икенче төрле хәлләр булып ята. Менә әйтеп кара халыкка: нигә СССР бөтен тишеккә борынын тыга? Бушлай бөтен дөньяга диярлек корал әзерләп җибәреп ята? Үзебездә проблемалар беткәнмени? Әйтеп булмый, чөнки сине шунда ук дошман күрә башлаячаклар. Органнар турында әйтмим әле мин, гади халык турында гына әйтәм.

—Әйе, хәтеремдә әле, Никита Сергеевич заманында күрше Гөлҗиһан апаң: и-и, шул Хрущевны кысып кочаклар идем, суырып үбәр идем! дип урамда кычкырып йөрде. Ә Хрущевы хәлдән тайган колхозларны ныгыту урынына казакъ далаларына күпме акча түкте? Күпме халыкны, күпме гаиләләрне таратты. Килешәм синең сүзләрең белән. Үзем дә эчемнән генә уйлап йөрим инде. Ник, мин әйтәм, үзең ыштансыз көйгә ярты байлыкны читкә таратып ятырга? Бае башта үзең, туйдыр халкыңны...

—Әткәй, авыл мәктәбе белән нәрсә килеп чыкты ул, ни өчен мәктәпне бетерергә булдылар?

—Бетерми соң... Тирә-юньдә кечедән кече алты татар авылы бар. Безнең җидееллык мәктәп шул авыл балаларын ничек тә укытып килә иде. Аны бетергәч, балалар район үзәгенә русча укырга китәләр иде. Син үзең дә шулай иттең ич... Башлылары барсы да укып чыкты, кеше булды. Урысчаны ныграк белим дигәннәре бишенче сыйныфка ук урысчага барып керәләр иде. Әмма барыбер калганнарны күпкә узмадылар... Ә хәзер, имеш, татарча укуның бөтенләй кирәге юк, институтка кергәндә татарча имтихан бирмиләр! Шулай итеп, “ата-аналар соравы буенча” татар мәктәбен бетерделәр. Үзәк усадбага әверелгән мари авылында урта мәктәп ачалар. Гел русча гына укытачаклар!

—Чынлап та ата-аналар соравымы соң бу?

—Ни эшләп алай булсын ди?! Өй буйлап районнан кушкан кешеләр йөрделәр дә, халыкның имзасын куйдырттылар.

* * *

...Поездга билетлар алу кыен булмады, урыннары да барысының бер купега туры килде. Поезд килгәч Кадим гаиләсенең әйберләрен вагонга кертеп урнаштырды да, саубуллашып вагоннан чыкты. Халисә һәм балалар вагон тәрәзәсеннән кул болгап үзләре яшәгән шәһәргә, көньякка табан юл тоттылар.

Ә Кадимнең Казанда торып калуы күп нәрсәләр белән бәйле иде. Беренчедән, алар яшәп яткан шәһәрдә югары уку йортлары аз, Маратка уку урынын белешәсе бар. Шәһәрдә политик, юридик, педагогик институтлар бар анысы, медицина институты да бар. Тик Марат икенчерәк белем алу турында хыяллана: журналистика тарта аны: гәзитләрдә инде күп кенә мәкаләләр дә бастырды. Керсен иде шул үзе сайлаган юлга!

Казанга бөтенләй күчеп кайту фикере дә инде ничә ел баштан китми. Николай Палевич та, Мамед Сурханович та бу омтылышны хуплый. Аннары икенче ягы да бар бит әле Казанга кайтуның: әти-әни картаеп килә! Кадим үзенең төпчек малай икәнен дә онытмый. Безнең татарда шулай бит инде ул: әти-әнине карт көнендә малайлар үз өстенә ала. Берничә малай булса—иң кечесе. Ә Кадим бердәнбер малайлары. Кияүдәге апасы ала алмый бит инде аларны, якын гына торсалар да... Ата-ана картайгач, Кадим ярдәменә мохтаҗ калачак...

Поездның коерыгы күздән югалгач Кадим телефон-автоматка юнәлде. Исәбе—танышы Владимир Петрович Виноградовны өендә чагында тоту иде. Кадим Пенза шәһәрендә хезмәт иткән заманда күрше частьнең командиры иде ул. Хәер, часть дисәң артыграк булыр. Бер округка буйсынган база иде инде шунда. Кадим еш кына аның янына кереп йөри иде, чөнки бу базада Кадимгә кирәк приборлар, радиодетальләре тулып ята. Шул сәбәпле дуслашып киттеләр.

—Исән-саумы, Володя? Бу мин—Шәймәрданов.

—О-о-, исәнме Кадим. Мин дә исән әле. Син үзең ни хәлдә? Кайдан шалтыратуын, Казаннанмы?—Әһә, шулаймы. Мин бик шатмын! Килеп җит тиз генә. Үзем ялгыз гына ятам. Вокзалдан? Икенче троллейбус. Машинада? Ершов урамы, училищеның капка төбенә кил дә тукта. Хәзер үк КППга шалтыратып куям, пропуск әзерләгәнче үзем каршыларга чыгармын.

Кадим белә бу училищены. Унбиш минут үтмәде, барып та җитте. КППда хәрби билетны күрсәткәч, кизу офицер якты чырай белән каршылады. Шул арада Володя үзе дә килеп җитте.

Владимир Петрович КАИда лаборатория башлыгы булып эшли икән. Кафедралары самолет һәм ракета конструкцияләре, аларның ныклыгын тикшерү буенча эшләр башкара булып чыкты.

—Мин шундый шатмын, Кадим! Сагынып беттем инде сине. Докучаевтан да хәбәр-хәтер булмагач... (Докучаев дигәне Пензадагы уртак дуслары иде). Монда элеккеге хәрбиләр арасында сезнең кебек алтын кешеләрне таба алмыйм. Шуңадыр инде күңелем тыныч түгел. Картаям ахрысы. Кайт, Кадим, Казанга! Үзең татар бит әле син. Бергә картаербыз ичмасам. Ишеттем синең армиядән ничек киткәнеңне, сөйләп торма. Син гаепле түгел. Киресен сөйләсәләр дә ышанмас идем.

—Мин Казанга кайтырга уйлыйм, Володя. Шуңа синең янга туптуры килеп кердем дә инде. Ярдәм ит, киңәш бир!

—Бөтен көчемне бирәчәкмен, Кадим. Иртәгә үк йөз таныш кешем белән очраштырам. Белеп тор, Казан ул шундый шәһәр... Шундый шәһәр...

—Йөз кеше белән үк бәлки кирәкмәстер дә. Мондагы хәл-әхвәлне аңлатырлык кешеләр генә кирәк.

—Була, була! Бүген үк телефоннан килешеп куярбыз. Иртәгә үк очрашырбыз.

Владимир Петрович Кадимгә үзенең дүрт бүлмәле фатирын күрсәтеп чыкты, бер бүлмәсендә, менә монысында күпме теләсәң шул хәтле яшәрсен,

дип, чәйгә чакырды. Кадим машинасы янына чыгып кереп авылдан килгән күчтәнәчләрен тапшырды.

Виноградовның хатыны кичен эштән кайтып кергәндә ике дус кешенең кәефләре иң югары билгегә житеп бара иде инде...

Владимир Петрович тәкъдим иткән танышлары дәрәжәле кешеләр иде. Алар, барысы да диярлек, әгәр монда кайтып пропискага керсән, эшкә урнаштырачаклары турында вәгъдә бирделәр. Владимир Петровичка Кадим бик рәхмәтле иде.

—Алмашырга фатир эзләүне дә якыннан гына башларбыз—безнең шәһәрчектә, дим. Хезмәтне бетергәч моннан туган якларына кайтып китүчеләр шактый. Әйдә, эзләп карыйбыз, бәлки Саратовка кайтучылар да бардыр. Дөнья рәхәте ул безнең шәһәрчектә яшәү.—Владимир Петрович инде Кадим белән рәттән яшәвен күз алдына китерә иде бугай. Кадим үзе дә моңа каршы килмәс иде, әлбәттә...

Икенче көнне Володяның фатирыннан өенә шалтыратты, Халисәнең һәм балаларның исән-амин кайтулары, аларны Саратов вокзалында каршы алулары турында белгәч, кәефләре тагын да күтәрелеп китте.

Биредә Кадимнең тагын бер танышы белән очрашасы бар иде. Ул күптән инде Кадимне кунакка чакыра, хатлар яза, телефоннан шалтырата. Владимир Петрович, мин дә барам дигәч, Кадим болай диде:

—Гафу ит, Володя. Бу егет безнең күрше авылдан, татар малае. Без аның белән татарча сөйләшергә күнеккән. Сиңа кызык булмас.

—Синнән каласы килми шул. Әллә миннән яшерен сүзең бармы соң? Юк, тукта әле, син татарча беләсеңмени?

—Ник белмәскә ди, беләм! Мин татарлыгымны онытмадым бер кайчан да.

—Ну-у, менә сиңа мә! Совет офицерлары барсы да урыс түгелмени? Мин сине фамилияңә карамастан, урыс дип йөри идем.

—Ә син үзең яһүд түгелмени? Пензада чакта әйткән идең бит, минем каным урыс каны белән буталмаган, дип...

—Әйткән идем. Әмма мин урыс фамилиясе, исеме артында яшеренеп яшим, ә син һаман татар исемен йөртәсең. Шуңа исем китеп сорыйм инде, чынлап та татарлыгыңны югалтмадыңмыни, дип?

—Юк, югалтмам да дип уйлыйм! Татар булып каласым килә.

—Ярый, бетте. Иртәгә синең белән бергә буласым килгән иде килүен. Болай булгач теләгемнән кире кайтам. Сөйләшегез, чөкердәшегез. Соңгы вакытта татарлар чыннан да үзләре турында каты-каты фикерләр әйтә башладылар.

—Әллә бик куркыныч фикерләр дә ишетеләме?

—Юк, алай дип әйтмәс идем. Күпләре безнең уйларга да тап килә.

—Кемнең—сезнең?

—Безнең инде, яһүдләрнеке белән дә...

—Ничек, ничек?

—Шулай менә.

Кадим башын кашып куйды—әллә нәрсәләр ишетерсең әле бу дөньяда...

Якташы белән очрашуы, сүзләре бер кичкә генә түгел, ике кичкә дә сыймады. Күп нәрсәләргә икенче яктан карарга мәҗбүр итте аны якташы, күп нәрсәнең капламасын ачты. Килешмәгән нәрсәләр дә ай-һай күп иде.

Менә кайда булырга кирәк икән Кадимгә! Казанда булырга кирәк икән аңа һичшиксез!

Эшкә ул тиз урнашты. Республиканың элемтә идарәсендә бүлек мөдире урыны табылды. Моңа, күрәсең, Поповскийның шалтыратуы да ярдәм иткәндер. Ансыз гына булмас. Чөнки идарә башлыгы Поповскийның күптәнге танышы, дусты икән... Бер ай да үтмәде, идарәнең тулай торагында аерым бүлмә дә табылды. Ә фатирны кайчан бирерләр? Военкоматта фатир алу өчен чиратка басучылар күп. Дөрес, чиратны төрле группаларга бүлеп төзиләр: өлкән офицерлар, кечеләре, сугышта катнашканнарны. Соңгыларына

әлбәттә, льготалар бирелә. Менә шул группага керә Кадим. Аңа өмет күбрәк. Бер дә юкка тропик илдә сугышып йөрмәде ич ул!

Казанда таныш-белешләр күбәйгәннән күбәя. Алар арасында татар зыялылары да бар. Инде күп еллар элек, Казанда хәрби госпитальдә яткан вакытта, танышып алган шагыйрь Мәхмүт Хөсәен белән күп мәртәбә очрашты Кадим. Үзе офицер булганга күрә Мәхмүт абый буш вакытын бик теләп хәрбиләр белән үткәрә иде. Виноградовларга да килергә тарсынмады ул. Володя белән милләтләрнең хәле, милләтчелек проблемалары турында озак кына бәхәс тотты. Татарларның өченче сорттагы милләт булып калуына көенеп утырды. Ниндидер көрәш юлы табарга кирәклеге турында сөйләде. Шигырьләрен укып Володяны шаккатырды: ул аның шагыйрь икәнен белми иде бит. Пәлтә кесәсеннән әле генә чыккан кечкенә шигырь китабын чыгарып, аңа язып та биргәч, хуҗаның түбәсе тәмам күккә тиде.

Татар зыялыларының милләт турында уйлану-әзләнүләренең җанланып китүе Кадимне шатландыра иде. Капма-каршы фикерләр йөрү яхшыдан түгел, әлбәттә. Бердәм фикер булса оешу эшләре турында да уйларга булыр иде. Эш шуңа таба бара. Әнә, партиянең Генераль секретарьлары Черненко да, Андропов та, дөнья куйды. Илдә гади генә сүлпәнлек түгел хәзер. Әмма бу дөньяның кайсы юлдан китәсен беркем дә белми. Халыкның хәле көннән көн начарлана бара. Мәңге түзә алмас халык, барыбер үзенең сүзен әйтер. Татарларга да тегенди-мондый очракка әзер булырга кирәк...

Кадим бөтен буш вакытын китап укуга бирә. Күбесе яна танышларыннан алган китаплар. Тарих, яңа тарих... Гарәп алфавиты да яхшы гына үзләштерелде инде. Даими укысаң, көннән-көн алга барасың икән! Кадим өчен иң мөһиме—мондагы тормышның күңелгә ошавы. Бөтен-нәрсә үзеңнеке бит! Халык, табигать... Көе-моңы, туган телдә сөйләшү, аңлашу, көлешү үзе генә ни тора!

"Эш вакыты узып бара, бүген Володя янына кереп чыгарга кирәк",—дип уйланып утыра иде Кадим, телефон шалтырады.

—Тыңлыйм.

—Бу мин, Володя. Шәһәр советына килгән идем. Бер уңайдан фатирлар бүлегенә кереп чыктым. Сине бит чиратка куймаганнар монда.

—Ничек инде куймаганнар, мин бит гариза калдырып киттем...

—Гаризаң бар, күрдем. Ләкин синең монда Саратовтан белешмәң юк. КЭЧтан. (Квартирно-эксплуатационная часть.)

—КЭЧтан? Мин андый белешмәне фатирымны бушаткач кына алачакмын.

—Ә-ә, менә шул шул! Әллә син тегендә сөйләшеп ул белешмәне алып килдең микән дип уйлаган идем. Димәк, син ике ай вакытыңны югалткансың. Бу арада әллә ничә кеше чиратка баскан инде синнән алда. Ну, кайгырма! Мин сиңа сюрприз әзерләдем. Әйдә, кузгал. Мин сине фатирлар алмашу фирмасы янында көтәм.

—Кайда ул?

—Беләсең ич, урамны аркылы чык та...

—Аңладым, хәзер килеп җитәм.

Кадим Виноградовны ерактан ук күреп алды. Ул бер юан гына гәүдәле кеше белән нәрсәдер турында сөйләшеп тәмәке көйрәтә иде.

—Таныш булыгыз: бу полковник Курочкин, өереннән аерылып калган кош кебек көньякка омтыла. Саратовка, значит! Ә монысы—подполковник Шәймәрдәнов, ул да үз оясына, Казанга кайтырга тели.

—Исәнмесез.

—Бик шатмын,—Курочкин Кадимнең кулын кысты.—Сезнең торган урыныгыз турында Володя сөйләп бирде. Миңа таныш булырга тиеш. Әгәр сез аның сүзләрен расласагыз, ачыклабрак сөйләп бирсәгез, мин сезгә хәзер үк фатирымны күрсәтә алам. Совет мәйданында ул.

Кадим хәрбиләрчә кыска гына Саратовта торган район турында, фатирының ничәнче катта, ничә метрлы булуын, күршеләре турында сөйләп бирде.

—Анлашылды. Безгә бөтен ягы да килешә бу! Әйдәгез минем фатирны да карыйк,—дип, такси тотарга ук тәкъдим итте Курочкин. Каршы килүче булмады, әлбәттә, чөнки Кадимгә йортның урыны бик ошый иде.

Икенче катта өч бүлмәле фатир икән. Кухнясы, коридоры бик зурдан булмаса да, әйбәт иде Курочкинның торагы.

—Мин килешәм мона!—диде Кадим сүзне озакка сузмыйча.

Менә шулай бер сәгать эчендә диярлек алмашырга фатир табылды да куйды. Әнә шулай җае килеп тора ул дөньяның. Кайсы вакытта...

* * *

Күченү мәшәкатен үзе күченмәгән кеше генә белми! Юкка гына: ике күченү бер янгынга тиң ул, димәгәннәр. Күп нәрсә ватыла, күп нәрсә югала. Әмма ни генә булмасын, күчәргә кирәк. Бәлки шәһәрдән шәһәргә күченүнең дә соңгысыдыр инде бу?!

Кадим көне-төне әйберләр җыйды, аларны әрҗәләргә тутырды, төргәкләргә бәйләде. Алмашу бюросында тегесенә шоколад, монысына кәнфитләр төртеп документлар эшләп җибәрүне тизләтте. Шулай итә-итә яңа елга дүрт көн кала, бөтен нәрсә әзер иде инде.

Әйберләрне төяп озаткач ук юлга чыгарга җыенган иделәр. Ләкин алай килеп чыкмады. Машина кузгалып киткәндә өй тулы кеше иде: булышырга килгән кешеләр, озатучылар... Монда полктан да, элемтә идарәсеннән дә, күрше-күләннәр дә күп. Ничек ташлап чыгып китәсең, алар бит сине ихтирам итеп, саубуллашырга килгәннәр. Һәрберсенең җылы сүз әйтеп каласы килә. Изге юллар, тазалык, уңышлар теләп калырга дип килгәннәр. Кадим буш фатирда калган иде, бердән-бер өстәл өстенә эчемлекләр, Халидә кабымлык чыгарды. Ягымлы сүзләр әйтелде. Көтмәгәндә, кара син аны, Валерий Петрович та килеп керде.

—Һо! Монда буш бүлмәләр генә калган икән. Соңлабрак килсәм күрми дә калыр идем, ә?

—Юк, Валерий Петрович, сезгә кермичә китмәс идек. Башка иптәшләр белән дә хушлашасы бар.

—Николай Павлович белән дәме?

—Мамед Сурханович белән дә...

—Кузгалабыз алайса. Алар безне, дөресрәге сезне көтеп калдылар.

Мул итеп өстәл әзерләнгән. Бу Шәймәрдәновларны озату хөрмәтенә икән. Менә кемнәр белән аерылышырга туры килә бит! Күздән яшьләр чыга язды. Николай Палевич та йомшарып китте, еласы килгән бала кебек тота үзен.

—Кыска булды безнең танышлык. Шул хәтле яратып очраша идем сезнең белән, Кадим Каюмович... Хәзер менә Мамед Сурханович белән Валерий Петрович кына калды якын кешеләремнән. Үзем дә аңламыйм, нигә мине, карт кешене, хәзерге яшьләргә тарта микән?

—Барыгызны да Казанга кунакка чакырабыз. Яңа торган җиребезне күреп китәргә! Күрешеп торырга язсын иде,—дип Халисә дә сүзне киләчәктә күрешү өметенә юнәлтергә маташты. Чөнки барысының да кәефе төшенке иде.

—Барачакбыз яңа фатирыгызны котларга, һичшиксез җыелып барачакбыз!—диде кунаклар.

... Алар юлга чыкканда кышкы озын төннең караңгылыгы бетмәгән иде әле. Озак кына сүзсез бардылар. Һәрберсе үз уена баткан иде. Аз дисәң дә, кыска түгел—тугыз ел гомер үткән монда! Нәрсәләр генә булмаган шушы тугыз ел эчендә! Тормышның әчесен дә, төчесен дә татып карарга туры килгән. Инде бөтен нәрсә челпәрәмә килде, дип, күңелләр төшкән чаклар да булды. Әмма тегеләй-болай итеп, тырмашып-тартышып алга атланды. Ышанычлы дуслар рухны күтәрергә ярдәм итте. Тормыш тагын йөзе белән борылды. Дусларга рәхмәт!

Юлның беренче яртысын әйбәт кенә үттеләр. Кадим белән Марат руль артында алмашына-алмашына килделәр, алҗытмады да диярлек. Ләкин кыенлыклар Ульяновскины узып берәр сәгать чамасы үткәч башланды.

Кышкы кояш баер вакыт җитмәгән иде әле. Тирә-якны кинәт кенә караңгылык басып алды. Идел ягыннан искән салмак җил көчәйде. Болай да болытлы күкне кара болыт басып алды. Минут та үтмәде, өерелеп-өерелеп кар ява башлады. Яндырган фара утлары диварга терәлгән кебек кар өермәсенә терәлде. Берни дә күреп булмый иде. Гүя алар кар диңгезе төбендә калдылар. Анда давыл котырына. Инде юлда көрт өемнәре күтәрелеп чыкты. Машинаның алгы тәгәрмәчләре көрткә килеп керә дә, туктап кала яза. Бу хәлдә алга бару мөмкин түгел иде, туктарга туры килде. Әмма болай күпме торырга була? Билгесез бит бу давылның кайчан бетәсе. Кадим туңып, бүреген киеп машинадан чыкты да, фаралар яктысында алгарак үтте. Юлны кар баса бара, ә алда җитмәсә уйсулык икән әле.

—Монда карны тагын да күбрәк өя иде. “Бу уйсулыкта калырга ярамый, озакламый безне кар бөтенләй күмеп китәчәк”,— дип уйлады Кадим һәм куйган жиреннән көрәк тартып чыгарды. Яуган карны көрт магнит кебек тарта иде шикелле— Кадим көри тора, ә көрәк белән алып ташлаган кар урынына шунда ук яңасы килеп тула. Шулай да ашыга-ашыга машина үтәрлек итеп юл ясады. Аннан соң тиз-тиз генә руль артына кереп утырды да, машинасын алга омтылдырды. “Тотыныгыз!”—дип әйтергә өлгерде һәм машина үкереп көрт эченә кереп китте. Әмма озак бара алмады, тизлеген әкренәйтеп бер урында диярлек үкерергә тотынды. Кадим газны әзәйтмәде, тәгәрмәчләр әйләнә торды. Рульне уңга, сулга боргалады. Машина әкрен генә булса да алга таба шуыша иде кебек. Әйе, әйе, машина карны зур кыенлык белән булса да ерып, алга үрмәли иде. Һәм, ниһаять машинаның алга барганы сизелгәннән сизелә башлады. Тагын бераз, тагын! Чыгып этәсе иде дә соң! Кая ул этү—чыгып булмый тышка. Шулай да китте.

—Чыктык, чыктык!—дип кычкырып җибәрде Марат. Машина инде көрне үтеп өскә таба үрмәли икән. Кадим газын киметте, чөнки алда һаман бер нәрсә дә күренми. Менә инде юл тигезләнде, кап-кара булып асфальт чагыла башлады. Монда кар тоткарланмый, җил аны кайдадыр читкә себерә.

—Инде туктарга да була, әти,—диде Марат.

—Әйе, туктыйбыз. Монда безне кар күмеп китмәс дип уйлыйм.

Ул, машинадан чыкканда кигән бүреген салып ташлап, маңгаендагы тирләрен сөртеп алды.

—Искәрдеңме, Халисә—арттан да, алдан да бер машина да күренми!

—Әйе, бер машина да күренмәде!—Халисәнең йөзендә курку эзләре иде.—Мин инде кар бөтенләй күмеп китәр дип, кар астында күмелеп калырбыз дип курыктым.

—Без теге уйсулыкта утырып торсак, шулай булачак иде,—диде Марат.— Ярый әле чыгып өлгердек...

—Әллә бераз тамак ялган алабызмы соң? Халидә, кызым, синең ашыйсың килмиме?

—Хәзер килә ашыйсым, бая килми иде.

—Әйдә, әнкәсе, сал чәеңне.

Монарчы үз уйлары белән үткәннәрдән аерыла алмыйча, сөйләшмирәк барган Халисә дә телгә килде.

—Әллә нинди яман кыш килде быел, Кадим, ә? Башта озак кына кар төшми торды. Аннан күп итеп кар явып киткәч, кинәт кенә яңгырлар ява башлады. Аннан соң салкыннар китереп бәрде. Бозлавык...

—Әйе шул! Соңгы еллар бик сәер булды! Явымнар йә җитми, йә артып китә. Июнь башында кар ява, гыйнварда яңгыр... Ләкин үтәр алар, үтәр, Халисә! Бөтен нәрсә үз эзенә керер. Салкын кышлар үтәр, җылы язлар җитәр. Күрәсең ич—ничек аязып җибәрде Казанга якынлаша башлагач! Күктә йолдызлар да күренә...

# ШИГЪРИЯТ



## Рафаэль Сибат

### ГОМЕРНЕҢ ДҮРТ ФАСЫЛЫ

* * *

Ни пышылдый бу йолдызлар
Чекрәеп чиксеалектән?
Күңелдәге тынгысызлык
Нилектән соң, нилектән??

Ниләр мине Күккә дәшә,
Нинди сихри көч тарта?
Җанымдагы ашкынулар
Яшәгән саен арта...

Тән бик авыр Күкләр өчен—
Мин исән әле, исән...
Очмыйм инде, атлыйм гына,
Гомерне саклыйм дисәм—

Тын ишелеп, Сәер Көчләр
Иңә миңа тагын да...
Дөнья—минем йөрәгемдә,
Галәм—минем җанымда...

Бардыр инде кирәгем дә!
Серле утлар аңымда.
Мин—Дөньяның йөрәгендә,
Һәм Галәмнең җанында...

* * *

Хыялымда Зәңгәр көттем...
Сары чәчле Көнбагыш.
Кәс-кәс атлап хәсрәт килде,
Сак орынды моң-сагыш.

**Хыялымда Сөю көтеп,**
**Күп газаплар кичердем.**
**Мәхәббәтнең чишмәләре**
**Баллы агу эчерде...**

**Хыялымда—Хыял! иде—**
**Реаль булды барысы:**
**Ашау-эчү, байлык җыю—**
**Яшәү-үлем арасы.**

**Хыялымда Бәхет көттем...**
**Юлым—борчулы юлдыр.**
**Өметтә—бар, Чынлыкта—юк!**
**... Гомер итүләр шулдыр...**

## Чыклы манзара

**Ат пошкырды—**
**төнге чыкны коеп.**
**Йолдыз очты—**
**зәңгәр күкне кыеп.**

**Илаһым! Юк**
**җиһаныңда кыек.**
**Төн сурәтен—**
**Хисле җанга уеп,**
**Бәхиллэттем—**
**Шигырь язып куеп.**

**... Ат хәтердән чыккан...**
**Нигә истә**
**Терекөмештәй—**
**Көмеш тере чыклар?..**

* * *

**Күтәримме дисәм күңелемне,**
**Төшенке ул гомер-гомердән.**
**Батмас идем сагыш күлләренә—**
**Җан газабым авыр—тимердән...**

**Миндәме соң монда иң төп гаеп?—**
**Сызланулар яшьтән ияргәч.**
**Тормыш шундый: чәнечкеләр теккән**
**Мин менәсе атка-ияргә.**

**Кемнәр: "Яши белми!"—диеп сүгәр,**
**Алданулар—**
**Гомер юлдашым.**
**Ахырында сагыш ник булмасын—**
**Сары чәчәк иде юл башым...**

## Гомернең дүрт фасылы

Яз...
Бакчада чәчәкләр,
Өстәлдә чәк-чәкләр.
Әти-әни белән
Болдырда "чәп-чәпләр"...

Җәй...
Урманда агачлар,
Ямь-яшел яфраклар.
Йоп-йомшак туфраклар,
Бер керсез саф чаклар...

Көз...
Болында чүмәлә,
Янында чүгәлә:
Каты бер яңгырдан
Ул шулай чүгә лә...

Кыш...
Кырларда кибәннәр...
Башларын игәннәр.
Җаным гел биек ник?—
Өстемә өелде
Кар—Мәңгедән хәбәр...



## Фәнис Яруллин

# ЯКТЫ САГЫШ

ХИКӘЯ

Мин армиягә китәсе елны безнең авылыбызга күрше Төрекмән авылыннан Флера исемле кыз килеп йөри башлады. Безнең авылда нининдер туганнары яши икән аның. Кыз бик шәп, яңа гына өлгереп килә торган чикләвек кебек. Бер көн чыга бу клубка, ике көн чыга. Туры килгүен әйт әле син аның: клубта аның урыны һәрвакыт минем янга эләгә. Кайтырга чыксак—абыйлары безнең юл өстендә. Җитмәсә әле, кунак кызының караңгыда курка торган гадәте дә бар икән: авылның төнлә ай яктысыннан башка яктылык күрмәгән урамына чыгу белән: "Ай, куркам!" -дип, чытырдатып миңа ябыша. Ул тотынуга минем тәнем буйлап яшен утлары йөгерешә башлый. Җил булып колакка җеннәр пышылдый: "Чикләвегең йомшаграк чакта ватып кал, юкса тешеңне сындыруың мөмкин".

Минем үземнең дә бу "сөтле чикләвектән" бик авыз итәсе килә килүен. Әмма ләкин тора салып ничек инде, караңгыдан да курыккан кунак кызына: "Минем сөтле чикләвек ашыйсым килә",—дисең. Бу сүзләрем белән куркытып аның бөтенләй өнен алсам? Аллам сакласын! Йөрәгемдәге ай яктысыдай өмет утымны сүндереп куйса нишләрмен. Болай да шәп әле миңа. Караңгыда куркып дер-дер калтыраган кызны җен-пәриләрдән саклап һәркөн саен өйләренә озатам. Өйләренә якынайган саен ул миңа ныграк елыша. Күрәсең, бу тирәдә җен-пәриләр күбрәктер. Мин дә сер бирмим: пинҗәк төймәләрен ычкындырып, кызыйны пинҗәк эченәрәк алам. Кайтып капка төпләренә утыргач, ул куенымнан башын сузып күккә—тулган айга карый. Һәм назлы итеп: "Ай матурмы, минме?"—дип сорый. "Һи, җүләр,—дим мин аңа,—синең белән чагыштырганда Ай нәрсә ул? Әнә кара әле, Айның йөзендә әллә нинди таплар бар. Ә бит синең йөзең..."

Мин шулай дидем дә туктап калдым. "Сөтле чикләвегем" түземсезләнеп: "Йә инде, йә, башлаган сүзеңне ярты юлда калдырма. Минем йөзем нинди?"—диде.

—Синең йөзенме?—дидем мин кыюланып.—Синең йөзең шикәр төсле. Аны ашыйсы, кимерәсе, шытыр-шытыр иттерәсе килә.

—Кимер алайса,—диде "сөтле чикләвегем" кайнар битен якынрак китереп.

Иреннәр якынайганнан-якынайды. Бөтен тән дер-дер калтырарга тотынды минем. Тагын бераз катырак кочсам, "сөтле чикләвегем" дә ярылырга әзер булыр сыман. Минем дә, кунак кызының да башы югалып бара. Иреннәребез иреннәргә кагылуга, электр чыбыкларының җилдә бәрелешүеннән чыккан очкыннардай, караңгы урамны яктыртып ут көлтәсе чәчрәр кебек.

—Их! Ни булса—шул булыр, яшьлек ике килми ул,—дидем дә шикәр

йөзле "сөтле чикләвегем"не шытырдатып күкрәгемә кыстым. Әмма ләкин кызның кайнар сулышы йөземә, пышылдаган сүзләре колагыма килеп ирешкәнче "гөмберт!" итеп ишегалды ягыннан бер чиләк салкын су безнең өскә килеп тә төште. Мәхәббәт исереклегеннән шундук айнып киттек. Кочаклар үзеннән-үзе ачылды.

—Абыйларына юри әйтеп куйгансың,—дидем мин, "сөтле чикләвегемә", чын-чынлап үпкәләп.

—Валлаһи әйтмәдем, билләһи әйтмәдем,—ди теге. —Абыйлар да түгелдер әле, мөгаен, күрше малае шаяргандыр.

Минем ачу тагын да арта төште.

—Ә күрше малаемыни әле?—дидем мин, калтырый башлаган тешләрне көчкә тыеп. Каһәр төшкән бу калтыравын әйтер идем. Сүзне юньле-башлы әйтеп кенә булмый бит. Кузгалып кына китәр идең, жилкә аша кереп чалбар төбенә тулган су балаклардан чыпырдап чыгарга тора. Тик торам балактагы суны койма буендагы кычыткannарга агызып. Ботинканың бөтен кремын юып төшерә инде, шайтан алгыры. Чүпрәк ботинкамны ике көн кремга батырып, аннары жиде кат тирем чыкканчы коры сукно белән ышкып кына ялтыраткан идем. Янадан элекке рәвешенә кайтару ай-һай жиңел булмас. Ә "сөтле чикләвегем" үзен гаепле сизгәндәй, янымда сырпалана.

—Ярар инде, үпкәләмә, кибәр әле. Телисеңме, хәзер Ык буена төшәбез дә әйберләреңне үзем юып бирәм.

—Алар кипкәнче мин шәрә торырга тиешме?

Кызый минем хәлне күз алдына китерде бугай, көлеп жибәрде. Аның көлүеннән мин янә турсайдым. Чалбар төбендәге су кычыткан арасына саркып беткән иде инде. Мин горур кыяфәт белән кунак кызын бер әйләнеп чыктым да, телемә килгән беренче жырны жырлый-жырлый, кайтып киттем:

Урамыгыз такыр икән,
Белмим, кар ятыр микән.
Китә инде башкайларым,
Әйләнеп кайтыр микән.

Дөрес, әле ул вакытта минем башым беркая да китәргә жыенмый иде. Бу жыр бераз үземнең бәямне күтәрү, "сөтле чикләвегем"не әз генә үкендерү өчен генә иде.

Киемнәр тузанланып, пычранып беткән иде. Аларны мин иртәгесен бик әйбәтләп юып, пот ярымлы күмер үтүге белән үтүкләп жибәрдем. Элеккедән дә шәбрәк булып киттеләр. Бигрәк тә чалбар балагымдагы сырлар шәп чыкты. Юып яңартылган киемнәрне киенеп, дулкын-дулкын кара чәчләремне әле уңайга, әле кирегә тарап-кабартып жиффәргәч, менә дигән егеткә әйләндем. Ботинкалар да рәткә керде. Дулкын-дулкын чәчләремне бер селтәп артка жибәрдем дә, көзге каршына килдем. Көзгедәге егет бик фырт иде. Тизрәк "сөтле чикләвегем"не күрәсем килде. Кичне көчкә-көчкә житкереп, клубка ашыктым. Юлда кызу-кызу барганда башыма "келт" итеп бер уй төште: "Тукта, егет, алай ашыкма. Горуррак бул. Егетлегеңне күрсәт!" Акылыма рәхмәт әйтеп, клубка ашыкмыйча гына бардым.

Мин клубка килеп кергәндә кичке уен кызып бара иде. Кызлар арасыннан, үзенә сиздерми генә, "сөтле чикләвегемне" эзләдем. Ул Айның жиденче кичәседәй балкып, авылның иң авторитетсыз егете белән сөйләшеп утыра иде. Йөрәк әллә нишләп китте. Сукыр икән бу, кеше белән кешене аера белми. Ярар, без дә төшеп калганнардан түгел. Гармунчы бер танцы көе уйнап жибәрүгә, кул астына туры килгән беренче кызны эләктереп, биергә чыктым. Ботинка әйбәт майланган—шыгырдап тора, жае чыкса-чыкмаса да, башны болгап-болгап алам—бусы инде чәчләрдәге дулкыннарны кузгатып жибәрер өчен. Пинжәк төймәләрен чишеп жибәрдем, чөнки өскә өр-яңа күлмәк кигән идем. Күрсеннәр. Зәп-зәңгәр бит, елкылдап тора.

Ну биеп тә карадым ул көнне. Үзем биим, үзем күз кырыем белән "сөтле чикләвегем"ә карап алам. Гармун тынган, биюләр туктаган арада ул мина таба якынлашмакчы, нидер әйтмәкче була, ләкин аны күрмәмешкә салышам. Шалишь, брат. Без андый авторитетсыз малай түгел. Безнең сорт югарырак!

Шулай борынны күккә чөеп, теге кызыйны күрмәмешкә салынып йөри торгач, ул чынлап та күренмәс булды. Ары карадым, бире карадым—җир йотты диярсең, юкка чыкты. Кызлардан сораштырып карыйм: андый чүп-чар күзгә чалынмады дип, җилкәләрен генә сикертәләр. Чүп-чар, имеш. Көнчс тараканнар. Сез андый булсагыз, күккә сикерер идегез әле. Күрсәтермен әле мин сезгә "чүп-чар"ны! Беләсегез килсә, ул сандугачлар иленнән килгән. Ул сезнең кебек прастуй авыл кызы түгел, ул гөлләр нәселеннән.

Үзем авыл буйлап "сөтле чикләвегем"не эзләп йөгерәм, үземнең телгә шундый сүзләр килә. Күрми калганнары өчен авыл кызларына әләгә. Ярый әле үзләре ишетмиләр.

Ул көнне мин авылны өчме-дүртме урадым. Кунак кызын туганнарына кайткандыр дияр идең, өйләре тышкы яктан бикле. Өстәвенә чабата авызлы алабайларын бәйдән ычкындырып куйганнар. Алабаен әйтер идем: мине гомергә күрмәгәндәй, иләмсез зур авызын ачып, чалбар төбенә үреләә. Флера белән капка төпләрендә утырганда битне йөз кат ялап чыга иде үзе. Бүген исә танырга да теләми, минсинайтим.

"Сөтле чикләвегем"не ул көнне тәки күрергә насыйп булмады. Соңыннан белдем: ул Төрекмәненә сыпырткан булып чыкты. Шул көннәрдә миңа да, хәрби комиссариатка чакырып, язу килде.

Киттем районга комиссиягә. Эчне кара мәчеләр тырный. Әгәр дә мәгәр шушы барудан армиягә алып куйсалар, "сөтле чикләвегем"не янадан күрә дә алмый калам бит.

Юраганым юш килде, каһәре: кулга повестка тоттырдылар. Нишләргә? Уйлана торгач, үзебезнең авылга Төрекмән авылы аша кайтырга булдым. Менә бит ул башың эшләсә. Дөрес, моның өчен илле чакырымлап араны урарга кирәк кирәгән. Ну, минем кебек егеткә анысы пүчтәк инде аның.

Хәрби комиссариаттан чыккач, туры станциягә киттем. Ютазы станциясе әзме-күпме таныш. Шунда товар ташучы поездның бер шалтыравык вагонына эләктем дә Урыссуга элдерттем. Шалтырап кайта-кайта йоклап кителгән. "Сөтле чикләвегем"не төшемдә күреп уянып китсәм, поездым мине Туймазыга китереп җиткергән. Туймазыдан Төрекмән авылына ничә чакрымдыр, анысын бер Ходай белә—машинадан машинага күчә-күчә, тәки килеп җиттем мин бу Төрекмән дигән сандугачлар иленә. "Сөтле чикләвегем": "Авылыбызда бик матур мәчет бар, безнең өй шуннан ерак түгел",—дип сөйләнгән иде. Чынлап та мәчетләрс бар һәм бик матур икән. Минем әле ул вакытта эшләп торган, манарасы киселмәгән мәчет күргән юк иде. Озак кына карап, сокланып тордым мин бу иманлы бинага. Төрекмән авылы миңа, ничектер, башка дөнья булып күренде.

Хәер, минем сөйгәнем яшәгән авыл һич тә гади авыл була алмый иде. Нишләп әле мин шуны аңламый торам. Гади авылда яшәсә, ул да гади авыл кызы булыр иде. Ә ул бит... О-о! Андый кыз дөньяда бары тик берәү генә, һәм ул менә шушындый матур мәчетле Төрекмән авылында гына яши ала. Тизрәк эзләп табарга кирәк үзен.

Кешеләрдән сорашып-нитеп тормадым: мәчет янындагы бер йортка барып кердем. Анда ике хатын гөрләшеп чәй эчеп утыра иделәр. Өстәл уртасында бер таба коймак. Коймак күргәч кенә, бик каты ашыйсы килүне тойдым. Хатыннар минем хәлне аңлап табынга чакырдылар, ләкин мин: "Рәхмәт, сездә чәй эчеп утырсам, мине көтеп утыручыларның коймаклары суына",—дип, чыгып китә башладым.

Шунда хатыннарның берсе урыныннан кузгалып: "Безнең авыл егетенә охшамагансың, кем син, кемгә килдең?"—дип сораша башлады.

—Мин Кызылъяр егете,—дидем горур гына.—Монда сеңелкәшне эзләп килгән идем.

—Сеңелкәшең кем була соң?

—Флера! Мин аның Кызылъярдагы абыйсы булам.

—Шулаймыни?

Теге хатын миннән Кызылъяр хәлләрен сораштырырга тотынды. Сүз Флераның туган-тумачаларына килеп җиткәч, мин тизрәк бу өйдән чыгып китү ягын карадым. Миңа сораулар биргән хатын тәрәзә янына килеп: "Флераларның

йорты әнә тегесе була",—дип, урамнан эчкәрәк кертеп салынган җыйнак кына йортка күрсәтте.

Сөйгәнемнең кайда яшәгәнен белгәч, бер аягым монда, икенчесе тегендә булды. Мин атылып-бәрелеп диярлек Флераларга барып кердем. Ул чирләп ята иде. Мине күргәч, караватыннан торып утырды. Аннары тиз генә карават янындагы чаршауны тартып, күлмәген алыштырды. Өс-башын алыштырып минем янымa килеп басканда ул нәкъ безнең авылдагы төсле "сөтле чикләвек"кә әверелгән иде. Без кочаклашырга да, кочаклашмаска да белмичә, бер-беребезгә карашып тордык. Күзләр белән күзләр сөйләшә. Йөзләрдә әле шатлык яктысы, әле сагыш күләгәсе чагылып китә. Күкрәк читлегеннән йөрәк былбыл булып очып чыга да кызның иңнәренә кунып сайрый башлый. Аның йөрәк сандугачы минем иңнәргә килеп куна.

Менә шулай сайрашып-гөрләшеп мәхәббәт анлашканда бая мин кергән күрше йортта чәй эчеп утыручы теге хатыннарның берсе Флераларга килеп керде.

—Әнкәй,—диде Флера, сикереп торып.

—Әнкәй?..

Мин әле Флерага, әле теге хатынга карадым. Күр инде, нинди охшаш икән бит болар. Ә мин Флераның Кызылъярдагы туганы, дип, аңа әкият сатып маташтым. Вәт әкият!

—Ничек соң, Кызылъярда әйбәт кенә яшәп ятасызмы?—диде ул, хәйләкәр елмаеп.

—Әйбәт,—дидем мин, бераз уңайсызланып һәм китәргә җыена башладым.

—Бар, Кызылъярдагы туганыңны озат,—диде Флерага әнкәсе.

Флера иненә яулык салып, мине озатырга чыкты.

—Мин китәм инде,—дидем мин Флерага.

—Ашыкма әле. Урамда йөрик бераз...

—Армиягә алдылар мине, менә кулымда повестка.—Мин Флерага кәгаземне күрсәттем.

—Ә мин?—диде ул, сабый баладай үпкәләп.—Мин бит... Мин бит сине беренче күрүдә үк... яраттым...

Һәм ул көпә-көндез минем муеныма сарылды. Өстәмә кинәт мондый олы бәхет ишелүдән башым әйләнеп китте. "Мин сине күргәнче үк ярата идем инде",—дип әйтергә теләдем, ләкин Флераның кайнар сулышы сүзләремне әйтергә ирек бирмәде.

—Мин сиңа көн саен хат язармын,—дидем аерылышканда.

—Ә мин көненә икешәрне,—диде Флера.

—Мин сине мәңге онытмам!

—Мин дә! Гомерем буе көтәрмен.

—Сиңа озак көтәргә туры килмәс. Синең сагынуың мине бик тиз тартып кайтарыр. Син сагын гына, онытма гына!

—Онытмам!

Без шулай вәгъдәләр бирешеп аерылыштык.

Аннан бирле инде күпме еллар үтте, тик минем колак төбемдә һаман да Флераның: "Онытмам!"—дигән ягымлы тавышы яңгырап тора сыман. Мин ул чагында сөйгән ярларның "онытмам", дип онытуларын, "ташламам", дип ташлауларын белми идем әле. Бәлки шул белмәвем белән бәхетле дә булганмыңдыр. Юкса якты сагыш булып әллә кайдагы вакыйгалар күңелдә сакланыр идемени?!

*1998*

ШИГЪРИЯТ



# Рөстәм Султи

## ЧИТТӘ УНЫНЧЫ КӨЙ

* * *

*"Догрүйү сөйләйәни докуз*
*көйдән коварлар"*
*(Турысын сөйләгәнне тугыз*
*авылдан куарлар)*

Төрек мәкале.

**Бу унынчы авыл, бу—унынчы көем,***
**Газизләрдән газиз гаҗиз әнекәем,**
**Ничек сыйдым икән синең кочагыңа,**
**Дөнья шулай тармы, гаҗәпләнәм шуңа,**
**Тугыз көем—иске, унынчысы яңа.**

**Бу—унынчы көем, бу—унынчы авыл,**
**Бөтерепләр йөртә язмыш дигән давыл,**
**Кочагыңа синең ничек сыйган идем,**
**Юкса, бу дөньяны ничек сөйгән идем.**

**Сыймасам да сөйдем,**
**Кыйналсам да түздем,**
**Үз сүземне сөйләп дөньяларны гиздем,**
**Туры сүзле булып яман атым чыкты...**
**(Туры сүзле булып ялган җаным чыксын!)**

**Кеше көен көйләп үз сүземне әйттем,**
**Тугыз авыл артта, унынчыга җиттем,**
**Үз сүземне сатып гомер үткәргәнче,**
**Каршы алсын мине, көтсен унберенче!**

---

*** К ө й —төрекчә авыл дигән сүз. Ред.**

## Хәсрәт

Оялмасаң ела, үкси-үкси
Кайтавазың килсен, таулар көлсен,
Ела оялмасаң, кыяларга
Оялаган кошлар качып китсен.

Елар идем—бер-беренә мәңге
Кавышалмас таудан оялмасам,
Кыяларга оялаган бөркет
Балаларын уятырга кыя алсам.

## Океан кирәк миңа!..

Океан кирәк миңа, җитми диңгез,
Океан тели җаным иксез-чиксез,
Кайда соң ул аваз: "Шәкерт, уян,
Тор, бак, алдыбызда океан!.."

Инеш идем, актым Иделләргә,
Иделләрдән актым диңгезләргә,
Инде миңа җитмәс, имеш, диңгез—
Океан тели җаным иңсез, төпсез...

Сез ничаклы сабый-бала чаклы,
Үсмер, картлык чаклы, мин шулчаклы.
Чишмә-инеш чаклы, Идел чаклы,
Диңгез чаклы, инде океан чаклы...

Тәндә җаным барда, җанда—өмет,
Ни нәсыйхәт телим, ни бер үгет,
Бер фатиха, юл догасы булсын,
Хыялдагы, алдагысы булсын!

Океан кирәк миңа, җитми диңгез,
Җилкәннәрнең зурын киерегез,
Хыяллар зур, чөнки зур дулкыннар,
Океан зур, чөнки каным кайнар...

Аһ, мәңгелек хәрәкәттә булсам,
Аһ, мәңгелек бәрәкәттә булсам,
Аһ, мәңгелек сәяхәттә калсам,
Аһ, мәңгелек мәхәббәттә калсам!..

## Көзге моңсулык

Чираттамын, кыр казлары кебек
Саф-саф чират... Көзге моңсулык...
Итем сиңа, сөягем дә сиңа,
Виза сорыйм синнән, консуллык!

Югарыга багам, кыр казлары
Канат кына кагып узалар,—
Миңа исә кирәк консуллыклар,
Илчелекләр, чикләр, визалар.

Дөнья бер йорт диеп өйрәттеләр,
Шул йортның мин газиз, үз улы,
Тик аягым-кулым ник богаулы—
Консуллыклы, мөһер-визалы?!

Һич булмаса уем чиксез калсын,
Юатмасын беркем: "Каз алар..."
... Канатлылар, хәерле юл сезгә,
Ерак торсын бәла-казалар.

Мин—визасыз, имеш, җәзалымын,
Җәзасызмын—әгәр визалы...
Белсә икән бәндә, югыйсә бит
Виза булу белән җәзалы...

Беркем туктаталмас, беркем әйтмәс:
«Кыр казлары канун бозалар"...
Монда туу белән гаеплемен,
Язмыш менә шуңа җәзалар.

Чираттамын, кыр казлары кебек
Саф-саф чират... күзге моңсулык...
Югарыга багам—илдә калам...
Виза гына булсын, консуллык!

## Чит җирләрдә

Шүрәлесез урман,
Гармун-моңсыз урам,
Безнеңчә белмәгән сулар,
Шундый шыксыз, шәрә сыман,
Шундый моңсу, ямансулар—
Күңел мөлдерәмә!

Урманына керсәм—көләр идем,
Урамында җырлар көйләр идем,
Агымсуы кыйсса сөйләр иде—
Күңел мөлдерәмә!

Елыйм дисәң, үзе ни елатмый,
Күз яшьләрне сөртеп, ни юатмый,
Ни көлдерми, ләм-мим бер сүз әйтми—
Күңел мөлдерәмә!

## Үз-үземә

Егет булдың, ир булдың,
Ни майтарып, ни кылдың?
Буеңнан оялсана,
Уеңнан оялсана!

Илме күрде игелек,
Җирме сөрдең җигелеп?
Атыңнан оялсана,
Атаңнан оялсана!

Дәрман булдыңмы дәртқә
Бер моң булып йөрәккә?
Сүзеңнән оялсана,
Сазыңнан оялсана!

## Тәрәзәңне япма

Болыт түгел, кучмә кошлар килә,
Хәерле юл, ап-ак юл телә.
Үткәннәрнең әрнүләрен тыңла,
Киткәннәрнең сыкрауларын аңла,
Тәрәзәңне япма!

Зәңгәр биекләрдә моң чайкала,
Җаны булган нишләр бу мәлдә,
Яңгыр диеп тәрәзәңне яптың,
Нишлисеңдер ялгыз бүлмәңдә.
Зәңгәр күкнең керфек очларында
Мөлдер-мөлдер килеп яшь тора,
Зәңгәр күзле ярың искә төшсен,
Тәүге, соңгы тапкыр хәл сора.

Чылатыр тик сине—яңгыр түгел,
Кошлар кәрванының күз яше.
Тәрәзәң ач, бу бит киткәннәрнең
Калганнарга булган эндәше.

Болыт түгел, кучмә кошлар килә,
Хәерле юл, ап-ак юл телә.
Киткәннәрнең әрнүләрен тыңла,
Киткәннәрнең моң-зарларын аңла,
Тәрәзәңне япма!

*1997—1998*
*Измир шәһәре. Төркия*

*Әхәт Гаффарга 50 яшь*

# ХАЛЫКЧАН ИҖАТ ИЯСЕ



*Журналист, язучы буларак, Әхәт Гаффар яшьли, иртә өлгереп җитә. Балык Бистәсе төбәгендәге тирәюньдә абруйлы булган Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлагач, ул 1971 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. Ошбу уку йортын тәмамлау белән үк, республикабыз матбугатында эшләргә керешә. Шул ук вакытта әдәби эшчәнлек белән дә шөгыльләнеп, үз көчен сыный, илһам, иҗат канатын ныгыта бара. Аның беренче хикәясе сигезенче сыйныфта укыганда "Яшь ленинчы" (хәзерге "Сабантуй") гәзитендә басылып чыга. Булачак әдипнең шуннан соң язган "Әҗәт" дигән кыска, әмма җитди хикәясе үк әдәби җәмагатьчелектә, укучыларда зур кызыксыну уята. Ары таба иҗат ителгән "Яра", "Язлар моңы", "Гозер", "Су астындагы чишмә", "Бишек", "Яшиселәр алда иде әле" һәм башка ике дистәләп повесте, "Бодай бөртеге һәм тегермән ташы", "Олы юлның тузаны" исемендәге романнары аны татарның күренекле язучылары рәтенә куя.*

*Әхәт Гаффар драматург буларак та зур абруй казанды. Аның "Язлар моңы", "Соңгы ләкләк", "Җиләк вакыты бер генә", "Өч сорауга бер җавап", "Сызылып таңнар атканда" кебек пьесалары тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителде, татар драматургиясе, театры тарихында лаеклы урын алды. Аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.*

*Әхәт Гаффарның әдәби язу алымын кыска гына метафорик иҗат дип бәяләргә, билгеләргә булыр иде. Шул ук вакытта аның заманча проблемаларны күтәргән чәчмә әсәрләре халык иҗатына, фольклорга нигезләнә. Әдип әнә шул фикри һәм образлы киеренкелек, халыкчанлыкның тыгыз, аерылгысыз бердәмлеген табуга ирешә.*

*Язучы үзенең 50 яшь тулган көннәрен "Богау" дигән романын иҗат итеп каршылый. Ул Габдулла Тукайның бала чагын тасвирлаган "Дәрья башы" повестен, яңа романын, төрле хикәяләрен туплаган бу китабы Татарстан китап нәшриятында чыгып килә.*

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

# Әхәт Гаффар

## ШӘҖӘРӘМ АҖАГАННАРЫ

хикәят

### Көндезге истәлекләр, төнге уйлар

*Яшәү нәрсә?*
*Мәңгелек тә бар ла!*
*Соң лабаса кемнән ким идек?*
*Без бар идек,*
*без бар,*
*булырбыз да!*
*Шуның өчен дөньяга килдек.*

*Ә. Г.*

Борынгы грек фәйләсуфе Луций Анней Сенека: “Яшәү—үләргә өйрәнү ул”,—дип язган. Әнә шул үлем дигәннәре мина ни өчендер табигатьнең, җиһанның үзе үк рәвешендәдер, шуның йөз-кыяфәтендәдер кебек тоела. Чөнки һәрбер фасыл үз вакытында күзен ача, үз сәгате суккач йома да. Быел—1998 сәнәнең халык бәрәңге алганы чагында Кырлайга барып чыккач, яшәү белән үлемнең бер йомгак хәлендә икәнлегенә дәлилле үрнәккә тап булдым.

Казан рәссамы Магдалина Мавровскаяның “Тукай” дигән графика рәсемнәре арасында “Кырлай авылы. Күперчек” (1951 ел) атлысы бар. Аның төрле басмаларда нәшер ителгән күчермәсен күргән, караган идем. Әлеге сурәттә Габдулла укыган мәдрәсә белән мәчет арасындагы инеш аша салынган күперчек, аның суы ярындагы ялгыз юан, карт тирәк, уң ягындагы тагын бише, арырактагы өчесе тасвирланган. Бу юлы килеп, шул күперчек төбендә торганым мәлендә теге ялгыз тирәкнең авып, инеш аркылы сузылып ятканын күрдем инде. Кырлайда күпме тапкыр булып, әүвәл моңа илтифат ителмәгән. Әйе, тамырларының какшаганы соңында әлеге—киләчәктәге мәшһүр Тукай булачак бәләкәй Апушның яшьтәше карт тирәк, урак урып аргач, төшлектә инеш ярына хәл алу нияте белән барып авышкан бер агай сыман, бөтен буена сузылган да яткан икән.

Тик... Әйе, тик ул шуннан алда соңгы сулышын алган чагында үзенең балалары, оныклары саналган газиз ботакларына гадәти дә, гаҗәеп тә әманәтен тапшырып калган: ЯШӘГЕЗ!—дигән.

И яшиләр дә. Мәгърур сурәттә үсеп торалар бит, әй!

Теге—1951 елда алынган рәсемдәге казлар да шундук йөзә бирә. Казлар... алар ел саен борынлап чыгалар да буй җиткерәләр, каурый, канат нығыталар, ә тәмам үсеп җиткәч исә... үзегез дә беләсез. Кышка кердек инде дигән иртәләрнең берсендә ап-ак карны кучкыл кызыл җылы кан эретер... Әйе, яшәргә өйрәнеп җиткәндә генә үләргә дә өйрәнеп өлгерәләр...

Шуннан. Магдалина ханымның рәсемендә ары таба бер печән эскерте сурәтләнгән. Кырлайдагы нәкъ мәчет урынында, имеш. 1903 елда төзелгән мәчет бинасын зобанилар заманында рәсемгә төшереп кара син! Бүген исә ул мәчет үлеменнән соң янә яңарып тора. Монысы—үлемнән соң яшәү була инде.

Әйе, Яшәү белән Үлем арасы бик якын ул, бик якын...

Инде хәзер—фани дөньяда бик дистә еллык гомеремне кичерү дәвамында төнге аяз күк гөмбәзендәге үз Йолдызыма баккан мәлләрдә үткән-сүткән чыклы эз, тар сукмак, сикәлтәле озын юл борылмаларын барлыйсың икән ул. Ә бу

гамәлләр исә чатнаплар торып яшьнәгән яшеннәрне турыларга теләгән, ниятләгән ише, гаять тә четерекле, читен, хәтәр нәрсә. Якты дөньяга яратылуын белән ләухел-мәхфүзендә язылганны барларга тырышуга тиң бер гамәлдер.

## Үлмәс өчен яшәү

Мин—үлемнең күзенә биш мәртәбә текәлеп караган адәми затмын. Ничектер, шулай, җәйге чиллә сүрелеп, әни сыер сауган, әти капка төбен себергән мәлдә ялгызым гына су коеныръга төшеп киткәнмен. Ул чагында биш яшем чамасы, терекөмештәй тоттырмас җанлы, ләтчәдәй житез, тилгәндәй куркусызмын. Су якын гына: капкабыз төбеннән нибарысы утызлап сажин арырак. Ул вакытта авылыбыз, күмәк хуҗалыгыбыз заманына күрә шактый хәллеләрдән санала, халкы эштә уңган, тырыш, көн күрүдә үҗәт. Һәр елны май аенда ике көпчәкле җигүле арбаларда, бердәнбер йөк машинасында Мунчала күле тирәсеннән туфрак, балчык ташыла, салам, куаклар түшәлеп, зур буа буыла, су электр станциябезгә текә ярлы, төз, матур канау казыла. Станция алдында житмеш биш сутый кадәрле мәйданлы үзенә бер күл—хәвыз бар. Авыл ягындагы яры йомшак чирәмле, каз үләнле, уйдык-уйдык исле ромашкалы су туплагыч хәвызның җирән үзле балчыклы төбенә юка гына сары ком яткан. Шунда тәмам күшеккәнче коенабыз, балчыктан төрле-төрле сыннар әвәләгәч, тегермән буйлата сузылган амбарларның такта түбәсенә тезеп, кояшта киптерәбез, уйныйбыз. Яз көннәрендә шул урын боздан арчылгач, яр кырыенда шактый киң калганыннан тимер таяк, лом, көрәк белән ике-өчебезне тотарлык боз ватып, кубарып алабыз да колга белән этә-төртә кинәнеп салда йөзәбез. Без малай-шалай бу хәлне котып дингезләрендә сәяхәт кылуыбыз рәвешендә тоябыз, күз алдыбызга китерәбез, хыялланабыз, әлеге хыялны чын итәбез, имеш. Саксызрак, дуамалрак кыланганда салыбыз алпан-тилпән чайкала да, аннан коелышып, бил тинентен суга килеп төшәбез. Шул килеш чатыр-чотыр дигәндәй өйгә йөгереп кайту шүрләтә. Арырак аулак бер урында коры әрем, әрекмән сабаклары, чыбык-чабык җыештырып, әүвәлге әвен базыннан калган чокырда ут тергезәбез, кипшенәбез. (Җаядә дигәндәй әйтергә кирәктер: ошбу урын—бабабыз Гаффарның заманында яшелчә бакчасы булып, шундук мунчасы да торган. Әлеге шул мунчасына җәйләренме, кышларынмы үргән арба, йә артлы чанага җигелгән юртакта гына йөргән, Һидиястә әбиебезне бик затлы япма җәеп кенә алып барган. Бабай 1939 елда вафат булган, шуңынчы колхозга кермәгән, большевиклар хакимиятен кабул кылмаган, үзенә үзе хуҗа сыйфатында гына көн күргән, гомер сөргән. Әлбәттә, бар мал-мөлкәтен кычкыртып талаганнар инде.) Әйе, суга баткач кипшенгәндә кием-салымыбызга әче төтен исе сенеп беткәч, әллә кайдан аңкып торган булса да, без "дингез бүреләре"нә ни әти, ни әни артык тиргәп сүз әйтми, җиңелчә генә битәрләп алудан гайре әллә ни узмыйлар. Әни киемнәребезне юа, әти бутый, күнитекләребезне үзебезгә чистарттыра...

Шулай итеп, җәйге чилләнең тәмам сүрелгән чагы. Үрдән түбән төштем дә, шәфәкъ нурына манчылган хәвызга илткән калку муентыктан үтеп чишенгәч, су коеныръга керешкәнмен икән. Ул урынның тирән икәнен дә беләм югыйсә: бер яктан йорт-курабыз янәшәсеннән язларын кинәттән (бездә хәтмәле диләр) ургып-ташып төшә торган ерганак тамагы казып чоңгыллатса, каршы тарафтан хәвызның агымсуы ашаган, боларның маңгайга-маңгай очрашкан, бәрелешкән урын. Күрәсең, нәкъ шул турыга эләккәнмен инде. Сизәм: батам да калкам, калкам да чумам, чоңгылның үзле балчыклы ярында тәпиләрем шуа гына, аяк бармакларым җиргә капмый, тын алам дигәндә авызга һаман саен су гына эләгә, тончыктыра. Югыйсә мин йөзү дигәндә балык белән бер ләбаса инде үзе. Мелләле, курку хисе биләп алып, бар ихтыяр көчемне су сибелгән учак сыман баскандыр.

Кирәк бит, Алла рәхмәте: бездән бер өй аша торган тегермәнче Зыятдин абыйларның өлкән кызы—миннән өч яшькә олырак Фирая (Габделхак абыебыз белән бер сыйныфта укый иде) көянтә-чиләген асып килеп төшкән дә миңа көянтәсен сузган; шуңа чытырдап ябышканмын да өстерәлеп, сөйрәлеп чыкканмын.

Бу хәл минем гомердәге күз алдымда, йокымдагы төшемдә әле дә булса кабатлана тора, кабатлана тора...

Ә Фираяның шуннан соңгы кыш аенда авыл клубындагы көндезге кинога бик ашыгып, абыйны дәшеп өйгә кергәне исемдә. Абый бармаска булган (яшеренбатырын түгел, биш тиен бакыр акча тапмагандыр). Ә Фираяның атасы, әйткәнемчә, тегермәнче бит—ул тапкандыр инде, тапкандыр.

Ашыккан шул Фирая, ашыккан. Кәримулла абый Гатиятуллин кузгатып җибәргән чылбырлы тракторның арткы басмасына менеп баскан, ә бишмәт итәген чылбыр бармаклары каптырып алган да—Фираябыз... алга барып төшкән. Матур апа иде. Җылый-җылый җирләделәр...

Ул—миңа әнидән соң икенче яшәү биргән кешедер кебек.

Бүтән үлемем мине "Атау эче" дип йөртелгән уйсу таулы, түгәрәк күлле, акчарлак, тәкәрлек, бака чеңәне мыж килеп торган сазлыклы урында сагалап торган икән. Өлкән абыебыз Габделбәр белән аның "гадугы" Сәйфи Вакыйфы Кәрәкә күленә җәтмә белән балык сөзәргә кереп киткәч, мин—ярда калган сапсары чәчле малай җиргә ятканмын да йоклап киткәнмен. Ә анда йоклау түгел, ә бәлки әзрәк черем итү нияте белән ятып торсаң да мәлҗерисен, күз кабакларына кургаш тагыла да куя. Халыкта ул урын буыннан-буынга "Женле жир" дип телгә кергән. Ничек кирәк алай уятып, житәкләп алып кайтканнарын хәтерләмим, жылы мич башында зиһенемә килгәнем исемдә. Янымда авыл фельдшеры Банат апаның ак халаты чагылып-чагылып киткәнен искәртәм, әтинең әнигә:

—Харап булды бала!—дигәнен бүген дә ишетеп торам шикелле.

Тернәкләнгәнмен, терелгәнмен.

Өченчесе. Өебездә—Сабан туе көннәрендәге мәҗлес. Әти гармун уйный, әни җыр башлый, кунак-төшем иплә кенә кушылып китә. Көн эссе, ә монда—салам түбә астында тымызык салкынча. Кызык ич: күрше Нурислам яшьтәшем белән өйалдындагы караңгы чоланга кердек тә, бер литрлы чүмечкә агызып, татлы да, әчкелтем дә нидер эчтек. Ие, шул нәстә инде—бал. Шуннан соң чатыр-чабып су коенырга ашкындык. Майкы белән трусигыбызны ярда калдырып, буа артындагы өч сажинлы текә кызыл ярдан тобага, чумгалак кыр үрдәгедәй, баш белән очып чумганбыз. Чумганбыз да... сизәм бит: әйләнгеч су түбән тарта, сулыш житми—батам. Ул чагында үлемнең ни нәрсә икәнлеген каян белим соң әле? Көч-хәл белән йөзеп чыкканымны, киемемне култыгым астына гына кыстырып, өйгә элдергәнемне бик яхшы чамалыйм...

Дүртенчесе. Әлеге электр станциябез алдындагы сусаклагычның бик саеккан арасы иде. Анда иркенләп, колачлап йөзәрлек түгел. Ә станция эшли, тегермән он тарта, су ага да ага. Без бала-чага нишләгәнбез? Хәвыз алдындагы канауның көчле су агымына барып кергәнбез. Керүен-кергәнбез, ә мин сизәм: мине су әйди, өстери, сөйри, әүмәкли, алҗытып, хәлдән тайдырып, тиздән шлюз астыннан турбина залына илтеп тыкмакчы, кысмакчы...

"Әхәт, чык, жир тырна, сөйрәл—тик чык!"—дип, үз-үземә боерык биргәнем кичә генә булган хәл сыман...

Бишенчесе. Инде халыкта танылган язучымын, имеш. Әдрән диңгезендәге бер йөзештә шагыйрь Равил Фәйзуллиннан соң икенче булып килдем. Ул турыдан гына—яр борылышларына исе китмичә, дельфин шикелле, сикерә-оча йөзә. Ә мин, алай-болай көзән-фәлән жыера күрмәсен дип, яр буйлата—бөгелеш буенча колачлыйм... Башкаларның һәммәсе берәм-берәм төшеп калып, яр буенча гына кайнар комнан тәпиләп титаклаган да, без килеп җиткәнче , безгә бүләккә ниятләнгән бар шәрабне эчеп бетерә язганнар, юньсезләр. "Каз тиресе" белән капланган тәнебезне әз-мәз жылытырга иренгә соңгы тамчылары гына тиде.

Ул чагында һәр елны йә Кара диңгездә, йә Балтыйк диңгезендә, иң мөһиме, Әлмәткә әүвәлге су суырткыч бассейнның буеннан-буена көн саен өчәр, дүртәр чакрым йөзеп чыныкканга күрә, мин инде суда йөзүне тәмам үз иткән идем. Ә бер заманны Равил абый белән өч сәгать буена үзара теннис уйнап тирләгәнебез, арыганыбыз соңында аргы Кабан күленә йөзәргә чакыруын кабул кылган идем.

Бардык, чишендек, кердек. Ә мондагы су жиңел икән—тәнне, гәүдәне диңгез суыдай өстә тотмый. Ә шагыйребез йә акулага, йә крокодилга, йә чуртанга

биргесез тәстә йөздә дә китте. Артка калдым инде. Сизәм, күрәм: моның артыннан һич тә җитешерлек түгел. Шуңа күрә Кабанны кыл урталай кистереп чыгарга ниятләдем. Су—ул ярдан караганда гына тар шикелле күренә, тоела. Кердең исә, яссылыгы иксез-чиксез кебек.

Күлнең уртасына җитәрәк, янәшәмдә Әҗәл сулышын искәрдем.

—Әй! Кенәз-з! Батам!—дип кычкырам. Сызгырам. Сәлам индереп:

—Йөз, Йөз!—дип, кулын болгады.—Кергәнсең икән, син чыгарга да тиеш!

Тагын үз-үземә, маршал Жуков сыман:

—Алга, Әхәт!—дип боердым.—Икенче сулыш! Икенче сулыш...

Чыгып җиттем дә авырайган, хәлсез гәүдәмне яр буена сузып салдым инде. Күрәсең, Аллаһы Тәгалә Үзе гозеремне кабул кылып, мине, әнә шулай, биш үлемнән йолып калуны кирәк дип санагандыр: "Син Миңа бу дөньяда кирәк әле",—дигәндер кебек... Ул көнне исә мин күбрәк йөздем.

## Заманалар арасы—җан күземнең карасы

Болгар дәүләте, монгулларга җиңелгәч, кара күмер булып көйрәп ята. Ак пулатларны корым, сөрем каплаган, урамнарны кучкыл кан баскан. Үтерелгәннәр, шәһит киткәннәр җыеп күмелмәгән, җирләнмәгән әле. Һавада козгыннар каркылдап очына, тирә-юнь урманнардагы бүреләр мәетләр исенә шашына.

Йәмән өлкән яшьтә, карт иде инде. Угланы Мөхәммәтхуҗаны үз катына дәшеп алды да әйтте:

—Ыруны сиңа тапшырам. Төн ягына барасың. Чулманны кичәсең. Кашан каласын узып, көн чыгышы тарафына юнәләсең, кушылдык инеш тамагыннан сул кул якка борыласың. Анда күл булыр. Шул тирәдәге акылыңа, күңелеңә хуш килгән урынга төпләнәсең. Дошман зәгыйфьләнде, тиз арада бимазаларга җөрьәт итмәс.

Батый хан бу кавемне эзәрлекләүне Сүбәдәй баһадурга тапшырды:

—Әшнәк Йәмәнен кыр,—диде.—Ул миңа буй сындырмыйча качып китте. Кавеменең каны белән Чулманны шәфәкъ иттер.

Сүбәдәй Йәмән кавемен Чулманга төнгә катыш кына кысрыклап терәде. Аның кылычы таң нурын көтте. Буй сындырмаганнар да, канга сусаган баскыннар да төнгә учаклар тергезде. Һәр ике як та алҗыган, йокларга яткан кебек.

Таң сызыла башлар алдыннан Мөхәммәтхуҗа уяу торган халыкны кузгатты да Кашан каласы юнәлешендәге ат корсагына җитешле яшертен кичүдән аргы текә ярга алып чыкты, ары алып китте.

Таң атканда Сүбәдәйнең кынынннан чыккан кылычы кояш нуры булып алга томырылды. Ат тояклары җирне тетрәтте.

Ә яр буш иде инде: төн буена янган учак күмерләре сүрелгән, соры көлгә әйләнеп бетеп бара. Аргы текә чаллыга чыгарга баһадурның йөрәге кыймады: анда аның үзен, чирүен яшендәй уклар гына көтә иде инде.

"Гаип булганнар",—дип уйлады ул. Җәядәй кысылган күзе ук очышы кинлегендә Чулманны сыйдыра, иңли алмады. Ул чирүен кирегә борды да:

—Алга!—дип боерды.

Мөхәммәтхуҗа үз кавемен үргә алып менеп китте дә багъ алмагачлары таралышып үскән ачык үр кашы буенча түбәнтен әйдәде. Башта Чулман елгасына килеп кушылган бормалы-сырмалы инеш тамагы тигезлегенә төпләнергә ниятләгән иде.

—Төн ягына!—дип боерды Йәмән.—Җалпы тауларын узып, Лашман белән Табай арасындагы Чәбе үренә тукталабыз, угланым. Йортыбыз шунда булгыр...

Безнең Олы Әшнәк авылының зәңгәр Күк, якты Кояш, моңсу Ай астындагы тормыш бишеге шул заманнан тирбәлә башлый инде.

Хәзер безнең Балык Бистәсе төбәгендә шул атальштагы дүрт авыл бар: Олы Әшнәк, Кече Әшнәк, Югары Әшнәк (Зәнгәрле дип тә йөртәләр), Рус Әшнәге (руслар килеп чыккач нигез салынган). Тагын бер Әшнәк—Алексеевски районында—борынгы Биләр төбәгендә. Безнең ыру-кавемебез шул тирәләрдә төпләнеп яшәгән булган. Һәрхәлдә шәҗәрәбезнең кендек очы шул җирдә дип тоям. Ул авылда студент чагыбызда бер җәйне эшләп тә алган идек. Сөйләмнәре, сүзләре, бию, җырлаулары, гореф-гадәтләре, холык-фигыльләре—нәкъ безнекечә.

Безнең оч урамы буенча, инешебезгә янәшә сузылган зиратыбызда өч борынгы кабер ташы саклана иде. Берсе юкка чыккан инде. Икенчесенең язуы укырлык хәлдә түгел. Ә өченчесенен—халык телендә "Хан кызы кабере" диеп йөртелгәненең язуын галимнәребез Фәрит Хәкимҗанов, Әнвәр Хәйруллин, Илшат Хәлиуллин кайта-кайта тикшерделәр, язуын күчереп алдылар: анда әлеге дә баягы Йәмән улы Мөхәммәтхуҗаның Сәбилә атлы кызы җирләнгән. Шул тирәдә генә Изгеләр каберлеге дигән урын да бар. Археолог Илшат Хәлиуллин тикшереп, карап, анда төрбә барлыгын ачыклаган иде. Сөйләвенчә, ул шундагы кәз астында тоташлый түшәлгән таш плитәләр тапкан.

Әлеге кабер ташындагы язуга караганда, Олы Әшнәк халкы бик борынгы Эскил (Иске ил) кабиләсенә кергән. Иске ил микән, башка мәгънәсе дә булганмы—белеп җиткермим инде.

Ә менә 1989 елны без, Татарстанда беренчеләрдән булып, бик олылап, Сабан туеннан соң ун көн үтәр-үтмәстә авылыбызның 750 еллык бәйрәмен уздырдык. Ул вакытта Татарстан Мәдәният фонды рәисе урынбасары вазифасында идем. Шушы оешма, тагын шуңа караган Ш. Мәрҗани исемендәге җәмгыятьнең президенты Рәфыйк ага Хәмидуллин, әлеге Илшат Хәлиуллин башлап йөрүе, ул чагындагы районыбыз хакимияте башлыгы—аксакалларча милләтпәрвәр Хатыйп Газизовның ифрат ярдәме белән. Язучылар, журналистлар, галимнәр, артистлар, тирә-юнь авыл халкы шул рәвешчә тагын бер "Сабан туе" ясап алган иде.

Боларны ни өчен язам әле? Бердән, һәр кеше, һәр авыл, тулаем халык үзенең асыл тарихына, олы шәҗәрәсенә шушылай кадер-хөрмәт күрсәтсә, без бик күп фаҗигаләргә тарымыйча, бүгенге әхлагыбызның, көн күрешебезнең байтак алама якларыннан котылыр идек дип искәртәсем килә. Икенчедән...

Икенчедән, 1981 ел җәендә бөтен Советлар Союзыннан җыйналган утыз журналист белән Португалиягә сәяхәткә чыккан идек. Кояшлы бер көнне Эвора дигән шәһәргә алып бардылар. Мин халык җырлары язылган көйләр язмасы сайлап торган арада, безнекеләрне бер гыйбадәтханәгә әйдәгәннәр. Мин барып кергәндә чыгып киләләр иде инде. Хатыным Фәридә:

—Бар әле, кара, кызык анда,—дигәч, түргә үттем дә сул яктагы бер залга җиттем. Карасам! Бөтен дивары, дүрт кырлы колонналары, алар терәгән ярым түгәрәк аркалары... кеше сөякләре белән бизәкләп эчләнгән, тышланган. Түрдәге тәрегә мумия кадаклап куйганнар. Җаным өшеп, тетрәнеп киттем.

—Кыргыйлык ич бу!—дип, татарчалап әйтеп салганымны сизми дә калдым. Мин шаклар каттым. Ә Америка сәяхәтчеләре миңа гаҗәпсенеп, сәерсенеп карый.

Бу урын "Сөякләр кәшәнәсе" (часовнясы) дип атала икән. Баксаң, һич тә искитәрлек түгел: урта гасырларда руханилар, үзләре вафатыннан соң биш ел үткәч, үз сөякләрен казып алып, шундый кәшәнә ясарга васыять иткәннәр икән.

Хәзер мин моның кыргыйлык булмыйча, исәннәргә яшәү белән үлем хакында мәгънәле итеп искәртү икәнлегенә төшендем инде.

Ә бездә? Авылыбыздагы ике мәчетне сүтеп ташлап, бүрәнәләреннән клуб, колхоз идарәсе, авыл советы, китапханә урнашкан ике катлы бина төзегәннәр, мәктәп салганнар, күрше рус авылы Корноухово (берчакны район үзәге булып торды) инеше буена кибет сипләгәннәр, анда аракы да сатыла иде. Ул авылның үр башында зур кызыл таш чиркәү дә клуб ителгән. Әлеге чиркәү каршысында бер кабер ташы тора иде—соңгы инкыйлабкача шушы

тирәдәге җирләрне белеп торган Капитон Макашин атлы байныкы. Бер елны шул кабер ташын трактор белән йолкып чыгарып, эченә төшкәннәр дә табутын да сөйрәп менгергәннәр. Әллә алтын-көмеш әйберләргә дә юлыкканнар дигәннәр иде инде шунда, бусы никадәр хактыр. Ә баш сөяге... язгы ташкынга хәтле күпер астында аунап, типкедә яткан дип сөйләделәр.

Моның кайсысы кыргыйлык соң әле? Португалиянең халкы, Икенче бөтендөнья сугышына катнашмый калуына рәхмәт йөзеннән, башкалалары Лиссабонга каратып, Тежу елгасы аша салынган өч чакрымлы асылмалы күпер төбендәге тауга Иисус Христосның йөз метр биеклегендәге сынын бастырып куйганнар. Кулын җәеп, шәһәрне үз канаты астына алырга әзер торамыни.

Ә бездә? Заманында Балык Бистәсенең Чулман буенда утырган чиркәвен шартлаттылар, Анатыш, Шумково авылларындагы гыйбадәтханәләрдә техника тоттылар. Мәчетләрне хакарәт итүләрне әйткән дә юк инде, Олы Әшнәктәгеләренең язмышын әйттем.

Бу кыргыйлык, дәһшәтле вәхшилек сәбәбенең галәмәте нидә соң? Тарихыңа төкереп, шәҗәрәңне онытуда.

Әлмәт язучылар оешмасын җитәкләгән вакытымда нефтьчеләр турында әйбәт кенә хикәяләр язып йөргән акыллы бер кеше—Владимир Ларин белән танышкан идем. Заманында партиянең әлеге Корноухово районы комитетының беренче секретаре булган кеше. Ул болай дип сөйләгән иде:

—Ахмак булганбыз. Бер елны Зюзино чиркәвендә һәм шул авыл йортларында булган барлык иконаларны җыеп яктык.

Ә гарәп әлифбасында язылган күпме китап зиратларга күмелде, яшереп куйган җирләрдә туздды, череде. Тик шулай да кала икән ул, кала. Әнә, фидакарь рәвештә борынгы кульязмаларыбызны, китапларыбызны җыючы каләм иясе Дамир Гарифуллин, Сарманыннан тиклем килеп, безнең авылыбыз зираты йорты чардагыннан мәшһүр Кол Галинең илаһи “Кыйссаи Йосыф” әсәре язмасының бер өлешен табып алган иде. Каян килгән ди ул? Әнә шул Эскил кабиләсенең мирасы түгел микән? Бәлки, бәлки...

Шулай. Аламалык, яманлык белән генә кешенең, халыкның хәтерен һич тә бетереп, китабын ягып, шәҗәрәсен онытырып булмый ул!

Бер нәрсә дә юкка чыкмый. Халкыбыз тарихы, нәселебез шәҗәрәсе минем дә Канымда, Аңымда, Җанымда, Иманымда.

Авылыбыз җирләренә кергән Атау эчендәге Ялпы тавы кашында борынгы Болгарның бер шәһәрчеге булган. Моны дөнья күләмендә атаклы археологыбыз Альфред ага Халиков раслый. Шул хакта сөйләшеп утырганыбыз да булды. Без шундагы җиләкне учлап-учлап ашый, чиләк-чиләк җыя идек. Шул җетекызыл җиләк минем дә кан тамчыларым төсендә тәнемә иңгәндер. Без балаларны өлкәннәр зур зиратыбыздагы кузгалак, кукы, каен, җир җиләге җыеп ашаудан да тыймады. Җир, шулай итеп, мине ата-бабаларыбызның рухы белән туендыргандыр. Боларның барчасы күңелемне сугарып, бала чагымнан ук кулыма күтәрмәс каләм тоттырган да Язучы, елъязмачы иткәндер дә инде.

Боларның һәммәсен ак кәгазьгә күчерим дисәң, каләм өчен Җирдәге агач төтмәс, кара өчен дәрья җитмәс шикелле.

... Шәҗәрәмнең бүтәннәре моңарчы китапларымда шәрехләгәннәремдә иде, калганнары, Аллаһы Тәгалә вә сөбханә боерса, алдагыларында булыр.

## Каләм белән кәгазь

Инде дә шушы хәлләрне күреп үсүем, шуларны уйлавым һичничек эзсез калмаган икән ул. Тора-бара минем җаным, аңым сиздермәстән-нитмәстән үзенә күрә бер саркыткычка әйләнгән. Тормыш итү, яшәү сөте савыплы бер савытта оеган да, мине шул оеткыны әйрәнме, эремчекме итәр өчен иләк, марля урынына келәт диварындагы чөйгә, кадакка элеп куйганнары ише.

Әй ул тормыш әйрәне! Әче. Ә шуңа, әниебез Бибигайшә кебек, җәйге чиләдә җир җиләге салып изсәң, ул таңгыйы, кичкеме шәфәкътәй нурлана, татлылана. Әй ул яшәү эремчеге! Татлы. Ә шуны кече учак казанына салып кайнатсаң, ул алсу тәстәге турага әверелә.

Язу гамәле дә шуның сыман инде: күргәненне татлыйсың, уеңны кайнатасың.

Ике кызымның да бер-бер артлы яза башлаганнарын, язмый тора алмаганнарын белеп алгач, мин аларга:

—Язмагыз,—дигән идем.

—Нигә?

—Язу ул—каторга хезмәте. Бик авыр яшәү. Үзеңне үз ихтыярың белән тегермәннең ике ташы арасына кертергә дучар итү.

Нишлим дә нишләтим соң? Яза башладылар. Язалар. Әнә, төпчек кызыбыз Сөмбел унҗиде яше тулар-тулмаста беренче әкиятләр, хикәяләр китабын нәшер итте инде. Аның өлкән апасы—Ләйләбезнең шундагы хикмәтләргә карата ясаган рәсемнәре белән. Анысы да үзенең яшәү мәсләге сыйфатында иң авыр бер һөнәрне—журналистлык эшен сайлады шул. Җитмәсә, Казан университетын тәмам итәр дип көткәнебез заманында Төркиядәге Әнкара университетына гыйлем эстәргә китеп барды, аны тәмам итте. Тагын да авыррак эшкә керешердер, күрәсең. Ул—җаны-тәне белән—дипломат. Журналист белән язучы, кеше белән кеше арадашчысы булса, дипломат—халыклар белән халыкларны таныштыручы, тынычтыручы инде ул. Бар, таныштырып кара, әйеме?

Ә мин үзем соң, үзем? Нишләдем дә—нишлим?

Шул инде—язам, җуләр.

Авылыбыздагы китапханәне "су урынына эчеп чыккач", гыйлем Мәккәбез Олы Солтан урта мәктәбендәге китапханәгә керештем. Ул бик бай иде! Шундагы китапханәче Разия апа Яруллинаның әче тавышы белән:

—Гаффаров! Җиттеме сиңа, юкмы? Дәресеңне укы!—дип тиргәүләре минем җаныма сары май булып кына ягыла иде.

Ә мин, җуләр,кичләрен малайлар белән кәрт сугып, кызлар белән сөйләшеп чыгасы урынга инглиз язучысы Томас Майн Ридның авантюра, маҗара белән тулы, Америкадагы кыерсытылган халыклар газабын, көрәшен чагылдырган романнарын—әйтик, хәтерлим, оныта алмыйм, "Ак юлбашчы", "Квартеронка", "Семиноллар юлбашчысы Оцеола", бигрәк тә "Башсыз җайдак" әсәрләре белән бергә, "Большая Советская Энциклопедия" дәрьясында балыктай гизәм. Шушы чакта ук сыйныфташларым мине Габделәхәт ясә Әхәт диясе урынга Гаффар дип кенә йөртәләр иде инде. Укый, пытамушты, җитмәсә, яза да әле тагын. Стена (исеме ни тора!) гәзитенең алыштыргысыз мөхәррире, район гәзитенең иң күп язучысы—эшче-крәстиян корреспонтенты булып саналу, ахыр килеп, танылу—уен эшмени! Әнә ич: вакыты-вакыты белән яуган игелекле яңгыр шикелле, гонорарлары ишелепләр килә тора: сиксән, туксан тиеннән алып кайчакны өч, биш сумга кадәрле! Бер айга. Бу инде ул вакытта Әмерикән язучысы Джек Лондонның (аны күп укыдым) Клондайкта бер алтын кисәгенә тап булуы белән тәңгәл гамәл иде! Хәтерлим: ничектер шулай, сигезенче сыйныфта чакта бугай, "Үсә республикам Татарстан" дигән бер шигырем Питрәч район газитендә басылгач, Олы Әшнәктәге әдәбият укытучыбыз Мингалим абыйның дәрескә кереп:

—Күрдегезме, балалар? Габделәхәт шагыйрь булган,—дип, миңа тоелганча, астыртын елмаюы маңгаема салкын тир тамчылары булып чәчрәп кунган иде. Моңа карамастан, Африкадагы Конгоны үз кочагына алырга ниятләгән "җәбер" Чомбеның тетмәсен тетеп, Әмерике "янки"ларының үнәченә ябышып, тагын бер "шигырь" чыгарам.

—Кем ул Чомбе?—дип сорасам, хәзер сезнең аптырап калуыгызны сизеп, күреп торган шикелле булам. Өстәп тагын бер сорау биримме?

—Аның исеме нинди?

Җавапсыз калуыгызга иманым камил. Ә мин беләм, канга сеңгән:

—Морис.

Тагын өстим әле. Казандагы бер урам исеменә тагылган Лумумба кем ул?

—Ә ул әлеге Морис Чомбе үтерттергән Патрис Лулумба була инде.

Карасана, ә? Ачлы-туклы яшәп, уналты яшемдә үк Африка халыкларының колонизаторлар хакимиятеннән котылуы хакына җан атып торганмын бит, бичара!

... Шулай бер заманны әлеге Олы Солтан урта мәктәбе китапханәсендә: "Тагын ни укыйм икән инде?"—дип актарынган чагымда мин юка гына бер әйбергә юлыктым. Юлыктым да, утка баскандай, интернатыбыз бүлмәсенә алып кердем.

Бу—кульязма журнал иде. Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Мидхәт Миншин, Рәшит Гарипов, Давыт Сөнгатов... шигырьләре. Шулар үрнәгенә ярдем дә киттем бит, әй!

Тагын берәүне искәрим әле. Ул—Вакыйф Нуруллин. Иң өлкән апабыз—хәзер инде әниебез урынына калган Әлфия апабыз белән шушы ук Олы Солтан урта мәктәбенә аягына чабата киеп, аркасына бәрәнге кушып пешерелгән ипиен биштәрләп күтәреп йөргән егет күршедәге Зәңгәрле (Югары Әшнәк) авылы егете. Нишләгән? "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналында үзенең бик кызыклы "Шинельсез солдатлар" дигән повестен чыгарттырган. Шуны күргәнмен, укыганмын да:

—Мин дә язам!—дигәнмен.

Шуны язмаса, мин менә хәзер, шушы—төнге сәгать өчтә бу юлларны сырлап маташырга дучар булыр идеммени?! Өстәп, нәкъ менә шушы "җәбер" сөлектәй егет чагымда миңа "СССР Язучылар союзы" әгъзалыгына кабул итү тәкъдимен дә язып бирде бит. "Үзем генә язу тәмугында азапланып ятмыйм, күрсен әле күрмешен!"—дигәндер инде. Гази ага Кашшаф, Рафаэль Мостафин белән бергә, ул минем язмышымны үзгәртте дә куйды.

Боларга Илгиз Хәйруллинны да өстәргә кирәк.

Урта мәктәпне тәмам иткәнем соңында—инде авылда калырмын (әти—вафат, әнигә авыр, ике энекәш мәктәптә укый, апалар кияүдә—очкан-киткән кошлар) абый—студент, берсе—читтә дигәндә, 1966 елның июль аенда "Уфалла"мнан аерып, мине Комсомолның Балык Бистәсе район комитетына дәшеп алдылар. Үзе какча, йөзе сипкелле, җирән чәчле беренче секретарь Фролов миңа:

—Сине, Гаффаров, үзебезгә инструктор итеп алырга дигән карарга килдек. Иртәгә обкомга собеседованиегә барып кайт,—диде.

Бардым. Таптым. Чибәр генә бер абый минем белән "собеседование" үткәрде. Икенче көнне райкомга барсам, теге Фролов әйтте:

—Без башка кандидатурага тукталырга карар иттек инде, иптәш Гаффаров,—диде.

Күрәсең, теге "обком" мине ошатмагандыр инде: киемем—крәстиянча гына, ә сөйләшүем—урысча түгел бит. Мин—тере урысны сагынганда бер генә дигәндәй күргән малай ич. Монда синең, әйтик, "Большая Советская Энциклопедия" укып йөргән "гыйлеме иясе" икәнең ярдәмче түгел.

Шуннан соңгы гарьләнүемме?!

Әнигә:

—Мин укырга барам!—дидем.

—Кая?

—Университетка.

—Кая-кая?—диде әни, аптырап.

—Университетка.

—Суң, улым, анда сине кем кертсен? Анда Зәңгәрле авылыннан пыркарур Мәхмүт Әхмәтшин гына укыды.

—Икенчесе мин булырмын, әни!

Җыен язганнарымны туплап, көрнәп, каптырмага каптырдым да шул июльнең егерме тугызында журналистлар бүлегенә илтеп бирдем. Авылга кире кайтып, тагын китеп барып, беренче август алдыннан тулай торакка урнаштым да имтихан тотарга керештем. Беренчесе инша иде.

—Писать по-русски,—дип куштылар.

Ә мин, акыллы баш, житмешме, туксанмы (хәтерләмим инде) егет-кыз арасыннан саф татарча фикерләп койганмын да татарча язып куйганмын!

Тарихтан имтиханга кергәч, йөзтүбән яткан бер билетны ("Триумфальное шествие Советской власти", "Восстание Ивана Болотникова"—менә хәтер, ә?) алып, күз ташлау белән:

—Отвечать мужны?—дип сорадым.

—Утырыгыз,—диделәр.

—Ә, абый. Сез—татар икәнсез. Шуңа күрә мин дә татарча сөйлим әле.

—Почему?

—Урысча сөйләсәм, сез миңа "өчле" куярсыз. Ә миңа "бишле" кирәк.

Керфек тә какмыйча, чытырдатып татарча сөйләп бирдем. "Дүртле" куеп чыгардылар.

... Ә аннары остазым Гази Кашшаф минем Муса Җәлил иҗаты турындагы курс эшләремне укып та тормый иде инде. Ул:

—Булган бу, Гаффар,—дип кенә куя иде.

Тулай торакта Клара Булатовадыр, Зөлфәттер, Мөдәррис Әгъләм, Марсель Галиев, Рәзил Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиевтер белән ләчтит сатмыйча, көнетөне укыгач, язгач, Гази ага мин фәкыйрьнең кемлеген, кем булу ихтималын, авырткан аягының һава үзгәрешен сизеп торуы шикелле, сизгер чамалагандыр инде, күрәсең.

Егерме биш яшем тулып җиткәч, мине, бик тиз генә, СССР Язучылар союзы дигән аратага кертеп куйдылар. Ул чорда шартлар бик катгый иде: кимендә ике китап иясе булуың кирәк. Шунсыз якын да җибәрмиләр. Бәхетемә, 1973 елны гайрәтле Барлас ага Камалов очрап (чәчмә әсәрләр бүлеге мөдире), ни арада язучыларны җыеп, кульязмамны тикшерү үткәрде, аны нәшриятка тәкъдим иттерде. Инде дә әлеге "Әҗәт" китабы дөнья күргәч, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф ага Ахунов 1975 ел җәендә идарәсен җыеп, мин бәләкәй көймәне иҗат, әдәбият дигән олы дәрьяга кертеп җибәрделәр. Хәсән ага Туфан, Гомәр ага Бәширов, Гази ага Кашшаф, Хәсән ага Сарьян, Вакыйф абый Нуруллин, Рафаэль абый Мостафин кебек олуг шәхесләр мин—яшь әтәчнең кикриген кәперәйттеләр дә куйдылар...

Инде менә СССР булып СССР гаип булды. Шуннан соң аның газиз бер баласы—СССР Язучылар берлеге дә таралды. Хәзер барчабызның хәл кадәри үз Казаныбызда гына кайнашып ятмышыбыз. Әрмән, бурят, якут, грузин, эстон, латыш, украин, молдаван, чуваш... язучыларыннан, күпме каләмдәш-дусларыбыздан мәхрүм калдык.

Мәскәүдә урысча өченче китабым нәшер ителеп, инде дөньяның тугыз төп чит илләр телләрендә әсәрләрем тәрҗемә ителгәч, "Долг" дигән китабым өчен Максим Горький исемендәге яшьләр премиясе алгач, "Советский писатель" нәшриятындагы СССР халыклары әдәбияты редакциясенең баш мөхәррире эстон Арнольд Освальдович Тамм белән гомерлек дустым, язучы, тәрҗемәчем Җәмил ага Мостафин миңа:

—Мы из тебя второго Чингиза Айтматова сделаем,—дигәннәр иде.

—Мне второго не надо. Раз уж на то пошло, сделайте из меня первого Ахата Гаффара,—дип җавап кайтардым.

Ә хәзер мин үземнең мененче... йөз мененче, җыйнак кына буй-сынлы, тик Мөхәммәтгаяз Исхакыйның мыегыннан да мулрак мыеклы бер... җүләр икәнемне беләм инде.

Кеше череп баеганда череп хәерчеләнеп ятар өчен төннәр буена йокы күрмичә каләм тирбәтүне мин фәкать кояш баеганнан соң сайрарга тотынган сандугач моңына гына алмаштыра аламдыр шикелле.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Марсель Зарипов

# ГЕНЕРАЛ БУЛУ РӘХӘТМЕ?

*Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, язучы-публицист Марсель Зарипов, ничәмә дистә еллар буена нефть осталары белән аралашып туплаган зур тормыш тәҗрибәсенә таянып, Татарстан нефтьчеләренең эш-гамәлләренә багышланган зур күләмле документаль китап язды. Ул хезмәт җөмһүриятебездәге атаклы Ромашкино нефть ятмалары ачылуга илле ел тулган көннәрдә—1998 елның көзендә Мәскәүнең "ИП РадиоСофт" нәшриятында ике том булып, урыс телендә "Черное сокровище" дигән исем белән басылып та чыкты.*

*"Казан утлары" журналының Татарстан нефтьчеләре белән әдәби-мәдәни бәйләнешләре бик күптәннән—җөмһүриятебездә нефть чыгарыла башлаганнан бирле килә. Марсель Зариповның әлеге саллы хезмәтеннән байтак кына бүлекләре белән журналыбыз укучылары танышкан иде инде ("Яшел чишмәләр". NN 7, 9.—1997; "Иван Губкинның тантанасы һәм фаҗигасе". N 3.—1998; "Кара май"ның калҗасы". N 5.—1998).*

*Журналыбызның бу санында без М.Зариповның шул китабыннан Татарстан нефте җитәкчеләренә багышланган бүлеген тәкъдим итәбез.*

*Нефтьчеләр аларны хөрмәтләп, "безнең генераллар" дип йөртәләр. Татарстан нефте тарихында алар җидәү булды. Җиденчесе—бүген дә шул хезмәттәгесе—"Татнефть" акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат Галиев. Быел гыйнвар аенда Ринат Галиевкә алтмыш яшь тулды. Без аны олуг юбилее белән ихластан котлыйбыз һәм игелекле, авыр хезмәтендә уңышлар телибез!*

*Язманың журнал варианты*
*Марс ШАБАЕВ*
*иректле тәрҗемәсендә бирелә.*

* * *

*Хаким, булса синдә акыл һәм белек,*
*Исеңдә тот фикер: улдыр игелек.*
*Бу игелек сине дан юлга салыр,*
*Башыңызга олуглык таҗы сарыр.*

Мөхәммәдьяр,
XVI йөз татар шагыйре.

ТАТАРСТАН нефте табылуның илле еллык юбилеен җөмһүриятебез шаулатып-гөрләтеп бәйрәм иткән көннәрдә без "нефть генералларыбызны" янә бер кат рәхмәт хисләре белән искә төшердек. Алар, төнге күктәге Җидегән йолдыз кебек, нефть сәнәгате тарихында һәрвакыт янып-балкып, башкаларга юл күрсәтеп торырлык олуг шәхесләр, күренекле җитәкчеләр булдылар. Җидегән йолдыздай җиде генерал... Әйе, әйе,

нефтьчеләр аларны яратып, хөрмәт белән шулай "генералларыбыз" дип атап йөртә.

Кемнәр соң алар—Татарстан нефтенең беренче генераллары? Алар—Алексей Шмарев, Валентин Шашин, Рәфкать Мингәрәев, Әгъзам Вәлиханов, Ришат Булгаков, Әкълим Мөхәммәтҗанов һәм Ринат Галиев.

Салават күперенең җиде төсе шикелле, җидесе җиде төрле холык-табигатьле, төс-кыяфәтләре белән дә бер-берсенә һич охшамаган, һәркайсының үз гадәтләре, үз рухи дөньясы булган бу җиделекнең һәрберсе белән таныш идем мин. Журналистлык-язучылык хезмәтемнең күпчелек өлеше Татарстан нефте һәм нефтьчеләренә багышланган булгач, мин бу күренекле шәхесләр турында үз вакытында аз язмадым шикелле. Ә шулай да күңелне һаман ниндидер канәгатьсезлек тырнап-бимазалап тора иде. Язарга иде бит алар турында тәфсиллерәк аерым бер китап!

Әлегә журнал битләрендә җиде нефть генералының беренче алтысы турында йөгертебрәк узып, җиденче генерал—үзенә төшкән авыр вазифаны бүген башкаручы Ринат Галиев турында күбрәк сөйләсәм, укучылар гафу итәрләр дип уйлыйм. Чөнки...

Чөнки, беренчедән, Татарстан нефте һәм нефтьчеләренең бүгенге хәле бик җитди һәм катлаулы, кичекмәстән хәл итәлергә тиешле мәсьәләләр баштан ашкан. Болар һәммәсе Ринат Галиевнең йөрәгә аша уза. Икенчедән... Хәер, "икенчедән"ен әлегә кузгатмый торыйк, вакыты җиткәч, әйтербез.

Татарстан нефтенең язмышы "Татнефть" берләшмәсе кулында. Берләшмә 1950 елда оештырылып, ул хәзер—базар икътисады шартларында—акционерлык җәмгыяте булып әверелде.

"Татнефть"нең беренче генераллары Алексей Шмарев белән Валентин Шашин урыслар иде. Башка тел, башка кан, башка милли холык-табигать булса да, болар Татарстан җирендә бик тиз үз кеше булып киттеләр. Җирле халык арасында да, "җир мае" исен сизеп төрле тарафлардан җыелган башка төрле кавемнәр арасында да ышаныч казандылар алар. Нефть эше республикабыз халкы өчен әлегәчә күрелмәгән яңа бер эш-шөгыль иде. Ил-дәүләт икътисады өчен бик тә мөһим-әһәмиятле бу олуг эш Идел-Урал киңлекләренә таралып утырган төрле милләт халыкларының—татарлар, башкортлар, марилар, чуашлар, удмуртлар, урыслар һәм башкаларның да язмышларына зур йогынты ясаячак иде. Татарстанның үзендә нефть осталары булмаганлыктан, бу эшне нәкъ менә өтиләре дә нефтьче булган Алексей Шмарев белән Валентин Шашин башлап җибәрделәр. Аннары килеп, инде ун елдан соң, үз милләттәшләребез "Татнефть"нең командирлары булып өлгереп җиттеләр.

Рәфкать Мингәрәев нефть эшенә Урта Азия якларында өйрәнгән, Татарстанга ул Мәскәү нефть институтының аспирантурасыннан килгән иде. Әгъзам Вәлиханов белән Ришат Булгаков—Башкортстаннан, ә инде Әкълим Мөхәммәтҗанов белән Ринат Галиев төп үзебезнекеләр, тирә-ягын нефть манаралары урап алган татар авылында үсеп, канат ярган кешеләр.

Нефть эшендә шулай: булдыклы-уңган булсаң, тиз арада иң биек урыннарга күтәреләсең, әмма чик-чамасын белмәсәң, бик тиз генә тәгәрәп төшүең дә ихтимал.

Ярты гасыр гомер—кешеләр өчен шактый зур вакыт, тарих өчен ул бер мизгел генәдер. Бу вакыт эчендә кешеләр һәрьяктан сынала, танылa ала. Шул җәһәттән карaганда, Татарстан нефте командирларының берсе дә үз намусына тап төшермәде, эш урыныннан явызларча файдаланмады, урлашмады, ришвәт алмады, борын күтәреп, тәкәбберләнеп йөрмәде. Боларның һәрберсе башка эшкә күчкәндә янә дә югарырак урыннарга үрләделәр, үз җилкәләренә ил-дәүләтнең тагын да авыррак йөкләрен күтәрделәр. Валентин Шашин СССРның нефть сәнәгате

министры булды. Алексей Шмарев, Рәфкать Мингәрәев, Әгъзам Вәлиханов, Әкълим Мөхәммәтҗановлар үз чиратларында геология һәм нефть министрлыкларында министр урынбасарлары йөген тарттылар. Ришат Булгаковка исә Көнбатыш Себер нефть промыселларын өзеклектән чыгару кебек авыр бурыч йөкләтелде.

Җиде шәхес, җиде язмыш...

Алар барысы да чын мәгънәсендә талантлы командирлар—асыл һөнәрмәннәр булдылар.

Инде хәзер "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат Галиевкә йөкнең иң авыры төште. Нефть сәнәгатендәге чиктән тыш зур кыенлыкларга илдәге социаль һәм сәяси вәзгыятьнең гаять болгавыр-буталчык булуы, кыргый базар икътисадындагы берниндн калыпка сыймый торган аңлаешсыз мөнәсәбәтләр дә килеп өстәлде.

Әйе, "Татнефть" берләшмәсе җөмһүриятебезнең җир куенында "кара май" ятмаларының шактый бай булуын ачыклагач оешкан иде.

Татарстан нефтенең беренче генералы Алексей Шмарев безгә килгәнче Грозный һәм Башкортстан нефть промыселларында чыныгу алган кеше иде. Нефть сәнәгатенең галәмәт зур көпчәген әйләндереп, хәрәкәткә китереп, оештыру эшләрен башлап җибәрү аның өлешенә туры килде. Ничек кизәнсәң, шулай сугарсың, диләр. Җәяңне никадәр киереп тартсаң, угың да шулкадәр ераккарак очар, дигәне дә бар әле. А.Шмаревның ихтыяры һәм тырышлыгы белән эшләп киткән нефть гиганты—"Татнефть" берләшмәсе ил-дәүләтнең сугыштан соңгы сәнәгате елъязмасында Магнитка һәм Днепрогэс, Байкал-Амур магистрале һәм Кама автогиганты кебекләргә тиң бер казаныш иде.

Алексей Шмарев, күрәсең, чегән каны уйнагандыр, юкса, кара чутыр йөзле бу кеше шулкадәр тиз кабынып китүчән, кырыс һәм кискен холыклы булмас иде. Шул ук вакытта ул гаҗәеп түзем, башкаларның борчу-кайгыларына искиткеч сизгер, һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торыр иде. Бөгелмәдә (ул вакытта Әлмәт шәһәре юк иде әле) ул ике катлы бер йортта, гап-гади квартирада яшәде. Озакламый Никита Хрущевның төрле тайпылышлары башланды, министрлыклар урынына совнархозлар оештырылды. Бу вакытта нефть җөмһүриятебез икътисадының төп тармагы булып өлгергән иде инде. Татарстан совнархозына җитәкчелек итүне нефть генералы Алексей Шмаревка тапшырдылар. Ул "Татнефть"тә нибары биш ел гына эшләп калды, ә никадәрле эш башкарды!

Алексей Шмарев башлап җибәргән эшне Валентин Шашин дәвам итте. Ул җитәкчелек иткән чорда "Татнефть" офыкларын киңәйтте, Татарстан якларын бар дөньяда ныклап "Икенче Баку" дип йөртә башладылар. Әмма сәләтле Валентин Шашинны да Мәскәү үзенә кирәкле санады: аны тиздән СССРның нефть сәнәгате министры итеп билгеләделәр.

Валентин Шашиннан соң "Татнефть"нең командиры Рәфкать Мингәрәев булды. Аның вакытында атаклы "Ромашкино пирогы"н үзләштерү эшендә күрелмәгән революцион алымнар кулланылды, Баулы тирәсендәге ятмаларда скважиналарның яртысын ябып, алар өлешен чыгару-суыртуда кыю тәҗрибә үткәрелде. Бу җитәкче башлаган күп кенә эш-гамәлләр, идея-фикерләр бүген дә нефтьчеләргә хезмәт итә, ул салып калдырган фәнни һәм гамәли җегәр шундый көчкә ия булып чыкты. Р.Мингәрәевне дә Татарстанда озак тотмадылар, аның тирән фәнни белеме кирәк булгандыр—үзен Мәскәүгә министр урынбасары итеп күтәрделәр.

Татарстан нефтенең СССР күләмендә беренче урынга чыгып, иң тантаналы-шатлыклы чорында "Татнефть"нең капитан күперчегендә Әгъзам Вәлиханов торды. Нефть ятмаларын эшкәртүдә кирәкле барлык чаралар—"кара май" запасларын эзләү, скважиналар бораулаудан башлап фәнни тикшеренүләр, алынган нефтьне эшкәртеп, чит илләргә озатуларга кадәр—барысы да аның җитәкчелегендә эшләнде. Бу чорда әле бер генә илдә дә кулланылмаган яңа алым—барлык көчләрне бер төбәккә

туплап, мөмкин кадәр тизрәк һәм күбрәк нефть алу ысулы тормышка ашырылды. Татарстан елына бер йөз миллион тоннадан артык "җир мае" чыгара башлады. Барлык мәйданы СССРның ярты проценты җирен дә тәшкил итмәгән кечкенә җөмһүриятебез илдә чыгарыла торган нефтьнең өчтән берен бирү кодрәтенә иреште.

Әгъзам Вәлихановка алмашка "Татнефть"кә җитәкче булып Ришат Булгаков килде.

Бер генә тармакта да эш һаман да уңышлардан гына тормый. Күтәрелүләрдән соң төшүләр була. Зур нефть фонтаннары заманы үткән, җиңел алына торган ятмалардагы "җир мае" суыртылып беткән, җиде ел дәвамында йөзәр миллион тонна нефть биреп килгән промыселлар табигый рәвештә ярлыланып калган иде. Ә нефтькә ихтыяҗ зур. Мәскәү: "Бир! Бир! Бир!"—дип кенә тора. Бу бик йончыта, бигрәк тә психологик яктан изә. "Кара май" чыгаруны киметмәү, туктатып булмаслык һәлакәткә җиткермәү өчен икеләтә-өчләтә күбрәк тир түгәргә туры килә. Күз алдына китерегез: нефть алу кими башлаган беренче елда ук 12442 скважина көне-төне "җир мае" суыртырга мәҗбүр булды. Бу сан беренче мәртәбә йөз миллион тонна нефть алган елдагыдан 4351 скважинага артык иде. Скважиналар саны арта, эш күләме арта, ә нефть һаман кими бара...

Бу вакытта, Татарстан һәм башка төбәкләрдәге нефть промыселларыннан тыш, инде Көнбатыш Себер нефть ятмалары да ачылган һәм эшкәртелә башлаган иде. Ришат Булгаковны шунда күчерделәр. Үзен генә түгел, Татарстан нефтьчеләре анда вахта ысулы белән йөреп нефть суырта башладылар.

"Татнефть" берләшмәсенә җитәкчелек итү бу чорда Әгълим Мөхәммәтҗановка тапшырылды. Ул бу йөкне ун ел буе тартты. Илнең төрле төбәкләрендә вахта ысулы белән эшләү яңалык булып тоелса да, ул безнең өчен генә шулай иде. Дөнья күләмендә бу ысул гадәти хәл санала. Америка нефтьчеләре, мәсәлән, Техас, Луизиана, Аклахома, Калифорния штатларында яшиләр, ә эшкә меңнәрчә чакрымнарга—Аляска, Африка, Иран, Гыйрак, Сәгуд Гарәбстаны кебек җирләргә йөриләр. Нишләмәк кирәк, нефтькә ихтыяҗ арткannan-арта бара. Башта Татарстан нефтьчеләре Себергә скважиналар бораукларга гына йөрделәр. Алар Минзәләдән, Баулыдан, Лениногорскидан, Азнакайдан, Актүбәдән самолетлар белән бара-кайта очып йөрергә мәҗбүр иделәр. Әмма борауланган скважиналар саны ишәя, ә алардан нефть суыртуны җайлау-көйләү эшләре тоткарлана килә. Шуннан соң "Татнефть" берләшмәсе карамагына Лангепас тирәләрендәге ятмаларны тулысы белән тапшырдылар: нефть суырту өчен кирәкле барлык гамәлләрне үзләренә башкарырга калды.

Шул рәвешле, икегә өзелеп эшләргә—Татарстанда нефть чыгаруны да киметмәскә, Себердә дә җитештерүчәнлекне арттыра барырга кирәк иде. Вахталар алмашлап эшли: ике атна Себердә, ике атна өйдә. Ә җитәкчеләр икеләтә-өчләтә җигелергә тиеш—тегендә дә булырга кирәк, монда да... Гаиләләрне сирәк әләгә торган бәйрәм көннәрендә генә күрергә кала иде.

Тырыша-тырмаша торгач, Татарстан нефтьчеләре яңадан да әлек яуланган биеклеккә күтәрелделәр диярге була. 1990 елда 34 миллион тонна нефть Татарстан скважиналарыннан, 26 миллион тоннасы Себер ятмаларыннан алынды. "Татнефть"нең зур уңышы иде бу!

* * *

КЕШЕЛӘРНЕҢ тормыш юлы туп-туры, төп-төз сызылган юл түгел. Һәркемнең үз җиңүләре, үз табышлары булган кебек, хаталары, югалтулары да була. Без яшьрәк чакта эстрада җырчысы Вадим Мулерман тыпырдый-тыпырдый җырлый иде:

*Как хорошо быть генералом,*
*Как хорошо быть генералом!*
*Лучшей работы я вам, сеньоры, не назову!*

Хәзер минә уйлыйм: генерал булу, чыннан да, рәхәтме икән? Үзем күргән-ишеткәннәрдән бер-ике гыйбрәтле мисал.

Ришат Булгаков кешеләрнең фикерләрендә тәгәллек булуны ярата иде. Бервакыт, ул әле "Әлмәтнефть" идарәсе башлыгы булып эшләгән, идарә нефтьчеләре Бакуга караганда ике мәртәбә артык—елына кырык миллион тоннан "җир мае" алган заманда, аның "Комсомольская правда" газеты хәбәрчесенә, ачылып китеп, зарланып утырганын хәтерлим. "Ярты вакытым кирәкмәгән кәгазьләр укып үтә. Һәммәсе дә миңа—җитәкчегә кәгазь ташый. Әгәр дә шушы эшне үз җилкәсенә алып, мине бу кәгазь боткасыннан коткарырлык рәтле-эшлекле бер секретарь табылса, валлаһи, өч бүлмәле фатир бирер идем үзенә!"—дип ычкындырып ташлады бу. Хәбәрче Жан Миндубаев шундый отышлы мизгелне ычкындырамы соң инде? Ришат Булгаковның бу сүзләрен газет битләрендә бөтен илгә тарата. Р.Булгаков исеменә хатлар ява башлый: Сахалиннан да, Брест-Литовскидан да, Нарьян-Мардан да, Сочидан да, дигәндәй... Менә шуннан соң инде "генералыбыз" һәрвакыт төгәл булуны, үз фикерләрен бозмауны таләп итә торган булып китте.

Валентин Шашин турында шундый бер мәзәгрәк вакыйга сөйлиләр. Моның инде Мәскәүдә нефть министры булып эшләгән чагы икән. Ничектер шулай үзенең дуслары-фикердәшләре булган нефть командирлары белән ауга киткәннәр болар—куян куарга, очраса, кабан атарга яки бүре-фәлән куркытырга, янәсе. Кыскасы, бер җилләнеп кайтырга. Ярый, киткәннәр... Йөри торгач, адашканнар бит! Төн җиткән. Нишләргә? Басудагы бер салам кибәненә чумып йокларга уйлаганнар. Учак та ягып җибәргәннәр. Утны күрепме, болар янына машинасында колхоз рәисе килеп җиткән. Килә-килешкә тузына башлаган: фәлән-фәсмәтән, сез кемнәр? Әйдәгез милициягә, имеш! Бик күңелсез хәл бит. Министрның салам кибәнендә йоклап ятканын белсәләр, ә?! Шул вакыт Валентин Шашин усал рәисне бер читкәрәк алып китеп сөйләшә башлый. Бераздан кибән хуҗасы аучылар янына килеп: "Шоферыгызга рәхмәт әйтегез! Ярар инде..."—дип китеп тә бара.

Ринат Галиевкә кадәрле эшләгән алты генералның берсе дә пенсия яшенә җиткәнче үз урынында утыра алмады. Әз генә эшләре күренә башладымы, йолкып алалар да башкалага алып китәләр иде. Туфрагыннан тамыры-ние белән йолкып алынган гөл шикелле, вакытыннан алда шиңделәр дә алар: йә инфаркт, йә инсульт, йә башкасы шунда... Шмарев алтмыш бише тулганчы дөнья куйды, Шашин—алтмыш бердә, әле пенсиясен дә юллап өлгермәгән иде, бахыр... Булгаковка нибары илле җиде генә иде... Мингәрәев тә яшьли китте...

Татарстан нефте генералларының элеккеләреннән Әгъзам Вәлиханов белән Әкълим Мөхәммәтҗанов кына исән-саулар. Социалистик Хезмәт герое, элекке союз министры урынбасары Ә.Вәлиханов картлыгын үткәрергә ыгы-зыгылы Мәскәүдә яшәп калды. Ә.Мөхәммәтҗанов, шулай ук элекке министр урынбасары, үзебезнең якларда яшәп ята—лаеклы ялда.

Илле ел эчендә "Татнефть" берләшмәсе башында торган җиде генералның әлеге алтысы турында сөйләр сүзләребез күп булса да, тукталып торыйк. Хәзергә алты генералның хөкүмәт бүләкләрен санап чыгу белән генә чикләнәбез.

Алексей Шмаревның күкрәгендә Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Почет билгесе орденнары һәм берничә медаль балкыса, Валентин Шашинның Ленин орденнары дүртәү, бер Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бар иде. Шуның өстенә ул Ленин премиясе лауреаты да булды. Рәфкать Мингәрәев тә Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры, Ленин премиясе лауреаты иде. Әкълим Мөхәммәтҗанов

бәйрәм көннәрендә түшенә Ленин, Октябрь революциясе һәм ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары тагып чыкса, Әгъзам Вәлиханов белән Ришат Булгаковларның түшендә Социалистик Хезмәт Герое Алтын Йолдызы балкыр иде.

Менә шулай. Хезмәт фронты генераллары гына димәссең, әйтерсең, сугышчан маршаллар! Шагыйрь хаклы: сугыш өчен дә, хезмәт өчен дә орден-медальләрне бер металлдан коялар.

* * *

БҮГЕНГЕ нефть генералы Ринат Галиев, мөгаен, иң кыен язмышлы шөхестер. Михаил Горбачевның "үзгәртеп кору чоры" дигәне Борис Ельцинның реформалары белән буталып, ил-дәүләтнең асты—өскә килде.

Болай да инде унтугыз ел дәвамында "Татнефть"нең эшләре һаман түбән тәгәри иде, хәзер бөтенләй харап... СССР дигән ил-дәүләт таркалды, элекке кануннар коелып төште, "ил корабын җил сөрә": ул әле уңга, әле сулга янтая—төпсез упкынга чумармы, үзе дә юньләп белмәгән юлдан берәр ярга барып чыгармы?—белгән юк...

Россиянең нефть сәнәгате булган барлык төбәкләрендә дә эшләр хөрти: нефть җитештерү елдан-ел кими. Ил икътисады белгенлектә. Ә нефть—төп байлыкларның берсе. Әле кайчан гына КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы ил нефтьчеләре алдына елына 500-600 миллион тонна нефть алу бурычын куйган иде. Куйган иде...

Хәзер барысы да җимерелә, алар урынына хосусыйлаштырылган-фәлән ителгән әллә ничә төрле ярымхосусый, ярымдәүләти нефть-газ компанияләре калкып чыкты. "Главтюменьнефтегаз" дигән галәмәт монстр берничә мөстәкыйль фирмага бүлгәләнде. Себердәге Лангепас, Урай, Кагалым нефть ятмалары "ЛУКойл" кулына күчте. "Сиданко", "Сургутнефтегаз", "Мегионнефтегаз", "Сибнефть" кебек төрле компанияләр һәркайсы үз "көймәсендә" ирекле базар икътисадына таба юл алды. Кыргый базар диңгезенең давылларында аерым-аерым йөзүе тагын да кыенрак булып чыкты. 1995 елда Себер промыселлары элек бирә торган нефтьнең яртысын гына бирә алдылар. Россиянең барлык нефть компанияләренең дә "җир мае" чыгарулары кимеде, табыш ала алмадылар.

Әмма алар арасында "Татнефть" акционерлык җәмгыяте юк иде. Барлык нефть төбәкләрендә хәл бер төсле, һәммәсе дә бер үк гомуми базар шартларында эшли, ә "Татнефть"нең эш нәтиҗәләре уңай: бер елга шактый гына үсеш бар. Төгәл саннарга күчереп исәпләгәндә, өстәмә бер миллион ярым тонна нефть дигән сүз бу. Менә шундый табышмак! Татарстанда Ромашкино ятмалары шикелле бай яңа ятмалар да табылмады югыйсә, уннарча-йөзләрчә скважинаны алыштырырлык бер бәхетле скважина да бораууланмады, геологик хәлләр дә үзгәрешсез иде. Сер-хикмәт нәрсәдә соң? Димәк, кешеләрдә. Алар табигый каршылыкларны җиңәргә сәләтле. Димәк, унтугыз ел буе кимеп барган "җир мае" кимүен туктату өчен нефтьчеләрнең тырышлыгын җыгә белерлек җитәкче кирәк булган. Яңа генераль директор Ринат Галиев шундый җитәкче, димәк.

Атны—юл, җайдакны ияр сыный, диләр.

1995 елда Татарстан нефтьчеләре нефть алуны ике миллион тоннага арттырдылар. "Булдырдыгыз, афәрин!"—дип кул чабарга гына кирәк иде дә...

Әмма дан-мактаулар урынына аңлашылмас буталчык бер хәл көткән булып чыкты. Борис Ельцин командасы оештырган ВЧК (Всероссийская Чрезвычайная Комиссия—татарча Бөтенроссия Гадәттән тыш Комиссиясе буладыр инде) дигән нәмәрсә бөтен дөньяга ишетелерлек гауга куптарды: имеш, "Татнефть" банкротлык алдында тора, имеш, куәте белән Россиядәге ягулык-энергетика комплексында

дүртенче урындагы бу предприятие, базар мөнәсәбәтләре кагыйдәләре таләп иткәнчә, аукционга куелып сатылачак икән. Чубайс, Березовский кебек "акча капчыклары", әйдәгез, ябырылыгыз! Алып калырга ашыгыгыз! Менә шундый зур җәнҗал кубардылар кубаруын, әмма соңыннан моның уйдырма икәнлеге, кемнәрдер оештырган әшәке ялган булуы ачыкланды.

Ринат Галиевнең башына күсәк белән сугуга тиң эш иде бу. Дәүләт башында утыручы хәзерге түрәләр, ниндидер "акча капчыкларына" сатылып, явызларча эшләнгән бу гамәлнең "Татнефть"кә китергән зыяны өчен кем җавап бирергә тиешле? Себердәге "ЛУКойл" дәүләт бюджетына өч триллион сум чамасы (иске акча белән), "ЮКОС" алты триллион сум чамасы бурычлары белән дә банкрот түгел, ә нибары алтмыш сигез миллиард бурычы булган (анысы да шикле әле) "Татнефть" банкротмы? Дөнья базарына чыгып сәүдә итә башлаган нефтьчеләребез абруена шундый кара күләгә төшергән кемнәрдер бу зыянны ничек капларлар икән? Базар шартларында фирма намусы, аның абруй-дәрәҗәле исеме— иң кыйммәтле капитал ул. Хәзер Ринат Галиев үзенең партнерлары белән ничек аралашырга, эш йөртергә тиеш булыр? Әйтик, хөкүмәт җаваплылыкны үз өстенә алмаган хәлдә дә, бары тик генераль директор Ринат Галиевнең намуслы булуына ышанып, "Татнефть"кә җитмеш биш миллион долларлык кредит ачкан "Дрезднер-банк" (Германия) финансчыларына ничек итеп аңлатырга бу әшәкелекнең асылын? Нефтьчеләрдә артык акча юк. "Нефтедолларлар яңгыр булып ява" дигән әкиятләргә беркем дә ышанмас. Ике дистәдән артык һәр төрле коточкыч салымнар, саткан нефтеңә акча ала алмаулар шундый чиккә китереп тери ки, хезмәт хакы түләргә дә бурычка керергә туры килә. "Татнефть" акцияләре дөнья базарына чыгып, әйләнешкә кергән, уңай нәтиҗәләре күренә башлаган бер вакытта гына шундый этлек эшләсеннәр әле! Гомер-гомердән Татарстанны сөйкемсез сәяк итеп күрергә гадәтләнгән Мәскәү түрәләренең бик астыртын-мәкерле бу эше өчен кемнәргә күпме түләнде икән?

Әле бит сәүдә-коммерциядән тыш әхлакый ягы да бар моның. Ринат Галиев—Татарстанның Дәүләт Советы депутаты. Депутатлык гомерлек дәрәҗә түгел, яңа сайлаулар килеп җитәр, мандат өчен көрәш-ярыш зур булыр. Галиевнең көндәшләре бу банкротлык гаугасын казып чыгарырлар, хәзерге болгавыр замандагы башка кыенлыкларны да исәпкә алырлар: кыскартылган эш атналары бар, эшчеләргә әбәт өчен түләүләр бетерелде, пенсионерларга өстәмәләр бик аз, санаторий-профилакторийларга элек бушлай бирелә торган юлламалар бик кыйммәт...

Бу ялган банкротлык җәнҗалы китереп чыгарган зыянны үземчә мин дә исәпләп карадым: минемчә, "Татнефть"нең юридик хезмәт күрсәтү бүлеге гаеплеләргә йөз кырык мең акционерлары исеменнән биш йөз миллиард сумлык дәгъва белдерә алыр иде. КамАЗны да үз вакытында шулай банкротлыкка чыгарып азапландылар, аның зыяны двигательләр заводындагы янгын китергән зыяннан ким булмады. Чит ил инвесторлары финанслауны туктаттылар, автомобильләр сату мең данәгә кимеде. Ә бит һәр машина 150-200 миллион сум табыш бирә иде. Нефтьчеләр күргән зыян да шуннан аз түгелдер, мөгаен.

Ринат Галиев бу очракта нишләде соң? Җиңелдем, дип, кул күтәрдеме? Һич юк! Галиев—сугышчы. Үзе җитәкләгән "Татнефть" өчен соңгы тамчы канына хәтле сугышырга әзер торган гладиатор ул. Безнең нефть генералыбыз көне-сәгате белән бөтен Россияне аякка бастырды. Иң әүвәле телефон аша президент Минтимер Шәймиев белән элемтәгә керде, кайнар кулдан Россия премьер-министры Виктор Черномырдинга телеграмма сукты: "Бу кабахәтлекне ачыклагыз, тәртип урнаштырыгыз!" Аннары Россия телевидениесе каналлары аша әлеге ялганны кире кагуны оештырды: үзе тиз генә телевизион тасмага төшеп, аны зәңгәр экраннарга җибәрде. Намуссыз Россия түрәләренең

финанс җәнҗалын чит ил тамашачыларына да күрсәтүгә иреште. Яман дан—шулай ук реклама ул!

Ни өчендер, шушы гаугага, арбаның бишенче көпчәге булып, Россия "Газпром"ы башлыгы Рэм Вяхирев килеп тыкшынды. Ул "Аргументы и факты" атналык газетының 1996 елгы 47 нче санында: "Татарстан нефтьчеләрен катырак китереп кыскач, алар ике көн эчендә 12 триллион сумны табып та өлгерделәр",—дип язып чыкты. Ике атнадан соң шул ук газет аша Ринат Галиев "Газпром" башлыгының, йомшак кына әйткәндә, ялганлаганын фаш итте. Бюджет мөнәсәбәтләре һәм ВЧК эше белән азмы-күпме таныш булганнарга билгеле: "Татнефть"не федераль бюджетка 407 миллиард сум гына салым түләмәүдә гаепләделәр, аның да 365 миллиард сумы авыл хуҗалыгы эшчәннәренә товар кредиты итеп бирелгән иде. "Татнефть" бу уйдырма мәсьәләне Россия финанс министрлыгы һәм салым җыю оешмалары белән ике атна эчендә ачыклап хәл итте. Без шушы мәгълүматны басып чыгаруыгызны һәм, "Татнефть" адресына карата кылган әдәпсезлегенә карамастан, Вяхирев әфәндегә дә хөрмәтебезне җиткерүегезне үтенәбез, аларның да бюджетка түләүдәге мәсьәләләрен уңышлы хәл итүләрен теләп калабыз". Җавап менә шундый булды.

Бу инде хуҗалык җитәкчесенең генә җавабы түгел, бу астан ут йөртеп яки ачыктан-ачык хәйлә-мәкерле көрәшүчеләрне яхшы белгән, тәҗрибәле, үткен сәясәтче җавабы иде.

* * *

НЕФТЬЧЕЛӘРЕБЕЗНЕҢ "Дрезднер-банк" финансистлары белән ничек эшләүләрен, нинди мөгамәләдә булуларын сөйләп үтим әле.

Немецлар Татарстанның нефть башкаласы Әлмәткә үзләренең белгечләре, референтлары һәм хатыннары белән килеп төшкәннәр иде. Алар башта самолетта Мәскәүгә, аннары инде махсус ялланган рейс белән бирегә килгәннәр. Якын ара түгел, әмма акча дигәндә банкирларны юл кыенлыклары куркытамы соң?

Мин боларны бик кызыксынып күзәтеп йөрдем. Журналистлар белән очрашуларында да катнаштым. Журналистлар күбрәк белергә теләп, сорауларны сиптереп кенә торалар, тегеләр исә, артыгын ычкындырып ташламагаек дип, бик сак-саран гына җавап бирәләр. Нефтьчеләребезнең үзләрен күрсәтәсе килә инде, әлбәттә, ә немецлар,— арий канлылар һәм аннары акча капчыклары да бит!—бик акыллы гына, дошми-тынмыйчарак, уй-хисләрен йөзләренә чыгармаска тырышып йөрделәр. Әйтерсең лә, Африканың таш балбал сыннары инде менә! Әмма күңелдәге эчке тойгыларны яшерә алмыйсың, күзләреннән күренеп тора: хуҗалар күрсәтеп йөргәннәрнең кайсысы чын, тормышчан да, кайсысы гадәти күз буяу, реклама гына?—боларның шуны беләсе килә иде. Кәнбатыш эшмәкәрләрен алдый алмассың—начар товарны күбрәк мактаганны алар сизенә.

"Дрезднер-банк"ның нефтьчеләребезгә 75 миллион долларлык кредит бирүләре турында бер җөмлә белән әйтеп була. Әмма бу килешүгә ирешү өчен никадәр озын, газаплы-катлаулы юл үтелгәнен бик азлар белә, бик азлар аңлый.

Иң әүвәл зур ил-дәүләтнең болгавырлы үзгәртеп кору чорын үтәргә, сәяси һәм икътисади системаларның җимерелеп төшүеннән исән-сау чыгарга кирәк иде, аннары—тагын да болгавыррак реформа-ислах еллары, мавыктырып-ымсындырып торган базар мөнәсәбәтләренә күчү, капиталистик муллык-иминлек юлына аяк басу... Ә бит болар элеккеге юл күрсәткеч—коммунистик маяклардан бөтенләй каршы якта икән! Мавыктырса да, бик хәтәр куркыныч юл икән ул...

Ринат Галиев һәм аның командасы немец финансистлары офисына

беренче мәртәбә аяк баскач,—әлбәттә, алдан сөйләшеп-килешеп, бөтен дипломатик нечкәлекләрне үтәп!—аларга немецлар үзләренең милли горурлыгы булган эчемлекне—"Кельн" дип аталган бавар сырасын тәкъдим итәләр. Әле беренче генә очрашу булса да, һәр ике як та бер-берсе турында житәрлек төпле мәгълүмат туплаган була инде. Эшмәкәрлек—бизнес дөньясында ишекләрне тиктомалдан гына ачмыйлар. Башта өч ел дәвамында диярлек чит ил аудитор фирмасы "Прайтс Уотерхаус" белгечләре Татарстан нефть промыселларының хәл-әхвәлен, эшләренең торышын тикшерделәр. Алар барлык нефть ятмаларын өйрәнделәр, эшләп утырган һәр скважинаны энәсеннән җебенә кадәр дигәндәй карап чыктылар, нефть ятмаларының куәтен-запасын чамаладылар, гади мастерларның һөнәри осталыклары, идарә башлыкларының инженерлык белеме дәрәҗәсе—һәммәсе исәпкә алынды. Җентекле тикшеренү-исәпләүләр биредә элеккеге елларда күпме нефть алынганын да, киләчәктә нинди күләмгә чама тотарга кирәклеген дә әйтеп бирделәр. Бары тик шуннан соң гына фирма башлыгы Джеральд әфәнде Рохан рәсми белдерү ясады: "Россиядәге бер генә нефть компаниясе дә "Татнефть" ирешкән дәрәҗәгә ирешә алмаган,—диде ул.—Татарстан нефтьчеләренең урыны дөньяга танылган "Стандард ойл", "Шелл", "Амоко", "Эксон", "Бритиш Петролеум", "Тексако" кебек фирмалар белән янәшә торырга лаек..."

Һәр белешмәне, һәр фактны җиде кат тикшермәсә, банкир банкир буламы? Шуңа күрәдер инде, эксперт-аудиторларның рәсми белешмәсе салынган папкада тагын ике документ бар иде. Берсе Татарстан нефтьчеләре генералы Ринат Галиевнең үзенә кагылышлы: Кем ул? Нәрсәләр майтара ала? Җыелган мәгълүматлар совет КГБсын, Америка ФБРын һәм немецлар Авберын барысын бергә көнләштерерлек тәфсилле һәм тулы булгандыр.

Ринат Галиев әле эшлек-ле очрашуга чакыру алганчы ук "Дрезднер-банк" җитәкчеләре өстәлендә аның ата-бабаларына кадәр өйрәнелгән белешмә ята иде. Ул белешмәдә Ринат Галиевнең милләте белән татар булуы, эштә алган сөяллеренннән курыкмаучы крестьян гаиләсендә туып үскәнлеге әйтелә. Институт тәмамлагач, ул скважиналарга капиталь ремонт ясау бригадасында бораулаучы ярдәмчесе булып хезмәт юлын башлаган, җиде кат җир астыннан нефть суыртучы насосларны, торбаларны алыштырган, көйсез-кире катламнарны көйгә китергән. Генераль директор кәнәфиенә утырганчы, барлык "майлы-мазутлы" һөнәрләрне үзләштергән—мастер да булган, мөстәкыйль нефть-газ табу идарәсенә дә җитәкчелек иткән. Фәннәр кандидаты да икән, докторлык диссертациясен яклавы да ихтимал. Әһә, менә бер кызыклы факт! Цех партия оешмасы секретаре булган, коммунистлар партиясенең шәһәр комитеты башлыгы да булган. Большевиклар теләсә кемне андый югары урыннарга



*Нефтьчеләр тарафыннан төзелгән өч дистәгә якын мәчет арасында Р. Г. Галиевның туган авылы Шарламада аның әтисе Гыймаделислам исемен йөртүче мәчет тә бар.*

урләтмәгән. Димәк, булдыклы-тырыш кеше! Нәсел-нәсәбе, гаилә хәленә килгәндә, Р.Галиев ишле гаиләле колхоз бригадирының беренче улы булган, тагын өч энесе, ике сеңлесе бар. Алар да нефть төбәгендә яшиләр. Энеләре—нефть эшендә, сеңелләре—педагоглар. Ата-ана йортында төпчекләре—Булат яши икән. Калганнары әти-әниләренең каберен зиярәт кылырга кайтып йөриләр. Ринат Галиев өйләнгән, ике кызы бар. Өлкәне әтисе юлыннан киткән—нефтьтә, кечесе балалар табибәсе, махсус докторантурада бик тә мөһим бер мәсьәлә белән шөгыльләнә. Әти кеше хәзер күбрәк оныклар өмет итә инде—берәү бар, бер унлап булсалар иде, ди икән.

Балалар-онықларына килеп җиткәч, шәҗәрәсен—нәсел агачын да тикшерергә онытмаганнар. Фамилиясе, исеме, атасының исеме нинәрсәне аңлата икән нефть генералының? Серле Шәрекънең төрки-мөселман халыклары исемнәрне дә бик мәгънәле куя килгән бит. Аларның гореф-гадәтләрен белүчеләр әйтеп бирәләр. Галиев фамилиясе пәйгамбәр Галидән—гарәпчә "бөек, олуг" дигән сүзләрдән алынган икән. Күрәсең, кайсыдыр бабасы олуг затлы, ихтирамга лаек шәхес булгандыр. Кара әле, исеме Ринат итальян тамырларына ишарә шикелле, итальяннарда Ренато Гуттузо дигән музыкант-җырчы да булган ич! Ә менә атасының исемен паспортында "Гимадельисламович" дип, урысча язганнар икән. Аны таркатып укып карасаң, гарәпчә "Гыймад—терәк, багана" дигәнне аңлата, әл—кушымча гына, "ислам"ны исә белмәгән кеше юктыр: ислам—мөселман дине, иман ул. Димәк, "ислам терәге, ислам баганасы" була икән. Җыеп әйтсәң, Галиев Ринат Гыймаделислам улы иманлы, ислам диненә турылыклы терәк булырлык олуг, бөек зат булып чыга. Начар түгел!

Әмма ата-бабасы, исем-фамилиясе бер хәл, киләчәктә кулга-кул тотынып эшләрлек финанс мөмкинлекләре бармы икән соң бу кешенең? Шуңа күрәдер, яшерен кәгазьләр арасында тагын бер иң мөһиме бар иде—ул да булса, Россия бюджетына бурычларны "Известия" газеты бастырып чыгарган исемлек иде. Исемлек башында иң акчалы ягулык-энергетика комплексы тора. Аннары "ЛУКойл", "Нижневартовскнефтегаз", "Юганскнефтегаз", "Кондпетролеум", "Оренбургнефть", "Удмуртнефть", "Архангельскнефть"...—кыскасы, бөтен Рәсәйнең илле компаниясе. Немец банкирлары, бик тырышып эзләсәләр дә, бу исемлектән "Татнефть" акционерлык җәмгыятен тапмадылар. Димәк, бурычсыз яши. Финансистлар йөрәгенә сары май булып ятты бу мәгълүмат!

Шул ук вакытта Ринат Галиев тә "Дрезднер-банк"ның бронялы ишекләрен урамнан килеп шакучы түгел иде. "Татнефть"нең дә үзенең махсус куркынычсызлык бүлекчәсе бар. Аның хезмәткәрләре, мал-мөлкәтне әрәм-шәрәм итүчеләр белән көрәшеп, фирманың яшерен серләре дөньяга фаш булмауны күзәтеп тору өстенә, әле "Кем кем соң?" дигән белешмәне дә җыеп баралар. Әлеге "Дрезднер-банк"ны да бик җентекләп өйрәнгәннән соң, аның "Вестдойче Ландсбанк", "Дойчебанк", "Коммерцбанк" кебек Көнбатыш Европа банклары консорциумы башында торганлыгын белгәннән соң, финанс мөмкинлекләрен аныклагач кына сайлап алдылар.

Кыскасы, Германиядәге беренче эшлекле очрашуга һәр ике як та бер-берсен энәсеннән җебенә кадәр өйрәнеп, тикшереп килгән иде. Шуңа күрә, сөйләшүләр үзара әдәплелек кагыйдәләрен саклап, шунда ук эшлекле юнәлеш алды.

Беренче булып сүзне хуҗалар әйтте. Хәл-әхвәл сорашу, президент Минтимер Шәймиевкә исәнлек-саулык теләү озакка бармады. Татарстан нефтьчеләренең тәвәккәллеген, куркып калмыйча, европага чыгарга омтылышларын мактадылар.

Ринат Галиев, хуҗаларның күңелен күрергә дигәндә, сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел: ул, немецларның милли хисләренә чиртеп, үзләренең бөек Гете, Шиллер, Гейнелар иленә килергә күптән

хыялланганлыкларын әйтеп узды; немец философлары Гегель, Кант, Ницшеләрне дә искә төшерергә онытмады, хәтта канцлер Бисмарк белән король Фридрих Барбароссаны да телгә алды. Аннары, сәясәткә артык тирән кереп китмәгәем, дигәндәй, немецларның сыраларын мактады, биредә сыраның биш меңнән артык төре барлыгын белгәч, исе киткән шикелле булды. Сүз арасында Татарстан нефтьчеләренең "Ромашкино сырасы" дигән үз сыралары да халыкара күргәзмәдә беренче катнашуында ук көмеш медаль алуын искәртеп куйды. Нефть төбәкләрендәге йөзләгән-меңләгән чишмә суларының сафлыгын-тәмлелеген дә шул сыра сыйфатына китереп бәйләде.

Иң татлы-матур сүзләр дә, озынга китсә, ялыктыра башлый. Матур-итагатьле сүзләр артында һәр ике якның да үз мәнфәгатьләре—бирәүләрнең бурычка күбрәк валюта каерасылары килү теләге, икенчеләренең бурычка биргәндә үз файдасына күпме табыш буласы, шул хакта кызыксыну ята иде.

Шуңа күрә ике арада мондыйрак сөйләшү булып алды.

—Безнең уебызча, хөрмәтле кунакларыбыз безнең белән хезмәттәшлек итәргә телиләр булса кирәк. "Дрезднер-банк"тан кредит алыргамы исәбегез?—дип сорадылар немецлар.

Галиев килешеп баш какты:

—Нәкъ шулай. Дөрес уйлыйсыз.

—Ниндирәк суммага исәп тотасыз?

—Банкыгызның мөмкинлекләре ничектер бит...

—Яхшы, яхшы! Гут! Ниятегезне хуплыйбыз. Кемнәр сезгә ышаныч белдерә? Кем җаваплылыкны үз өстенә ала? Россия Үзәк Банкымы?

—Юк.

—Бәлки, берәр финанс фирмасыдыр.

—Юк.

—Әллә Россия яки Татарстан хөкүмәтеме?

—Юк. Төп җаваплылык Татарстан нефтьчеләренең абруенда, минем шәхси намусымда.

Немецлар бераз уйланып тордылар.

—Данлы нефть төбәге Татарстаннан килгән кунакларыбыз аңлыйдыр: банк—ул урта гасыр рыцарьларының ярыш мәйданы түгел, ә, бәлки, финанс оешмасы. Безнең үз намуслылык кагыйдәләребез бар.

Галиев югалып калмады:

—Банкирлар үз фирмаларының маркасын-дәрәҗәсен, данын-абруен төшерергә теләмиләрдер, шөт,—диде.—Хәзерге заманда абруй-дәрәҗә рыцарьлар заманындагыдан күпкә кыйммәтрәк тора дип уйлыйбыз. "Татнефть" белән хезмәттәшлек итү сезнең өчен дан гына китерердер. Без Россиядәге нефть компанияләре арасында дүртенче урында торабыз.

Эшлекле мөгамәләләр тәртибеннән караганда, ышанычлы таяныч булырдай дәлил таләп итүче банкирлар, һичшиксез, хаклы иде, әлбәттә. Әмма өч миллиард тоннага якын "кара алтын" чыгарган, бөтен дөньяга даны таралган Татарстан нефтьчеләре дә немецларга озак вакытка хезмәттәшлек—табышлы хезмәттәшлек!—тәкъдим итә бит. Бер-береңә каударланып-кабаланып ышану тәвәккәллек сорый, билгеле—зыян күрүең дә бар. Баш тартсаң—бөтенләй шымытыр тотып калуың да ихтимал. Көндәшләр, бигрәк тә американнар авызыңа керергә торган табышыңны тартып алырга да күп сорамаслар.

Американнар татарстанлыларга 250 миллион доллар кредит бирергә риза, әмма шул суммага алардан нефть сәнәгатенә кирәкле җиһазларны сатып алуны шарт итеп куялар. Монысы безнекеләр өчен бер дә файдалы булмаячак иде.

Шуңа күрә дә немецлар белән озаклап, җентекләп сөйләштеләр һәм башта, бер-берсен сынамактан, ун миллион доллар кредитка килештеләр. Бу әле чын мәгънәсендә зур хезмәттәшлек җепләренең

төене генә иде.

Шушы беренче очрашудан соң ярты ел узгач, "Дрезднер-банк" финанс әһелләре зур бер төркем булып Әлмәткә килеп төштеләр дә инде. Эшлекле сөйләшүләр яшерен шартларда барды, журналист халкын анда кертмәделәр. Әмма "акча капчыгы" булган немец банкирларының нинди хис-тәэсирләр алып киткәнлеген без күреп-күзәтеп тордык.

Иртәннән барысы да бер зур автобуска,—ул төрекләрдә эшләнгән немец автобусы "Мерседес-Бенц" иде булса кирәк,—төялеп, тәрҗемәче әйтмешли, "нефтькә буялып кайтырга" чыгып киттеләр.

Беренче тукталыш "Торнакай" дигән балалар бакчасында булды. Әллә кичәге коммунистик заманнан калган гөлбакча иде ул, әллә капиталистик иртәгәнең үсентесе идеме—әйтә алмыйм. Җылы-якты сентябрь көне—әбиләр чуагы иде. Сабыйлар, дөньяларын онытып, комда уйныйлар: кем ракетага атланган, кем атка, кызлар кулында курчаклар... Чыр-чу!

Сабыйларның ашау ягы ничек, дигәндә—һәр көнне ите-сөте, алмасы-әфлисуны—барысы да тиешенчә һәм кирәгенчә. Җәен кояш, су, саф һава... Кышын нәнекәчләр яланаяк-яланөс карда йөгереп йөриләр. Шулай чыныгып үсәләр алар. Чынлап торып хәреф танырга, укырга-язарга да өйрәнәләр. Урыс, татар, инглиз телләрендә "пупалыйлар". Мәктәпкә шундый өзерлекле балалар барачак. Бакча өчен түләү дә арзан, күп балалы гаиләләр бөтенләй түләми.

Немецларның исәбе төгәл: бер тәүлектән китеп барасылары бар. Шуңа күрә танышу сәяхәтен йөгертеп кенә узарга иде ниятләре. Әмма бу сөйкемле сабыйлардан ничек тиз генә аерылып китмәк кирәк? Кунаклар икегә бүленде—хатын-кызлары "Торнакай"да калды, ир-атлар "нефтькә буялырга" китте.

Кунакларга күрсәтәсе урыннар нибары дүртәү генә иде.

Әүвәле "Әлмәтнефть" идарәсенең беренче промысел скважиналары янына тукталдылар. Монда әллә ни-нәрсә күреп тә булмый—барысы да җир астында. Сүзне "хуҗа"—идарә башлыгы Марс Җәләтов алды. Сөйләшү бик гади: сорау—җавап, янә сорау—янә җавап. Кунаклар бик ачылып китә алмаса да, идарә башлыгы аларны "уяту" җаен тапты:

—Без сезнең белән нефть күле өстендә басып торабыз,—диде ул.—Әлмәт шәһәре астында сигез миллион тонна нефть бар.

—Ә ничек алмакчы буласыз? Шәһәрегезне башка урынга күчерерсезме?

—Сугыш алдыннан Апшерон ярымутравындагы "кара алтын"ны суырту өчен шулай эшләмәкче—Сурхан эшчеләр бистәсен күчермәкче булганнар. Без исә нефтьне горизонталь скважиналар тишеп суыртачакбыз. Шәһәрне шулай итеп бөҗралап алачакбыз. Ферштейн? Аңлашылдымы?

—Ферштейн, Гут, гут!—диештеләр немецлар.

Икенче тукталыш металл торбаларга эчтән һәм тыштан—ике катлы полиэтилен "күлмәк" кигертә торган заводта булды.

—Җир астына мондый торбалар салу бик кыйммәткә төшәдер бит?—дип сорадылар кунаклар.

Җавап дәлилле иде:

—Мәсьәләне арзан-җиңел генә хәл итәрлек бай түгел әле без. Гади торбаларны еш алыштырырга, ямарга кирәк, ярты вакыт шул "салкын янгын"—тутык белән көрәшкә китә. Әлбәттә, полиэтилен "күлмәк" кыйммәтле, авыр эш. Коми республикасындагы нефтьүткәргечтә булган һәлакәтне ишеткәнсездер, мөгаен. Һәлакәт-аварияләр белән көрәшү тагын да кыенрак-кыйммәтрәк бит. Ә экология ягы? Димәк, аварияләрне булдырмаска тырышырга кирәк. Безнең исәпләүләр шуны күрсәтә: "күлмәк"ле торбалар елына 600 миллиардны янга калдыра...

—Долларлармы?

—Юк, сумнар. Сумнарны долларга әйләндерү кыен эш түгел, шулаймы?

—Гут, гут!

Аннары немецларга җиде мең метр тирәнлеккә бораулнырга

тиешле скважинаны һәм нефть эшкәртү заводын күрсәттеләр. Скважинаны әле тагын ике мең метр бораулыйсы бар икән. Әлмәт бораулау эшләре идарәсе башлыгы Тәлгать Бикчурин,—менә дигән җитәкче, сөләтле уйлап табучы, техник фәннәр кандидаты,—болай дип аңлатты:

—Бу икенче шундый тирән скважинабыз. Беренчесен фәнни максатларда бораулаган идек, монысыннан нефть алырга уйлыйбыз.

—Бик кыйммәткә төшмиме соң?

—Кыйммәт, әлбәттә. Ун гадәти скважинага торырлык. Нефть эшендә "саттым-алдым" белән генә булмый бит. Алгарак карап исәп-хисап йөртергә туры килә.

Нефть эшкәртү заводының файдасы чи нефть сатуга караганда ике-өч мәртәбә отышлырак икәнен дә күреп-төшенеп китте кунаклар.

Журналистлар белән булган йомгаклау очрашуында бирелгән сорау-җаваплар күп тә, кызыклы да иде. Мин иң соңгысын гына искәртеп узам. Сорау мондый иде:

—Немец финансистлары килеп, күреп китүләреннән канәгатьме? Иң көчле тәэсирләрегез нинди?

Банкирлар төркеменең башлыгы Бернд әфәнде Фарһольц болай дип җавап бирде:

—Бүген үк очып китәсебез булуы кызганыч. Тәэсирләребез—эшлекле. Банкыбыз идарәсенә үз сүзебезне җиткерәчәкбез: Татарстан нефтьчеләренә кредитны җитмеш биш миллион долларга күтәрү кирәклеген әйтәчәкбез. Тәвәккәллек зур булган саен уңышка ирешү мөмкинлеге дә арта. Алга таба тагын карарбыз әле: нәтиҗәләр нәрсә күрсәтер? Әлегә биргән кадәре кредитны файдалы итеп тотарга кирәк.

Аэропортка илткәндә кунакларны табигать кочагына алып кереп чыгарга да онытмадылар. Автобус, олы юлдан борылып, саф һавалы куе урман аланына барып туктады. Ак каеннар күләгәсендә салкын чишмә челтерәп агып ята иде. Шунда яшел чирәм өстенә мул сый-нигъмәтле табын корылган. Табында—нефтьчеләрнең үз агрохуҗалыкларында үстерелгән-җитештерелгән затлы ризыклар. Ни-нәрсә генә юк иде анда: тау-тау җиләк-җимеш, яшелчә, татарча өй токмачлы кайнар тавык шулпасы, майлары сыгылып торган шашлык, тутырылган тавык, сап-сары кәрәзле бал... Башта барысы да чишмә янына ашыкты, аның төмле салкын суын татып, бит-кулларын юып алдылар. Йә Хода, мондый рәхәтлек тагын кайда бардыр?!

Ринат Галиев бу рәхәт-татлы мизгеллләрдән бик оста файдаланып, нефть төбәкләрендәге чишмәләр турында сөйләп алды. "Чишмәләр—куанычыбыз да, борчуларыбыз да,—диде ул.—Саф сулы чишмәләр—саф-намуслы эш-гамәлләребез символы".

Аннары ул, мангалларда шашлык кыздырылган арада, бик гыйбрәтле бер борынгы риваятьне сөйләде.

...Борын-борын заманнарда бер татар авылында бер карт белән карчык гомер кичергәннәр икән. Бабай көн саен урманга бара, бер бәйләм чыбык-чабык күтәреп кайта, әби исә өйдә кыштырдаган була—учак тергезә, ашарга пешерә. Көннәрдән бер көнне әби тәрәзәдән караса, ни күрә: ишек алдына карт бабай урынына җилкәсенә ат йөге кадәр утын күтәргән гайрәтле-чибәр бер баһадир егет кереп килә икән. Гаҗәпләнүеннән тораташ калган әбигә әлеге егет хикмәтне сөйләп бирә: урманда йөри торгач, бабай бер чишмә янына килеп чыккан икән, бик сусаган-эсселәгән булган ул, чишмәдән куш учлап туйганчы төмле салкын су эчкән. Шунда үзенә, көч керүен, дәрте-җегәре артуын, яшәрүен тойган бабай. "Менә, күрәсең бит: тәмам егет булдым!"—дип сүзен йомгаклауга, әй тотынган әби егет-бабайны тиргәргә, әй тотынган, мин сиңа әйтим, чыдап кына тор! "Син соң, карт җүләр, ник шунда мине исеңә төшермәдең? Әллә миңа картаймыш көнемдә бик рәхәт дип беләсеңме? Ник кайтып мине дә чишмә янына алып бармадың? Син гомерең буе гел үзеңне генә кайгырттың инде, мине

бар дип тә белмәдең... Яратмадың да!"—дип, әби елап та җибәргән. Хатын-кыз күз яшенә түзеп торган ир-ат бармы соң дөньяда? Егет-бабай карчыгын юатып та караган, иркәләп тә караган, аннары урмандагы терек сулы чишмәгә ничек барырга икәнен дә өйрәткән. Әбигә шул гына кирәк тә! Елавыннан шунда ук туктаган ул, яулыгын кысып бәйләгән дә, кулына таягын алып, тиз-тиз генә урманга чыгып киткән. Яшьлеген кайтарып алырга дип инде! Егет-бабай әбинең өйләнеп кайтуын бик озак көтеп утырган, караңгы төшкән, төн җиткән, күктә йолдызлар җемелди башлаган, ай калыккан. Әби һаман юк та юк икән... Пошаманга төшкән егет-бабай карчыгын эзләп урманга ашыккан. Чишмә янына сулулары кабып йөгереп килсә, ни күрсен—яшел үлән өстендә тупырдап торган бер кыз бала—сабый ята икән! Аның үз карчыгы икәнлеген егет-бабай яулыгыннан гына танып алган. Әби карчык, яшәргәннән яшәрәсе, гүзәлләрдән гүзәл буласы килептер инде, чишмә суын тыела алмыйча эчкән дә эчкән һәм... сабыйга әйләнгән, имеш!

—Безнең чишмә сулары шундый көч-кодрәткә ия. Карагыз аны, чамалап эчегез!—дип хикәятен йомгаклады Ринат Галиев.

Кунаклар рәхәтләнеп көлештеләр:

—Гут, гут!—диештеләр.

Табын гөрләде дә гөрләде. Самолет та үзләренеке булгач, банкирлар ашыкмадылар. Салкынча рәхәт урман күләгәсендә матур-матур тостлар әйтешеп, алдагы килешүләр, тагын да нәтиҗәлерәк хезмәттәшлек турында сүз куерттылар. Ир-атлар һаман да шулай эш турында сөйләнгән арада хатын-кызлар, Ринат Галиев бәян иткән риваятьне дә онытып,—ә, бәлки, онытмыйчадыр?!—салкын сулы чишмә янына әледән-әле барып килә тордылар. Аларның битләре әллә табындагы сый-нигъмәттән, әллә салкын чишмә суыннан алланып яна башлады. Бу мизгелдә барысының да күңелләре күтәренке иде.

* * *

"ТАТНЕФТЬ" зур дөнья базарына әнә шулай юл яра. Ул хәзер америкалылар, японнар, инглизләр, канадалылар, итальяннар, испаннар, австриялеләр кебек егерме илнең фирмалары белән тигез, тулы хокуклы хезмәттәшлек алып бара. Аларның һәркайсы белән бар нәрсәне җитди уйлап-исәпләп, үз файдаңны кайгыртканда аларның мәнфәгатен дә онытмыйча эш йөртергә туры килә.

Бу җәһәттән нефть генералы Ринат Галиевкә бирәсе сорауларым байтак җыелган иде. Ничек була соң әле бу? Нефтьне юкка гына "кара алтын" димибез ич, шул кадәр табышлы тармактан алынган байлык көндәлек ихтыяҗларны канәгатьләндерергә дә, алдагы матур, өметле уй-ниятләрне тормышка ашырырга да җитәргә тиеш бит. Ә безнең нефтьчеләребез, һөнәри һәм милли горурлыкларын тыеп, чит ил банкларына баш иеп баралар, бурычка керәләр. Нефтьтә йөзгән Гарәп Әмирлекләре, Сәгуд Гарәбстаны, Кувейт кебек илләр нефть сатып баеп беткәннәр, акчаларын дөньяның иң абруйлы банкларында саклыйлар, һәр яңа туган балага, махсус өлеш чыгарып, банк исәбе ачалар. Көнбатыш сәнәгатьчеләренең дә иң байлары—нефть компанияләре: "Стандард ойл", "Тексако", "Амоко", "Шелл", "Эксон", "Бритиш петролеум"...

"Ни өчен,—дип сорыйсым килә минем Ринат Галиевтән,—ни өчен, "кара алтын"ны елдагыдан ике миллион тоннага күбрәк алып та, байый алмыйсыз, ихтыяҗ-хаҗәтләрегез кимеми, бурычка керергә мәҗбүрсез? Инде бурычларсыз-кредитларсыз мөмкин түгел икән,—дөнья базарында бу гадәти хәл, моның бер ояты-хурлыгы да юк,—ни өчен акчаны чит ил банкларыннан сорыйсыз? Чит илләрнең финанс хәлен яхшыртуга караганда, үз илебездәге банклар белән хезмәттәшлек итү хәерлерәк түгелме соң? Әллә инде безнең үз банкирларыбызга ышаныч азмы? Әллә Гайдар-Чубайс реформаларыннан соң өмет өзелдеме?"

Ринат Галиев ярдәмчеләре, секретарьлары, куркынычсызлык хезмәте сакчылары артына ышыкланып, журналистларның буе җитмәслек командир булып утыра торган шәхес түгел-түгелен. Шулай да аның янына керүе, очрашып әңгәмә корып утыруы җиңел дип уйламагыз. Аның тәүлектәге егерме дүрт сәгате һәр минутына кадәр әллә ничә көннәргә алдан уйланган-исәпләнгән. Генерал белән күрешергә теләүчеләрне бик тиз "тотып" алалар, йомышын-гозерен тәгаенләгәч, тиешле бүлекләргә озаталар, бәхет елмайганнарның да күбесе Ринат Галиевнең җиде урынбасарының берсенә килеп эләгә. Юк, генерал алай журналистлардан качып йөрми, киресенчә, ул "дүртенче хакимият" дип йөртелгән массакүләм мәгълүмат чараларыннан бик оста файдалана белә. "Татнефть" акционерлык җәмгыяте кушбитле ике газет (берсе татарча, берсе урысча) чыгара, тапшыруларның төп өлешен нефть төбәкләре тормышын яктыртуга багышлаган җирле "Нур" ("Луч") телевизион каналына да финанс ярдәмен кызганмый. Көн саен иртәнге сигезенче яртыда телевидение хезмәткәрләре Фәрит Муллагалиев, Атлас Ганиев, Рәис Шәйхетдинов, тапшыруларны алып баручы Суфия Гарифуллина, ике газетның мөхәррирләре Ирек Бәдертдинов белән Нур Әхмәдиев "Татнефть" аппараты җитәкчесе Ришат Әбүбәкеров бүлмәсендә җыелышып, булачак көн вакыйгаларын ничек оештыру, ничек яктырту турында тиз генә сөйләшеп-фикерләшеп алалар. Ринат Галиев нефть төбәгендәге авыл-шәһәрләрдә яшәүчеләр яңалыкларны җитәкчеләр авызыннан ишетергә тиеш дип саный. Шуңа күрә ул телевизион тапшыруларда, газет битләрендә еш чыгыш ясый, бәхәс-диспутларда катнаша. Әгәр дә нефть генералы Татарстан яки Россия телеканалларында күренә икән, монысы да журналистлар эше генә түгел, Ринат Галиевнең үз теләге буенча үтәлә, дигән сүз.

Югарыда сөйләп үтелгән гаугалы банкротлык вакыйгасын искә төшерик. "Татнефть" белән "КамАЗ" тирәсендәге шау-шудан гауга оештырырга теләгән журналистлар килгәч, әлеге вакыйганың төп каһарманнары үзләрен ничек тотты соң? Автогигантның генераль директоры Николай Бех "өйдә юк" булып чыкты һәм... оттырды. Ринат Галиев исә—һәр адымын уйлап-исәпләп эш итә торган кеше—бу юлы гөлтләп кабынып китте. Шау-шу күтәрелгән көнне үк үз аңлатмасын бәян иткән бер минутлык язмасын махсус кеше белән Мәскәү телевидениесенә җибәрде. Тизрәк, тизрәк! Бары тик шулай гына "Татнефть"нең банкротлыкка чыгуы турындагы уйдырманы тыеп-туктатып була, компаниянең эшлекле абруен саклап калып, финанс һәлакәтеннән котылып була. Россия телевидениесе дикторлары зәңгәр экран аша егерме секунд эчендә бөтен дөньяга шул уйдырма әкиятне тараткан булсалар, Ринат Галиев кырык секунд сөйләде. Ул мескенләнеп, зарланып утырмады, кулындагы дәлилле саннар белән салым инспекциясе чиновникларын тар-мар итеп ташлады, аларның абруйлы дәүләт түрәләре булмаганлыкларын, буталчык провокаторлар икәнен турыдан-туры ярып салды. Куркып тормады ул. Хакимиятне таныргa, аңа хөрмәт белән карарга кирәктер, әмма бюрократ түрәләрнең һәр төчкергәненә "ләббәйкә!" әйтеп, тәлинкә тотып, баш иеп торырга да ярамый. Һич ярамый!

Бервакыт нефтьчеләребез янына Россия телевидениесенең атаклы гармунчысы, "Уйна, сөекле гармуным!" ("Играй, гармонь любимая!") тапшыруы башлыгы Геннадий Заволокин килде. Мин дә шунда чак иде бу. "Кара алтын" осталары һөнәри осталык ярышы үткәреп, хезмәт бәйрәме оештырдылар. Жюри ярышка йомгак ясаган арада, Геннадий Заволокин мәйданда ук концерт башлап җибәрде. Телеоператорлар концертны тасмага төшергәнен чамалагач, мин дә телекамера күзе төшәрлек җиргәрәк барып бастым. Җирле хакимият башлыгы Илдус Гәрәев белән Ринат Галиев, тыйнаклык саклап булса кирәк, тамашачылар арасына кереп кунаклаган иделәр. Үткен күзле Геннадий Заволокин аларны шунда ук танып, халык төркеме арасыннан аерып алды да, минем янга китереп бастырды. Ул: "Мотор!"—дип фәрман бирүгә, безне

төшерә дә башладылар. Аннары безне такмаклый-такмаклый биюче түгәрәк уртасына өстерәп керттеләр. Сулда—Галиев, уңда—Гәрәев, мин уртада. Геннадий Заволокинга минем кыяфәтем ошамадымы, ул кинәт кенә: "Ә син, бабакай, бәлки читкәрәк китеп торырсың?"—димәсенме! Ринат Галиев шунда ук: "Бу безнең бабай, үзебезнеке..."—дип, мине яклап алып калды. Шулай итеп, нефть генералы белән бергә шул тапшыруга эләктем бит. Бер-ике айдан соң үземне Мәскәү телевидениесе экранында күргәч, сөенеп куйдым: Геннадий Зоволокин егет икән, "бабакай"ны кадрдан кисеп ташламаган.

Монысы ярады-яравын. Әмма бит минем Ринат Галиев белән озаклап-озаклап әңгәмәләр корып, күзгә-күз, тезгә-тез дигәндәй, үземне борчыган сорауларыма җавап алып, сөйләшеп утырасым да килә. Һич кенә дә шундый уңай вакытны туры китереп кенә булмый.

Шулай да бервакыт бәхет елмая язып калды: Ринат Галиев белән бер самолетта очарга тиеш идек. Бернинди телефон шылтырауларсыз, йомыш белән кереп бүлдерүчеләрсез берәр сәгать самолет салонында әңгәмәләшеп барырбыз дип сөенгән идем. Без өйләнгәч, төн кыска булып чыкты—һава бозылып китте дә, оча алмый калдык...

Ә очарга җыенуыбызның сәбәбе үзе бик кызыклы иде, аны уйлап та чыгара алмассың.

Михаил Горбачевның үзгәртеп корулары, Борис Ельцин реформалары нефть сәнәгатенең элекке канун-кагыйдәләрен җимерде дә ташлады. Техникага, электр энергиясенә, нефтьне эзләү һәм чыгару өчен кирәкле әйберләргә бәяләр дистә меңнәрчә мәртәбә күтәрелде. Шуның өстенә һәртөрле салымнар, пошлиналар, акцизлар һәм башкалар... Кыскасы, "җир мае"ның һәр алынган тоннасыннан тиеннәр дә калмый башлады. Промыселларда үзләрен аклый алмаган скважиналар, мәйданнар, ятмалар барлыкка килде—аларны эшләтү файдасызга әверелде. Әгәр дә акыллы икътисади чаралар кулланылса, әйтик, кыен алына торган "җир мае"на салым ташламалары ясалса, эшләр җайланып та китәр иде. Әнә, американнар үзләрендәге энергетик кризис елларында аз табышлы скважиналардан алына торган нефтькә бәя чикләүләрен бетергән булганнар һәм тернәкләнеп киткәннәр. Әмма Россиягә чит ил тәҗрибәсе кирәкми шул, аның үз акылы үзе белән!

Җиде дистә елларга сузылган совет хакимияте чорында "кара алтын"ны "план өчен" дип, "намус һәм бурыч эше" дип, мескен тиеннәр бәрабәренә сыгып ала килделәр. Эш чыгымнарына тотылган сумнар белән нефтьне сатудан алынган сумнар аермасын, ягъни бар табышны дәүләт кырып-себереп ала торды. Нефтьчеләрнең үзләренә ихтыяҗ-хаҗәтләре өчен тиеннәрне бик санап кына кайтаралар иде.

Ниһаять, демократия килде, дип сөенгән идек. "Кара алтын" осталары үз хезинәләренә хуҗа булу ирегән яулап алырга, үз хезмәтләренең җимешен үзләре файдаланырга мөмкинлек туды шикелле. Илнең борылышларда бик авыр хәрәкәт итә торган икътисад "корабы" йөз сиксән градуска борылыш ясады, чит илләр белән дөнья бәяләре буенча турыдан-туры сату итә башладык. Әмма янә бәла: бар табышны диярлек салымга басып калалар. Һәр бер сумның илледән алып туксан тиененә кадәр өлешен федераль бюджетка сыдырып алалар. Татарстан бюджетының да нигезе—нефтьтә. Ә кайтарып бирергә уйлап та каручы юк...

Нефть ятмалары, катламнар, скважиналар, галәм күгендәге йолдызлар шикелле, бер-берсеннән нык аерылып торалар. Бер урында "җир мае" ургып бәреп чыкса, икенче урында аны өллә никадәр көч һәм чыгымнар түгеп, җир астына химик катнашмалар кудырып, "мунча ясап", насослар белән көчкә суыртып алалар. Татарстан промыселларында бер скважинаны гади бентонит балчык белән эшкәртү-сылау гына да өллә ничә мең сумнарга төшә. Ә андый эшләр меңнәрчә скважиналарда башкарыла. Ә менә ни өчендер нефть эшендә барысын да бер чыбыктан куалар—бөтен төр салымнар да бертигез алына.

Шуңа күрә нефтьчеләр табыш алып булмастай скважиналарны икътисади вәзгыять яхшырганчыга кадәр томалап-ябып торуны мөгъкуль күрәләр. Ә кайчан яхшырыр ул икътисади хәл? Анысын бер Алла гына белә! Хәзер инде Россиядә ябылган скважиналар саны кырык меңгә җитә, дип сөйлиләр.

Тукта! Ни өчен нефть сәнәгатендә нәтиҗәле эшләүне, һөнәри мәсьәләләрне һаман да Мәскәү, Үзәк хәл итәргә тиеш соң әле? Үзебез игълан иткән суверенитет—бәйсезлек, җир-суларыбызга, җир асты байлыкларына—кыскасы, җөмһүриятебезнең барлык хәзинәсенә тулы хокуклы булуыбыз—болар Татарстанның төп законында—Конституциясендә язылган.

Әмма тулы бәйсезлеккә ирешү—озак һәм катлаулы юл, ул уңышлы да булырга мөмкин, күренерлек нәтиҗәле булмавы да ихтимал. Әлегә бар өметебез шул нефтькә бәйле. Димәк, "кара алтын" өчен кайгыртучанлык күрсәтү бүген иң мөһим, иң төп мәсьәлә!

Барлык парламентларның бәласе шулдыр: алар никадәр буш сүз тегермәне корсалар, шулкадәр вакыт та бушка ага, җилгә оча. Матур сүзләр күп сөйләнде, әмма закон чыгаручы депутатларыбыз нефть тармагын үстерүне хокукый нигезләргә салган, юл күрсәткеч булырлык бер закон эшләп бирә алмадылар. Нефтьчеләребез кыргый базар мөнәсәбәтләренең давыллы диңгезендә менә ничәмә-ничә еллар инде "законсыз" йөзә. Ә бит мондый закон өчен көрәш-тартыш парламентта да, хөкүмәттә дә, Президент аппаратында да туктамый дәвам итә! Тик нәтиҗә генә бик күренми. Нефтьчеләрнең таләпләре бер генә: нефть сәнәгате белән икътисади идарә итү төрле ятмалар-катламнар, аерым мәйданнар өчен бер төрле генә булмаска, бер чыбыктан куылмаска тиеш. Һәр очрак—табигатьнең серле бер могҗизасы ул, һәр скважинаның үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен анык билгеләп, белеп эшләргә кирәк. Шуңа яраклаштырылган икътисади хокуклар-законнар да булырга тиешле.

Әйе, нефть турындагы шундый закон һава белән су кебек кирәк, тиз кирәк.

Ринат Галиев командасы Татарстан Дәүләт Советының реформалар комиссиясе утырышына әнә шул эшне тизләтү өчен очмакчы иде. Промыселларның язмышы шунда хәл ителергә тиеш—алар "кара алтын" чыгаруны дәвам итәчәкләрме, әллә, "табышы аз" дигән сылтау белән, күп кенә скважиналарны ябып куярга туры киләчәкме?

Казанга сәгать иртәнге тугыздан да калмый барып җитәргә кирәк иде, шуңа күрә юлга таң белән кузгалдылар. Аэропортка сәгать алтыда юл тотканда әле яктырмаган да иде. Февраль ае. Томан, бозлавык. Алтмыш чакрым юлны шулай да хәвеф-хәтәрсез генә барып җиттек. Команда мондый: нефть генералы Ринат Галиев үзе, баш инженер Шәфәгать Тәхаветдинов, баш геолог Ринат Мөслимов, чит илләр белән сәүдә итү фирмасы башлыгы Эдуард Акопджанов, баш бухгалтер Владимир Лаврущенко, генераль директорның тәзелеш буенча урынбасары Семен Фельдман. Күрәсез, барысы да зур белгечләр—тарткалашырга-көрәшергә ныклап әзерләнгәннәр. Арбаның бишенче көпчәге сыйфатында мин дә ияргән идем. Өметем: юлда Ринат Галиев белән иркенләп сөйләшеп бару иде. "Нигә машинада ук сөйләшә башламадыгыз?"—дип сораучыларга җавабым шул: аларда минем кайгым юк иде—һаман да "Казанны ничек яулау" кайгысы иде...

Әмма... әйткәнемчә, хәерчегә җил каршы, дигәндәй, һава бозылды. Ринат Галиев янәшәсенә утырып, әңгәмәләшергә дип, сорауларымны әзерли башлауга... булмады... Казан өстен куе томан баскан, дип хәбәр иттеләр. Двигательләрен дә җылытып өлгермәгән самолеттан башны иеп чыгып китәргә туры килде. Көн дә әрәм булды, генерал белән дә әңгәмә өзелде...

*Ахыры бар*

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кешелек җәмгыяте өчен гаять мәгънәле дата—2000 нче ел якынлашып килә. Бу дата тормышыбызның төрле тармаклары турында житди уйлануларга этәрә, үткән чорга нәтиҗәләр ясауны, киләчәк елларга күз салуны сорый.

Шул уңайдан "Казан утлары" журналы редакциясе язучыларга һәм киң катлам укучыларга, әдәбият сөючеләргә гасырыбызны йомгаклаучы туксанынчы еллар әдәбияты турында түбәндәге сорәулар белән мөрәҗәгать итә:

**—Соңгы ун-унбиш елда басылган кайсы әсәрләрне (проза, поэзия, драматургия, публицистика) әдәбиятыбыз казанышы дип санаесыз? Ни өчен?**

**—Сезнеңчә, туксанынчы еллар татар әдәбиятында нинди уңай сыйфатлар бар? Ә кайсы яклар Сезгә ошап җитми? Киләсе гасырга Сез кайсы әсәрләрне алып керер идегез һәм татар әдәбиятында нинди сыйфатларның өстенлек алуын теләр идегез?**

**—Әдипнең җәмгыятьтәге урынын киләсе гасырда йичек итеп күз алдына китерәсез?**

**Радик Фәизов:**

Кешелек дөньясы үзенең тарихи юлында нәүбәттәге үргә—2000 нче елга якынлаша. Бу датага безнең татар әдәбияты ни рәвешле килде? Гасырыбызны йомгаклаган туксанынчы елларда ул җәмгыять тормышын ничек чагылдырды, ничек тәрәккый итте?

Башта шунысын ачыкларга тырышыйк әле: туксанынчы елларда без нинди чорда яшәдек, җәмгыятебезнең алга бару юлы ничек булды? Моны уйлап карасаң, ирексездән, "тарих кабатлана!" дигән гыйбарәнең никадәр дөрес икәненә ышанасың. Без туксанынчы елларда, нәкъ менә шушы гасырның егерменче елларындагы кебек үк, зур үзгәрешләр, җәмгыять үсешендә иҗтимагый-икътисади формация алмашыну чорында яшәдек һәм яшибез. Тоткан кыйблалар үзгәргән, уй-фикерләр пран-заран килгән, ачык кына барыр юнәлешебез булмаган чорда. Шул ук инкыйлаб дәверендә дисәң дә ярый.

Тик монда шунысын да искә алырга кирәк: туксанынчы елларның егерменче елларга караганда тагын үзгәлеге бар. Ул замандагы инкыйлаб асылда югарыдан, өстән ясалмады, анда киң халык массалары, хезмәт ияләре, шул исәптән әдипләр һәм зыялылар да катнаштылар. Шул исәптән, безнең татар зыялылары һәм әдипләре дә. Әдәбиятта, безнең татар әдәбиятында да, бу инкыйлабның ничек әзерләнүе, барышы һәм җиңүле тәмамлануы киң чагылыш тапты. Әдәбият бит ул тормыш барышыннан каядыр читкә тайпылып, үз юлы белән генә китә алмый. Бу һәркемгә мәгълүм. Ул вакыттагы әдипләр дә, кайсысы тормыш агышына ияреп, ә зур күпчелеге аңлы рәвештә инкыйлабны кабул иттеләр, аның идеалларына хезмәт итә башладылар. Һәм, курыкмыйча, кыю төстә әйтергә була; моның белән әдәбият үз-үзенә дә хыянәт итмәде, үзе тоткан юлдан да аерылмады.

Чөнки аның тоткан кыйбласы—халыкка хезмәт итү. Ә ул заманда халык шушы юлны сайлады.

Ә менә туксанынчы еллар инкыйлабы асылда югарыдан, өстән ясалды, анда халык, хезмәт ияләре бөтенләй дә катнашмады. Гәрчә зыялылар һәм әдипләр социалистик җәмгыятьнең төссезләнә, какшый, югарыдан һәм түбәннән таркала баруын әсәрләрендә, публицистик язмаларында күрсәтеп, туксанынчы еллар инкыйлабын әзерләүдә зур гына өлеш кертсәләр дә, аны башкаруда урын тотмадылар. Шулай булгач, әлбәттә инде, барышын да яктырта алмадылар. Безнең татар әдәбиятында бу түнтәрешнең билгеле бер баскычын, соңгы фазасын яктырткан бердәнбер әсәр, Ринат Мөхәммәдиевнең "Утлы таба өстендә" дигән романы булды. Аны укып без бу түнтәреш турында күзаллау һәм мәгълүмат алабыз. Чөнки Ринат үзе шул вакыйгаларда кайнаган, аларны оста сурәтләгән дә.

Туксанынчы еллар инкыйлабы, нәкъ Октябрь түнтәреше кебек үк, халыкка, шул исәптән, зыялылар һәм әдипләргә дә зур кыенлыклар китерде. Авыр заман килде, аны сөйләп тә торасы юк, һәркемнең күз алдында. Әмма монысын да кыю төстә әйтергә була, туксанынчы еллар инкыйлабы әдәби агымга бернинди киртә, тоткарлык салмады. Бөтенләй дә киресенчә! Аның нәтиҗәсендә без зыялылар өчен иң кыйммәтле, газиз нәрсәләрне—сүз һәм вөҗдан иреге алдык. Әле кайчан гына безне чикләп торган киртәләр алып ташланды, кысып торган кыршаулар таралып төште.

Мин үзем, шәхсән, менә шушы ирек алынуны туксанынчы еллар әдәбиятының иң зур казанышы дип саныйм. Гәрчә асылда өстән бирелсә дә, уртак казанышыбыз бу. Һәм аның нәтиҗәләре дә калку булып, ап-ачык күренде. "Әдипләребез югалып калды, тема ярлылыгы, ни язарга белмиләр" дигән фаразлар, бәхеткә каршы, дөрескә чыкмады. Киресенчә, соңгы елларда әдәбиятыбыз җанланып, төрләнәнеп китте! Әйтерсең, барысын да тоткарлап торган ниндидер буа ерылды. Әдәбият төрле юнәлештә үсте. Соңгы елларда никадәрле романнар, истәлек-публицистик әсәрләр, хикәяләр, эсселәр, шигырьләр һәм поэмалар, тарихи һәм фантастик әсәрләр иҗат ителде. Санап бетергесез! Һәм тагын шунысы куанычлы: сүз ирегеннән файдаланып никадәр читкә тайпылулар, үзенчәлекле әйтергә омтылып кыланулар булмасын, татар әдәбияты үзенең кыйбласына—халыкка хезмәт итү юлына тугры калды.

Шушы уңайдан һәм соңгы елларда басылган әсәрләрдән әдәбиятыбызның бер казанышы итеп мин Фоат Садриевның "Таң җиле" романын әйтер идем. Гади халык турында, гади кешеләрнең тормышын һәм хезмәтен сурәтләп, аларның язмышы өчен ачынып язылган әсәр бу. Үзәккә гап-гади хезмәт кешесен, хатын-кызны куеп язылган. Чын халыкчан әсәр. Әйткәнебезчә, туксанынчы елларда бик күп яңа романнар, повестьлар, хикәяләр дөнья күрде. Аларның кайсысы казаныш икәнне төгәл генә билгели дә алмассың. Укыганнардан хәтергә кереп калганнарын әйтсәң генә инде.

Соңгы дистә елларда әдәбият мәйданына Гурий Тавлин, Зәки Зәйнуллин, Әнәс Галиев, Суфиян Поварисов, Тәлгат Галиуллин кебек зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, хезмәт юлы үткән, дөньяны танып белгән әдипләр; Флүс Латыйфи, Вахит Имамов, Рафаэль Сибат, Роберт Айзатуллин, Айдар Хәлим кебек яшьрәк, әмма зур сәләт һәм кыюлык иясе булган язучылар килеп керде. Һәркайсы үзенчәлекле тавышы, темасы, дөньяга карашы белән алар әдәбиятыбызның йөзен үзгәртеп, баетып җибәрделәр. Зәки Зәйнуллинның "Ат караклары" романы хәтергә сеңеп кала. Аны укып безнең буын бөтенләй дә белмәгән бу һөнәрнең ярату тарихы, үсеш юллары, ат каракларының яшәү рәвеше турында гаять кызыклы, тулы мәгълүмат аласың. Галим һәм җәмәгать эшлеклесе Тәлгат Галиуллинның шушы авыр замандагы тормышыбызга, анда барган бәйләнешләргә, төенләнешләргә тирәнтен анализ ясап иҗат ителгән "Тәүбә" һәм "Элмәк" романнарына укучылар асылда югары бәя бирде инде. Гурий Тавлинның "Афәт" романы теге каһәрле елларда гади кешеләрнең ни рәвешле бөтенләй хаксызга рәнҗетелүен бөтен фаҗигасе белән күз алдына китереп бастырды.

Соңгы елларда укыган тарихи әсәрләрдән миңа иң охшаганы Флүс Латыйфиның "Хыянәт" романы булды. Ник ошады? Иң кадерлесе шул: роман үзәгендә төрле морзалар, түрәләр, ханнар түгел, ә гади кеше тора. Шул хәтәр

заманда, дәүләтебез, Казан ханлыгы җимерелеп төшкән дәвердә ул вакыйгаларга гади кешенең ничек катнашуы, анда тоткан урыны күрсәтелә. Татар иленә ул заманда гади кешеләр хыянәт итмәгән, азатлыкны саклап калу өчен алар тормышларын җәлләмичә көрәшкән. Каушап калучылар, хыянәтчеләр—түрәләр һәм хакимнәр.

Бу яшьрәк әдипләрдән Рафаэль Сибатның "Исабәт" романы да бик үзенчәлекле.

Безнең күз алдында социализм җимерелеп төште, бөтен бер җәмгыять формациясе яшәүдән туктады. Аның кыйшаю һәм таралып төшү сәбәпләре, бу фаҗиганең җирлеге ничек барлыкка килүе дә әдипләребез иҗатында киң яңгыраш тапты. Әнәс Галиевнең "Җимерелгән хыяллар", Роберт Айзатуллинның "Ирекле тоткыннар" романнары һәм башка күп, бик күп әсәрләрдә без әнә шул фаҗиганең ничек әзерләнүен күрәбез. Хакимият ничек явызланды, халыкка һәм аның ихтыяҗларына карата ничек сансызланды, ә халык исә, үз чиратында, ничек битарафланды. Кыскасы—җәмгыять ничек таркалды—бу әсәрләрдә менә бу сорауларга җавап табып була. Кирәкле, файдалы әсәрләр, үткәнебезне аңларга ярдәм итәләр.

Истәлек-публицистик әсәрләр мәйданга чыкты. Гомере буе колхоз рәисе булып эшләгән Фәйзи ага Галиевнең "Икмәк язмышы" һәм башка әсәрләре, Гариф Ахуновның электә безнең Арчада район Советы рәисе булып эшләгән Тимерхан ага Борһановның тормышы турындагы повестьлары, Ләбибә апа Ихсанованың "Кемгә сөйлим серләремне?" , халык шагыйре Шәүкәт ага Галиевнең "Илһамым—мәхәббәтем" һәм "Минем икенче гомерем" повестьлары гаять кызыклы һәм гыйбрәтле әсәрләр.

Кайчандыр Адлер Тимергалин берүзе диярлек алып барган фантастика жанры да яңарды. Флүс Латыйфи һәм Ринат Якушлар иҗат иткән һәм "Тамга" дигән китапка тупланган фантастик повестьлар моның ачык мисалы.

Монда, урын тарлыктан, Җәмит Рәхимов, Рәфкать Кәрәми, Барлас Камал, Марсель Галиев, Роберт Батулла, Нәбирә Гыйматдинова, Марат Әмирхан һәм бик күп каләмдәшләребезнең акыллы, әйбәт әсәрләре хакында сөйләү мөмкинлеге юк.

Минемчә, туксанынчы еллар әдәбиятының уңай сыйфаты да—нәкъ менә шушы үсеш, төрлелек, җәмгыять тормышын киң колачлау.

Әдәби әсәрләргә бәяне, минемчә, һәркем үзе тоткан кыйбладан, сыйнфый карашыннан чыгып бирә. Миңа соңгы елларда әдәби әсәрләргә үтеп кергән натурализм, тормышның пычрак якларын ачып күрсәтү, гади кешеләр, хезмәт кешеләре язмышына битараф булу охшамый. Максат куймыйча, кызык өчен генә язу. Андый әсәрләр дә бар.

Киләсе гасырда әсәрләребездә гуманлыкка, кешелеклелек, яхшылык, матурлыкка өндәү өстенлек итсен иде. Кешеләр арасында, халыклар арасында тигезлеккә, дуслыкка, хезмәттәшлеккә өндәү зарур.

Миңа калса, әдипнең җәмгыятьтә тоткан урыны үзгәрә алмый. Ул Эсхил, Софокл, Гюго, Стендаль, Пушкин, Толстой, Кол Гали, Мөхәммәдьяр заманнарыннан халыкка хезмәт иткән һәм мәңге шулай булып калыр да.

## Рәфикъ Шәрәфиев:

"Казан утлары" куйган сорауларга җавап бирергә тырышканда, сүз башы итеп, шуны әйтәсе килә: бердәнбер әдәби журналыбыз, проза турында шактый саллы сөйләшү уздырганнан соң бер ел узуга тагын бер бәхәс ачып укучыларына мөрәҗәгать итә икән, димәк, анда милли әдәбиятыбызның бүгенгесе өчен дә, киләчәге өчен дә борчылалар, тыныч түгелләр, димәк, бу хакта гамьләнергә сәбәпләр бар.

Соңгы ун-унбиш елда дөнья күргән, укучыларга барып ирешкән әсәрләрнең теләсә кайсы турында сүз барганда да "әдәбиятыбыз казанышы" кебек үтә олы бәяне куллланудан тыелып каласы килә. Әш, билгеле, узгандагы әдәбиятыбызның

үтә макталган, зур бүләкләр алган күп кенә әсәрләре яңа чор сынавын үтә алмыйча, "казаныш" сүзенең очсызлануында да, әдәби көчләребезнең таланты саегып, уңышлы әсәрләр бөтенләй язылмауда да түгел. Безнең буын кешеләре югары уку йортларында марксистик фәлсәфә фәнен үзләштергәндә иҗтимагый аңның, шул исәптән әдәбият-сәнгатьнең торышын иҗтимагый яшәеш билгеле дип өйрәнделәр. Ә яшәешебезнең, үзебез бик теләп төзешкән җәмгыятьнең бүгенге хәле, әдәп-әхлагыбызның торышы, хакимиятнең фикергә һәм каләм хезмәтенә, халыкның китап сүзенә мөнәсәбәте әдәби казанышлар туугa һич тә ярдәм итәрлек түгел. Һәм без аның нәтиҗәсен әдәбиятның уйга салырлык халәтеннән күреп тә торабыз. Мондый күренешне Әхсән Баянов гади генә итеп "Әдәби хәрәкәтнең болганышы икътисадка бәйле"—дип язды ("Мәдәни җомга"). Зарлы шигъриятне исә, андагы зар кабатланмас илаһи осталык белән җырланса да, бөек диярга тел бармый, чөнки шагыйре мескен дәүләт үзе дә бөек була алмый. Андый чактагы әдәби казанышка куанып бәйрәм итү үзе үк үләт вакытындагы туйдан бүтән нәрсә булмас иде. Заманында Галимҗан Ибраһимовның "Адәмнәр" әсәре язылуга шатлана алучылар булды микән соң? Инде республиканың әдәбият өлкәсендә Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре дә, ялтырап, казаныш буларак туган, бәяләми калу мөмкин булмаган аерым бер әсәргә түгел, күп очракта авторның шул елга кадәрге әдәби эшчәнлеген искә алып бирелә. Соңгы унбиш елны күздән кичерсәк, бүләкләрнең аерым бер әсәргә атап бирелгәннәре өч кенә күренә: Мәхмүт Хәсәновның "Язгы ажаган"ы, Ибраһим Салаховның "Колыма хикәяләре", Ринат Мөхәммәдиевнең "Сират күпере". Араларында "Язгы ажаган"—халык тормышын катлаулы язмышлар аша романга хас киңлек-тирәнлектә оста тасвирлавы белән аерылып тора. Ә соңгы ике әсәр темаларының ул чор өчен бик яңа, татар әдәбиятында әле бердәнбер булулары, яңарыш әдәбиятына кыю юл ярып бирүләре белән күбрәк оттылар, дип беләм.

Укучыны биеккә күтәрә, пакьләндерә, савыктыра һәм яшәргә көч бирә торган әсәр генә чын мәгънәсендә казаныш дип бәяләнергә хаклы түгел микән? Бу фикер янына мисалны рус әдәбиятыннан эзләсәк, шуны күрәбез; әйтик, Валентин Распутинның "Живи и помни", "Прощание с Матерой", "Последний срок" повестьлары соклангыч осталык белән язылсалар да һәм үзләренең коточкыч дөреслекләре белән чәчрәп торсалар да, җәмгыятьнең андый әсәрләр язылуга сәбәп бирүе һич тә куанычлы хәл булмыйча, ә бәлки бәласе, халык фаҗигаседер. Ә фаҗигадә туган талантлар, гадәттә, озак яши һәм бөек әсәрләрне күп иҗат итә алмыйлар, бер балкыйлар да сүнәләр, җәмгыять белән тигезләшеп төссезләнәләр. Менә мисал—шул ук Распутинның әлеге повестьлардан соңгы иҗаты.

Үтә сирәкләр генә үз биеклегендә кала. Бүген әдәби казаныш дип әйтелерлек роман-эпопея, драма, поэма яза алган әдипнең иртәгә тагын да мәшһүррәк әсәр иҗат итәрлек җегәре һәм теләге калса, аның дәвамчылары да күп булса гына әдәби мохит үзен бәхетле саный ала. Ә бездә хәзергә нәкъ шулар юк. Авыр газаплар һәм адәм җаны түзмәслек гаделсезлекләр кичергән Хәсән Туфан нилектән гомер азагына хәтле дәртләнеп иҗат итә алды? Чөнки ул шигъри сүзнең халкына кирәклеген күрде, аннан да бигрәк, Зөлфәт кебек, Мөдәррис Әгъләмов кебек аңа тиң дәвамчылары барлыгына сөенеп, шигъриятнең киләчәге өчен тыныч күңел белән яшәде. Инде, мисал өчен, прозага кыю бәреп кергән Тәлгат Галиуллин "Тәүбә" кебек, "яңа" җәмгыятебезнең үзәген ярып күрсәткән бүтән бер әсәр яза алырмы икән? Татарстан Язучылар берлеге бу романны хәле кадәренчә бәяләп бүләкләсә дә, эш шуннан узмады ич. Беренчедән, һәркемне диярлек куркуга төшергән бу теманы күтәреп алып дәвам иттерергә омтылучы күренми, димәк, автор беркем белән ярышка чыга алмый, ул ялгыз. Ә икенчедән, роман безнең бөтен җәмәгатьчелекне сискәндереп уйга салырга, кирәксә, шау-шу кубарырга, һич югы, тормыш чынбарлыгына туры килми дип, Хәсән Туфанның "Казан утлары"нда чыккан мәгълүм сатирик шигырьләре кебек элекке партия бюросы, хәзерге хакимият утырышларында тикшерелергә тиеш иде. Ә без аны җиңел генә йоттык та җибәрдек: кем күрде, ә кем "күрми" дә уздырды, газета-журнал битләрендә бу әсәрнең тел кытыршылыклары турындагы вак бәхәсләр генә теркәлеп калды. Ә бит җинаятьчел төркем, "милләт каймагы булган мафия"

башлыклары романда үзләрен кемнәр яклаганын, кемнәргә таянуларын ачык әйтәләр. Димәк, "Тәүбә"дә тасвирланган "тормыш"—инде һәркем өчен күптән күнегелгән, беркемнең дә вөжданын борчымый торган, бәхәс тә тудырмаслык гадәти күренеш. Шуңа күрә аны яздың ни дә язмадың ни! Әдәби әсәрне күрми үткәрү, анда язылганнарга кычкырып торган битарафлык белдерү дә язучының иҗат дәртен арттырмый, шунлыктан хәзер болар әдәбиятка мөнәсәбәттә киң кулланыла башлады. "Гөнаһ"ны яза алган Зөлфәт Хәким хәзер кайда, ни эшли, үзенең гөнаһлы каһарманнары арасында гына калмадымы?

Соңгы еллар татар әдәбияты моңа кадәр тыелып килгән темаларга кыюрак алынуы, милләт һәм дәүләт язмышын, иман яңартуны үзәккәрәк куеп язуы, фикерләве, тарихи темаларның җанлануы белән үзенчәлекле булды. Чөнки бүгенгене аңлау өчен үткәннәребезне тирәнрәк белергә кирәк иде. Ә нәрсәләр белдек тә, бу мәгълүматлар безне ни дәрәҗәдә куандырдылар соң әле? Кешеләр авыр сугыш елларында да бүгенге кадәр өметсезлеккә төшмәгәннәр, иң хәтәр чорларда да аңлы баштан бер-берсен хәзерге кебек үтерешмәгәннәр, әдәп-әхлак бу кадәр тапталмаган—узганнарны тасвирлаган әдәбият безне әнә шуларга ышандырырга омтылды шикелле. Әмма безнең әдипләр халыкның үткәне белән көлә-көлә аерылышырлык җегәр тапмадылармы, данлы дәүләтен югалткан халыкның фаҗигасе бик тирәнме, алар әнә шул фаҗигане төрле яклап күрсәтү белән мавыктылар. Соңгы еллар әдәбиятыннан Зәки Зәйнуллинның "Ат караклары" романы һәм "Үрләр аша", "Каршы таулар" повестьлары, Зөлфәт Хәкимнең "Гөнаһ" романы, Таһир Нәбиуллинның "Качкын"ы, Фәүзия Бәйрәмованың "Кара урман"ы, Мансур Кашаповның "Кара язмыш"ы, (элек әдипләр "Ак төннәр", "Ак чәчәкләр", "Саф күнел" дип язалар иде, хәзер исемнәрдә үк тормыштан күчкән шомлы каралык, караңгылык, гөнаһлылык!), Туфан Миңнуллинның кайбер драмалары (бу әдип бик килештереп көлә дә белә)—шундый әсәрләр рәтеннәндер. Ләкин тормыш көтелмәгән яклары белән үзгәреп тора. Әсәрендә халыкның үткәндәге авыр язмышын күрсәтүгә юнәлеш алган әдип, мәсәлән, менә бүген, үзебез теләп, яулашып алган чынбарлыгыбыз узгандагыдан да караңгырак һәм хәвефлерәк булып әверелгәч, нәрсә уйларга, ни язарга тиеш? Һәм менә нәкъ шушы чиккә—бүгенгебезгә ачыграк күз белән карау ихтыяҗына килеп житкәч кенә, үткән көн темаларына язган әсәрләре өчен мактылып һәм бүләкләнеп килгән әдипләр җәмгыять өчен кирәксез булып әвереләләр. Татарстанның төп китап нәшрияты туктау хәлендә, чөнки аны беркем финансламый, үләм-калам гына чыгып килгән газета-журналлар еллар буе каләм хезмәтенә түли алмыйлар, "шигырь укып кинәнәсе малай кастет игәгәндә" (Зөлфәт сүзләре), җәмгыятьнең әдәбият кайгысы юк. Яңа чор, яңа алдану әдипне шулкадәр бутады, тәвәккәлләп заман темасына тотынса да, "кай жиреннән мин моны, дим, ләктерим" (Г. Тукай сүзләре) диярга гена калды. Милли әдәбиятның үзегенә куеласы омтылыш—дәүләтчелегебезне торгызу—бөтен халык эше булып әверелмәде, халык, нигездә, вак гамьнәр чолганышында яшәвен дәвам итә, димәк, милләт каһарманнарын, зыялыларны халык аңламады, китаптан да ераклашты. "Иң якын перспектива—иртәгә ничек ашарга табу уе белән яшәгән кеше—иң көчсез кеше",—ди Виктор Гюго. Көчсезләрне язучы әдәбиятның көчле була алуы икеле, ул халык рухы белән бергә генә биеккә күтәрелер иде.

Татар әдәбиятының киләчәге турында уйланганда, бер фоторәсем күз алдына килә. Чардуганлы яңа кабер, аның янына мәрхүмнең туганнары һәм дуслары тезелгән, алар әле генә әдип Фәрваз Миңнуллинны җирләгәннәр. Әдипнең элекке хезмәттәшләре—Рәис Даутов, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Харрас Әюпов, ул чактагы директоры, әдәбият галиме Харис Әшрәфҗанов—читкәрәк урнашканнар. Китап басучылар Татарстанның иҗтимагый тормышыннан да шулай читтә инде хәзер.

Рәсемдә иң тетрәндергәне—Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның карашы. Өлкән әдип алгы планга чүгәләгән, ә калын пыялалы күзлек аша зураеп ачылган күзләре сагышка батып билгесез ноктага бакканнар. Бу күзләр шуннан элек кенә халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевны мәңгелеккә карап озатканнардыр. Чиратта кем? Безнең гамьнәребез кемнәргә кала, күтәреп алып китәрлек яшьләр кайда соң?—дип уйлыймы ул. Миргазиян Юныс сүзләре күңелгә

килә: "Чын язучылар... әзәя баралар. Бәлки, бу җәмгыятьтә берзаман бөтенләй бетәчәкләр".

"Бу җәмгыятьтә!" Татарстанның әдипләре, зыялылары зур өмет белән алышкан азмы-күпме мөстәкыйльлеге, рухыбызның читлектән котылуы инде кемнәргәдер иркенлек, тормышларын үзләренчә кору мөмкинлеге китерсә дә, нәкъ шунысы каләм хезмәтендәгеләр өчен тыелган җимеш булып чыкты. Зур хыяллар белән кадерләп үстергән баласында өметләре акланмаган ата-ана бәхетсезлегенә тиң иде бу. Җәмгыятьне савыктырабыз, югалган дәүләтчелегебезне торгызабыз, телебез һәм көй-моңнарыбыз, әдәбебез һәм милли әхлагыбыз үз урынын ала, милләт табигый үз асылына кайта—мәдәниятле кешеләрчә яши башлыйбыз, дип өметләнгәндә, татарны шушы казанышларга илтәчәк һәр гамәлне хуплап, хәленчә өлеш кертеп килгәндә, барысының да диярлек мираж гына булуын бөтен ачылыгы белән аңлау, инде ят кавемнән генә түгел, үзебезнекеләрдән дә алдану әдәби хәрәкәткә дә нык удар ясады.

Инде халыкны кая чакырырга? "Бетте көч, сынды кылыч..." Әдип тә бит—кеше, җитмәсә, аның да тиз яраланучан нечкәрәк җанлысы. Бөек Тукай "җырлап торам, торган җирем тар булса да" дип язган икән, бу әле тарлыкта, кысынкылыкта иҗат итү рәхәт дигән сүз түгел. "Курыкмыйм, сөйгән халкым татар булса да"—дип дәвам иттерәме шагыйрь? Үз халкының авыр үткәненә сызланулы тәнкыйть аша караулары белән бер-берсенә шактый якын торган Солженицынны руслар пәйгамбәр урынына күтәрсәләр, без—кыерсытылган үзебезнекеләрне кыйнарга яратучылар—Миргазиян Юнысны тагын бер типкәләп кенә узабыз. Мисалы—Сәгыйть Хафизов мәкаләсе. Галина Старовойтованың һәлак булуына урынлы сәяси бәлдерү белән чыккан әфәнделәр үзебезнең Сүрия Усманованың милләт язмышы турында ихлас борчылуларына ник колак салмыйлар?

Җәмгыятьтә ун еллар элек башланган "җылы" яңарышның чагылышын бүгенге әдәбиятта күрәбез. Әмма яңарыштан соң әле килгән торгынлык һәм чигенеш иртәгәге әдәби хәрәкәттә ничек гәүдәләнер? Егерменче гасыр башының җепшек җилләре, ирек тою әдәбиятны да җанландырып, Тукайларны биргән дә бит, яңа йөзьеллык башында да шундый хәл кабатланыр дип көтә алмыйбыз ич! Көткән яңалыгыбыз Россиядә тагын бер революция сыйфатында килсә—иң хәтәре. Чөнки тәмам шәфкатьсезләнгән, өметен, кыйбласын кат-кат югалткан җәмгыятьнең җимергеч тетрәнүеннән соң нинди дер уңай күренешнең исән калып игелек тудыруы икеле. Бу юл безнең өчен түгел.

Якын киләчәктә әдәбият бүгенгебезне язуга йөз тотар, нәкъ шушы хәл аны укучыларына да кабат якынайтыр. Бу җиңел булмас, тормышта да, әдәбиятта да уңай каһарман юклыгын Мәгъсүм Хуҗин "Тар тыкрык сукмагы" исемле зур хикәясендә оста күрсәтте.

Тик менә татар милләтен рухи савыктыру, мәдәниятен һәм милли мәгарифне үстерү, дәүләт мөстәкыйльлеген ныгыту өчен реаль тормышта Фәндәс Сафиуллин, Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Рәфис Кашаповлар кадәр генә көрәшкән һәм нәрсәдер эшли алган каһарманнар да әдәбиятта юк әле. Андыйларны язу өчен нигә тагын җитмеш ел көтәргә? Вакытлы матбугат үзәгендә исә—нәкъ шуларның тискәре яктагылары. Хөкүмәт үзе үк җегәрсез, өнсез калдырган әдәбиятны җанландыру чарасына да керешер, чөнки халыкның рухи савыгуы, Татарстанның ирекле, имин, демократияле, иҗатта кайнап яшәве чыннан да кирәк булса, бу юлда каләм ияләре—аларның бердәнбер юлдашлары әле. Чорыбызның төп темалары буенча ел саен әдәби иҗат бәйгеләре үткәрергә кирәк, моңа бер автоузыш акчасы да китмәячәк.

Кешелекнең яңа гасыры рухыбыз пакъләнә бару белән бергә башланыр. Өметләнергә һәм гамәленә керешергә! Халык язучыларының сагышлы карашлары каберләр янында гына калсын.

*Сәнгать*

**Шамил Монасыйпов**

# УРМАНЧЕНЫҢ РУХИ ДӨНЬЯСЫ

*Күңел багладым эшем уңасына,*
*Тәвәккәл иттем Кодрәт иясенә.*
*Өметем камил, ышанычым нык*
*Бу фәкыйрьгә бәхет иңәсенә.*

Бакый Урманче.

## "Sapienti sat—серне белгән аңлар"



Җитмешенче еллар уртасында Казанда рәссам Бакый Урманче йортында үзенчәлекле бер музыкаль-әдәби сәнгать салоны оешкан иде. Бакый аганы хөрмәт иткән татар язучылары, музыкантлары, шагыйрьләр, рәссамнар була иде анда. Картиналар, график рәсемнәр, сыннар арасында көй, шигырьләр яңгырый, әңгәмәләр бара. Болар барысы да күңелгә бер рәхәтлек бирә, көндәлек мәшәкатьләрдән арынырга, олуг аксакалның бөек фикерләр агымына кушылырга мөмкинлек тудыра иде.

Кичәләрнең берендә Бакый ага ниндидер шатлыклы, үзгә бер халәттә иде. Моңа Чыңгыз Айтматовның үзәк матбугатка биргән интервьюсы сәбәп булган икән. Танылган язучы һәм ул чакта КПСС Үзәк Комитеты әгъзасы халык алдында ясаган әлеге чыгышында, "мин үзем коммунист булуыма карамастан, кешенең үлемсез өлеше бар дип ышанам, ул—кешенең җаны булса кирәк",—дип әйткән. Бу фикер фәнгә каршы килгән идеалистик теория буларак, ул заманнарда коммунизм идеологлары арасында фетнә дәрәҗәсендә кабул ителде. Әмма ул фетнә җәмгыятьнең рухи ярлылыкка, хаҗәт үтәүчелеккә авышканлыгын газапланып кичергән Урманче фикерләре белән аваздаш иде.

Бакый ага озын гомерле булды. Ул унтугызынчы гасырның азагында туып, егерменче йөз еллыкның бөтен бөек үзгәрешләрен күргән кеше. Рәссам 1905 елгы революциядән соң якты идеаллар һәм демократик ирекләрнең чәчәк атуына шаһит булган. Аннары, коры материализмга, алдашуга корылган заманда да Бакый ага үткәнгә җанлы күпер буларак яшәде. Урманче үзенең бер өлеш гомере белән татар мәдәниятының тәнзимат—якты үзгәрешләр вакытына карый. Ислам традицияләрен иске рәвештә үзләштерүнең мең еллык тарихы йомгакланып килгән чак иде бу. Аңа алмашка догматик ноктадан тагын да күтәренкерәк булган, "Мин-аң"ны формалаштыручы көчләр килде. Алар кешенең чын бәйсез индивидуальлек алуына юл ачканнар. Ул индивидуальлекнең үзаңы, ачык логик һәм фәнни фикер йөртүе, тулы иҗат иреге һәм үз эшчәнлеге өчен дөнья каршында җаваплылыгы булырга тиеш. Яңа дәртле омтылышлар дини тормышта, милли сәнгати сүздә, профессиональ музыкада чагылыш тапты һәм татар халкының иң олуг шәхесләре Мәрҗани, Тукай, Сәйдәш исемнәре белән бәйле булды.

Язмыш Урманченың үзенә дә реформатор вазифасын хәзерләгән булып чыкты. Ул татар мәдәниятында үз-үзенне танытуның яңа тибын булдыруга нигез салды, сынлы сәнгать ярдәмендә рухани идеалларны күрү, тою мөмкинлекләрен ачты.

Бакый ага иманушынча, чиксез киң һәм серле кеше яшәеше нинди дә булса күзаллаулар системасында аңлатылып бетә алмый. Талантлы сәнгать иясе дөньяның серләренә тирәнрәк төшенә. Инсан рухы тудырган бөек сәнгать әсәрләрендә кешеләргә янадан-яңа тирәнлекләр ача торган образлар яши. Әсәрнең чын мәгънәсендәге әһәмияте әнә шулар белән үлчәнә дә. Мондый карашларны Урманче кешелек дөньясында катлаулы эчке сынаулар кичереп, танып-белү процессының асылына төшенә алган бөек шәхесләр белән уртаклаша иде. Алар фикеренчә, хәзерге заманның дөньяви фәннәре кешенең эчке асылы хакында канәгатьләнерлек белем бирә алмыйлар, аны сәнгать алымнарыннан башка тирәнрәк өйрәнеп булмый.

Бакый ага яратып укыган Аурупа шагыйре Гете да сәнгатьне практик фән дип саный. Үзенең эзлекле гыйльми фикерләвен, нечкә зәвыклы рухи сәләтләрен үстерүче художник алдында табигатьнең яшерен кануннары ачылганлыгын әйтә. Матурлыкның шушы кануннарына үтә алып, илаһи иҗатка ияреп, рәссам яңа әсәрләр булдыра, сәнгатьне культ дәрәҗәсенә, дини хәрәкәт дәрәҗәсенә күтәрә, аңлау актыннан әхлакый башлангыч, әхлаклылык алып килүче эшчәнлеккә күчә.

Сәнгати дәртләр цивилизациянең дүрт тармагы фән, сәнгать, дин һәм әхлакның берләшүенә ярдәм итүче беркеткеч чылбырларның берсе булып тора. Аларның уртак тамырына төшү тормышыбызны дөрес кору өчен кирәк. Шуңа күрә фикер иясе-рәссам җәмгыятьне үзенә җәлеп итә. Дөньяны бары аң белән чикләнеп кенә кабул итү мәктәбен узган кешеләрне ул үзе артыннан алып бара. Бакый ага нәкъ шундый кешеләрдән иде. Аның янына гаплэшергә, нәрсә турында булса да аның фикерен белергә, иҗат әсәрләрен күрергә дөньяның төрле төбәкләреннән кешеләр агылып торды. Алар һәммәсе сәнгаткярләр генә түгел, дин әһелләре, сәясәтчеләр, галимнәр, гади эшчеләр—төрле профессия һәм катлам кешеләре—үзләренең сорауларына җавап, нинди дер күтәренке рух, иҗатка җегәр табып китәләр иде. Үз тарафыннан оста кай яклары беләндер игътибарны җәлеп итә килгән кешеләр сурәтләрен кәгазь, агач, таш, йә балчыкка күчереп калдыра иде.

Бакый Урманче бай сәнгать мирасы калдырды, әмма ул үз иҗаты турында аз сөйли иде. Совет чорында яшәү аркасында, үз карашларын ачыктан-ачык белдерү мөмкинлеге булмаудан гына түгел бу. Оста аннан курыкмый да иде. Ул күп мәгънәле образларын бәһа төшерәчәк абстракт фикерләү төшенчәләренә күчерергә теләмәде. Сынлы сәнгать әсәрләрен сыйфатлаганда, Бакый ага гадәттә мифик образлар, дөньяның илаһи килеп чыгышын читләтеп әйтүләр аша аңлата. Музыкаль образларда да шундый ук эчтәлек тапканга, ул еш кына аңгәмәләрне җыр, скрипка уйнау белән тәгәлли һәм, шуның белән, фәлсәфи сорауларга җавапны кеше асылының тирәнлекләреннән эзләргә кирәклегенә ишарәли иде. Туксан яшенә багышланган юбилей кичәсендә Урманче үз иҗатын борынгы грек мистерияләреннән алынган “Сапиенти сат—серне белгән аңлар” гыйбарәсе белән сыйфатлады. Бу—аның иң яраткан афоризмнарыннан: рухият өйрәнүчеләр (духовидцы) теләндә илаһи белемнәр серенә якынайган галим генә әйтелгәннең чын мәгънәсенә барып җитә дигәнне аңлата.


*Тукай. Мәрмәр.*

Рәссамга нинди серләр ачык, аны нинди рухани көчләр туендыра һәм аның аркылы татар мәдәниятенә үтеп керә соң?

## Рухи шәкертлек

Мулла гаиләсеннән чыккан Б. Урманче дини белем нигезләрен башта әтисе Идрис хәзрәттән, аннан соң “Мәдрәсәи Мөхәммәдия”дә ала. Бу мәдрәсә XIX-XX гасырларда татар дини мәктәпләре арасында әйдәп баручылардан санала. Элеккерәк заманнарда мәдрәсәләр чын-чынлап рухият үзәкләре булган, сайлап алынган укучылар гына дөньяны танып белүнең мистик ысулларына якынайтылган, аерым кешеләргә

генә аңлашыла торган ислам серләренә багышланганнар. Аларны "китап ачучы", "күрәзәче" (ясновидящий), ишан һәм башка рухият дәрәҗәләренә ирештерә торган булганнар. Әлеге тәрбиянең элементлары "Мөхәммәдия"дә дә сакланып калган. Ләкин дини белемнәр бирү белән бергә, анда дөньяви фәннәр дә укытылган, бу аны берникадәр Аурупа колледжларына якынайткан.

XX гасыр башында инде мәдрәсә "сер багышлау" баскычына күтәрелмәгән, әмма абруйлы остазларын хөрмәтләгән, дәреслеккә, хакыйкатьне танып белүгә омтылырга тырышкан. Тәрбия инде борынгы грек заманнарыннан ук килгән "дөньяны танып-белү өчен үз-үзеңне өйрәнү" девизы астында алып барылган. Укучының игътибары иң әүвәл үзенең эчке асылына һәм берникадәр тышкы вакыйгалардан читкә юнәлтелгән. Бу исә башка мәктәпләрдә башкача һәм алай ук көчле үсмәгән фикер, хис һәм ихтыяр көчләрен ныгыткан. Шулай итеп, мәдрәсә шәкертләре "рухани багым", "алдан күрүчәнлек" ярдәмендә башка дөньяны сиземнән тыш күрүгә юл ачучы гадәттән тыш көч тапканнар. Мондый хәл дөньядан аерылуга китерми, киресенчә, социумда актив эшчәнлек алып барыр өчен әхлак импульслары бирә. Б.Урманче "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе турындагы мәкаләсендә "аны тәмамлаучылар XIX гасырның икенче яртысы һәм XX гасыр башында татар интеллигенциясенең асылы иде", дип яза. *(Б. Урманче. Чыкса мәгърифәт кояшы.—Казан, 1992.)*


*Сөембикә. 1980 ел. Агач.*

1917 елгы инкыйлаб вакыйгалары мәдрәсә һәм аның шәкертләре язмышын кискен үзгәртеп җибәрә. Соңрак репрессияләр дә Бакый ага Урманчены читләтеп үтми, әмма ул ирекка чыгарга насыйп булган аз санлы бәхетлеләр арасына эләгә. Әти-әниләре, дин юлыннан китәр, дип фаразласа да, Урманче рәсем сәнгатен сайлаган. Әлбәттә бу җиңел бер сайлау да түгел. Дөресрәге, бу—грандиоз карар. Милли традицияләргә, дини догматларга, ниһаять, гаилә кысаларына революцион, инкыйлаби гыйсъянчылык карары. Профессиональ сынлы сәнгате булмаган илдә беренче ныклы адым ясау карары иде. Бу сайлау очраклы да түгел, чөнки Урманченың профессиональ җырчы булырга да мөмкинлекләре зур булган: менә дигән вокаль сәләт, сәхнәви күренеш, музыкант буларак та шактый танылган. Шулай да балачактан ук аны башка нәрсәләр үзенә тарта.

Ерак балачагыннан бик тә символик бер хатирә сакланган. Ул үз иптәшләре белән берлектә авыл тормышында кирәкле булган һөнәрчелек белән кызыксына башлый. Бигрәк тә итекче, читекчеләр хезмәтен сәгатьләр буе карап тора алуын сөйли иде. Әмма ул инде башкалардан аермалы буларак, йорт кирәк-ярагы урынына скрипка ясый. Һәм мөселман дөньясында танылган мулла, әтисе Идрис хәзрәт, әлеге уен коралын табып ала да аны челпәрәмә китерә. Егетнең гадәттән тыш омтылышлары һәм әтисенең кадими карашлары арасындагы конфликтта яңа заман сулышын тоярга мөмкин һәм бала киләчәктә дини тирәлектән китеп бара. Догмалардан азат, ачык кузаллаулар, "мин-аң" формалаша. Мәдрәсәдә һәм соңрак гимназиядә табигый-фәнни ысулларда тәрбияләнгән фикерләү рәвеше Урманченың рухани сәләтен үстерүгә этәргеч бирә.

Гете: "Табигать үзенең серләрен кемгә дә булса ача башласа, ул кеше табигатькә лаеклы аңлатма бирүче сәнгатькә җиңеп булмаслык омтылыш сизә", дип язган. Урманчега әнә шул серләр ачыла. Үзенең кырык яшьлек тормыш сызыгына килгәндә, ул инде сиземнән тыш булган дөньяны да анык кабул итә. "Идел серләре" шигырендә ул гадәти булмаган рухи кичерешләреннән берсен тасвирлап, болай ди:

Мин бер төн,
Гаҗәеп айлы төндә,
Төш түгел, өндә,
Аек өнемдә
Иделнең биек яры үзәрендә,
Күкрәгем куеп яр күкрәгенә,
Бер сагыш җыйдым сызлар күңелемә.
Күңел инде Иделнең күк серләренә,
Акрын агым, акрын гына уйга талдым.

Тирәмдә табигать тынга калды.
Ялгыз алма багларында сандугачлар
Чытланышып, назланышып, сызланышып,
Ниндидер дәртле аһәң моңлап алды.
Мин шунда, шул урында төнгә калдым.
Бер вакыт яр астына энҗе комга -
Вак гәрәбә ташларга күзем салсам,
Судан чыгып, бер гаҗәп бәндә яткан.
Бәндә түгел, ничек әйтим, әйтә алсам:
"Су патшасы".
Алып кебек, Коркот кебек карт, чаларган,
Дәү гәүдәсен гәрәбәдәй комга сузып, тынып калган.
Адәм дисәң, адәм түгел, кул-аяксыз.
Балык дисәң, балык түгел, бүксәм—кеше,
Адәм сыман булса да, бар мөчәсе,
Балык сыман күренә кайбер төше.
Бүксәме (күкрәге) адәм сыман
Булса да, балыкка охшаш түше.
Әмма чырай, сакаллар—шундый адәм
Сыйфатлы, бөтенләй, тәмам кеше!
Минем сиңа сыйфатлаган бу сурәтем
Бу мәхлукның күрсәтә бары тышын.
Белмим, кем ул, ни эшли ул, нинди җаны?
Куркынычмы, түгелме? Белмим эчен.

Урманче, "су патшасы"н күреп, югалып калмаган. Алдан күрүчәнлекнең беренче баскычы булган имагинациядә торган ул. Образларны шул рәвешле кабул итү аны предметлы дөньяның тышкы күренешләре артында торучы объектив көчне күзәтә алырлык иткән. Әлбәттә бу аның фантазиясе дә, галлюцинация дә түгеллеген яхшы аңлый ул. Мондый күзаллаулар барлык рухият мәктәпләрендә "Китап ачучыларның" башлангыч баскычларына туры килгән.

Имагинатив сәләт пластик сынлы сәнгатьтә аерым бер әһәмияткә ия. Ул элекке заманнарда грек һәйкәлтарашларын хәзерләүнең алшарты хисапланган. Сәнгаткярләрдә төп рухи көчләрне тулысынча кулда тоту күнекмәләре булдырылган. Иҗатчы, шәхси симпатия-антипатия хисеннән аерылып, сафлыкка ирештерүче төрле сынаулар аркылы уза, катарсис, пакьлану кризисын кичерә һәм, физик җисемне формалаштыручы тормышның чын көчләрен күрә башлый, безнең тышкы карашыбызга ачылган нәрсәләрне генә теркәүдән туктый.

Һәйкәлтараш медитациядә үз фикерләре белән балчык кебек күреп эш итә. Әзер тәгълиматларны кабул итү белән генә канәгать булмыйча, һәрнәрсәгә иҗади якын килә һәм һәйкәлне конкрет кеше копиясе итеп түгел, бәлки гомумиләштергән образ буларак ясый. Ул үзе аркылы үтеп кергән Бөек Замана Рухының таләпләрен үти.

Шәкертләрне татар мәдрәсәләрендә "хәзерләү" билгеле бер дәрәҗәдә грек скульптура мәктәбе тәрбиясенә охшаш булган. Бервакыт Бакый ага безгә, ягъни үзе янына йөри торган яшьләргә, борынгы тәрбия элементларының скульптор хезмәтенә йогынтысы нинди булганны күрсәтеп бирде. Аксакал яшь Тукай скульптурасын ясый иде. Безнең балчык изү, гипстан формалар кою кебек "кара" эшләргә ярдәм итүебезне үтенде. Без инде бик үк теләмичә һәм мәңгелек эш киеме—алъяпкычларны да кимичә тотынуыбызны күргәч, авыл мәдрәсәсе хәлфәләренең баланы укуга алганчы ук иң авыр кара эшләр башкаруларын таләп итеп, һәр эшкә мәхәббәт, намуслылык тәрбияләгәннәре хакында сөйләп алды. Татар һөнәрчеләре династияләрендә һәрбер өйрәнчек, шул исәптән аның үз бабасы—киндер буяучы Хәсән карт Урманче да шундый тәрбия күргән. Урманче үзе дә балачагында хезмәткә шундый эчкерсез бирелгәнлек мәктәбе уза һәм нинди дә булса түләү көтмичә, Муза хакына иҗат итә. Менә шуннан да аның искиткеч хезмәт сөючәнлеге, эшләренең саллылыгы, эгоистик мәнфәгатьләр белән арусызланмаган саф фикер йөртүе. Рәссам шулай ук эчке сафлану процессы да уза. Урманче, Сталин лагерьларының сынауларын кичеп, усалланмый, явызлыкны кабул итми, эчке чистарыну, катарсис баскычын да үтә һәм кешеләргә миһербанлы, объектив караштa кала. Болар барысы да аңа яхшы әсәрләренең эчтәлеген билгеләгән имагинатив образларны кичерү, дөньяның фактларын гади тою юлыннан тыш та кабул итүләр мөмкинлеге ача.

## Иҗат призмасы аша карагандa Урманче рухияты

Урманченың иҗади эшчәнлеге искиткеч күпкырлылыгы белән аерылып тора. Ул үз эченә сынлы сәнгатьне генә (нәкышь, скульптура, графика) түгел, архитектура, каллиграфия, текстология, публицистика, тәрҗемә, педагогика, шигърият һәм музыкаль башкаруны да ала. Аның шигырьләре—рәссамның эчке дөньясын яктыртучы шигъри көндәлек ул. Шуңа күрә, Бакый аганың сынлы сәнгатькә кагылышлы мирасын өйрәнгәндә, әлеге көндәлекләрнең әһәмияте зур.

Останың эшчәнлеге төрки телле биш халыкның—татар, башкорт, казакъ, үзбәк, уйгур мәдәнияте белән бәйле. Аларның тамырлары, үз чиратында, Көнчыгыш цивилизацияләренә алып чыга. Азиянең бөек рухи агымнары аның әсәрләренә үтеп керә. Алар арасында ислам универсумы идеяләре аерым урында. Дөрес, алар рәссамның төп асылын тәшкил итә. Әйтик, гарәп графикасында уку, язу татарча мең еллап элек үк, ягъни ана сөте белән кергән цивилизация булганга, бу гасыр башындагы ул хәреф тыелуын, бер үк вакытта каллиграфия сәнгатенә өлеш кертә алмавын да Урманче авыр кичерә. Җандай яраткан күркәм язу стильләре сөлс, тәгълик, куфи һ.б. буенча 1960 елларда Казан университетында дәрес тә биреп йөрде. Ә 1936 елның 24 июлендә исә шул стильләрнең берсенә мәдхияне ул эзоп теле белән—хатын-кыз матурлыгына соклану итеп язган.

### Тәгълик

Нинди садә вә назлы сызыклар!
Сылу билләр,
Акрын-акрын йомры күкрәк калкулары,
Җәя киергән күк кыйгач кашлар
Вә кискен кара керфек ялкыннары,
Кара бөдрә чәчләр
Зифа иңнәренең үзәрендә.
Матур беләкләр, нәфис беләзек
Вә сылу бармаклар.
Аларның нәзек, назлы очларында
Асылташтай аллы тырнаклар!
Нинди шук вә хуш аһәңле
Шигырь әйтүләр вә сүзләре!
Чайкалып, чытланып йөргән чакта
Ритмик адымлар!
Шашындырыр янбашлары!
Нинди нәфислек хуҗалары—ул аяклар
Вә аларны бизәгән башмаклар!

Сүз белән ясаган бу сурәтне Урманче сынлы сәнгатьтә гомере буе, аеруча Дәрдмәнднең "Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан" шигыренә ясаган бик күп вариацияләрендә кабатлый.

Көнчыгыш күзаллауларында дөньядагы һәр нәрсәне образ-символлар аркылы аңлату бар. Кояш, ай, йолдызлар, җирдәге һәр тере һәм тере булмаган байлык, ниһаять, кеше үзе, аның сөйләме, хисләре, фикерләве, ихтыяры—барысы да билгеле бер рухи баскычлар сурәте буларак карала.

Урманче көнчыгыш мистик тәгълиматның апологеты түгел иде. Иҗатын яшерен дини серләрне чагылдыруга багышлау теләге дә булдымы икән? Әмма ул тәгаен шушы мәдәният рухында яшәгән. Әлбәттә, ул ислам эзотерикасы сурәтләре белән дә таныш. Алдарак телгә алынган "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе хакындагы мәкаләсендә дә Бакый ага Тукай шигырьләреннән алган бер серле сурәткә туктала. Әлеге шигырьдә кояш көнбатыштан чыккач, Ахырзаман килә, диелә:

Чыкса мәгъриптән кояш, шунда заманның ахыры,
Бу—китапларда язылган күп галәмәтнең бере...

Бүгенге көн интеллектуаль күзаллаулары багымыннан караганда, мондый сурәт әдәби уйдырма буларак кабул ителергә мөмкин. Суфичылык күзлегеннән эш йөртсәң, монда сүз оккульт сер турында бара. Ул исә җирнең физик юкка чыгуы котылгысызлыгын

сөйли. Ахырзаман, кешеләр физик, шул ук вакытта рухи, димәк, икс дөньяда да тигез рәвештә яши алганда гына житәчәк. Алар инде бу вакытта, төнлә "мәгъриптән", кире яктан Кояшның рухи субстанциясен көзгедә сыман күреп, гадәти тоемлаудан югары торган дөньяда аңлы рәвештә яшәү сәләтенә ия булачак. Суфыйларда төнге намазда яки төштә кояшны күрү кешенең "күрәзәче" баскычына ирешүе дип исәпләнгән. Кеше белемнәренең яшерен серләрен чагылдыручы мондый үзенчәлекле символика аңлы рәвештәме, табигый гынамы, Бакый Урманче тарафыннан кулланылган. Мөгаен, ул моны төгәл төшенчәләрдә аңлатып та бирә алмас иде. Шулай да, аның әсәрләрен күз алдыннан кичергәндә, аларда физик вакыйга һәм күренешне чагылдырудан зуррак нәрсәләр дә бар икәнен аңлыйсың. Ул нәрсәләр кешегә сиземнән тыш дөньяны белү һәм кабул итү юлларын ачу, үлемсезлек, кеше аңын баету идеяләре белән бәйле.

Урманче иҗатында халык темасы мөһим урын алып тора. Ул аның кайгыборчулары белән шәхси омтылышларын үлчи.

Кайгым бер, сагышым бер һаман:
Халкым, бул! Илем, бул аман![1]

Әлеге теманы ачканда "Салтык болыны", "Башкорт авылы" ("Колхоз ындыры") картиналарында, рәссам хезмәт бердәмлеген оешкан берлек, төзек көйләнгән организм итеп аңлата. Кешеләр киемендә, кәефләрендә, хәрәкәт динамикасында шундый гаҗәеп гүзәллек, көч, гармония хөкем сөрә ки, алар үзебезнең җаннарыбызда бары тик макрокосмик тәртип белән генә ассоциацияләнә ала. Бу кичерешләр Урманче шәмаилләренең берсендә чагылган сурә белән бик тә аваздаш: "Аллаһе җәмилен, хөббел җәмал" (Аллаһе гүзәл һәм гүзәллекне ярата, дип тәрҗемә итә иде үзе).

Кешеләргә ни өчен үзара дус һәм туган булу бәхете язмаган? Башкаларның уңышына сөенү сәләтен үзеңдә ничек булдырырга? Бер-береңне ярату, кызгану хисе каян килә? Социаль темага мөрәҗәгать иткәндә, рәссам әнә шундый сораулар алдында кала:

Дустлар белән утырганда, күңел гөрли...
Картлыклар, авырулар онытыла.
Нигә соң бик күпләр белми моны,
Дошманлык казганып йөри һаман?

Бу сорауларга җавап конкрет рәвеш ала: үз-үзеңә "дөньяда мин генә" дип карауның иң чик дәрәҗәсе, акыл адашулары, кеше хәленә керүнең юкка чыгуы—бердәмлеккә каршы торучы көчләр шулар. Рухани дөнья белән бәйләнешеңне, үзеңнең галәми табигатеңне аңласаң гына, тормыш турында космик масштабта фикер йөртсәң генә бу каршылыкларны җиңеп була. Кеше әхлакый биеклекләргә омтылганда гына үзен эгоцентрик индивидуальлек буларак кабул итүдән югары күтәрелә ала. Җир материализмын моңа каршы юнәлештә үстерү социаль дөнья бетүгә китерә.

## Җугашвили (Сталин) үлгәч.

Исрафил сурны өрде. Ватылды туп.
Мәхшәр купты, халыклар калыктылар.
Дошман саиб куркышып йөргән халык,
Дуслашып, танышып кавыштылар.
Юылырмы нахакка түгелгән кан?!
Тынычлык табармы зурланган[2] җан?!
Кыз—анасын, ата—углын табып, янә
Тату яшәү юлларын карадылар,
"Без барыбыз туган икән", диештеләр.
Күңелләр тынычланып килештеләр.
Дошманлашып күнеккән бәхетсезләр
Дошманында дуст табып сөештеләр.
Чыраенда гел хәсрәт, курку йөзләр.

---

1. Б у л  а м а н—була азат. Чагыштыр: "Идегәй" дастанында—әл аман бул миннән соң". Бәлки бу шигырь 1942 елда язылган, 1997 елда беренче тапкыр күргәзелгә "Туктамыш" аквареле белән дә бәйледер.
2. З у р л а н г а н—җәберләнгән.

Шатлыктан елмаешып көлештеләр.
Бергә-бергә кумәкләшеп яшәр өчен,
Ил төзәр өчен кулларын бирештеләр.

Урманченың иң әһәмиятле әсәрләреннән саналган "Татарстан" триптихы үз халкының киләчәге, бердәмлеге турында уйланулар буларак туа. Бу әсәрнең өч казыгында бүгенге мәмләкәтебезнең нәгыйшь "картасын" тасвирлап, рәссам тормыш реалияләре аша милли мәдәниятнең тирән агымнарына күз сала. Һәр өч картинаның үз мәгънәви үзәге бар, алар газиз гыйбадәтханәләр аркылы бирелә. Триптихның кырый канатларында болгар башкаласының борынгы һәйкәлләре һәм православие чиркәве белән Свияжск бистәсе. Ә үзәк картинада—"Сөембикә" манаралы Казан. Гыйззәтле бу манара, мөселман мәдәниятенә нисбәтле, суфичылык юлыннан күтәрелү этапларын чагылдырып, җиде баскычлы конструкция-мәкамга ия: тәүбә, гөнаһка әйдәүче коткылардан качу (вәрә), ярамаганнан тыелу (зөһд), матди байлыкларны алгы планга куймау (факр), сабырлык, тәвәккәллек, ризалык. Җиде буынлы бу конструкция кеше төзелеше әгъзаларын да белдерә. Дүрт түбән физик җисем һәм өч илаһи әгъза.

Манара архитектурасы эчтән шулай кеше табигатенең өчтөрлелегенә ишарә итә: җисми тән, җан һәм рух. Кешегә дин аша ачылган Сүз (шәригать), Канун (тәрикать), һәм Юл (хакыйкать) символларын да аңлата ул. Шулай итеп, "Сөембикә" манарасында исламның гына түгел, башка конфессияләр мәгънәсе дә табыла. Бу образлы символ аша триптих авторы татар мәдәниятенең эчке халәте һәм байлыгы белән барлык рухани агымнарны берләштерә: ислам культурасын, крәшеннәр традицияләрен һәм борынгы бабаларыбызның гореф-гадәтләрен. Гади акыл мөселман, христиан һәм болгарларның борынгы диннәре уртак тамырларын күңел күзе аша багымлый да алмый, бары тик аларның каршылыкларын гына күрә. Ул Гайсә Мәсихнең бөтен галәмгә мәхәббәт, миһербанлык импульсы һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең кеше абстракт интеллектын үстерә торган Мефистофельлек тенденциясенә каршы көрәшкә куйган көч белән болгарларның Аурупа юнәлешендәге рухани культура булдыруда аерым бер ролен бәйләп карый алмый. Ләкин болар барысы да кешенә гуманизмга таба алып бара торган "Мин-аң культура" дәрьясы тармаклары.

"Татарстан" триптихы (зур төсле эскиз рәвешендә генә калган хәлдә дә)—татарларның бөтен конфессияләрне якынайта торган үзенчәлекле "Яңа завет"ы ул. Аны бик нигезле рәвештә кеше рухының иң бөек иҗади әсәрләреннән санарга мөмкин. "Триптих" әһәмиятен бары тик элгәрләребезнең борынгы васыяте булган "Сөембикә" манарасының үзе рәтеннән генә аңлап булыр. Урманче безнең һәммәбезне үз эчендә биеклеккә омтылган гармоник манара төзергә, барлык проблемаларыбызга космик кеше багымыннан зур җаваплылык белән карап алырга чакыра сыман.

Татар халкының мәдәни тамырларын рухани тикшеренү методы нигезендә эзләү Бакый Урманчены мәшһүр болгар шагыйре Кол Гали портретын иҗат итүгә этәрә. Бу скульптура болгарлар заманы һәм мәдәнияте хакында безгә килеп җиткән өзек-төтек хәбәрләр, фрагментар фикерләр нигезендә ясалмаган. Урманче үзенең эчке рухи-рухани барлыгы белән мәшһүр "Кыйссаи-Йосыф" поэмасы эчтәлеге, аның шигъри ритмы, көй-моңы, музыкасы эчендә яши, аларны өйрәнә. Бу әсәр Урманче үскәндә һәр татарның өстәл китабы булган. Ана сөте белән кергән шул эчке караш алдында тере имагинация, шундый реаль сурәт калкып чыга ки, аның чынлыгын шул юл белән баручылар гына түгел, хәтта башкалар да төшенә алыр.

Кол Гали портретында безнең хәзерге замандашларыбыздан шактый аермалы кеше сурәте чагыла. Ул үзенең рухи сафлыгы һәм эчке гайрәте (бессамостность) белән аерылып тора. Шагыйрьнең карашы фанилыктан югарыга юнәлтелгән. Бу—алдан күрүче карашы. Аның аңы—абстракт фикри тип белән түгел, ә тере образлар белән эш итүче аң. Ул галәм күренешләренә физик күзләре белән бакмый, ә үз барлыгына, ягъни үзендә дә галәм вә табигать патшалыкларындагы кебек хөкем сөргән көчләр яшәешенә тирәннән, эчке бер багым белән карый. Бу көчләр рух ияләренең ачык сурәтләре аша күренеп, алдан күрүче өчен реальрәк һәм үтемлерәк булалар, чөнки формалашкан физик дөнья—ул югары илаһи тормышның тыгыз бер чагылышы гына.

Шагыйрь эчке иҗади ыргымын тулысынча гамәлгә ашыру аркасында рухани агымнар йогынтысын тоя. Анда Аллаһе ихтыяры бөеклегенә һәм мәрхәмәтенә инану хөкем сөрә. Аның исеме Кол Гали—Аллаһының бөек колы булуы да очраклы түгел.

Биредә Урманче болгарларның рухият өйрәнүчеләр чыганакларында сакланган серләренә якыная. *(Р. Штайнер. Эзотерические наблюдения над кармическими*

*закономерностями.—т.III.—Дорнах, 1964.)* Әлеге чыганакларда урта гасырлар Ауропасы халкы болгарларның гадәттән тыш алдан күрүчәнлек сәләтенә ия булганлыклары хакында әйтелә. Андый сәләт бик борынгы заманнарда һәр халыкта булган, яңа эра тирәсендә инде ул күп халыклар тарафыннан җуелган, бары болгарларда гына XIII-XIV гасырларга хәтле сакланган.

Төннәрен, тирән йокыга талгач, башкалардан аермалы буларак, болгарлар "Мин" хисен, аңны югалтмыйлар, тәмам онытылмыйлар. Рухани багым вә үз эченнән ишетү белән алар космостан килгән төсле яктылыкларның үзара тәэсирен, физик дөньядагыга караганда чагыштыргысыз дәрәҗәдә яктырак музыкаль гармонияләрне кабул итәләр. Иртән йокыдан торгач та, күктән җиргә, үсемлекләргә, хайваннарга төшүче һәм үсү, үлү процессының шарты булган, төсле тәтенгә охшаган рухани яктылык күрүләрен дәвам итәләр. Әлеге көчләрне болгарлар аера беләләр һәм аларны практик тормышында эшчәнлектә гадәттән тыш зур осталык белән кулланалар. Мәсәлән, алар музыка ярдәмендә малларның сөт савымын арттыра белгәннәр. Ә инде дошманнар һөҗүм иткәндә алар каты яңгырлар, томан, хәтта җәй уртасында карлы бураннар чыгара алганнар. Көнбатыштагы табигатькә һәм кешегә булган материалистик нигезле карашларын алар акыл томанлануы итеп аңлыйлар, тере реалияләрне хаклы рәвештә абстракт-фикри күзаллаулар белән алмаштыру дип саныйлар. Шуңа күрә болгарларны физик үлем куркытмый, ул аңның җисми чылбырдан арынуы һәм шәкелен генә үзгәртүе дип саныйлар. Күмәк ритуаллар вакытында алар үлгән ата-бабаларның үз тормышларына катнашуын аңлыйлар һәм югары илаһи чынлык белән рухани кушылалар. Шулай итеп, җирдә гармоник берлек булдырырга омтылалар, үзләренә рухи якын кешеләр белән хәзерге һәм киләчәк тормышларында, башка инкарнацияләрендә кыйммәтле рухани дөнья белемнәрен саклау һәм кешелеккә җиткерү өчен берләшәләр.

Болгарлар тормышка һәм мәдәниятка Ходай Тәгалә кодрәте белән күчкән ак һәм кара рухани агымнарны аера белгәннәр. Җөмләдән, Чыңгыз ханның җимергеч басымы аркасында камнау, багучылык кебек шаманлык калдыкларын терелтергә маташуларны хупламаганнар. Болгарлар чыңгызлылар тарафыннан империячел тоталитарлык алга сөрелүенең һәлакәткә илтәсен дә аңлыйлар. Соңыннан бу идея Иван IV сәясәтендә коточкыч гамәлгә ашырылуын тапты. Ихтимал, шуны аңлауларына таянып та, көчләрнең гаять тигезсез булуына карамастан, болгарлар кыю рәвештә илбасарлар юлына каршы чыгалар.

Урманче борынгы болгарлар рухы белән тыгыз бәйләнештә тора. Әгәр борынгы болгар кешесе принциплары бүгенгебезгә күчерелсә, аның тормыш позициясе рәссамлыкы белән тәңгәл булыр иде:

Магол узар.
Аксак Тимер килер дөньяга,
Җимереп төзек илне,
Баскынчылык итеп төрек илләрендә,
Хәсрәт, каһәр, золым ясап дөньяда.

Болгарларның бөек рух—бөтен нәрсәне инләүче һәм бар нәрсәгә җәелгән, ясаган, әмма иң тулы рәвештә яратылмышның таҗы булган кеше турында күзаллаулары, аларның таш сыннары да Урманчега яхшы таныш. Бәлкем шуңа да аның иҗатында портретлар галереясы пейзажга караганда баерактыр. Кеше—Урманче иҗатында үзәк тема. Язмыш рәссамга төрле кешеләр портретларын эшләүне насыйп итә. Җәмгыять вә тарих тарафыннан төрле бәяләмә алган кешеләр белән сөхбәтләшеп, йә бәхәсләшеп тә, аеруча ул кешеләрнең иҗат көчләренә сокланып, рәссам визуаль дөньяда үз идеал күрсәтү мөмкинлеген эзли, шуңа бер кешенең берничә портретын да ясый иде. Бер үк вакытта әлеге затның замандашына абстракт фикер аша түгел, хис һәм ихтыяр көче белән тәэсир итүен тасвирларга тырыша. Тормышның кыйммәтен материаль байлыклар белән генә бәяләүче кеше Урманче герое була алмый.

Әй, адәм...
Әүвәл мал җыясың, комсызланып,
Аннары кол буласың шул малыңа,
Картаясың, малыңа сакчы булып,
Барысын да калдырасың, үзең үлеп.

Кешенең рухи башлангычын кире кагучы иҗатчыга да Урманче мәдхия җырлый алмый:

Әдипләр катында табиб,
Табиблар янында язучы.
Әдәптән өлеше булмагач,
Чүплектән гайбәт казучы.

Мольберт янына утырганчы, яисә кулына балчык алганчы ук ул энҗе эзләүче кебек, кешедәге иң үзенчәлекле сыйфатны, иң кыйммәтле якны күрсәтергә омтылды. Бу аңа кеше асылын чын яктылыкта күрсәтү мөмкинлеген бирә иде.

Борынгы көнчыгыш күзаллаулары буенча, индивидуаль рух тормыш агымына өч төрле шәкелдә керә: физик җисем тәннән югары, түбән һәм тигезлектә. Һинд традицияләрендә мондый халәтләр гуналар дип атала һәм саттва (саф), тамас (караңгылык) һәм раджас (хәрәкәтчән, эшчән) дип билгеләнәләр. Гуналарга кермәгән тагы бер халәт була. Анда адепт, иң әүвәл кулына "сафлыкның алтын чылбырын" алып, "караңгылык тимер чылбырыннан" котыла, аннан соң икесен дә алып ташлый һәм югары рухани юлга кереп китә. Башкача әйткәндә, ул (адепт) илаһиятнең турыдан-туры үзенә иңүенә юл куя, эгоистик мәнфәгатьләреннән, хәтта сафлык вә пакьлыкта тору теләгеннән дә азат була. Гади күзаллаулардан азат булып, ул дөнья корылышының объектив көчләре сыман хәрәкәт итә.

Бу карашларга Урманче тулысынча кушыла ала иде. Аның иҗатын шушындый ракурста караганда әлеге кешеләрнең рәссам тарафыннан ясалган бик күп сурәтләре гигант пирамида кебек тезелә. Аның иң очын бөтен җәмгыятьне игелекле импульслар белән туендыручы, "Югары багышлама алган адепт" (гуналар кырына чыккан фигуралар) бизи. Иң әүвәл бу—Туран күчмә халыкларының легендар укытучысы Коркот-бахшы (40 нчы елларда Казахстанда агачтан иҗат ителеп, Ташкент Үзәк музеенда саклана). Рәссамга рухани күренү ачылганнан соң ясалган азаккы бик күп картиналарының берсендә автор Коркот йөзен тасвирлаудан баш тарта. Мөселман традицияләре буенча, ул тамашачыны илаһи дөнья символына юнәлтә, ә икенче картинасын "Әүлия-Ата даласы" дип атый. Монда бик матур пейзаж һәм рухани имагинация кебек, болытлар арасыннан гыйбадәтханәләргә охшаш нидер күренеп тора, рәссам безнең фикерләрне турыдан-туры космос белән бәйли.

Урта гасырларның багышланмыш икенче бөеге "Ибн-Фазланның Болгарга килүе" картинасында күрсәтелә. Шәхси әңгәмәләрдә Бакый ага бу адепт парампарасын (пәйгамбәрләрнең мөритләре чылбыры) туры багышламалардан (укытучыдан укучыга) пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күтәрелүен һәм Идел буена X гасырда килгәннән бирле безнең көннәргә хәтле саклануын сөйли иде. Киндердә гарәп дөньясы илчесенең йөзе ясалмаган. Моның белән эш ни илченең, ни сәркатип Ибн-Фазланның шәхесендә түгел, ә бәлки рухани агымның башта пәйгамбәргә, аннан иң бөек илаһият югарылыкларына юнәлү икәне күрсәтелә.



*Р. Рәхимова. 1940 ел.*

Пирамиданың иң очына якынлашып, Мәрҗани хәзрәтләре Шиһабетдин бине Баһаветдин фигурасы калка. Бу скульптураны рәссам Татарстан партия җитәкчеләреннән курыкмыйча, Казанга кайткач та иң беренче эше итеп иҗат итә (60 нчы еллар). Урманче аны ритуал кием—чалма-чапаннан гипста иҗат итеп калдырган. Автор аны бөек шәхес, дин реформаторы, ислахчы галим дип бәяли, һәм абстракт төшенчә булып калмасын өчен, татар телендә дә бик урынлы, әмма бик борынгы заманнарда ук гарәп универсумыннан алынган азамат (олпат, бөек), үзе артыннан гаскәр ияртүче, беренче булып сугыш утына керүче хәрби исеме белән атый.

Мәрҗанинең ислах эшчәнлеге татар җәмгыятенең исламга догматик рәвештә иярүдән, алдан күрүчеләрнең рухани дөнья турысындагы хәбәрләрен кабул итәрлек дәрәҗәдә күтәрелгән һәм ул дөньяны

аңлауга мөстәкыйль рәвештә ирешкән фикерләү көче булдыруга хезмәт итә. Мәржани артында гавам халкы күрми үткән, руханиларның да билгеле бер өлешенә генә мәгълүм булган яшерен "халык укытучылары" басып тора. Бакый ага Гали ишан дигән яңа заман әүлиясы—рухланып, туып килә торган "мин-аң" культурасы әйдәп баручысы һәм изге язмаларны тәфсилләп аңлатучы Салих Тархани кебек иерархлар сере белән дә кызыксына иде. *(А. Монасыйпова. Гали ишан хикмәтләре.—Идел, 1993, № 5).* Аның күзаллавында рухани җитәкчелек кешелек җәмгыятенең үсү асылын тәшкил итә. Сурәт-символика ягыннан бу аның апасы "Советлар Союзы Герое Баки Рәхимов әнисе Рабига Рәхимова" портретында чагылыш таба. Рәссам бу әсәрендә Коръән укучы хатын-кызны сурәтли. Шуның белән ул кешене иң югары "Мин"гә күтәрә торган, шәхесне каһарманлыкка алып баручы рухи чыганак итеп иманны куя!

Бу—сафлар сурәте. Бирегә рәссам бөек Мәржани белән рәттән Сөембикә патша һәм шагыйрь Тукай тарихи фигураларын куя алыр иде (алар скульптура гына түгелләр). Бу темага соңгы эшләре Сөембикә ханбикәнең агач скульптурасы (юкә, Казан Сынлы сәнгать музеенда), һәм шагыйрьнең яшь чагын сурәтләгән зур гипс портрет (Тукай музеенда, Түбән Камада шуннан бронза һәйкәле коелган) бер вакытлардарак—1970-1980 еллар арасында ясалды. Бу инде рәссамның республикабызның үсеп килә торган суверенитет идеяләренә җавабы иде, ул ирекне алу шарты һәм юлларын күрсәтүе. "Сөембикә" исеме белән югарыда атап үтелгән ата-бабаларыбызның тынычлык сөюче сәясәте һәм җиде баскычлы гыйбадәт манарасы символында аңлатылган рухани васыяте. Тукай исеме белән исә телнең милли даһәсе (гений) һәм бик бай сәнгать традицияләре булган халык рухы сынланды. Болар икесе "алтын баганалар" булып суверенитетка һәм татар халкының якты киләчәгенә нигез булып күрсәтелә.



***Коркот.** Тушь, пумала.*

Бу корифейларга якын гына итеп, Урманче Дәрдмәндкә багышланган бик күп эшләрен, шул исәптән ике-өч скульптура портретын куя. Бөек Тукай замандашы әсәрләреннән сынчы үзенә рухи көч чыганагы, иң югары дөньяга алып менүче яктылык таба. Дәрдмәнд аңа яңа формация укытучысы була: мулла-аксакаллар шикелле ул Җанабе хак алдында рухи нәҗиплек һәм сүз-шигырь осталыгы гына тәрбия итми, фикерләү һәм ихтыярга азык та бүләк итә. Әлеге рухият укытучысының сурәтен имагинатив кабул итүгә Урманче үзенең "Иман" дигән шигыре аша алып килә.

## Иман

Дәрдмәндне укыгач, җанга көч, күңелгә
Яңа өметле дәрдләр, аңга тыгыз көчле азык бирә торган,
Тирән мәгънәле, самими, бәгырьләрнең
Януыннан, дәртләрнең нурлы гөлләреннән
Ясалган нәҗип һәм назлы сүзләр кабатлыйсы килә.
Бөтен барлыкның "Ясаганы", бөтен чынлыкның һәм нәфислекнең
Раббысы булган, бөек, югары, киң, олы
Тәңренең күренмәс, сизелмәс, тотылмас,
Ишетелмәс, бары гаҗәеп серле булган,
Тирән һәм нәҗип тойгыларда гына тәҗәлла иткән
Химая нияте алдында тез чүгеп, сәҗдә кылып,
Шул нәфис, рухани хакыйкать белән киеренгән
Сүзләрне укый-укый, күзләрдән татлы

Яшьләр түгәсе килә.
Әзәлдән[1] әбәдкә[2] юл тоткан чакта,
Нинди генә гүзәл сәгатьләр, рухани галактик буларак,
Бинибая күңел галәмен нурландырмыйлар!

Соңгы өчъюллыкта Урманче, әйтерсең, иң югары гакыл хәзинәсенә кереренә ирешүдә үз тәҗрибәсен чагылдыра. Алар аның көндәлек, тирән уйланулары, галәм хакыйкатьләренең иң мөһимнәрен аңлау вә кичерүгә илтүче медитациясе.

Бу өчъюллык сөземтәсенең беренче юлында аксакал эзотерик мөселман универсумына илтүче идеяне кертә: кеше юлы "әзәлдән әбәдкә", "тумаган үткәннән—бетмәс киләчәккә" юнәлгән... Җир йөзендә "тумаган" сүзнең "башлангычсыз кеше" мәгънәсен саклаган телләр күп калмаган. Татар телендә әле ул архаизм буларак яши, әмма аны да бүген һәркемгә аңлаешлы дип әйтеп булмый. Бу сүз белән бергә хәзерге җәмгыять кеше асылының илаһият, рухани дөнья өлеше икәнен белүен онытты. Ә бу белем—һәрбер индивидуумның ата-анасы тарафыннан (төптә исә беренче Адәмнән үк) бирелгән, үләргә тиешле гәүдәсе булса да, ул әле үлемсез, өзлексез, иң югары рухани чыганакка ирешүче имматериаль өлешкә дә ия икәнен белү. Җиһандагы иң олуг гамәлләр һәм корбаннар борын-борыннан шушы кичерешләр белән, шушы белем аркасында эшләнгән. Әмма Мөхәммәд галәйһиссәләм заманына житәрәк инде бу хакыйкать гавам аңында буш бер фразага, кеше ирешмәслек сергә әйләнгән була. Ул сер инде рухани мәктәпләрдә генә саклана һәм бары багышланмыш кешеләр тарафыннан гына буыннардан—буыннарга бирелә башлый. Ихтимал Оста үзе дә шул багышланмышлар арасында булгандыр. Чөнки бүгенге көндә җансыз интеллект, куркыныч пессимистик Мефистофель позициясенә каршы бердәнбер реаль чара һәм тере идея булып, шушы "әзәл-әбәд" турындагы сер кала.

Бүгенге көндә күп дини конфессияләр бетмәс киләчәк турында гына сөйлиләр һәм "оҗмах тәкъваларга гына тиячәк", дип, кеше эгоцентризмын куерталар. Аның белән антропософия ярдәмендә генә көрәшергә һәм югары фәлсәфи ноктага тагын да якынрак килеп була. Клиник үлем яисә көчле стресс кичергәннәр тасвирлавынча, кеше асылы физик гәүдәсеннән аерылгач та яшәвен дәвам итә. Ләкин тән кешегә бу дөньяда да, теге дөньяда да матрица шикелле индивидуаль форма биреп тора. Аннан ваз кичәргә ярамый.

Мондый фикерләр мөселманча тәрбияләнгән Б.Урманче өчен дә яңалык түгел. "Кубәләктәй җанга көч" дип җырлаган һәм "Иман" догасын белгән һәр мөэмин шикелле ул теге дөньяда хәят барлыгына инана.[3]

Югарыда искә алынган кичәдә Б.Урманчега аеруча тәэсир иткәне—Ч.Айтматовның шул фикерләрне ачыктан-ачык әйтә алуы иде. Калмык шагыйре Д.Кугультинов бюстын ясаганда да ул аның белән җан һәм әзәл-әбәд турысында әңгәмәләр алып бара, аның шигырь-поэмаларын укыта иде. Бирсдә сүз рәссамның дөньяга бу карашы ничек югары сәнгать әсәрләрендә чагылуы хакында бара.

Урманче эшләренең зур гына сериясен уртанчы раджас гунындагы шәхесләр били. Бу кешеләрнең рух вә җисемнәре маятник хәрәкәте кебек даими көрәштә булалар һәм гомуми бер тигезлек хасил итәләр. Андый кешеләр җитешсезлекләрдән дә азат түгелләр, әмма үз гамәлләрен гомумкешелек идеаллары белән бәйләргә тырышалар. Монда рәссам җәмгыятьтә һәм материаль дөньяда шәхес ролен саф Шәрекъчә аңлаудан ерагая. Әгәр чал Шәрекъ рухани укытучыларны күтәрә һәм аларны якын итә икән, хәзерге Аурупа традицияләре бу укытучылар белән рәттән күренекле осталарны куя. Бакый ага зур осталык һәм керсез күңел белән үзен-үзе аямыйча реаль кыйммәтләр булдыручыларны өстен куя иде. Җир эшкәртүче һәм тышкы дөньяда иҗат итүче Хаин ыруын Урманче эчке рухани дөньялык Абил ыруы кебек үк ихтирам итә. Шуңа да аның остаханәсендә мулла—мәгърифәтчеләр, ташчы-корымчылар, сугыш һәм хезмәт геройлары, сәясәтчеләр, мәшһүр шагыйрьләр, язучылар, рәссамнар, музыкантлар. Автор бу портрет галереясында җәмгыятьнең тулы социаль йөзен чагылдыра, әмма Урманче игътибарына лаек булган кешеләр очраклы туры

1. Әзәлдән—башлангычсыз борынгылыктан.
2. Әбәдкә—бетмәслек киләчәккә.
3. Мәсәлән, Н. Думави, Сәкья Муни (Будда) фикерләрен дә искә алып— "Үлгәннән соң тәнемез шул үзе яралган табигатькә кайтып таралып бетсә дә... Сизенүнең, аңның асылы булган бернәрсә кала булырга тиешле",—дип язган. *(З. Рамиев. Нәҗип Думави үзе турында. Казан, 1990, 80 б.)*

килмәгән. Ул аларны теге яки бу шәхес белән үзенең нинди дә булса мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, аларның популярлыгына да, рәсми дәрәҗәләренә дә карамастан сайлый. Һәм кайчак автор белән аралашкан кешеләр яки якын туганнары аңа модель булганда, ул портретларда күбрәк гомумкешелек өчен мөһим эчке халәт үзенчәлекләрен һәм сәнгати идея табарга тырыша иде.

Бу җәһәттән сынчының композиторлар темасына иҗат иткән өч скульптурасы гыйбрәтле. Ул—татар профессиональ музыкасының чишмә башында торган Сәйдәш, Җиһанов һәм Яруллин портретлары. Олуг шәхесләр, үзенчәлекле талантлар буларак, алар билгеле бер дәрәҗәдә иҗатта да, тормышта да мәгълүм антиподлар иде. Аһәңсазларның бу аерымлыклары күпләр тарафыннан эмоциональ хуплау йә кимсетү "партияләренә" эләгеп, аларның үлмәс иҗатыннан тәм табу, ләззәтләнү түгел, ә бәяләү, үлчәү кебек вакланута китерә иде. Урманчены мондый яклар әлбәттә кызыксындырмый. Ул шушы өч композитор иҗат бердәмлеге агымнарында милли профессиональ музыка нигезләре салынганын аңлый. Салих Сәйдәшнең җанны әсир итүче моңнарын ул ихлас ярата һәм соклана, Фәрит Яруллинның милли характерлы нәфис образларына таң кала, Нәҗип Җиһанов драматургиясенең конфликтлылыгын, катлаулылыгын аңлап дәртләнә. Югары әхлак вә әдәп биеклегеннән торып фикер йөртү аны вак субъектив күзаллаулардан ерак тота:

Җирдә туып, күккә карап гомер үтте.
Гомер җебен төн белән көн һаман сүтте...

Урманче иҗатында рухи башлангычны танымаган һәм аңламаган, материаль эшчәнлеккә баштанаяк чумган, ягъни "тамаста"—караңгылыкта калган шәхесләрнең портретлары да урын таба. Язмыш аны совет дәүләтенә нигез салган, материализмның идеологы булган В.И.Ленин белән дә очраштырган. Ихтыярын явызлык белән аяусыз көрәштә көч куеп җиңүгә юнәлткән бу шәхес белән очрашу егерменче елларда ВХУТЕМАСта була.

Ленин образын идеаллаштырган, аңа эчке бөтенлек, рухи сыйфатлар гармониясе бирергә тырышкан классик кануннарга бирелмичә, Урманче 1968 елда тәмамлаган скульптурасында ихтыярый сыйфатлары дөрес арттырылып күрсәтелгән һәм ул сыйфатлар кеше җанын басып, изеп торган, эчтән тынычсыз бер сугышчы шәкеле иҗат итә. (Бәлки шуңа күрә дә Урманченың бу скульптурасы озак еллар партия җитәкчеләре тарафыннан күргәзмә залларына, тамашачылар алдына чыгарылмый торгандыр).

Кеше рухи халәтендәге мондый дисбаланс коры материалистик позициядә торудан, инсаниятнең рухани ориентацияләрен аңламаудан килеп чыга. Урманче, киресенчә, үзенең "рухани күзләре" белән нәзек идея дөньясын, бөек әхлакый идеалларны күрә белә, алар буш "идеология" түгел икәнлеген, бәлки шәхси һәм иҗтимагый организмнарның дөрес яшәешенә алшарт булуларын аңлый. Бакый ага үз вакытында февраль революциясенең өч бөек лозунгын хуплап кабул иткән, аларның җуелуын авыр кичергән. "Ирeклек, Тигезлек, Туганлык!"—боларны тормышка ашырыр өчен ниләр кирәк? Бу сорауга рәссам гомере буе җавап табарга тырышты. Әгәр рух турында хәзерге фәнни ачышлар белән таныша алса, ул бик шат булыр иде. Чөнки антропософия рухи карашларны өстен куеп, әлеге лозунгларның революция фетнәсендә, материализм юлында буталганнарын һәм аларны дөрес кулланмауны күрсәтә. Әгәр бу лозунглар һәркайсы үз урынында гамәлгә ашырылса, Советлар иле башка нәтиҗәләргә килгән булыр иде: рухани һәм дини хәяттә—ирек; сәясәттә һәм хокук аланында—тигезлек; иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә—туганлык *(Р. Штайнер. Сущность социального вопроса. Калуга, 1992.)*.

Урманче үзен ничек дип таный соң? Нинди төркем кешеләре арасына куя? Аның автопортретларында—аягында нык басып торган, чиктән-чиккә ташланулардан, төрле вәсвәсәләрдән ерак булган чын ир, көчле рухлы шәхес. Сабырлык, чыдамлык, зирәклек үзеннән-үзе генә һәм бик җиңел килми. Яшьрәк вакытында көчле эмоция чайпалышлары гыйсъянчылык булып тышка бәреп чыккан:

Бу дөньяны төзек күрсәм, дигән идем.
Баш идем кайчак.
Каршылык кылдым, ызгыштым кайчак.
Күтәрдем дау, кан түктем игелексез.

Акыл иясе рәссам озак вакытлар дәвамында кешедәге хис һәм фикернең үзара мөнәсәбәтен тикшерә. Ир булып өлгергәч кенә аңа хисләрнең кеше җисеменә акылга

караганда да тирәнрәк үтеп керүе хакындагы хакыйкать килеп ирешә.

Акыл белән яшәп булмый, ди шул,
Өстен чыкты һаман тойгылар, дәртләр...

Намуслы кеше буларак, Урманче кешеләрне югары күтәргән акылның фикри сөземтәләре үз буталчык юлларында ук адашу мөмкинлеген күргән:

Акыллылар һаман мал туплыйлар,
Акыллылар илне саталар.
Мал һәм дан табалар,
Вөждан сатып гомер сөрәләр дә,
Хәрәм майда, балда йөзәләр дә,
Күргәч мохтажлыкны аягындамы,
"Акылсыз" дип безне сүгәләр.

Әмма акылны да читкә куярга ярамый, юкса хисси кичерешләреннән давылында чарасыз, яклаучысыз калуың мөмкин. Ә бу каршылыкларны гомумән тигезләп буламы соң? Ике арада бәргәләнергә торган җанны тирән сагыш баса, хәсрәт бөтереп ала. Эзләнүләр лзаманы һәйкәле—үзенең рухани автопортреты булырдай данлыклы бер скульптурасын һәм шигырьләреннән берсен ул нәкъ шулай исемләгән дә[1]:

## Сагыш

Йөрәгемнең ярасы бар уналмаслык,
Ачынулар, көенечләр төзәлмәслек.
Аңымның үзәрендә авыр хәсрәт,
Гуя җанны басып алды зур албасты.

Рух турындагы фән күзлегеннән караганда, сагыш, ялыгулар билгесезлектә югалганлык хисеннән чыгарга ярдәм итүче рухи көч тудыралар. Имагинатив аң аркылы аны кичерә алуга сәләтле җан, матди дөнья чылбырларыннан азат булып, рухани яшәешкә омтыла.

Проблемага тирән үтеп керү нәтиҗәсендә, Урманче: "Иң югары "мин"—тормышта үз хисләре һәм акылы идарә итәргә тиешле хаким", дигән фикергә килә. Ул акылы һәм хисләреннән арынмый, киресенчә, икесен тәңгәлләштерергә тырыша, тәрбияли һәм үстерә, шулай итеп "тоя", йә булмаса "фикерли" торган җаннан да югарылыктагы аңга ирешү юлларын ача башлый. Җанландырылган һәм акыллы "Мин" үзен, фикерне объектив һәм субъектив танудан читкә киткәч таба. Бу "Мин" өчен фикер баш миеннән башка яшәми, әмма бавырдан үт агып чыккан шикелле дә бүленми, ә предметлар дөньясыннан булмыйча, кешенең үз рухыннан билгеле булганча алына. Көнчыгышта җанлы фикерләү символы—канатлы ат "Тулпар". Оста аның рәсемен дә, агач сыннарын да ясаган. Тулпар—рухани дөньяларга очкан канатлы, ачык фикер. Әлеге киңлекләргә ул Остаңы да алып чыга.

Тулпар белән бәйләнешкә керү өчен, аны тере җан итеп тоярга, идеяләр һәм төшенчәләрне, субъект иркендә генә булмыйча, дөньяви тәртип белән бәйләнештә хәрәкәт итүче реаль фикри җисем сиземләргә кирәк.

1956 елда язылган гаҗәеп матур һәм камил бер шигырендә рәссам югары аңның беренчел чагылышларын житкергән "күрү"не тасвирлый:

Фикер сараеның өчелеген генә күрдем,
Гыйлем, әдәп түрләренә узалмадым.
Еракган ишеттем үзәгендә түрнең
Сәгъдиләр, Мәгарриләр, Дәрдмәндләр,
Гаҗәеп әңгәмәләр әйтеш белән, әдәби үрнең
Түбәсенә әкрен генә ашынганнар.
Миңа кайда ул нурлы түбәләргә
Ашмак, аңа бармак?!
Түбәндә торып, шул гаҗәп әңгәмәне

---

1. Бу скульптурага Р. Харис, Г. Афзал, Э. Мөэминова һ.б. шагыйрьләр дә үз әсәрләрен багышлады.

Ишетүемә,
Аңлавыма
Шөкранам чиксез,
Шатлыгым зур.

Югары үрләргә менү юлларында Урманче ярдәм алыр өчен төрле чыганакларга мөрәҗәгать итә. Һәм, әлбәттә, беренче чиратта, изге язмалар—Коръән, Талмуд, Инҗилгә. Аларны өйрәнүгә ул үзенең шактый гомерен багышлый. 1974 елда аны хәтта Петербург мәчетенә имам итеп тә чакыралар. Бу китапларда беръяклылыкка—идарә ителмәгән хисләрлеккә (Люцифер-Иблискә) юлыгу яисә коры акылга (Сатана-Шайтанга) табыну куркынычы хакында күрсәтмәләр бар: "алтын уртак" кешенең чын "Мин" белән кушылуында. Җир йөзендә моның иң югары мисалы—Алла Сүзе буенча туган яна Адәм—Мәрьям Ана улы Гайсә Мәсих (Коръән, 3,52 (59)).

Чын мәгънәсендәге "Мин"—Алла дип аталучы Берлек һәм ул тирән аңлылык, рух, оптимизм белән сугарылган, безгә Өмет бүләк итә. Гакыл "Мин"е барлыкның бер өлеше һәм җисемнәр дөньясыннан югары күтәрелә алмый, үлем бусагасын атлап чыкмый һәм үз-үзен чиктән тыш ярата, шикчел, төшенке. Урманче "Өметсез—Шайтан"ны еш кабатлый иде. Аксакал Коръәнне, аның эчтәлеген генә түгел, акылны читләп, рухи дөньяга турыдан-туры алып чыгучы галәм ритмы һәм яңгырашларын чагылдырган сәнгати-мистик ягын да чиксез югары бәһаләде. Моны аның искиткеч тирән мәгънәле дистәләгән шәмаилләре дә дәлилли.

Мөселманнарның күпләгән буыннары шушы юлны узды. Һәм ул Урманче өчен дә таныш иде. Шулай да рәссам хәзерге абстракт фикерләүнең дөнья яратылышы парадокслары берлеген аңлату, изге Китапларның чын асылын иңләү сәләтенә ия булмаганлыгын аңлады. Акылның сукырларча дини традицияләргә табынырга, йә булмаса изге рухны тулаем кире кагарга мөмкинлеген дә таныды.

Әлеге юлларның кайсысын гына сайласа да, кеше тискәре нәтиҗәләргә килергә мөмкин. "Мондагы дөнья миннән башка тудырылган һәм миннән башка да яши ала, мин монда бары тик кунак кына", дип актив эшчәнлек өчен кирәкле нигезләрне югалта. Йә инде, киресенчә, материалистик башлангычка гына ышанып, ул җисми дөньяга чума һәм шунда үзен югалта, үзе тузанга әйләнә. Урманче исә үзенең илаһи табигатен аңлы рәвештә тану юлыннан китте.

Бу юлда аның "төш күрүче" тәҗрибәсе мөһим бер чылбыр булып торды. Һичбер тупас материализмсыз, ялгансыз, рухлы көндезге эшчәнлегеннән соң төннәрен ул бик үк гадәти булмаган төшләр күрә. Алар тәртипкә салынган, "хәбәр итүче" төшләр, бөтенләй башка чынбарлыкны ачалар һәм аңа фикри интеллектуализмнан камилрәк формадагы аң бирәләр. Шушы аң рәссамга сиземнән тыш дөньяның реальлеген күрсәткән якты, кыйммәтле кичерешләр бирә, аны алдан күрүче дәрәҗәсенә күтәрә:

Чын тормышны бары төштә күрдем,
Төшемдә генә кордым сарайлар,
Хыял кордым, сарай коралмадым,
Өмет булды, бушка планнар.

Биек сарай корырмын дип хыялландым
Иделкәйнең биек яр башында.
Утырыр сөйгән ярым, сылу ярым
Ак балконда минем каршымда.

Юк, теләмәдем язмыш хыялларының
Чынбарлыкка сикереп кичүен,
Ерак түгел кояшлы бу илемнән
Икенче бер илгә күчүем.

Бу—дөньядан качу түгел, киресенчә, дөньяны, җир өстендәгечә тоемлау богауларыннан, иллюзияләрдән азат булу: сафлык, пакълек (саттва) халәте ул. Шуннан соң җанны коткару, гөнаһлардан арынуны кайгыртасы гына кала.

Бу мәсьәләнең иң җаваплы ягы—рәссамның үз иҗат асылына мөнәсәбәте иде. Татардагы ислам догматлары кеше сурәтен ясауны тыйган. Шушы тыюны ачыклар өчен Коръән-Кәримне кат-кат укыса да, Б.Урманче ни сынлы сәнгать, ни уймачылыкны тыйган сүзләрне таба алмый. Бу турыда Түбән Камада узган "Җидегән чишмә" кичәсендә ул күп санлы халык алдында, шулай ук үзе бик хөрмәт иткән Риза казый

Фәхретдиннең дә бу сорау белән кызыксынганын һәм Коръәндә тыю тапмаганын әйтте (1988). Әмма рәссамны җәмгыятьнең консерватив карашлы әгъзалары фикере генә өркетми, ә үз вөҗдан авазы тынгы бирми. "Ялгышмадыңмы? Адашмыйсыңмы? Үз фикерең белән генә чикләнеп, халык ышанулары буенча, теге дөньяда һәр тере җан сурәте өчен җавап бирәчәгеңне онытмыйсыңмы? Әзерме син моңа?"

Мондый уйлануларын аның ВХУТЕМАСка укырга кереп кайткан улының маңгаеннан үбеп, әтисе Идрис хәзрәтнең фатиха бирүе дә җиңеләйтә алмый. Чөнки булачак рәссам алдында инде үз иҗаты өчен генә түгел, ә бәлки ул ачкан бөтен татар сынлы сәнгате, аның үсеше, юнәлешләре өчен дә җаваплылык тора иде.

Әлеге сорауларга җавап табу өчен соң дәрәҗәдә тугъры намуслылык, әчкерсезлек белән үз җанының асылына багарга һәм аны һәртөрле "мин-минлекләр", үзеңне сөюдән азат итәргә кирәк иде.

Һәм көнбатыш, һәм көнчыгыш сәнгатендә җан символы булып хатын-кыз образы тора.

Бервакыт Урманчеда: "Гаҗәп, юнанилар (греклар) хатын-кызны бик катлаулы киендерәләр ирләрне алай түгел", дигән фикер туа.

Әлеге мәсьәлә белән кызыксынган кеше җавапны тирәннән эзли: ир образын билдергән физик башлангычтан аермалы буларак, тышкы сиземләүләр ирешә алмаслык эчке дөньясын хатын-кыз образларында сурәтләнгән Изида япма белән яшерә. Җисми дөнья җаннан бу япманы алып ыргыта, җанны төрле сынау һәм газапларга дучар итә, шул ук вакытта аңа үз язмышын горур кабул итәрлек, югары дөнья белемнәрен туплар өчен көч, чыдамлык та бирә. "Үзенең табигатенә бәйле рәвештә ир кеше хатын-кызга билгеле бер дәрәҗәдә һөҗүм итә, никахлашу шартлары шушындый көч куллануга нигезләнә",—ди иде аксакал. Шуңа да, күрәсең, Б.Урманченың хатын-кыз темасын чагылдыручы әсәрләре күбесенчә нәфис нәгышьтә. Ә ир-ат портретлары— таш, агач, металл скульптурада. Хатын-кызларның сыннары исә (М.Ульянова портретыннан гайре)—гел гомумиләштерелгән һәм, башлыча, йомшак агачтан ("Сөембикә", "Гөлсинә", "Нәфисә", "Язгы моңнар" һ.б.). Һәм нәгыш, һәм сыннарда рухи халәтнең төп тәсмерләрен күрәбез. Аларны үз җаны аша кичергән Урманче рухи сафлык өчен көрәште. Түбәнгә тәгәрәгән хатын-кыз темасын ачкан "Мәрьям" шигъри циклында да ул аның җанын коткарырга тели:

Ялгыз кызганулар кылә, сине уйлап,
Янды гомерең, калдың мескен булып.

Җан, гамәлгә ашар хыялларга ирешер өчен, рух белән өретелгән булырга, "әзәлдән әбәдкә", башлангычсыз үткәннән чиксез киләчәккә юл табарга тиеш. Бу фикерен иң соңгы әсәрләреннән булган һәм тәмамланып бетмәгән "Нияз" (намазга оеган хатын-кыз белән яшь бала) скульптурасында рухи васыять шикелле чагылдырды. Образлы эчтәлеге ягыннан ул Гетеның "Фауст"ындагы бер эпизодка якын. Анда Фауст сәнгать һәм шигъриятне гәүдәләндерүче Гүзәл Елена рухын чакырып, аның белән никахлаша. Бу никахтан рухның иң нечкә субстанцияләреннән яралган бала туа. Ул бала (Эвфорион) Фаустка югары дөнья белән бәйләнеш бүләк итә. Арадашчы буларак, аның җанына үлемсез башлангычны ача.

* * *

Язмыш лабиринтларында рәссамга ике тапкыр никахлашырга насыйп була. Ике ханым аңа зур мәхәббәт, уллары шатлык китерә. Татар сынлы сәнгате "Сара" (1936), "Сара һәм Илдар" (1938), "Айгөл" (1967), "Айдар әнисе белән" (1971) һ.б. әсәрләр белән баеый. Соңгы мәхәббәтен ул "Айгөл" дип атый, аңа меннәрчә юл шигырь багышлый, дистәләгән портретларын яза.

Гомер азагында Урманче элекке "Сылуым" шигырендәге идеалы "гали мәктәп таба барган", яна, әлегә аңа таныш булмаган яшь бер затка юлыгуы өчен Тәңрегә рәхмәт укып, шөкрана кыла. Димәк, бу кавышу, мәхәббәтнең әһәмияте ике зур шәхес бәхетенә генә кайтып калмый. Аның дөньяда сирәк очраулы феномен икәненә басым ясарга кирәк. Бакый ага 93 яшьлек гомерен 3 утызъеллыкка бүлеп карарга кирәклеген һәм барча иҗат эшләренең 90% соңгы утызъеллыкка туры килүен кат-кат әйтә иде. Моны аның теләсә кайсы каталогын ачуга да күрергә мөмкин. Шулай итеп, аның дөньяга татар җанын, рухын нәзек һәм төгәл, нурлы һәм куәтле итеп ачу, дөньяга таныту буенча бу каһарманлыгын сөргеннәрдән исән-имин кайтып, яраткан җир-суында иҗатка чумып эшләү белән генә аңлатып булмый. Әле ул сөргеннең дә

рәсми реабилитациясен Урманче үз гомеренең соңгы көннәрендә генә алуын онытмау белән бергә анда фидакарь шәхес булганын тәкъдир итик.

"Айгөл" дигән шигырь һәм портретлар циклында шундый мәхәббәт, гармония, ике кеше күңелен тутырып торган матурлык калка ки, андый хисләр үзләреннән-үзләре генә килеп чыкмый. Югары гакыл аша, бер-береңң өчен үзеңне корбан итәргә әзер тору аша һәм үзеңне генә яратудан баш тарту аркылы үсә, пәйда була ул хисләр. Урманче хатын-кыз җанына гына хас сафлыкка мәдхия җырлый һәм безне "хатын-кызга мөнәсәбәт—ул Дөнья җанына, шул исәптән синең үзеңнең җанына да мөнәсәбәт" дигән фикерне аңлауга якынайта. "Син рухани якын бер җанны үз эченә кабул итәсең һәм шуның белән эгоизмыңнан да арынасың,—дигән кебек була рәссам.— Шул вакытта гына синең җаның бөек рух белән өретелә, шул вакытта гына ул үлемсезгә әйләнә".

Гомеренең соңгы сәгатьләрендә рәссамның көндәлегенә язып куйган сүзләре дә тирән мәгънәле һәм әһәмиятле. Үлем онытылуында торган кыска гына бер вакытта аны тәмам ачылып, ул үзенә бик тә якын булган җанга—җәмәгатенә болай мөрәҗәгать итә: "Син минем белән бәйләнешеңне югалтма. Без хәзер яңа тормыш башлыйбыз..." Бу сүзләр Урманче тарафыннан телдән генә әйтелгәндә дә буш сүзләр булмас иде. Аларны символик мәгънәдә дә аңларга ярамый. Бары туры мәгънәсендә, ягъни алдан күрүче (үз тәҗрибәсе буенча), фани дөньяның ахирәт белән рухани әйләнеше хакында язган дип белергә кирәк.

Урманче үз гомере белән ике дөнья арасында күпер салып калдырды. Әле бу дөньяны калдыргач та, үз халкына һәм заман Рухына хезмәт итәргә теләүчеләргә үз импульсларын үткәзеп ярдәм итәчәк. Аксакалның күп мәгънәле бу сүз-васыяте үз әсәрләрендә рухи омтылышларын тулаем чагылдырган үз халкына да юнәлтелә алган булыр иде. Бүгенге дөньяда кешеләргә җаннарын корытучы вульгар материалистик ориентацияләргә, һәлакәтләргә илтүче эгоистик теләкләргә каршы тора алырлык, аларны тигезләрлек рухи идеаллар табу мөһим.

Бакый Урманче үз иҗатын тулысы белән кайтавазын ишеткән Илаһи башлангычка багышлады. Бу иҗатташлык Заман Рухына җавап бирүче, мәңгелек бәйлыклар булган Хакыйкать һәм Ирек юлында якты, сүнмәс маякка тиң сәнгать тудырды.

Безне хәзерге заман "багышлама"сына илтүче татар милли культурасы үсешендәге үзәк импульс Урманче аша уза. Һәм без, аның замандашлары, бөек рәссам иҗатын үзебез өчен ачып кына калмыйча, аның эпохаль әсәрләрен мәңгеләштерергә тиеш. Җөмләдән, Казанның үзәк мәйданнарын яңа буыннарга нур сибеп торучы, көчле рухлы Мәрҗани, Дәрдмәнд, Ибраһимов һәйкәлләре белән бизәү мәгкуль булыр.

---

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ:

"Чынында мин рухым белән Казаннан беркайчан да китмәдем... Күңелем һәм йөрәгем монда. Кайда гына булсам да Казан турында уйлыйм һәм татарча дога кылам, мөселман булып яшим. Читтә сөйләшергә кеше булмаса, Алла бар, дим, Алла белән туган телдә—татарча сөйләшеп була. Кулымнан нинди эш килә, барысын да—тәрҗемәме ул, башкасымы—Татарстан өчен, туган халкым өчен булсын дип тырышам. Менә Лондонда "Казан" дигән альбом чыгардык, татар поэзиясе антологиясен чыгарырга торабыз. Кайбер татар шагыйрьләренең аерым әсәрләрен инглизчәгә тәрҗемә иттем һәм бастырып чыгардым. Би-Би-Си радиосы дулкыннарында Татарстан турында сөйләргә тырышам, татар көйләрен эфирга җибәрәбез. Би-Би-Си бик зур корпорация, ул бөтен дөньяга сөйли. Шуның аша татар көйләрен ишеттерәсе килә. Мәсәлән, Илһам Шакиров җырлары инде берничә мәртәбә Би-Би-Си дулкыннары аша дөньяның барлык илләрендә яңгыратылды".

*Бу өзек бүгенге көндә Лондонда яшәп иҗат итүче, Би-би-Си радиосында эшләүче танылган шагыйрь* ***Равил Бохарайның*** *шагыйрь* ***Гәрәй Рәхим*** *белән әңгәмәсеннән алынды. "Татарның үз миссиясе бар" дип исемләнгән әлеге язма журналның быелгы 2 санында басылып чыгачак. Моннан тыш та яңа санда укучыларыбызны җәлеп итәрлек яңа әсәрләр байтак.* ***З. Зәйнуллинның*** *"Агыйделнең аръягында" романы (ахыры),* ***Г. Ахуновның*** *"Тимерханның эзләнүләре" документаль повесте,* ***Ф. Батталның*** *сатирик хикәяләре,* ***А. Тимергалинның*** *"Пәйгамбәр" дигән күләмле язмасы, туксанынчы еллар әдәбияты хакындагы анкетага җаваплар әнә шундыйлардан. Шигырь сөючеләргә исә* ***Зөлфәт, Ш. Маннап, Җ. Дәрзаман*** *һәм* ***Г. Садәнең*** *яңа шигъри бәйләмнәрен бүләк итү күздә тотыла.*

*Тарих*

# ӘДӘБИ ТЕЛЕБЕЗ ТӨБЕНДӘ— АЛТЫН УРДА ТЕЛЕ



МАТЕРІАЛЫ

для

ИСТОРІИ КРЫМСКАГО ХАНСТВА

САНКТПЕТЕРБУРГЪ, 1864.

Шанлы һәм бай тарихын җанландыру, мәйданга кайтару өчен татар халкы берничә тапкыр көчле талпыну ясап караган. Һәм шулар нәтиҗәсендә мәйданга берсеннән берсе соклангычрак тарихчылар, фидакарь галимнәр килгән. Тарихыбыз җәүһәрләре "Дастан-и әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер" ("Дастаннар китабы"), "Әс-сәбгъс-сәйяр" I-Миңлегәрәйдән (1466 ел) II-Миңлегәрәйгә кадәр (1757 ел) Кырым ханнары тарихы) китапларын бастырып, халкыбыз тарихының яңа сәхифәләрен ачкан Ибраһим Хәлфин (1778-1829) шундыйларның берсе. 1858 елда Русия Фәннәр Академиясе юлламасы белән Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәүдәге архивында ел буе диярлек казынып, Кырым ханнары язмалары һәм документлары күчермәләрен алып чыккан Хөсәен Фәезханов (1828-1866) та шундый фидакарьләр рәтендә. 1864 елда ул аларны "Кырым йортына вә ул тарафларга даир *(мөнәсәбәтле)* булган ярлыклар вә хатлар" *("Материалы для истории Крымского ханства...")* исеме астында аерым китап итеп бастырып чыгара. Бу ике фидаи Кырым тарихын, Алтын Урда һәм Казан тарихларына охшатып, юкка чыгарудан шулай саклап калалар. Шаккатырлык шул! Бу материаллар дөнья күргәч аларны Көнбатыш тарихчылары файдалану ихтималы туа. Менә шул чакта беренчелек данын үзенә эләктереп калыр өчен Русиядәге төрки халыклар мәдәнияте палачы, карагруһ профессор, төрки китаплар цензоры В. Д. Смирнов эшкә керешә— Кырым ханлыгы тарихын язу эшенә алына. Шул ук вакытта аның шикелле мөтәгалимнәр тырышлыгы белән Хәлфин, Фәезханов хезмәтләре искә дә алынмый, гүяки алар бөтенләй булмаган. Ул гына да түгел, аларны хәтта башка урыс галимнәренеке дип раслау барлыкка килә.

Әмма эш инде эшләнгән. Бу галимнәр эшчәнлеге тарих фәнебез өчен яшәү суы бөркегәндәй була. Тарихыбызны эшләүнең Ш. Мәрҗанилар, Р. Фәхретдиннәр этабына юл мөмкинлеге ачыла.

Бу мәкаләдә Хөсәен Фәезхановның югарыда телгә алынган хезмәте белән укучыларны берникадәр таныштырып үтмәкче булабыз. Башта автор турында берничә сүз.

Хөсәен Фәезханов хәзерге Нижний Новгород өлкәсе Краснооктябрь районы Сабачай (Сафа җай) авылында 1828 елда дөньяга килә. Үз авылларында, аннан соң Казан якларына килеп, Бәрәскә авылы һәм Казан мәдрәсәләрендә белем ала. Шәкертлек дәверенең соңгы биш елын Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә үткәрә. Шәкерт белән остаз арасында иң якын дустанә мөнәсәбәт урнаша. Бер үк вакытта, белемгә һәвәс шәкерт университет даирәләре белән аралаша башлый, урыс теле һәм тарихын

үзләштерә, бу өлкәдәге белемнәрен камилләштерә. Университетның Көнчыгыш телләре бүлеге профессорлары А. К. Казембек, И. Н. Березин лекцияләренә йөри, бу өлкәдәге фән казанышлары белән таныша, фәнни-тикшеренү методларын үзләштереп, үз чоры Европа фәне югарылыгында торган шәрыкшөнас—Көнчыгыш халыкларын өйрәнүче белгеч булып җитешә. 1855 елда Казан университетының Көнчыгыш бүлеге Петербург университетына күчерелгәндә, фәнни хезмәткә сәләтен күрсәтеп өлгергән мулла Х. Фәезханов та төрек-татар телләре укытучысы итеп чакырыла. Биредә дә ул университетның һәм Фәннәр Академиясенең Көнчыгышны өйрәнүче күренекле галимнәре белән аралаша, булачак күренекле казакъ мәгърифәтчесе Чокан Вәлиханов белән якынлаша; яңа фикер хәрәкәте вәкилләре, урыс революционер-демократлары белән кызыксына, Курочкиннар, Пашинолар даирәсе белән якынлашу шул җирлектә барлыкка килә. Х. Фәезханов шул еллар татар укымышлылары арасында алдынгы фикерле, киң мәгълүматлы, тирән белемле, урыс фән дөньясында иң танылган бер кеше була. Мәскәүнең Тышкы эшләр министрлыгы архивында Кырым эшләре папкаларындагы кульъязмалар белән танышу эшен Фәннәр Академиясе ышанып аңа тапшыра. Яшь галим бу эшне сокландыгыч рәвештә башкарып чыга. Әйтер идем, колда да сирәк очратырлык чыдамлык, түземлек һәм аттай эшли алу сәләте күрсәтә. Аның өч-дүрт айлык хезмәт җимеше—хәтта күз алдына китерә алмас дәрәҗәдә зур. Ул сайлап алган язмалар иң кырыс фәнни таләпләргә җавап бирерлек төгәллектә һәм зур форматтагы 1000 битле басма китап күләмендәге документлардан гыйбарәт. Бу—яшь галимнең үзе эзләгән, үзе ярсып теләгән эшкә юлыгуы нәтиҗәсе. Ул татар халкы тарихы юкка чыгарылудан өзгәләнә; шул кимчелекне күпмедер дәрәҗәдә төзәтү мөмкинлеге ачылганда саулыгын, гомерен корбан итәрлек, эшләргә әзерлеген, сәләтен күрсәтә. (Һәм шулай булып чыга да: ул бик яшьли үпкә чиренә юлыгып 38 яшендә вафат була).

Аның хезмәтләре Академиянең 1858 елның 10 октябрьдә үткәрелгән зур җыелышында тикшерелә, аларны аерым китап итеп бастырып чыгару турында карар кабул ителә. Басмага редактор итеп академик В. В. Вельяминов-Зернов билгеләнә. Материалны басмага әзерләүдәге барлык “кара” эш исә тагын Х. Фәезханов өстендә кала. 1864 елда Х. Фәезханов күчермәләре—378 документ—кирпеч калынлыгындагы мең битле китап булып басылып чыга. Кереш мәкаләдә аны урысча да (китап оригинал телендә—татар телендә чыга) бастырып чыгару вәгъдә ителсә дә, ул чыкмый кала. Ә инде китап булып чыккан көннән бу хезмәт Х. Фәезханов исеменнән бөтенләй аерыла һәм академик исеме белән генә инде “Вельяминов-Зернов китабы” дип кенә атап йөртелә башлый. Х. Фәезханов исеме урыс фәнендә юкка чыгарыла. Без, татар тарихчыларының, моны онытырга хакы юктыр дип беләм. Түбәндә күренекле татар галиме Х. Фәезханов әзерләгән шул китаптан бик кызыклы бер документны укучыларга тәкъдим итәм. Ул татар теленең борын-борыннан дипломатия теле булуын тагын бер искә төшерүче документ буларак та, бүгенге сәяси вәзгыятьтә кайбер термин вә атамаларны эзләгәндә, кулланышка керткәндә ярдәмче әсбап буларак та кызыклы.

## Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйнең Польша короле Сигизмунд белән солых шартнамәсе (1520 ел)

Һүәл мөгазел могыйн. Бисмиллаһер-рахманир-рәхим *(Ул шан һәм ярдәм бирүче—Рәхмәт иясе Рәхимле Аллаһ исеме белән)* Бәлкуател Әхәдият вәл могҗизател Мөхәммәдият *(Берлегенең куәте һәм Мөхәммәдилек могҗизасы белән—югары дәрәҗәдәге язышулар алдына куела торган формула-гыйбарәләр)*.

Олы Урданың олу ханы, Дәште Кыпчак, барча Могул падишаһы

Мөхәммәдгәрәй хан, Сүзем—Ун кул, Сун кулның төмән, мең, йөз, ун белгән (билгән?) угланнар, биләр, мирзаларга; барча әләх *(ләх, поляк)* йортының кнәз Арс пишкуб башлыг, тәкый Лажлау пишкубы кнәз Матиаска, тәкый Прамсланың *(Перемышельнең?)* кнәз пишкуб путкансәләргә, тәкый Кирәгү вирдәсе(?) дәздары *(дәждар—начальник, комендант)* пан Криштуф олу канисәларга *(канцлерга)*, тәкый олу хәзинәче пан Никулайга, тәкый Каманичә *(Каменец?)* иләү виюдасы *(воеводасы)* олу маршалга, тәкый Позна *(Познань?)* виюдасыга, тәкый Судумир *(Сандомир?)* виюдасы пан Флияр олу һидманга, тәкый Люблин виюдасы пан Тусунҗеккига, тәкый болардан башка әләх йортының олу пускубларына вә калуникларына *(каноник-попларга?)* вә пиал банларыга *(паннарына)* вә мишчанларыга, вә эчке-дашкысыга, вә күп кара илгә—барча түзүнҗа Беленләр кем, мин, үзем Мөхәммәдгәрәй хан, тәкый углым Баһадиргәрәй солтан—без күрдек: безем кичкәнләремезнең дуслыгыны вә карендашлыгыны һәм барып-килешлегене. Олу Туктамыш хан берлә олу Хаҗигәрәй хан бабам башлап, олу корал *(король)* Ладежлау Ягал берлә әләхнең, андан соң Либканың *(Литваның?)* олу Давыд би берлә, андан соң Казимир курал (король), Әләхнең-Либканың олу би берлә. Болар берлә безем олу хан аталарымыз, агаларымыз—дус, карендаш ирде. Һәм барышыклыклары


قریم یورتینه
واولطرفلارغه دائر بولغان یرلیغ لرو خط
هو المعز المعین
بسم الله الرحمن الرحیم
بالقوة الاحدية والمعجزات المحمدية

чын ирде. Һәр дустка—дус, һәр дошманга—дошман ирделәр. Һәм нүкәрләре артып һәм мәмләкәтләре мәгъмүр *(төзек)* булып, дуслары—сөенеп, дошманнары сукыр булып ирде. Имди без дә ул борынгыларымыз барышкан юсенчә *(рәвештә)*, ары, чын күнелдән, Мөхәммәдгәрәй хан, тәкый углым Баһадиргәрәй, тәкый барча угланнарым-солтаннар, тәкый барча угланнар, биләр, мирзалар, тәкый барча эчке-дышкы нүкәрләремез, барымыз бергә торып. Бу шартнамәмезне алып барган—олу илчемез Ширин, дәүләтең би карачымызның углы Әүлия мирза Тити, урда би—инамлы *(өстенлекләргә ия)* нүкәрем Ибраһим би, тәкый сез карендәшемнең илчеңез пан Аинки Курнастай, тәкый, безем-сезең, яхшылыгымыз теләр агустин гари балдыз куалир Асирундыр. Боларның күзенчә *(күз алдында)*, безем Коръанымыздан без ант шарт кылдык кем: сез Жикмонд (Сигизмунд) курал карендашым берлә дуст, карендаш булгаймыз. Дустына—дуст, дошманына—дошман булгаймыз, бер-беремезгә, ничек кем әүвәлгеләремез ирделәр. Болай булган соң, безем арамызга һичбер дошман кереп булмастыр. Тәкый сез карендашем дә, безем дошманымыз Шәех Әхмәд ханны, янында нүкәрләрене бик *(бикләп, ябып)* тотып, үлем йиткинчә, мәмләкәтеңездән чыкармагайсыз. Тәкый безем арамызда катнаша *(йөри)* торган илчеләремезне, без дә—сез дә, ике айдан артык торгызмай, яхшылык берлә, терек йибәрәлек. Арамызда кешеләремез—терек барышып килешсәләр, ул—яхшыдыр. Тәкый, безгә әйткән, ел саен йибәрер

унбиш мең бүләк флүрене *(акча бирәмлеге)*, Әләх-Либка—бу ике йорттан сез карендашымдән теләк итәрмез. Имдидән соң, бер булҗәлдә *(үлчәмдә-мулҗәлдә)* йибәргәйсез, сезең йомыртка *(пасха)* бәйрәменездән йите һәфтә *(атна)* соң, пәнтәкүштә(?) бәйрәмеңездә йибәргәйсез. Тәкый Әләх йортыңыз өчен бер шартнамә теләтә йибәрепсез. Без дә бу, алтын берлә язган алтын нишанлы *(пичәтле)* шартнамәмезне олу илчемез Әүлия мирза Тити Ибраһим би берлә, сезең илчеңез Аинки Курнастай берлә, әләх йортыңыз өчен, сезгә йибәрдек. Әләх йорты, Липка йорты, икесе дә бергә-бердер. Һәркем, әләх йортының, Люблин илә вә Каманич Пудулия, Мажи(?), Бужа һималых(?) Латича(?) вә замкын, Бучачи, Бәльс(?), Сукал(?), Промислаус(?), Кулла, Эскала, тәкый болардан башка кирмәнләреңезгә, салаларыңызга, барча сезгә санлы илеңезгә—мәмләкәтеңезгә кем дошман булса, безгә дә дошмандыр. Һәркем әләх йорты берлә Липка йортына, бу ике йортка дошманлык сагынса, без аларга дошманмыз. Тәкый әләх йортыңдан, безем илемездән сезнең илеңезгә, сезнең илеңездән безем илемезгә базаргян *(сәүдәгәр)* барышып-килешкәй, көч-басыныч *(талау)* күрмәгәйләр. Йөз акчадан өч акча тамга биреп, андан башка тамга-бартынак *(салым)* бирмәгәйләр. Әман килеп, исән-әман киткәйләр. Әгәр безем угылларымыз солтаннардан, тәкый углан биләрдән, мирзалардан, казакларымыздан, барча безгә санлы *(безнеке хисапланган)* кешеләремездән, көч-басыныч кыйлып, малларын алсалар, алып биреп, түләгәймез. Безем базаргянларымызга да сезнең илеңездә-мәмләкәтеңездә, көч-басыныч булса, сез дә бер эксуксез *(кимчелексез)* түләгәйсез. Имди бу шартнамәмездә язылган барча сүзләремез өстенә, чынлык берлә, бик торыр өчен, мән үзем—Мөхәммәдгәрәй хан, углым Баһадиргәрәй солтан башлык барча угланнарым солтаннар, тәкый барча угланнар, биләр, мирзалар вә, эчке-дышкы барча нүкәрләрем сезгә бең ант шарт итәрмез: Тәңренең ады өстенә, тәкый динемездән, тәкый йөз мең, егерме дүрт мең пәйгамбәрдән, тәкый безем пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа хәзрәтеннән кем, Валлаһ вә Биллаһ вә Таллаһ, сезнең берлә ару *(саф)*, чын күңелдән дуст-карендашмез. Бу шартнамә эчендә язылган барча илеңезгә-мәмләкәтеңезгә, шәһәрләреңезгә, салаларыңызга—барча сезгә санлу илеңезгә-көнеңезгә, барча кешеләреңезгә бездән, угылларымдан, угланнар, биләрдән, мирзалардан, эчке-дышкы нүкәр ишемдән, казакларымыздан яманлык булмагай. Бу шартнамә сүземездән үзгә төрле булмагаймыз.

Бу шартнамәмезнең чынлыгы өчен, алтынлы шартнамә, алтын нишан басып йибәрдек, тарих тукыз йөз егерме алтыда, мөбарәк зөлкагыйдә аеның тугызынчы, якшәнбә көн. Шәһре мөгаззәм Фәрхе кирмәндә бөтелде.

*(Хәзерге ел хисабына күчергәндә, 1520 елның 22 октябре килеп чыга. Әмма 22 октябрь 1520 елда якшәмбе түгел, сишәмбе. Һәр һиҗри елга берәр көн аерма, чынлыкта, күрәсең, хәзерге 27 октябрь—якшәмбе көн язылган)*

Бу текстта мине иң беренче үтә гаҗәпләндергән нәрсә—аның теле. Бу Кырым татарлары теле дә түгел, XVI гасырга инде гарәп-фарсы алынмалары белән үтә чуарланган госманлы яки Төркестан төркисе дә түгел. Ул тулысы белән диярлек бүгенге Идел буе төркисе. Бу тел—Алтын Урда мирасы. Казан ханлыгы шикелле үк үзен Алтын Урданың беренче (һәм бердәнбер) варисы ("Олы Урданың олы ханы") дип расларга тырышкан Кырым ханлыгы да Алтын Урда эш кәгазьләре телен үзенә мирас итеп ала. Ягъни Х. Фәезхановның бу китабында без—юкка чыгарылган дип саналган, Алтын Урдадагы дәүләт эш йөртү кәгазьләре үрнәкләрен, аның тел үзенчәлекләрен саклаган бай мирас белән очрашабыз. Шул ноктадан, алар безнең мәктәпләрдәге тарих дәресләрендә, югары уку йортларында тел дәресләрендә җентекләп өйрәнелергә, өйрәтелергә тиешле мирас. Кызганычка

каршы, бездә бу эшкә карата һаман туң, бюрократик мөнәсәбәт:"Тарихыбыз юк!","Тарихыбыз юкка чыгарылган"...—дип ялган"яшь түгеп" акланган булып, эшләмичә, бар нәрсәне юк итеп яшәү канга сеңдерелгән.

Беренче сүзләреннән: "Олы Урданың олы ханы, Дәшти Кыпчак, барча Могул падишаһы", "Уң кул, Сул кулның төмән, мең, йөз, ун", хәрби бүлекләр башлыклары—"угланнар, биләр, мирзалар"—һәр сүзе Алтын Урданың административ, хәрби, сәяси тормышындагы билгеләмәләр, категорияләр, иҗтимагый, социаль төзелешенең ташка уелган билгеләре һәм билгеләмәләре, Алтын Урда сәяси терминнары, Алтын Урда теле. Дәүләтнең соңгы 100-150 елында Алтын Урда ханнары Көнчыгыш төбәкләрдән килгән. Батый хан варислары (туганнары—Урда Ичен һәм Шәйбан токымнары) Батыйдан соң Болгар улусы якларында очрактан очракка гына булганнар, нигездә алар—"Дәшти Кыпчак" (Каспий-Кара диңгез буе далалары) ханнары. Илне берләштергәндә дә, күбрәк Кавказ буйларында, Кырым тирәләрендә яшәгәннәр. Менә шул дәүләтнең язма телендә исә, Көнчыгыш төбәкләр (казакъ) теле тәэсире дә, Каспий-Кара диңгез буе төркие (нугай теле, Кырым татар теле) элементлары да күренми. Урта Идел татар теле лексик берәмлекләре, морфологик-синтаксик формалары исә җәйрәп ята. Х. Фәезханов хәрефен хәрефкә туры китереп күчергән дип уйласак, "суң (кул)", "башлык", "болардан башка", "эчке-тышкы", "кара-ил" (халык) һ.б. кебек Урта Идел сөйләм теленә якын формаларының активлыгы гаҗәпләндерерлек күренеш түгелме? Безнең бүгенге әдәби телебез шул язма телнең архаизмнардан чистарып камилләшә барган варианты икәнен күрү-аңлау кыен түгел (Бу нәрсә безнең бүгенге фәндә кабул ителгән язма һәм әдәби телебезнең нигез диалекты турындагы карашка да җитди төзәтмә кертә. Безнең хәзерге язма һәм әдәби телебезгә урта диалект—Казан арты сөйләме нигез итеп алынган, диләр. Болай фикер йөрткәндә"Казан арты телен" әле Алтын Урда үз язма һәм әдәби теленә нигез итеп алган булып килеп чыга түгелме?..

Бу телнең эчке егәре, мәгънә структурасы да аның Алтын Урдадан күчерелүенә тагын бер көчле дәлил була ала. Төрлечә аңлауга, ул якка-бу якка тарткалауларга, фикер төгәлсезлекләренә урын калдырмый торган юридик билгеләмә булырлык, конкрет, документаль сөйләм. Рим юридик кагыйдәләренә, "Юстиниан кодексы"на нигезләп төзелгән диярсең. Үзен "Олы (Алтын) Урданың олы ханы, барча Могол падишаһы санаган Кырым ханнары бу, формалалардай төгәл сөйләмнең төзүчесе—иҗатчысы була алыр микән? Юк, бу тел—Бөек дәүләт—Алтын Урдада формалашкан хәзинә, Кырымда яки Казанда ул инде мирас рәвешендә йөртелгән. Алтын Урда мәдәнияте хәзинәсе үзенең яшәүчәнлек кодрәтен күрсәтеп әнә шулай төрле җирләрдә кабат-кабат шытып чыга. Үтә күренмәле гадилектән, ясалма купшыландыру-күбекләндерү, күпертүләрдән бөтенләй азат сөйләм—бөек көч, бөек дәүләт хәзинәсе генә була ала. Ул елларда әле варислар бу хәзинәне җуймаган булган, шул көн кирәкләренә, үз дәгъваларын дәлилләргә иркен файдаланганнар. Казан ханлыгы да әлеге хәзинәдән, эш кәгазьләрендә һәм язу культурасында, нәкъ шулай файдаланган дип шикләнмичә әйтә алабыз. Аның ханнары да урыс кенәзләре каршында ,«Олы улусның олы ханы, барча Могол патшасы», Алтын Урданың чын һәм бердәнбер варисы сыйфатында, чар («царь») исемен йөрткәннәр... Димәк, бу документ, галимебез Хөсәен Фәезханов мәйданга куйган бу материаллар халкыбыз өчен икеләтә әһәмиятле. Алар, беренчедән, Алтын Урданың социаль төзелеше, язма һәм әдәби теле, эш кәгазьләре йөртү культурасы турында сөйләгән ышанычлы дәлилле бай чыганак булып торалар. Икенчедән, алар аркылы без Казан ханлыгы чорының рухи мәдәнияте, рәсми эш кәгазьләре теле, язма һәм әдәби телебезнең ерактагы халәтен күз алдына китерә алабыз.

**Мәсгуд ГАЙНЕТДИН.**

*Фатих Кәримнең тууына 90 ел*

**Рафаэль Мостафин**

# “ӨЗЕЛЕРГӘ ҖИТЕП СЫКРЫЙ КҮҢЕЛЕМ...”

## ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫНДАГЫ “АК ТАПЛАР”

*“Татар әдәбияты тарихы”нда (5 нче том, 95 бит) шагыйрь гомеренең бу еллары турында нибары бер җөмлә белән әйтелә:*

**“Бөек Ватан сугышы чорына Ф.Кәрим шәхес культы белән бәйле репрессияләр, төрмәләр, лагерьлар аша үтеп, ныгыган, чыныккан шагыйрь буларак килеп керде”.**

*Башка басмаларда да Ф.Кәримнең 1938 елның башыннан алып 1941 елның ахырынача булган гомере бөтенләй диярлек яктыртылмаган.*

### Беренче таш

Утызынчы еллар репрессияләренең үзенә күрә бер “кануны” була. Иң элек берәр газетада теге яки бу язучы турында үтергеч мәкалә басыла. Аннары әлеге мәкалә уңае белән “чаралар күрү” башлана: башта корбан буласы кешене партиядән яки комсомолдан куалар, аннан соң эшеннән чыгаралар. Ә тагы бераздан әлеге бәндә суга төшкәндәй эзсез югала. Әсәрләре басылмый, җырлары башкарылмый, исеме әдәбият тарихыннан сызып ташлана...

Фатих Кәрим белән дә нәкъ шулай була. Аңа беренче ташны “Яшь ленинчы” газетасы һәм “Пионер каләме” журналының баш мөхәррире язучы Ләбиб Гыйльми ата. “Кызыл Татарстан” газетында (1937 елның 29 март) басылган мәкаләдә ул Ф.Кәримне “чит элемент”, ягъни “халык дошманы”, “советка каршы коткы таратучы” дип атый. Мәкалә авторы яшь шагыйрьне үзенең социаль чыгышын яшерүдә (янәсе, мулла малае була торып, шуны яшергән дә алдау юлы белән комсомолга кергән), әсәрләрендә комсомолга, совет иленә яла ягуда һәм—иң әшәкесе!—рус шагыйре, “троцкийчы” Павел Васильев белән “элемтәдә булуда” гаепли. Ф.Кәрим, чыннан да, моннан берәр ел элек Мәскәүдә үзенең яраткан шагыйре Павел Васильев белән очраша. Алар ресторанда бер кич утырып гәп коралар, шигърият турында сөйләшәләр. Ә бераздан П.Васильевны “троцкизм”да гаепләп кулга алалар. Димәк,—ул чор карашлары буенча—Ф.Кәрим дә “троцкийчы” булып чыга.

Әлеге мәкаләнең тарихы турында Ф.Кәрим үзенең хатыны Кадриягә болай сөйләгән. Берничә ел элек Л.Гыйльми—ул вакытта әле комсомолның Татарстан өлкә комитетының икенче сәркәтибе—китап нәшриятына үзенең яңа гына тәмамланган “Чын мәхәббәт” исемле романын алып килә. Нәшриятның яшьләр-балалар редакциясе мөдире булып эшләүче Ф. Кәрим, романны укып чыккач, авторга кире кайтара. “Әсәр әлегә чиле-пешле, аның өстендә шактый эшлисе бар әле”,—дип әйтә. Республика күләмендә идеология эшләрен алып баручы, бу өлкәдә үзен зур белгеч дип санаучы Л.Гыйльминең моңа бик хәтере кала. Дөрес, ул романы өстендә эшләвен дәвам итә, аны шактый яхшырта, шомарта һәм 1936 елны аерым китап итеп бастырып та чыгара. Әмма җае чыгу белән үчен ала.

Калганнары инде югарыда телгә алынган “канун” буенча эшләнә. Ф.Кәримне

комсомол сафларыннан чыгаралар, бераздан нәшрияттан куалар. Тиздән кулга алачакларын сизенеп, Ф.Кәрим 1937 елның җәендә йөкле хатынын кечкенә баласы Ада белән Уфага, туганнары янына "ял итәргә" җибәрә. Үзе бер тиен акчасыз калып, ачлы-туклы яшәп, иҗат эшләре белән шөгыльләнә. Бернichә ай эчендә ул Марк Твенның "Том Сойер мажаралары"н тәрҗемә итеп чыга. Ялкынланып, ихлас күңелдән тырышып эшли. Ипи алырга да акчасы булмаганлыктан, ул базардан иң арзанлы әчегән эремчек сатып ала да, шуны ашап ята. Хатыны Уфадан кайткач, бу "эт ашамас әче тваругны" ташларга җыена, шунда Ф.Кәрим, мыек астыннан гына елмаеп, әйтеп куя: "Алай димә, сөеклем... Ул булмаса, ирең ачтан үлгән булыр иде..." Шунда гына Кадрия ханым иренең нинди хәлдә калуын аңлый башлый—монача Ф.Кәрим аңа үз хәлләре турында бер сүз дә ычкындырмаган. Хәтта Уфадан пароходның яхшы каютасында кайтыр өчен әҗәткә алып торып акча да җибәргән...

"Том Соейр мажаралары"н Ф.Кәрим нәшриятка, үзе урынында калган язучы Гариф Гобәйгә илтеп бирә. Күп тә үтми Ф.Кәримне кулга алалар. Төрмәдән язылган записскаларында ул хатыныннан нәшриятка барып, тәрҗемәнең язмышы турында белешүен үтенә. Гаиләсенә матди яктан бераз ярдәм булыр дип ышана. Кадрия ханым Гариф Гобәй янына баргач, тегесе "Том Сойер мажаралары"ның кульязмасы бездә юк, ул югалган,—дип җавап бирә. Ләкин күпмедер вакыттан соң бу китап нәшриятта басылып чыга. Тик аның тәрҗемәчесе Г.Гобәй дип күрсәтелгән була. Кадрия ханымның күңеле мона бик каты әрни, ул бу турыда үзенең көндәлекләрендә кат-кат яза. Ләкин нишләмәк кирәк?! Ф.Кәрим төрмәдә утыра, ә тәрҗемәнең кульязмасы аларда калмаган!

## 2—5956 нчы "Эш"

Фатих Кәримне кулга алганда (1938 ел, 3 нче гыйнвар) аңа әле утыз яшь тә тулмаган була. 29 нчы туган көнен ул берничә көннән, 9 нчы гыйнварда, ялгыз камерада каршылый. Бу вакытта ул инде язучы, унлап китап авторы буларак (сигезе—шигырь, икесе—проза) татар укучылары арасында шактый танылган була.

Нәрсәдә гаепliләр соң Ф.Кәримне? Татарстанның Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивында сакланган 2-5956 нчы "Эш" мона беркадәр ачыклык кертә.

Яшерен шымчыларның хәбәр итүләренә караганда, Ф.Кәрим бервакыт якын дуслары белән сөйләшкәндә: "Бездә талант партбилетсыз үзенә юл яра алмый",—дип ычкындырган. Тәнкыйтьче Гомәр Галины кулга алгач, Хәсән Туфан фатирындагы мәҗлес вакытында ул күз яшьләрен агызып елаган, Г.Галиның тизрәк котылып, исән-сау әйләнеп кайтуы өчен тост күтәргән. Барлык "гаебе" менә шушы. Моңа өстәп тагын аны "социаль чыгышын яшерүдә" гаепliләр.

Менә шушы "факт"ларга таянып, НКВД хезмәткәрләре Ф.Кәримне "милләтче", "пантюркист", "буржуазияне яклаучы", "троцкичылар белән элемтәдә булучы" дип атыйлар. 1937 елның 29 декабрендә язылган кулга алу турындагы ордерда, боларга өстәп, аны ниндидер уйдырма "хәрби контрреволюцион троцкичы" оешмада булуда гаепliләр. Бу оешмада хәрбиләрдән Якуб ага Чанышев, язучылардан Кави Нәҗми, Газиз Иделле, Сафа Гыйльфан һ.б. торган, имеш. Оешма әгъзалары С.М.Кировны, М.Горькийны һ.б. үтерүдә катнашкан, имеш. Ул чор гадәтләре буенча, НКВД хезмәткәрләре кулга алынганнарның барысын да "террор әзерләүдә" гаепләп иң югары җәзага—үлемгә хөкем итәргә җыеналар. Конкретрак алганда Ф.Кәримнең бу яшерен оешмадагы роле "оборона темасына язылган әдәбиятны тоткарлап, аны дөньяга чыгармаудан" гыйбарәт була.

Менә шуннан соң китә инде сорау алулар, кыйнаулар, тәүлекләр буе аягүрә бастырып тотулар, йокысыз төннәр һәм башкалар, һәм башкалар... Әмма Ф.Кәрим алай җиңел генә сыгылып төшүчеләрдән булмый, нык тора, берниндi гаебен дә танымый, беркетмәләргә кул куймый.

1938 елның беренче яртысында эчке эшләр наркомы Ежов урынына Берия килгәч, "һавалар" беразга йомшарып ала. А. Солженицын бу күренешне

“временный откат”—вакытлыча йомшару дип атый. Атарга өлгермәгән яки кыйналып-изелеп тә кул куймаган кайбер тоткыннарны ирекκә чыгаралар, икенче берәүләрнең “эш”ләрен судка әзерлиләр. Әлбәттә, суд шул ук хакимият кулында кала һәм НКВД хезмәткәрләре күрсәтмәләрен тәгәл рәвештә үтәп тора. Шулай да суд өчен ниндидер дәлилләр кирәк була. Һәм бу дәлилләрне ашыгыч рәвештә оештыралар да...

Иң элек үз кул асларында булган, ихтыярлары сындырылган тоткыннарны файдаланалар. “Эш”тән күренгәнчә, Ф.Кәримне берничә мәртәбә К.Нәҗми белән күзгә-күз очраштыралар. Кыйналган, изелгән, тәмам кешелеген югалткан К.Нәҗми, язучы иптәшенең күзенә туры карамаска тырышып, тикшерүче кушканнарны кабатлап утыра. Янәсе ул Ф.Кәримне “контрреволюцион яшерен оешмага” әле “Кызылармияче” газетында бергә эшләгән чорда ук тарткан. Янәсе, шагыйрь аның кушуы буенча советка каршы яшерен эш алып барган. Ф.Кәримнең: “Бу эш нәрсәдән гыйбарәт иде соң?”—дигән соравына каушап кала, нәрсә әйтергә дә белми, Ф.Кәрим “тоткарлаган” бер генә әсәрнең дә исемен атый алмый. Шуннан соң аны тәрткәләп-суккалап алып китәләр. Яңадан “инструкцияләр” биреп, тагы очраштыралар. Ниһаять, тиешле беркетмәне төзиләр.

Шулай да К.Нәҗми НКВД зобаныйларының “ышанычын” тулысынча аклый дип булмый. Билгеләнгән көнне аны судка сак астында “шаһит” буларак китерәләр. Һәм ул алдан язылган, мәҗбүр ителгән “показаниеләрен” укып чыга. Шулай да адвокат төп енә башлагач:

—Әйе, мин Ф.Кәримне яшерен контрреволюцион оешмага тарттым, ләкин ул үзе бу турыда белмәде,—дип җавап бирә.

Соңыннан, аның бу ялгыш кына ычкынган сүзләренә таянып, адвокат Ф.Кәримне яклау җаен таба...

Башка тоткыннардан да шул рәвешле кирәкле “шаһитнамәләр” алалар. Әмма мондый “шаһитнамәләрнең” чың бәясен үзләре дә яхшы аңлаганга, болар белән генә суд алдына чыгарга җөрьәт итмиләр. Иректә, алар кулы астында булмаган “белгечләр” кирәк була. Һәм андыйлары да табыла: атаклы совет язучылары Нур Баян, Гариф Гобәй, Рахман Ильяс. Алар НКВД хезмәткәрләре кушуы буенча Ф.Кәрим иҗатына “идеологик күзлектән” экспертиза язалар. Бу документ ДКК архивында әлегәчә саклана. Монда нигездә Ф.Кәримнең “Аникин” поэмасы тикшерелә. Шигъри юлларны аннан-моннан йолкып, үзләренчә аңлатып, “белгечләр” бу зур күләмле, тирән эчтәлекле, патриотик хисләр тәрбияли торган әсәрне “идеологик яктан зарарлы” дип табалар.

Шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә алар “кулак идеологиясе”, “советка, революциягә каршы коткы тарату” күрәләр. Менә шушы документ суд барышында хәлиткеч рольне уйный һәм Ф.Кәрим язмышын хәл итә дә инде...

Болардан тыш, судка шаһит буларак Ибраһим Газины чакырталар. Башта аның белән Черек күл бинасында тиешле “әңгәмә” үткәрәләр, ризалыгын алалар.

Шул ук архив материаллары күрсәткәнчә, 1939 елның 15 февралендә НКВДга Хәсән ага Туфанны да чакырталар. Ул Ф.Кәримнең үзендә кунакта чакта Г.Галины җәлләп сүз әйтүен таный, ләкин шулай да аны үзенчә яклап маташа. “Ф.Кәрим халык дошманы түгел, аның бөтен иҗаты халык мәнфәгатьләрен яклауга багышланган”,—дип әйтә. Соңыннан суд барышында да ул бу сүзләрен кабатлый, НКВД хезмәткәрләренең ачуын чыгара.

Нәтиҗәсе билгеле. Татарстанның Югары суды Ф.Кәримне ун елга иреgennән мәхрүм итәргә дигән карар чыгарганнан соң, башкаларга кагылмыйлар, ә Туфанны озакламый кулга алалар һәм шул ук Черек күл төрмәсенә ябып куялар.

**Татарстан Югары суды чыгарган хөкем карарыннан: “Каримов Ф.В. обвиняется по статьям 58-2, 58-10, 58-11 Уголовного кодекса РСФСР в том, что он являлся членом контрреволюционный право-троцкистской националистической организации и проводил активную контрреволюционную деятельность на культурно-идеологическом фронте, возводя на страницах художественной литературы клевету на советскую действительность. На основании вышеизложенного Каримов Ф.В. приговаривается Судебной коллегией по уголовным делам Верховного суда ТАССР к десяти годам тюремного заключения с поражением в избирательных правах сроком на пять лет”.**

*14 марта 1939 года.*

## Тоткын язмышы

Кадрия ханым көндәлекләрендә суд булган көн турында тәфсилләп язылган. Март аеның кояшлы, җылы, матур көне... Кадрия ханым ирен судка кайчан алып киләчәкләрен алдан белеп, Чернышевский (хәзер Кремль) урамында коляска белән аны көтеп йөри. Колясkada кечкенә кызы Ләйлә мышный-мышный йоклап ята... Менә Югары суд бинасы янында "кара козгын" машинасы туктый. Машинадан төшкәндә берничә мизгелгә генә ябыккан, йончыган, саргаеп беткән Фатих Кәрим йөзе күренеп кала. Ул хатынын күреп, кин итеп елмая, аңа кул изи. Һәм шундук аны этеп-төртеп суд бинасына кертеп җибәрәләр. Документларга караганда, бу 1939 елның 13 нче мартында була.

Судтан соң да Ф.Кәрим бер елдан артык Казанда була әле. Башта Беренче төрмәдә утыра. Аннан соң аны шул ук төрмә күршесендәге Беренче колониягә күчерәләр. Монда обойный цехта тоткыннар төрле өй җиһазлары: диваннар, урындыклар, пружиналы матраслар һ.б. ясыйлар.



*Фатих Кәрим*

Суд карарыннан соң Ф.Кәримгә аена бер мәртәбә гаиләсенә хат язарга рөхсәт итәләр. Хатларның берсендә ул Кадриядән күлмәк-ыштан, кашык-тәлинкә, бераз тәмәке сорый. Киная белән генә үзенең кай тирәдәрәк утырганын да хәбәр итә. Шуннан соң Кадрия ике яшьлек Ләйләне ияртеп, төрмә янына килеп йөри. Ләйлә: "Әти! Кайт инде! Тизрәк кайт!"—дип кычкыра. Ф.Кәрим кызының тавышын ишетә, күз яшьләренә буылып, бәргәләнә-бәргәләнә тыңлый...

Төрмәдә утырганда да ул иҗат итүдән туктамый. Шигырьләрен күңелендә ятлап саклый. Мөмкинлек булу белән, Хәсән Туфан сыман, папирос кәгазенә вак-вак хәрефләр белән язып, кием җөйләрендә яшереп тота. Аның тоткынлык чорында язылган шигырьләре аеруча лирик җылылыгы, эчкерсезлеге, мөлаемлеге белән аерылып торалар. Фикере һәрвакыт ачык, хисләре кайнар, тын алышы иркен. Ул һич көчәнмичә, һава сулаган сыман, иркен яза:

Тәрәзәмә кунган ак күгәрчен
Гөрли-гөрли канат кагына.
Кагына да уйнап, очып китә
Син яшәгән өйләр ягына.

Ә мин калам тынчу таш төрмәдә,
Тимер рәшәткәгә баш иям.
Өзелергә җитеп сыкрый күңелем
Сагынудан сине, Кадриям!—

Бу шигырьләрдә тоткын хәле бик ачык чагыла. Алай гына да түгел, шигърият аңа яшәү көче бирә, кешелеген сакларга, сыгылып төшмәскә ярдәм итә.

Диңгез төбендәге кораб сыман
Караңгыга чумган таш төрмә.
Таш төрмәнең цемент иденендә
Йоклап яткан ристан төш күрә,—

Хурланудан калтырана ристан,
Язмыш, язмыш, аны нишләттең?
Башын япса, аягына җитми
Тиң ямаудан торган бишмәте.

Хөкем карары белән килешмичә, Ф.Кәрим 1939 елның 25 мартында

кассацион гариза яза, эшен яңадан тикшерүне таләп итә. Хатыны Крылова фамилияле адвокат яллый. Ул кассацион гаризаны рәсми яктан дөрес, дәлилле итеп язарга булыша, Ф.Кәрим янына колониягә дә килеп йөри, аны коткару өчен шактый көч түгә. Гаризада Ф.Кәримнең ул вакыттагы адресы болай күрсәтелгән: Казан, Зур Вахитов урамы, 18, ИТК номер 1, обой цехы.

## Үлем баржасы

1940 елның 26 июнендә Ф.Кәрим хатынына болай дип яза: "Мине бүген этапка алдылар. Мин икенче төрмәдә булырмын. Юлдан хат язып торырмын, борчылма. Иптәшләр бик яхшылар, без бик күп".

Берәр айдан аңардан икенче хат килеп төшә.

"Без хәзер Ак дингез буендагы Молотовск исемле яңа шәһәрдә (Архангельск өлкәсе) зур төзелеш эшендә эшлибез. Килгәч тә бераз уңайсыз булды, чөнки яңа климат үзенекен итте—һич ашап булмады. Хәзер рәтләнеп киләм..."

Хат 1940 елның 15 июнендә язылган. Тоткыннарның хатларын энә күзеннән үткәреп тикшергәнгә күрә, Ф.Кәрим дөресен әйтә алмый, бик сак яза. Сөекле хатынын да борчыйсы килмәгәндер. Ә менә соңыннан, дусты Х.Туфан белән Кремль асты төрмәсендә очрашкач, ул аңа бу "бераз уңайсыз хәл" турында тәфсилләбрәк сөйли.

Бервакыт этап белән төньякка алып барган тоткыннарны диңгез буена китереп бушаталар. Берничә көн көткәннән соң аларны иләмсез зур агач баржаның трюмнарына дыңгычлап тутыралар. Утырган чакта ук Ф.Кәрим баржаның бик иске булуына игътибар итә. Буялары уңып-кырылып төшкән, палуба такталары ярым черек, ярыклардан су саркыла. Тоткыннар тез тиңентен салкын суда басып торалар.

Баржаны буксир белән тарттырып каядыр алып китәләр. Шактый барганнан соң тоткыннар төтен исен сизә, дөрләп янган ут тавышын ишетә. Ярыклардан күреп алалар: конвой солдатлары, буксир корабына төялеп, ут капкан баржаны ташлап китәләр. Китә мәхшәр—ачыргаланып кычкыру, ләгънәт уку... Кайберәүләр, такта сыныкларын табып, баржаны эчтән җимерә башлый, палубаның пожар капмаган ягына чыга, суга сикереп, йөзеп чыгарга тырышалар. Әмма бозлы су бик салкын—әллә ни ерак китеп булмый.

Бераздан баржа су тулып бата башлый. Ф.Кәрим, такта кисәгенә тотынып, башкалар белән ярга таба йөзә. Күбесе батып үлә. Ярга берничә кеше генә исән чыга. Алар арасында Ф.Кәрим дә була. Сакчылар аларны берни булмаган сыман көтеп ала да, берәм-берәм җыеп, яңадан лагерьга китереп урнаштыра.

Ф.Кәрим сүзләренә караганда, бу махсус шулай эшләнә: тоткыннар шул кадәр күп була, аларны урнаштырырга урын, ашатырга азык-төлек җитми. Шул рәвештә диңгезгә батырып "артык авызлардан" котылалар.

Соңыннан Ф.Кәрим бу вакыйга турында туганнарына да сөйләгән. Алар әйтүенчә, бөтен баржадан ике генә кеше исән калган.

Ул арада Казанда Ф.Кәрим язмышына кагылган бик җитди вакыйгалар була. "Хәрби оешма" эше буш куык булуы ачыклана. Я.Чанышев, К.Нәҗми, Г.Иделле һәм башка тоткыннарны тулысынча аклап төрмәдән чыгаралар. Ә бит Ф.Кәримне аларның сүзләренә нигезләнеп, алар группасында булуда гаепләп хөкем итәләр. Бу турыда ишетү белән, Ф.Кәрим СССРның Генераль прокуроры исеменә бик дәлилле итеп тагы бер гариза яза. Аның гаризасына кушылып, Кави Нәҗми дә Генераль прокурор исеменә бик җентекләп гариза яза. Төрмәдән чыгу белән К.Нәҗми үзенең Югары суд барышында биргән күрсәтмәләреннән баш тарта, барысы да физик басым астында, кыйналып яздырылган дип аңлата. Ф.Кәримне яклап, бер генә язмый—кат-кат яза, үзе дә суд сукмакларын таптый. Бу эштә Якуп ага Чанышев та катнаша, адвокат Крылова да бик нык ярдәм итә.

Йөрүләре нәтиҗәсез калмый. 1940 елның 2 ноябрендә СССР Югары суды Ф.Кәримне гаепләү карарын нигезсез дип таба. Дөрес, тоткынны иреккә чыгармый

чыгаруын, ләкин аның "эшен" яңадан тикшерергә дигән карар кабул итә. Тикшерү эшен янабаштан үткәрү өчен Ф.Кәримне Казанга кайтару турында күрсәтмә бирелә.

## Коми тайгасында

Фатих Кәримнең гаиләсенә язган хатларына караганда, тоткыннарны Ак диңгез аша Печора елгасы бухтасына илтергә тиеш булалар. Ләкин беренче баруда алар төялгән пароход боз тауларына килеп төртелә. Җәй уртасы булуга карамастан, пароход үтә алмый. Бозваткыч та бу очракта ярдәм итми. Тоткыннарны кире Молотовск шәһәренә кайтаралар. Бераздан, күрәсең, бозлар тарала төшә һәм тоткыннарны Коми тайгасы уртасына илтеп ташлыйлар.

1940 елның 6 июлендә язган хатында Ф.Кәрим үзенең яңа урында, Ягрын лагеренда булуын хәбәр итә. Адресын ул болай күрсәтә:

*Коми АССР, пос. Кожва*
*Усть-Усинского р-на, Печлагстрой, НКВД СССР*
*3-е отделение, колонна номер 40.*

Хатына шагыйрь юл тәэсирләрен чагылдырган шигырен салган, шигырьнең бер генә данәдә булуын һәм аны аеруча нык сакларга кирәклеген искәрткән:

Бәйсезлектә ярсып дулый-дулый,
Сырты күбекләнгән дулкыннар
Озаттылар мине Ак диңгездән,
Алда—үлчәү җитмәс упкыннар.

Алда кыргый бозлар океаны,
Җир шарының төньяк түбәсе,
Бу түбәгә, каршы йөзеп килгән
Боз тауларын җимереп менәсе...

Яңа урында да ул шигырь язуын дәвам итә, бу шигырьләрдә ул яшәгән мөхит ачык чагыла:

Ерып чыгалмаслык чиксез тайга.
Җәй дә монда ике ай гына.
Тын алмыйча тоташ улаган җил
Сала мине кара кайгыга.
Бөтен тормыш—көн-төн сыкрап эшләү.
Кәгазь дә юк монда, каләм дә...

Ф.Кәримне Казанга күчерү турындагы карар 1940 елның ноябрь башында ук кабул ителгән булса да, бу карарны үтәргә бик ашкынып тормыйлар, төрле сәбәп табып, аны Коми лагерьларында тоталар. Шагыйрь бу турыда үзенең 1941 елның 6 мартында язылган хатында ачынып яза. Аның язуына караганда, аны әле 18 февральдә үк Казанга кайтарып җибәрергә тиеш булалар. Ләкин бюрократик сәбәпләр аркасында ("Эше" әзер булмау) аны тоткарлап калдыралар. Ул бик авыр хезмәттә—Воркута ягына тимер юл салу эшләрендә катнаша. Тоткыннар тачка белән сазлыкка ком, таш, балчык ташыйлар. Нормасы зур, үтәрлек түгел. Ә норма тутырмаган кешегә паек бирелми. Соңыннан сәламәтлеге какшау сәбәпле аны бухгалтериягә күчереп, исәп-хисап эшен алып барырга кушалар.

Хат саен диярлек ул Кави ага Нәҗми, аның хатыны Сәрвәр апаларның хәлен сорашып тора, башка язучы иптәшләренә дә сәлам юллый. Үзеннән хатлар килеп торса да, лагерьга Кадрия язган бер хат та килеп җитми. Ә бәлки, килеп тә тапшырмаганнардыр...

Кожва поселогыннан соңгы хаты 1941 елның 27 мартында язылган. Шуннан соң, күрәсең, аны этап белән Казанга алып китәләр.

**"Муса Җәлил дә, Фатих Кәрим дә—сугышка кадәр үк формалашкан, дөньяга карашлары нык булган талантлы шагыйрьләр. Аларның озак вакыт хәзерләнгән рухи көче**

**ачылып китү өчен бары моментны гына көткән. Шәхес, шагыйрь үзен зур бәрелешләрдә таба".**

**Сибгат Хәким**

**Ф.Кәримнең "Сайланма әсәрләренә" (ТКИ, 1969 ел) кереш.**

## Хәсән Туфан белән очрашу

Шулай итеп, 1941 елның язында, тынчу төрмәләрдә, чиксез тайгаларда үлем белән күзгә-күз тарткалашып бер елга якын гомер узуга Ф.Кәрим яңадан Казанга кайтарыла. Әлбәттә, сак астында—тимер рәшәткәле Столыпин вагонында. Әмма зур өметләр белән, якты киләчәккә, хакыйкатьнең җиңүенә ышанып...

Бу турыда шагыйрь "Сагынып кайтам сине" исемле шигырендә бик үтемле итеп яза:

Казан! Казан! Сагынып кайтам сине.
Килеп җиттем менә Иделгә.
Ә шулай да якынайган саен
Нәрсәдер ят тоела күнелгә.

Кайда гына барып күз салсам да
Кул бирерлек кеше табылмас.
Элек бергә җитәкләшеп йөргән
Дуслар хәзер инде танымас.

Әлеге юллар Х.Туфанның: "Кайсыгызның кулы чиста? Бәйлисе бар йөрәкне" (беренче вариант) юллары белән аваздаш. Бу елларда Ф.Кәрим җан дусты Туфанны еш искә ала. Ул әле аның да кулга алынуын белми:

Иске капчык асып, конвой белән
Урамнарың аша узганда
Очраса, күрмәгәнгә салышып,
Узып китәр хәттә Туфан да.

Шагыйрь Туфанга булган үпкәсен яшерми, бу турыда йөрәк әрнүе белән яза. Әмма шигырьне җентекләбрәк укыгач, шуны аңлыйсың: Туфанга мөрәҗәгать иткәндә, Ф.Кәрим башка язучы-дусларын, экспертизага кул куйган, көндәшен батырып, орден-медаль алырга хыялланган элекке дусларын истә тота:

Тупас вөҗдансызлар көннәрендә
Син тезләнеп мескен булдыңмы?
Дусларыңның авыр язмышына
Чирканмыйча кулың куйдыңмы?

Соң әллә син, медаль алмак булып,
Кафияләр сайлап йөримсең?

Менә шулай Казан белән исәнләшеп, күнеленнән дусты белән сөйләшеп барганда, Ф.Кәримне Казанның Кремль асты төрмәсенә (ул пересыльный, ягъни вакытлыча төрмә була) китереп, Хәсән Туфан утырган камерага биклиләр. Була бит язмышның да шундый шаярган чаклары!

Хәсән аганың сөйләве буенча, бу камерада берничә дистә тоткын утыра. Утыра дип, басып торырга да урын булмый анда. (Пугачев заманында бу камерада ике генә кеше утырган) һава шулкадәр авыр, тынчу—тоткыннар идәнгә ятып, чиратлашып ишек астыннан кергән һаваны сулап торырга мәҗбүр булалар. Прогулкага алып чыкмыйлар. Ашау хөрти... Менә шушы тәмугка дыңгычлап диярлек тагы бер тоткынны китереп тыгалар. Хәсән абыйның караңгыгаияләшкән күзләре дустын шундук танып ала. Хәсән абый әйтүенә караганда, Ф.Кәримнең киеме иске булса да, таза, ямалган була. Аркасында киндер биштәр, аягында автомобиль покрышкасыннан эретеп эшләнгән, тоткыннар телендә "трактор" дип аталган, авыр, әмма теләсә нинди пычракта да аякны жылы, коры тоткан "ботинка" була.

Алар кочаклашып күрешәләр, Хәсән абый елап ук җибәрә. Бу көтелмәгән очрашу турында Ф.Кәрим бик тәэсирле итеп язып калдыра:*

Ничек онытыйм кремль буендагы
Пугачевлар яткан төрмәне!
Юк, онытмыйм тынчу камерада
Сулар һава тапмый йөргәнне.

Ишек ярыгыннан томанланып кергән
Бәдрәф исе катыш һаваны
Балык кебек авызларны ачып,
Алмаш-тилмәш икәү суладык...

Хәсән абый сөйләмәгән булса, мин бу юлларның мәгънәсен аңламаган булыр идем. Хәсән абый яшь ягыннан тугыз яшькә өлкәнрәк булса да, аңардан өч елга алданрак кулга алынган Ф.Кәрим "төрмә университетларын" күбрәк узган. Дустының авыру, тәмам хәлдән таю дәрәҗәсенә җиткәнлеген күреп, ул Туфанга ярдәм кулы суза, аны лазаретка урнаштыру юлларын таба, шулай итеп, котылгысыз үлемнән йолып кала. Шигырьләрендә Ф.Кәрим бу турыда да яза:

Яшь ягыннан абый син булсаң да,
Ристанлыкта абый мин идем.
Шунар ахры моң-зар, нәфрәт уты
Һәм әрсезлек миндә күп иде.

... Иске-москы салган капчык асып,
Төрмәләрдә байтак сөйрәлдек.
Катлы-катлы вә тәшдитле итеп
Сүгенергә яхшук өйрәндек.

Х. Туфан сүзләренә караганда, Ф.Кәрим Кремль асты төрмәсендә ярты елга якын утыра. Аңа хәтта башкисәр бандитлар да зур ихтирам белән карый. Моны раслый торган шундый вакыйга турында сөйләде ул.

Югарыда әйтелгәнчә, Ф.Кәрим чиста-пакь йөрергә ярата. Тоткыннарның сакал-мыек баскан, йончыган йөзләренә карап, ул: «Нишләп берегез дә кырынмыйсыз әле?»—дип сорый. "Һе,—дип җавап кайтаралар аңа.—Ничек кырынасың? Пәке юк бит! Пәке ише әйбер тоткан кешене тапсалар, шундук карцерга утырталар ич!" Ләкин Ф.Кәрим югалып калмый. Бервакыт конвой астында бәдрәфкә алып барган чакта юыну бүлмәсенең тәрәз төбеннән калай кисәге сындырып алып кайта. Бу калайны цемент идәнгә ышкып үткенлиләр дә бөтен камера—утызлап кеше—ялт итеп кырынып чыга.

Сакчылар моны күргәч, аптырап калалар. Кайсыгызның пәкесе бар?—дип таптыралар. Бөтен камераны астын-өскә китереп, тентеп чыгалар, ләкин берни дә тапмыйлар. Ачулары чыгып: "Әгәр әйтмәсәгез, бөтен камераны да карцерга утыртабыз",—дип яныйлар. Янап кына калмыйлар, болай да кечтеки азык нормасын (400 грамм солы кылчыклы катыш арыш ипиен) кисеп, көненә 100 граммга калдыралар.

Шуннан Ф.Кәрим:

—Утыз кеше газап чиккәнче, мин берүзем генә газап чигим ичмасам,—дип алга чыгып, "Мин гаепле", дип әйтә, таш ярыгына яшерелгән әлеге калай кисәген күрсәтә. Аны шундук юеш карцерга илтеп биклиләр. Көненә бер стакан су, бер телем күгәрчен икмәк бирәләр. Башкаларга исә элекке нормаларын кайтаралар.

Ф.Кәримне алып киткәннән соң, камерадаш иптәшләре, үзара киңәшеп, шундый карарга киләләр: һәркем үзенең көндәлек нормасыннан берәр телем кисеп, аңа калдыра. Бу ипи кисәкләрен киптереп, күз карасы кебек саклап, Ф.Кәрим өчен тоталар. Дүрт тәүлектән соң ябыккан, йөзе киткән шагыйрь

* З.Мәҗитов мәгълүматлары буенча, бу шигырь К.Нәҗмигә багышланган. Шулай булуы да мөмкин, чөнки шагыйрь бер очрашу турында гына язмый, гомумиләштерә.

камерага кайтарыла. Иптәшләре аны кочак җәеп каршы ала, әлеге ипи сыныклары белән туйганчы сыйлый...

## Яңа экспертиза

Фатих Кәрим Кремль асты төрмәсендә яткан вакытта аның шигырьләрен яңа экспертизага бирәләр. Бу юлы әлеге четрекле эшне язучыларга түгел, рәсми кешеләргә, партия өлкә комитетында эшләүче пропаганда бүлеге мөдире Ф.С.Семеновка һәм матбугат бүлеге мөдире И.Х.Сабитовка тапшыралар. Һәм шушы "кәҗүнни" кешеләр (җитмәсә, берсе урыс кешесе дә әле) "Аникин" поэмасында да, Ф.Кәримнең башка әсәрләрендә дә "советка, революциягә каршы бернинди "идеологик диверсия" дә юк, дигән нәтиҗәгә киләләр. Шулай итеп, Ф.Кәримнең ялганга, гайбәткә корылган "җинаять эше" җимерелеп төшә.

1941 елның 12 ноябрендә Татарстанның НКВД наркомы урынбасары Чембарисов: "Дело за недоказанностью прекратить, из-под стражи освободить", дигән боерыкны бирә. Карар Мәскәүдә раслану белән, 1941 елның 3 декабрендә Ф.Кәримне, ниһаять, төрмәдән чыгаралар.

**Татарстан НКВДсы карарыннан:**

**"Следственное дело в отношении Каримова Ф.В. прекратить за отсутствием улик, как недоказанное (реабилитировать)".**

*1 декабря 1941 года.*

Бу көн Кадрия ханым күңеленә мәңгегә уелып калган. 1941 елның декабрендә зәмһәрир суык көннәр тора. Кәримнәрнең Миславский урамындагы фатирлары бик салкын була, чиләктәге су боз булып ката, йокларга ятканда да өске киемнәрен салмыйча ятарга туры килә. Кадрия ханым көн саен эшеннән алданрак кайтып, мичне ягып җибәрә, шуннан соң кызларын алырга балалар бакчасына йөгерә.

3 нче декабрь көнендә дә ул шулай ашыгып-кабаланып кайтып керә. Фатир ишегендәге зур тимер йозак белән маташкан чакта, аңа күрше бүлмәдә (элек анда кухня булган) яшәүче Даша исемле дворник хатын дәшә:

—Бер генә минутка безгә кереп чык әле...

—Кит әле,—дип кул гына селти Кадрия ханым.—Соңыннан, соңыннан... Бер минут вакытым юк... Мичне генә ягып җибәрәм дә, балалар артыннан чабам...

—Шулай да кереп чык әле,—дип кабатлый тегесе. Серле елмаюыннан нәрсәдер сизенә башлаган Кадрия ханым күршесенә керә. Караса, тәрәзә янындагы урындыкта читкәрәк карап, таушалган бушлат кигән, сукбайга охшаган кеше утыра. Йөзен сакал-мыек баскан, үзе ябык, төсе сап-сары. Тик күзләре генә анык—кара күмер бөртекләре сыман ялтырап торалар.

—Фатихым! Синме бу? Булмас, булмас...

—Кадриям!—Алар бер-беренә ташланалар. Елашалар, көлешәләр. Кадрия ханымның буыннары йомшап китә, аягында да басып тора алмый, сыгылып төшә...

Бераздан, аңнарына килгәч, балалар бакчасына кызларын алырга йөгерәләр... Шулай итеп, Фатих Кәримнең дүрт елга сузылган—төрмәләрдә, лагерьларда үткәрелгән "чыныгу" чоры тәмамлана.

Шул ук елның декабрь азагында Ф.Кәримне армиягә алалар һәм ул фронтка китеп бара...

Китап күзәтү

# ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКАСЫ ТУРЫНДА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Менә берничә дистә ел инде Роза Исхакова-Вамба татар халык музыкасы буенча нәтиҗәле тикшеренүләр алып бара. Бу хакта аның әлегә кадәр басылып чыккан саллы монографияләре дә нигезле дәлил була ала: "Народные песни казанских татар крестьянской и городской традиций" (Казан, 1976), "Татарские народные песни" (Мәскәү, 1981), "Ангемитоника как музыкальная система" (Мәскәү, 1990). Моңа тагы галимәнең Казанда һәм Мәскәүдә басылып чыккан күп санлы фәнни мәкаләләрен дә өстәргә мөмкин.

"Татарское народное музыкальное творчество" дигән китабы исә—галимәнең берничә дистә ел буена алып барган экспедицион-практик һәм фәнни-теоретик тикшеренүләренең, һичшиксез, уңышлы нәтиҗәсе.

Безгә билгеле мәгълүматларга караганда, элегрәк язылган теоретик хезмәтләрдә халыкның шигъри-музыкаль иҗаты ике өлкә галимнәре—филологлар һәм музыка белгечләре тарафыннан аерым-аерым тикшерелә иде. Музыка белгечләре халык иҗаты әсәрләренең моң-көенә таянсалар, филологлар шигъри текстка нигезләнәләр иде. Нәтиҗәдә бер үк әсәрне музыка белгечләре бер төркемгә нисбәтән тикшерсәләр, филологлар шул ук әсәрне икенче бер төркемгә карый дип санайлар иде. Роза Исхакова-Вамба исә әлеге китабында конкрет мәсьәләгә якын килүнең методологиясенә зур яңалык кертеп, халык иҗаты әсәрләренең аерым төрләрен музыкаль яктан да, филологик, ягъни—шигъри текстлар ягыннан да тикшереп бара.

Фольклор әсәрләре халык телендә дә шулай яши бит: дастан, бәет, мөнәҗәт, җыр тик билгеле бер текстны музыкаль башкарганда гына, әйтелгәндә, җырлангәнда гына үзләренең барлык шигъри-музыкаль мөмкинлекләрен ача алалар. Җырланмаган җыр җыр була алмаган кебек, әйтелмәгән бәет тә бәет була алмый. Көйгә, музыкага, музыкаль башкаруга турыдан-туры мөнәсәбәте булган әсәрләрне шулай күзәтергә кирәк тә. Җырның тексты аерым, көе аерым йөри алмый. Алар бергә булганда, анда да әле оста җырчы башкарганда гына җыр үзенең бөтен гүзәллеген ача. Ягъни, бәет, мөнәҗәт, җырларны фәнни яктан тикшергәндә аларның сүзләренә дә, көйләренә дә бер үк дәрәҗәдә якын килү таләп ителә.

Роза Исхакова-Вамба халык иҗаты әсәрләренең табигый яшәешендә сүзнең дә, көйнең дә укмашып, үзара аерылгысыз берлектә килүен исәпкә алып, аларны әнә шул күзлектән тикшерә, һәм, һичшиксез, житди уңышларга ирешә. Мондый тикшеренү—шактый авыр хезмәт. Чөнки моның өчен фәнни яктан әзерлекле филолог та, шундый ук музыка белгече дә булырга, кирәкле фәнни әдәбиятның һәркайсысын яхшы белү таләп ителә. Төп белгечлеге музыка өлкәсе булса да, автор тарихка, этнографиягә, әдәбиятка, халык иҗатының текстларына караган әһәмиятле хезмәтләрнең күпчелеген җентекләп өйрәнеп чыккан һәм үз хезмәтендә кирәк дәрәҗәдә нигезле файдаланып, житди ачышлар да ясаган.

Язганыбыз коры сүз генә булмасын өчен кайбер мәсьәләләргә аерым тукталып үтик. Филология һәм музыка белемендә халык иҗаты әсәрләрен классификацияләү—аларны төркемнәргә бүлү иң катлаулы проблемаларның берсе дип санала. Шуңа күрә музыка белемендә булсын, филологиядә булсын әлегә кадәр төрле галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән төрлечә төркемләүләр яшәп килә (М. Нигъмәтҗанов, Ә. Абдуллин, И. Надиров, Ф. Урманче һ.б.). Роза Исхакова-Вамба әлеге классификацияләрнең барысын җентекләп тикшергән, уңай һәм, аның карашынча, җитешсезлекләрен күрсәтеп үткән. Нәтиҗәдә ул һәрбер әсәрнең,

һәрбер төрнең музыкаль үзенчәлекләрен дә, шигъри асылын да исәпкә алган үз классификациясен тәкъдим итә.

Мәсьәлә ифрат та житди булганга күрә без әлеге классификацияне бередә тулысынча китерәбез: 1. Йола жырлары. 2. Хезмәт жырлары. 3. Уен һәм бию жырлары. 4. Эпос (дастаннар, бәетләр, тарихи жырлар). 5. Дини музыка (мөнәжәтләр). 6. Шәһәр-авыл традицияләренә нигезләнгән лирик жырлар. 7. Башка жанр жырлары (лириканың төрләре): дуслык һәм кунак жырлары (йоладан тыш мәжлес жырлары), шаян жырлар, социаль протест жырлары (ярлылар, ятимнәр, рекрут һәм солдат жырлары һ. б.). 8. Инструменталь музыка.

Бу классификация төгәл һәм камил, аның бернинди дә каршылыгы, кимчелекләре юк дип булмый, билгеле. Мәсәлән, "Башка жанр жырлары" дигән шактый күләмле бүлекнең берникадәр бәхәсле булуы үзеннән-үзе күренеп тора. Бу ифрат та катлаулы мәсьәлә буенча киләчәктә дә төрле бәхәсләр булыр. Житди фән бәхәс-дискуссиясез яши алмый. Шулай да бу очракта Роза Исхакова-Вамба әһәмиятле классификация тәкъдим итә. Аның житдилеген раслап торган тагын бер ышанычлы күрсәткеч—әлеге классификациянең нигезендә заманында талантлы фольклорчы-галим профессор В. Я. Пропп тәкъдим иткән принциплар ята.

Күзәтелә торган фәнни хезмәтнең тагын бер уңай ягы—ул баштан ахырга кадәр диярлек тирән тарихилык принцибына таяна, халык ижаты төрләрен татар халкы тарихы белән аерылгысыз бәйләнештә тикшерә. Бу яктан шундый бер мисал аеруча игътибарга лаек: Казан ханлыгының чәчәк атып торган чорын галимә татар халкы язмышындагы иң әһәмиятле бер дәвер дип саный. Авторның бик хаклы язуынча, әлеге фикер халыкның рухи тормышындагы яңалыклар белән дә раслана: нәкъ әнә шул чорда татар халык бәетләре тулысынча формалашкан. Әлегә кадәр Болгар чорында барлыкка килгән дип саналган бәетләр күбрәк халыкның елауларын яки данлауларын (плач и прославление) хәтерләтәләр (117 бит). Тарихи жырларның барлыкка килүе дә шул ук Казан ханлыгы чорына—XYI гасырның икенче яртысына карый, дип яза автор (118 бит). Мөнәжәтләрнең мәдрәсә традицияләре һәм язма әдәбият белән тыгыз бәйләнеше турында да галимә гаять житди фикерләр әйтә. Филолог теле белән әйтсәк, лирик озын жырларның барлыкка килүе һәм оешу чоры да автор тарафыннан Казан ханлыгы дәвере белән нисбәтән күзәтелә (149-169 битләр).

XIX йөзнең соңгы чирегендә—XX гасырның башында халык ижатын өйрәнү татар халкының аерым этник төркемнәре буенча алып барылган: академик В. Радлов—себер татарлары (1872), венгр галиме Г. Балинт—керәшеннәр (1875), профессор Н. Катанов—казан татарлары (1899) фольклоры буенча зур күләмле махсус жыентыклар чыгарганнар. XX йөз башында казан татарлары, керәшеннәр, мишәрләр ижаты буенча аерым мәкаләләр һәм махсус китаплар дөнья күргән. Әмма утызынчы елларда бу күркәм традиция юкка чыга. Безнең көннәрдә музыка белгечләре ул уңай традицияләрне яңадан аякка бастыралар кебек. Һәрхәлдә, күзәтелә торган китапта Роза Исхакова-Вамба татар халык музыкасын өйрәнүдә этник принципны һәрвакыт истә тота. Нәтижәдә казан татарларының, мишәрләрнең, керәшеннәрнең, себер татарларының—һәркайсының шигъри-музыкаль ижатына хас житди үзенчәлекләрне күрсәтеп бара. Дөрес, бу принципны куллану әлегә башлангыч чорын гына кичерә. Шуңа күрә һәрбер этник төркемнең шигъри-музыкаль ижатына хас үзенчәлекләрне тулаем күз алдына китереп булмый: әйтик, казан татарларының ижатына гына хас сыйфатлар, керәшеннәрнең, мишәрләрнең һ. б. ижатларына хас сыйфатлар анык күзалланмый әле. Шулай да автор тарафыннан, һичшиксез, перспективалы юл сайланган. Ул киләчәктә дә дәвам итәр дигән өмет бар.

Роза Исхакова-Вамба хезмәтенең тагын бер уңай ягы—ул баштан ахырга кадәр диярлек үзе язып алган, үзе халык арасында йөреп өйрәнгән конкрет материалларга нигезләнә. Фольклорчы өчен бу ифрат та житди фактор. Халык арасында йөрмичә, кабинетта утырып кына чын халык ижатын өйрәнеп булмый.

Күзәтелә торган хезмәтнең байтак уңай яклары, әйтик—күп кенә конкрет әсәрләрнең шигъри-музыкаль үзенчәлекләрен, аларның барлыкка килүен, оешуын, тарихын жентекләп өйрәнү һ. б. турында тагын да тәфсилле итеп сөйләп булыр иде. Әмма кыска гына күзәтүдә бу мөмкин эш түгел. Инде берничә искәрмәне дә әйтеп үтик: татар фольклористикасы тарихы Г. Тукайның 1910 елда Шәрекъ клубында укыган лекциясеннән башлана

(5 бит) дип, автор ялгыша, әлбәттә. "Типтәр" этнонимы "тип тәрене"дән килеп чыккан дип уйлау да "халык этимологиясенә" нигезләнгән беркатлылык, безнеңчә. Танылган тарихчы-археолог А. Х. Халиков язганча, бу сүз "дәфтәр" сүзенең үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Башкортстанга күчеп килгән татарларны махсус дәфтәргә теркәп бара торган булганнар. Әнә шуннан инде типтәр сүзе килеп чыккан. Урысча язылган бу хезмәттә тел-стиль чатаклыклары да юк түгел.

Безнең әлегә төп фикеребез шул: Р. А. Исхакова-Вамбаның "Татарское народное музыкальное творчество" китабын тирән белемле тәҗрибәле мөхәррир, ә бәлки авторның үзедер, житди игътибар белән янә бер карап чыкса, аны, һичшиксез, докторлык диссертациясе сыйфатында тәкъдим итәргә мөмкин булыр иде.

**Фатих УРМАНЧЕ,**
профессор.

---

# ТАРИХКА КҮПЕР

Башта ук бер киңәшне әйтик әле. Хәзер фантастик әсәрләрне, телебезне чит терминнардан мөмкин кадәр арындыруга омтылып булса кирәк, еш кына "хыялый әсәрләр" дип атый башладылар. Безнеңчә, бу максатка ярашлы түгел. Болай эшләү әсәрләрнең колачын тарайта, алар күтәргән мәсьәләләрне гадиләштереп калдыра шикелле. "Фантастик әсәрләр" дигән төшенчә шулай калсын иде инде ул. Аннан килеп, телебезне инде үзебез ияләшкән, җайлашкан атамалардан мәхрүм итеп, аны үз-үзенә бикләп, ярлыландыра бару нигә?

Мин үзем, шәхсән, фантастик әсәрләрне ике төргә бүләр идем. Беренчесе— фәнни фантастика. Мондый әсәрләр безне үзебез яшәгән җирлектән, тормыштан аерып алалар. Галәм киңлекләренә, ерак планеталарга алып чыгып китәләр, яисә әле без яшь алмаган океан-диңгезләр төпләренә, хәтта җир асларына алып төшәләр. Аларда вакыйгалар да безнең көннәрдә түгел, ә якын яисә ерак киләчәктә бара. Алардагы геройлар да, гадәттә, без түгел, ә киләчәк буыннар кешеләре, техника да—без белмәгән куәтләргә, сыйфатларга ия киләчәк заман техникасы. Монысы, әйткәнемчә, чиста фәнни фантастика.

Моннан тыш әле тагын реаль, ягъни тормышчан фантастика бар. Андый әсәрләрдә инде вакыйгалар без үзебез яшәгән җирлектә, көндәлек тормышыбызга бәйләнеп бара. Геройлары да без үзебез яисә иптәшләребез, бик белгән танышларыбыз, дусларыбыз була. Әлегә без гайре табигый санаган, мажаралы һәм серле хәлләр үзебезнең көндәлек тормыш вакыйгаларына үрелеп бара. Хәтта геройлар эшләгән яисә укыган урыннар, яшәгән шәһәр һәм авыллар исемнәре дә төгәл күрсәтелә.

Мин әле күптән түгел танылган әдип Флүс Латыйфиның Казан дәүләт университеты доценты Ринат Якушев белән берлектә язылган һәм Татарстан китап нәшриятында чыккан "Тамга" дигән фантастик повестьлар җыентыгын укыдым. Укыгач шундый нәтиҗәгә килдем: кайберәүләр "мин фантастик әсәрләрне яратмыйм" дигән сүзне бер дә юкка гына әйтеп куялар. Менә мин үзем өлкән кеше, әдәби әсәрләргә бик таләпчән карыйм һәм укыганда тиз ялыгам да. Ә менә бу китаптагы "Тамга", "Соңгы кисәтү", "Игезәкләр" дигән өч повестьны һич ялыкмый, өзми-куймый, үзем өчен рекордлы вакыт эчендә укып та чыктым! Юк, бүтән төр әдәби әсәрләргә бер яклары белән дә бирешми бу повестьлар. Хәтта өстенлекләре дә бар әле. Беренчедән, алар укырга кызыклы, вакыйгалар тыгыз урнаштырылган, артык сүзләр сөйләмичә, тиз алмашыналар, сине җәлеп итеп алалар. Икенчедән, фән-техника яңалыклары һәм, иң әһәмиятлесе, үзебезнең татар халкы тарихы буенча әллә никадәр яңа мәгълүмат бирәләр. Болар үзебезнең җирлектә, бүгенге көндәлек тормышыбыздагы вакыйгаларны үткән тарихыбызга бәйләп, үткәнебезгә күпер сугып язылган чын реаль повестьлар.

Бу фантастик повестьларның геройлары бер фәнни-тикшеренү институтының яшь галиме Марат һәм аның борынгы тарих

белән “женләнгән” дусты, журналист Лотфи.

“Тамга” повестенда университетның тарих кафедрасы галимнәре фәнни экспедиция вакытында бик борынгы бер көмеш савыт табып алалар. Ул савытның кырыена борынгы хәрефләр белән нидер язылган була. Рун язуына охшаган бу язуны галимнәр күпме генә тырышсалар да, укый алмыйлар. Лотфи шушы язуның кәгазьгә күчермәсен дусты Марат янына күтәреп килә. Марат исә аларны компьютерда укырга тырышып карый, барып чыкмый. Акыллы машинаның да моңа зиһене җитми. Дөрес, институтта мондый машинаның тагын да зиһенлесе һәм куәтлесе—супертрансльютер, ягъни ясалма акыл бар. Бу электрон ми инде кешенең геннарында йоклап яткан, моңарчы төшенә дә кермәгән мөмкинлекләрне ача, акылы колачлый алмаган гаять киң, чын мәгънәсендә, гигант araларны, тикшереләсе проблеманың вакыт-галәм вариацияләрен күзалларга ярдәм итә ала. Тик... яңа машинада эшләргә, бигрәк тә яшь галимнәргә, рөхсәт кенә юк.

Менә Марат барысын да Алланың үзенә тапшырып дигәндәй, ясалма акыл машинасы янына килә, аңа тоташкан супершлемны башына киеп куя, идарә итү төймәсенә басып җибәрә. Һәм... китә башланып гаҗәп хәлләр! Акыллы машина яшь галимне күз ачып йомган арада моннан биш гасыр чамасы үткәнебезгә алып китә, ул чагындагы Казан ханы Сәхибгәрәй сараендагы иң күренекле, ханга якын кешеләрнең берсе, Морат бәккә әйләндереп куя.

Повесть бик тыгыз язылган, кыска. Вакыйгалар да бик тиз куера. Марат-Морат бәк кыю хәрәкәт итә. Үзенә яшь галимнең миһербанлылыгы да өстәлгән бәк кәнизәк итеп алынган бер гүзәл кыз баланы коллыктан азат итә. Марат-Морат урысларның зур гаскәр белән Казан ханлыгы өстенә һөҗүмгә җыенганын, татар иленә һәлакәт килү ихтималын, табигый ки, белә. Бу куркынычны, бу ихтималны, әлбәттә, Сәхибгәрәй үзе дә сиземли. Шуның өчен дә Төркиягә барырга, бөтен мөселман дөньясыннан ярдәм сорарга җыена. Ләкин соң була инде. Илне тәҗрибәсезләр карамагына калдырып китүе зур тарихи ялгышлык булыр иде. Морат бәк, фаҗиганең киләсен белгәне килеш, бу фикерне Сәхибгәрәй ханга җиткерергә ашкына. Әмма ләкин ул юлда хыянәтче аткан уктан һәлак була. Шулай итеп тарихи хата җибәрелә һәм аның аянычлы нәтиҗәләрен хәзер менә без татыйбыз.

Әнә шулай итеп әсәр безне үткән тарихыбызга ныклап китереп бәйли. Ул үткәнебез, инде җибәрелгән хаталар, вакытында оеша белмәү, хәтәр дошманга каршы тора алмаган өчен үкенү-сызланулар белән тулган. Кәнизәк кызның ирен читендәге тамганың безнең көннәрдәге шәфкать туташының сөйкемле йөзендә кабатлануы да безнең тарихыбызга, язмышыбызга салынган тамга кебек кабул ителә.

“Соңгы кисәтү” повестеның нигезендә тирән фәлсәфә, планетабызның, кешелек цивилизациясенең киләчәктәге язмышы өчен тирәнтен борчылу ята. Эш шунда ки, галимнәр фараз итүенчә, планетаның уңай энергия, ягъни ак энергия бүлеп чыгара торган урыннары бар. Андый энергия, гадәттә, кайчандыр борынгы цивилизация чәчәк аткан урыннарда була. Идел һәм Урал арасы, элеккеге Болгар һәм Казан дәүләтләре биләгән җирләр, ягъни хәзерге Татарстан һәм аның янындагы кайбер төбәкләр әнә шундый җирләрдән санала икән. Әмма соңгы вакытта планетаның күп җирләрендә, хәтта борынгы цивилизация хакимлек иткән җирләрдә дә, кара көч, кара энергия өстенлек итә башлады. Русиядә бигрәк тә ул Мәскәү тирәсендә көчле. Җирнең дә аурасы, ягъни күзгә күренмәс биоэнергетик тышчасы бар. Мәскәү тирәсендә ул ерткаланган, юкарган. Бу үзе үк кешенең психологиясенә, аның үз-үзен тотышына тискәре йогынты ясый. Кеше агрессивка әйләнә, җинаятьчелек үсә башлый.

Галимнәр фикеренчә, иң куркынычы, кешелек цивилизациясен алмаштыру өчен ҖИРнең информацион кыры параллель рәвештә яңа бер цивилизация тудырып маташа. Бәлки ул җан ияләре башка вакыт һәм пространство яссылыгында яши торганнардыр? Ләкин алар бар. Алар инде кешелек тормышына тыкшына да башлады. Соңгы вакытта күзгә дә күренәләр, игътибарны җәлеп итәләр. Моны сәяси тел белән әйткәндә, көч күрсәтү дияргә мөмкин. Җир шарының теге яки бу кыйтгасында яңадан ОЙБОлар (очып йөрүче билгесез объектлар), оча торган тәлинкәләр, ниндидер самолетка да, ракетага да охшаган җисемнәр күренүе шуның чагылышы. Алар белән контактка кергән кешеләрнең гайре табигый сәләткә ия була баруы да шуннан. Ләкин сөенергә ашыкмыйк. Җир шарында кара көч, кара энергия арткан саен, ул сәләт тә кешелеккә дошмани рәвеш ала бара.

Алдын-артын уйламаган кешелек яңа цивилизация кочагына ташланырга әзер. Ләкин ул үзенә һәлакәт янаганын, кешелек дөньясының яңа цивилизация бакчасына тирес булып ятарга тиешлеген белми әле.

Бу повесть геройлары Марат һәм аның дусты Лотфи менә шушы кара көчләргә каршы көрәшне башлап җибәрүчеләр. Марат фәнни экспедициядә, Тянь-Шань таулары арасында була. Ул шунда кыргыз карты Җомабайны кыен хәлдән коткара. Моңа рәхмәт йөзеннән йөз егерме дүрт яшьлек бу карт аңа бер кечкенә генә таш бүләк итә. Бик тә тылсымлы, кодрәтле, нык булып чыга бу таш. Аның ярдәмендә нәкъ әнә шул кара көчләргә каршы барып була.

Болар повесть сюжетының бер сызыгы гына. Аның әле тагын бүтән сызыклары, мавыктыргыч та, кызганычлы да маҗаралары бар. Аны дөньяны онытып, эшләреңне калдырып торып укыйсың. Һәм алдыңа сораулар да килеп туа. Чынлап та, ни булды соң бу дөньяга соңгы вакытта? Адәм балаларына бүгенге вөҗдансызлык, усаллык, явызлык һәм имансызлыклар кайдан килә? Кайчан да булса бу мәхшәрләр тукталырмы, адәм балалары акылларына килеп, Кеше дәрәҗәсенә күтәрелә алырмы? Фантастик әсәр менә шушындый тормышчан, җитди сораулар китереп тудыра.

Өченчесе повесть "Игезәкләр" шулай ук бик кызыклы һәм маҗаралы. Әгәр супертранспьютер янына утырып озак эшләсәң, аңа үз программаңны, уй-хыялларыңны салсаң, ул сине матдиләштерергә, ягъни икенче "син"не тудырырга да мөмкин икән әле. Институт лабораториясенә бик иртә, караңгы белән килеп кергән галим Марат анда үзенең күчермәсен, үзенең икенче нөсхәсен, чып-чын икенче Маратны табып ала. Болар бер-берсенә шулкадәр охшаган булалар ки, чын Маратның үз хатыны Рәхимә аларны һич кенә аерып таный алмый. Шуннан инде алар бу фани дөньяда бергәләп, ягъни бер кеше ике нөсхәдә булып яши башлыйлар. Бу хәл инде, билгеле, бик күп кызыклы да, кызганычлы да һәм икесе өчен дә гаять авыр хәлләр китереп чыгара. Берсе белән икенчесен бутамас өчен алар җирәбә салалар һәм яңа Маратка Морат исеме кушалар.

Иң кызыклысы шунда ки, яңа Марат чыннан да Морат, ягъни моннан биш гасыр элек яшәгән Морат бәк тормышын дәвам иттерүче зат булып чыга. Ягъни Маратның кыяфәтен алган борынгы бабасы! Һәм менә шушы 512 яшьлек карт үзара аңлашу вакытында университет галиме Маратка—аның йөзендә менә безгә, хәзерге замандагы бөтен татар халкы өстенә—авыр гаепләр ташлый.

—Мин Казанга, кешеләренә рәнҗим. Сез хөрлелегегезне җуйгансыз,—ди ул.—Сез кем икәнлегегезне оныткансыз, горурлыгыгыз югалган. Әллә нинди таш капчыктай йортларга, зиндан шикелле хөҗрәләргә кереп бикләнгәнсез. Бу шәһәрдә минем тыным кысыла. Бу Казан түгел! Бу безнең патшалык имәс! Кайда безнең хөрлек, иркенлек?! Дин беткән, ден беткән Казанда... Иман беткән! Ул гынамы? Тел беткән, кайчангы дошманыбыз телендә дөрес итеп сөйләшә-аңлаша алуны дәрәҗә саный башлагансыз... Кызганыч, хәтер ягыгыз саеккан, бигрәк тә саеккан шул...—ди борынгы бабабыз ачынып.

Бу туп-туры әйтелгән сүзләргә, бу ачы хакыйкатькә каршы нинди дәлилләр китереп куябыз? Юк безне, хәзерге татарларны аклый алырлык дәлилләр.

Менә шундый хәлләр... "Фантастик булсалар да безнең үткән аяныч тарихыбызга, бүгенге тормышыбызга турыдан-туры кагыла торган әсәрләр. Киләчәк көнебез, милләт язмышы турында тирән уйларга сала торган. Миңа охшаганы тагын шул булды: бу әсәрләр бик җиңел укыла. Алар сырламый-боргаламый, гади һәм аңлаешлы тел белән язылган. Хәзерге замандагы кайбер әсәрләрдән аермалы буларак. Тагын шунысы бар—бик үзенчәлекле, оригиналь китап бу. Яшереп торасы юк, безнең татарда хәзер урыс телендә генә укырга күнеккән кешеләребез дә бар. Андый укучылар табыла икән, рәхим итсеннәр, китапны кулда кирегә әйләндереп, аны азагыннан укый башларга гына кирәк. Китапның яртысы урысча, ягъни барлык повестьлар урыс теленә тәрҗемә итеп тә басылган. Бу инде, әлбәттә урыслар өчен дә уңайлы.

Безнең татар—фантазиягә бай халык. Һәм аның әдипләре арасында да фантастик әсәрләр иҗат итүчеләр җитәрлек. Монда бөтен дөньяга танылган Америка фантасты Айзек Азимовның да нәселе белән Казанга килеп тоташкан кеше икәнен әйтү урынлы булыр. Элекке буын һәм хәзерге көндә иҗат итүче әдипләр арасында да фантастикага мөрәҗәгать итүчеләр җитәрлек. Ә менә күренекле язучыбыз Аллер Тимергалин исә фәнни-фантастик жанрда гына иҗат итә.

Менә хәзер Флүс Латыйфи һәм Ринат Якуш иҗатын күрдек. Алар үзләренең бик үзенчәлекле, тормышчан, реаль фантастик әсәрләре белән бу өлкәдә яңа сүз әйттеләр, саллы өлеш керттеләр.

**Радик ХӘБИБРАХМАН**

# Uqucь syze

* * *

Qəderle jaqtaşlar, milləttəşlər!

Yzem daimi rəweştə aldьra torgan jaratqan ƶurnalьm "Qazan utlarь"nnan tanьlgan ədip Əxsən Bajanofnьņ "Su əslərendə paroxod" digən avtobiografik povesten (№ 11—12, 1997 jьl) ber utьruda tьn da almьjca uqьp cьqtьm.

Berencedən, avtor—minem jaqtaşьm həm jəştəşem. Yzem Ileş rajonь belən ciktəş Aqtanьş rajonьnda tuьp-ystem. Beznen Axun awьlь Sən bujьnda. Jьlganьn arjagьnda—Başqortstan. Şuņa kyrə əsər beznen təbəklərgə xas yzencəlekle cьn awьl tele belən jazьlgan.

Ikencedən, əsərdə tac minem bala həm jəşysmer cagьm surətləngən diərlek. Əlege povestne uqьganda gel awьlьma, jəşlegemə qajtьp kilgən tojgьlarda jəzdem. Şuşьlaj da oxşaş jazmьş bulsa bula ikən!

Sugьş başlanganda, çidence sьjnьfnь təmamlagan idem. Undyrt jəştən eşkə çigeldem. 1942 jьlda ətiem həm abьjьm sugьşqa kitkəc, əj xuçasь bulьp qaldьm. Əniem, enem həm senlem—minem qaramaqta. Utьn, pecən xəzerləy, gəilənen tamagьn tujdьru—minem çilkədə. Unaltь jəşemdə, awьlьbьzdan biş caqrьm jьraqlьqtagь Bajsar urta məktəbenen tugьzьncь sьjnьfьn təmamlagac, timerce alacьgьnda eşli başladьm (молотобоец bulьp). Gəmumən, kolxozda eşləməgən eş qalmadь ul caqta. Saban sery, cəcy cəcy, pecən cabu, kibən quju, aşlьq suqtьru, elevatorga ikmək taşu...—barьsь da bezdəj malajlar—jəşysmerlər həm xatьn-qьzlar çilkəsendə ide.

"Все для фронта, все для победы!"—digən lozung astьnda eşləp, kənenə ike tapqьr umac aşь cemerep ystek bez. Jaņa ikmək əlgergəc, xəkymətkə aşlьq tapşьru başlana. Əlege aşlьqnьn un protsentьn kolxoz qaramagьnda qaldьrьrga rəxsət itjlə. Menə şul protsentlardan jort sajьn berər pot arьş onь bylep birelə. Nəq menə şul kənne uramga jaņa peşkən arьş ipienen iskitkec təmle ise tarala ide...

Jьl azagьnda, eşləgən xezmət kənnəre əcen isəp-xisap jasalьp, tagьn ikmək bylenə ide. Kyp bulsa, ike qapcьq arьş tiə ide gəiləgə. Menə şunьn belən tuqlanasьn inde—kiləse jьlnьn avgust ajьna caqlь. Sət, bərənge, alabuta, baltьrgan, arьş umacь...—şular saqlap qaldь beznen çannь ul jьllarda. Beznen gəiləne tagьn balьq ta qotqardь. Jazgь taşu waqьtьnnan başlap, morda (taldan yrelgən jətmə) sala idek jьlgaga əni belən. Quşbaşlar belən bergə, ere-ere curtannar da eləgə ide bezgə, rəxmət təşkerləre!

Kyņelemne tirənten dulqьnlandьrgan povest avtorь Əxsən Bajan belən minem jazmьş jullarь unçide jəştən ajьrьla. 1944 jьlnьn kəzendə mina şinel kiderdelər. Zapasnoj polkta, aclь-tuqlь kileş, sugьş hənərləren əjrəndem. Sugьşqa "əlgermədek". Biş jьl soldat xezmətennən son, ofitser bulьp utьz jьl xezmət ittem (ilne saqladьm). Xərbi akademiə təmamladьm. Xəzer—otstavkadagь podpolkovnik. Təzyce—inzener. Xərbi xezməttən son, Belorussiədə jəşəp qaldьm. Ike ulьm bar. Berse—ƶurnalist, şagir. Ikencese—təzyce-inzener...

Gərcə ille dyrt jьl urьs arasьnda jəşəsəm də, ana telemne (Allaga şøker!) onьtmadьm. Əle də "Qazan utlarь"n aldьram, berence bitennən axьrgaca jaratьp uqьjm. Jьraqtagь Belarus' çirendə ul mina tuьp-yskən jaqlarьmnьn ilahi çьlьsьn, gəziz xalqьmnьn şifalь saf sulьşьn alьp kilə.

Ber yk waqьtta "Azatlьq" radiosьnьn tatar-başqort redaksiəse tapşьrularьn da tьnlap, tatar dənjasьndagь xəbərlərne beleşep toram. Mondagь çirle gazetalarga yzebeznen tatar xalqь turьnda məqələlər də jazam, radiodan cьgьşlar da jasьjm. Bik monlansam, qulьma taljanьmnь alьp, tulgan kyņelemne buşatam... Menə şulaj buldь minem jazmьş, Əxsən tugan!

Qəderle jaqtaşlarьma ixlastan saulьq, tьnьclьq, illərgə iminlek, bəxetle mul tormьş teləp:

**Saniaf GARDANOF.**
*Belarus' Respublikasь,*
*Grodno şəhəre.*

*Əz-məz məzək*

# Şamil Mannap (Şaman)

## Yçətleknen ylcəy berəmlege

Dənjada hər nərsənen ylcəy berəmlege bar. Əjtik, awъrlьkнь grammnar, kilogrammnar... belən, ozъnlьqнь metrlar, santimetrlar belən, məjdannь kvadrat metrlar... həm başqa berəmleklər belən ylcilər. Ə yçətleknen ylcəy berəmlege barmь? Bar ikən. Ьşanmasagъz, millətpərwər jazucь, bəxəstə hicberkemgə başbirməs, yz syzennən ber millimetr da cigenməs Zəki Zəjnullinnan soragъz. Ul bolaj səjlər:

—Rigadagъ min uqъgan xərbi ucilişce direktorь bolaj di torgan ide: "Сила электрического тока—один ампер, сила сопротивления электрической цепи—один ом, а *упрямство* измеряется так—*один Зайнуллин!"*

Jəgni, tərçeməse bolaj bula inde:

"Elektr togь kəcəneşe—ber amper, elektr celtərendəge qarşьlьq—ber om belən, ə kirebetkənlek, yçətlek—*ber Zəjnullin* belən ylcənə..."

## Kemne kem alьştьra?

Berwaqъt Ənəs Kamalga əjtələr, həwəskər dramkollektiv rezisserь sьranь bik jaratucь Xəmit Bakirof sin bulьp bik osta səjli, dilər. Ənəs Kamal tegene ocratьp, sьrraxanəgə caqьra: "Əjdə, sьjlьjm yzenne, ə sin min bulьp səjləp kyrsətersen..."—di. Xəmit Bakirof bik şatlanьp riza bula.

Beraz pirəşlənep algac, ul Ənəs Kamal rolenə kerep, tamaq təbe belən səjli başlъj:

—Min kommunizmga qьrъq piesa jazьp alьp baram, ə sin, cyprək baş, nərsə alьp barasьn?! (Ənəs abьj xatьnьn bitərli, jənəse).

Ənəs Kamal plastmas teşləren jьltьratьp, rəxətlənep kələ:

—Слушай, Bakьr-fakьr! Min ylsəm, mine копировать itərgə sin bar. Ə sine—sьra mickəsen, ylə qalsan, kem alьştьrьr?

Maqtau syze işetergə əmetlənep torgan Xəmit Bakirof jьrьlgan awъzьn tiz genə çьja da, sьraxanədən cьgьp taja, imeş.

## Qaraqlarnь qьzьq itkən

Əlege də bajagь, Ənəs Kamal kicen son gьna əjenə təpiləgəndə julьn qaraqlar kisə.

—Çanьnmь, malьnmь?!—dip, qurqьtьp, cişenderələr monь. Ənəs abьj qarşьlьq kyrsətmi, dəşmi. Əmma qaraqlar kitep barganda kinət alarga:

—Əj, jegetlər, in qimmətle nərsəmne almadьgъz bit, rəxmət sezgə!—dip qьcqьra.

Qaraqlar monь işetep, kire borьlьp kilələr.

—Jə, nindi qijmmətle nərsən qaldь? Bir!—dilər.

—Juq, seznen əcen xikməte juq anьn. Minem əcen genə, tuest xatьn əcen qimmətle nərsəm ul...—digəc, qaraqlar keleşələr həm bu adəmnen tapqьrlьgь-çorlьgь xaqьna kiemnəren kire yzenə qaldьrьp kitələr.

## Kiəy yzebezneke

Berkənne şagir Rəşit Əxmətçan eşkə jaŋa kurtka kiep kilde.

—Aj-haj, əjbət kurtkaŋ!—dip maqtap qujdь bylmədəşe Mansur Wəli.—Bazardan aldьgьzmь əllə?

—Çuq,—dide Rəşit.—Kiəy birde...

—Kiəweŋ jumart ikən.

—Əje, jumart... Şuşь kurtkanь yzenə tugan kənendə altmьş meŋgə alьp birgən idek, oşatmagan da, yzemə kire sattь, siksən meŋgə...

## Çəbraildən əstenrək

Rəşit Əxmətçan qajwaqьt eş arasьnda əstələnə ielep, bik birelep, nider jaza başlьj ide. Andьj waqьtlarda ul səjləşmi, yzenə dəşsəŋ də, iltifat itmi. Barь tik:

—Qomacaulamagьz! Min Alla ilcese—Çəbrail fəreştədən şigri wəxi alam!—dip kenə quja torgan ide.

Şulaj, "Çəbrail belən səjləşep utьrgan" cagьnda, kinət telefon cьltьradь. Rəşit tərepkəne qolagьna qujьp algannan soŋ, jalt qьna sikerep tordь da:

—Baş məxərrir caqьra!—dip, aşьgьp, şunda kerep kitte.

Ul əjlənep cьqqac, Mansur Wəli anь şajartasь itte bugaj, əjtte:

—Nişləp əle sin baş məxərrirgə də: "Min Çəbraildən wəxi alьp utьram, qomacaulama!"—diməden, ə?

—Əjtep qara!—dide Rəşit, zəŋgər kyzləren şajan jьltьratьp.—Rawil bit ul Çəbrail genə tygel!

## "Tişek başlь" marça

1957 jьlda bik zurlap, Məskəydə Tatar ədəbiatь həm səngəte dekadasьn uzdьrdьlar. Şunda barganda Jekaterina Sokolova, Zəjnəp Xəjrullina, Zələjxa Xismətullina ber kupega turь kilələr.

Bolarnьŋ kupesьna xəl beleşergə jazucь Fatix Xəsni kerə. Gadətencə, şajartasь itə. Əmma Jekaterina Sokolova aŋlamasьn əcen tatarca səjli:

—Sez bu marçanь əske jarusqa jatqьrmagьz, jugisə əzməwer gəydəse belən əstegezgə işelep təşsə, qandala urьnьna sьtar yzegezne, xi-xi-xi!

Başqalarga quşьlьp Jekaterina Sokolova da kələp çibərə.

—Işetməgən suqьr qьz kebek, nərsə aŋlap kelgən bula ikən inde bu?—dip, şajartuьn dəwam itə Fatix Xəsni.

Şul waqьt Jekaterina Sokolova telgə kilə:

—Ix, Fatix abьj, min bit tatarcanь jaxşь aŋlьjm, minem "başьm tişek" bit!

Bu julь inde barьsь da awъzьn acьp aptьrap qalgan Fatix abьjdan kələlər.

## Rəşit Wahapofnь çьrlarga əjrətkən

Filarmoniədə repetitsiə bara ikən. Jekaterina Sokolova pianinoda ujnьj, Rəşit Wahapof çьrlьj. Əmma pianistka çьrcьnь əledən-əle byldərep:

—Tonal'nost'nь tieşencə almьjsьŋ, awazlarnь tatarca dəres əjtmiseŋ!—dip şeltəli.

Şul waqьt bylməgə muzьka belgece Zəjnəp Xəjrullina kilep kerə. Rəşit Vahapof, yzenə jaqlaucь ezləgəndəj, aŋa qarap:

—Kyregez əle, Zəjnəp, bu pianistka marça başь belən tatarnь çьrlarga əjrətməkce bula labasa!—dip, zarlanьp ala.

Jekaterina Sokolova matur gьna jьlmaja da:

—Juq, dəres əjtmiseŋ, Rəşitik, min tatarnь tygel, mişərne tatarca çьrlarga əjrətəm,—di.

# Baştuq əjtmi jalgьşqan

Əgerçe jaqlarьna komandirovkaga barьp cьqqan ber zurnalist-jazucь şunda jəşəp içat itүce Cьŋgьz Musinnь ocrata. Aŋarda jaxşь gьna qunaq bula. Kitkəndə:

—Cьŋgьz abьj, Qazanga kilgəndə miŋa kermi kitmə. Kitabьŋnь bastьrьp cьgarьrga da үzem bulьşьrmьn. Nəşriat direktorь belən duslьq bar minem...—dip, bik çьlь saubullaşa.

Kennərdən ber kenne Cьŋgьz Musin quljazma çьjьntьgьn, şuŋa estəp ec litrlь banka belən bal, ber qaz tүşkəse alьp, Qazanga kilep cьga. Tege, tanьş jazucьga telefonnan cьltьrata.

—Min kildem! Sine nicek ocratьrga?—dip sorьj.

Terepkədə şaqtьj tьnlьq, jetkergən, tamaq qьrgan tawьşlar. Annarь:

—Sələm-sələm, Cьŋgьz tugan! Tik menə ni bit əle, çajsьzraq waqьtqa turь kildeŋ bit əle, sьrxabraq toram bit əle...

—Jarar, minem əle monda başqa jomьşlarьm da bar. Bernicə kennən, inşalla, sawьgьrsьŋ da. Şaltьratqalap torьrmьn,—di Cьŋgьz, emeten ezmicə.

Ul qunaqxanəgə urnaşьp, başqalada jəşi başlьj. Hərkenne tege "dustьna" cьltьrata, əmma hər cьltьratuьnda səjləşү salqьnraq, emetsezrək bula bara. "Dus" ejenə də caqьrmьj, qunaqxanəgə də "kilə almьj".

Ec-dүrt kennən, aqcasь betə başlagan Cьŋgьz Musin tərtəne Əgerçe jagьna qajьra başlьj. Əmma alьp kilgən ber banka bal belən qaz tүşkəsen nişlətergə? Ujlap-isəpləp torgac, jekneŋ awьrragь—baldan qotьlьrga bula. Anь qunaqxanədəge bүlməsen çьjьştьrьp torgan apaga birep qaldьra. Qaznь "на всякий случай" үze belən ala. Dus jazucь belən ocraşuga emeten ezmi əle haman.

Timer jul vokzalьnnan jənə cьltьrata tegeŋə.

—Minem kitep barьş bit inde, ocraşa almadьq təki...—di, nəүmizlənep.

—Xəjerle bulsьn inde, başqa waqьtta inde,—di zur wəgdələr birgən jazucь.

—Siŋa dip apkilgən balnь gostinitsadagь apaga bүlək ittem, inde menə bu qaz tүşkəsen kemgə birim ikən soŋ?!—di Cьŋgьz aptьrap.

Tege "dusnьŋ" jetkergələwe betə, kinət tawьşь acьlьp kitə:

—Əj, awьl gьjbadь, Qazanga kilep təşүgə şunnan başlarga ide sүzeŋne! Ket mine, xəzer barьp çitəm!

—Juq inde!—di Cьŋgьz.—Soŋ inde. Ənə, pojezdьm da kilep tuqtadь. Siŋa jazmagan rizьq bulgandьr. Xuş, телефонный друг!—di də, qaz tүşkəsen şunda eskəmiədə utьrucь fəqir genə kiemle ber əbineŋ itəgenə taşlap, platformaga aşьga. Tege əbi aptьrap, əle itəgendəge "Xodajnьŋ gaip xəzinəsennən" kilgən qazga, əle əpen-tepen kitep barucь səjer keşegə qarap qala...

# *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### ТАТАРСТАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ ҺИНДСТАНДА

Үткән елның ноябрь ахырында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация Һиндстан Республикасында булып кайтты. Делегация составына Татарстан хөкүмәте әгъзалары, сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләре, банкирлар, сәнгать әһелләре, кайбер районнарның хакимият башлыклары бар иде.

Визит барышында Һиндстан белән Татарстан арасында икътисади элемтәләрне тагын да ныгыту буенча эшлекле сөйләшүләр үткәрелде, һәр ике ил өчен дә файдалы, үзара дуслыкны ныгытуга юнәлдерелгән рәсми документларга кул куелды.

### ТЮРКСОЙНЫҢ УНБЕРЕНЧЕ ҖЫЕНЫ

15-18 декабрь көннәрендә Казанда ТЮРКСОЙның—төрки телле илләр мәдәният министрлыклары даими советының XI утырышы булып узды. Анда Әзәрбайҗан, Төрекмәнстан, Казагыстан, Кыргызстан, Башкортостан, Чувашстан, Саха-Якут, Гагаузия, Хакасия, Төньяк Кипр, Төркия һ.б. төрки республика-дәүләтләрдән вәкилләр катнашты. Әлеге җыенда сүз төрки халыкларның әдәбиятын-сәнгатен, мәдәниятын үстерү, төрки илләрне рухи берләштерү, үзара хәбәрләшеп яшәү турында барды.

ТЮРКСОЙ халыкара берләшмәсе вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры Р. Миннеханов һәм шулай ук Төркия Республикасының Татарстандагы Генераль консулы Ә. Дәмирәр белән очраштылар.

### АВСТРИЯГӘ ВИЗИТ

2-3 декабрь көннәрендә Австриянең Линц шәһәрендә Европа төбәкләре Ассамблеясе (ЕТА) конгрессы булды. Аңа дөньяның 23 иленнән 500 гә якын делегат килгән иде. Конгресс эшендә Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин да катнашты. Ул делегатлар алдында суверен республикабызның социаль-икътисади үсешенең төп юнәлешләре, хәзерге чорда Россиядәге федератив мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләре, Татарстанның Европадагы башка төбәкләр белән тигез хокуклылык һәм партнерлык принципларында хезмәттәшлек итәргә әзер булуы турында сөйләде.

Европа төбәкләре Ассамблеясенең җитәкче органнарына булып узган сайлауларда Ә. Гобәйдуллин, Россиядән бердәнбер кеше буларак, шушы оешманың Бюро составына сайланды.

### ПРЕЗИДЕНТ САРАЕНДА ОЧРАШУЛАР

9 декабрьдә Татарстан Президенты М. Шәймиев Республикабызның танылган бер төркем композиторларын кабул итте. Иң элек Җөмһүриятебез Илбашы күренекле композитор—Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Урал һәм Идел буе республикалары композиторларының региональ берләшмәсе җитәкчесе, Россия Федерациясенең, Татарстан һәм Каракалпакстан Республикаларының атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил премиясе лауреаты М. Яруллинны 60 яшьлек юбилее белән ихлас котлады, аңа иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен олы рәхмәтен белдерде, нык сәламәтлек, яңа уңышлар теләде.

Очрашуда катнашкан Татарстан композиторлар оешмасы җитәкчесе Р. Кәлимуллин, композиторлардан Р. Еникеев, Р. Ахиярова, М. Любовский иҗат берлегенең төрле өлкәдәге киң кырлы эшчәнлеге, хәл ителергә тиешле мөһим бурычлар, юбилейлар үткәрү турында да сөйләделәр.

* * *

10 декабрьдә Президент сараенда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары—әле яңарак кына 70 яшьлек юбилейларын билгеләп үткән Ш. Галиев, Н. Фәттах һәм 50 яшен тутырган Р. Мөхәммәдиев белән очрашу булды. Президент М. Шәймиев, ТР Дәүләт Советы һәм Хөкүмәт исеменнән, үз исеменнән аларны шушы истәлекле даталары

белән чын күңелдән котлады, татар әдәбиятын үстерүгә, кешеләребезне әхлакый һәм эстетик тәрбияләүгә зур өлеш кертүләре өчен рәхмәт хисләрен җиткерде.

Дустанә-җылы әңгәмә барышында республикабыз каләм әһелләре алдында торган җитди проблемалар һәм аларны чишү юллары турында да эшлекле сүз барды.

**МАМАДЫШТА—МАТБУГАТ КӨНЕ**

26 ноябрьдән 6 декабрьгә кадәр республикабызда "Татарстан матбугаты үз укучылары янында" дип исемләнгән уникөнлек үткәрелде. Шул уңайдан 27 ноябрьдә Мамадыш шәһәрендә ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы коллегиясенең күчмә утырышы уздырылды. Анда Татарстан радио-телевидениесе, газета-журналлар, нәшриятлар вәкилләре белән бергә, ТР Элемтә, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыкларының җаваплы хезмәткәрләре дә катнашты. Утырышта ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, "Татарстан почтасы" идарәсе башлыгы Ф. Хәбибуллин финанс-икътисади кризис шартларында массакүләм матбугат чараларының хәле, газета-журналларга язылуның барышы турында сөйләделәр. "Авыл хуҗалыгын реформалаштыру: юллар һәм проблемалар" дигән түгәрәк өстәл сөйләшүендә Мамадыш районы хакимияте башлыгы Ф. Идиятуллин, "Татар-Информ" Мәгълүмат агентлыгының генераль директоры Р. Ратникова, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары М. Ибраһимов һ. б. чыгыш ясады.

**ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ ИҖАДИ БӘЙРӘМНӘРЕ**

Мэрия һәм Язучылар оешмасы инициативасы белән, 16 декабрьдә Чаллыда Равил Фәйзуллинның иҗат кичәсе уздырылды. Шагыйрьне Чаллы шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Фәйрүзә Мостафина котлады. Кичәдә Тукай премиясе лауреатлары шагыйрь М. Әгъләмов, рәссам Ә. Фәтхетдинов, шулай ук, язучылардан А. Хәлим, Р. Хисмәтуллин, В. Имамов, Ф. Әмәк, М. Мирза һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады. Кичә ахырында Р. Фәйзуллин укучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирде, тамашачыларны яңа шигырьләре белән таныштырды.

* * *

2 декабрь көнне Питрәчтә шушы районда яшәп иҗат итүче язучы һәм педагог Павел Апушевның 60 яшьлек юбилее зурлап билгеләп үтелде. Шагыйрьне бәйрәме белән котларга Казаннан язучылар Мәгъсүм Насыйбуллин, Мансур Вәли, Әхәт Гаффар һәм "Ватаным Татарстан" газетасы журналистлары, радио-телевидение вәкилләре килгән иде.

**С. МАКСУДИ ИСТӘЛЕГЕНӘ**

Биектау районының Ташсу авылында туган олуг шәхес Садри Максудиның хезмәтләрен һәм истәлеген хөрмәт итү йөзеннән, Дөбъяз музеена, Суксу мәктәбенә аның данлы исеме бирелде. Район үзәгендәге 2 нче Яшел урам шулай ук С. Максуди исемен йөртә башлады.

**РӘССАМ КҮРГӘЗМӘСЕ**

13 ноябрьдә Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында күренекле рәссам К. Нәфиковның 60 яшьлек юбилеена багышланган иҗат күргәзмәсе ачылды. Анда Канәфи әфәндәнең төрле елларда иҗат иткән 200 дән артык эше куелган иде.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

Татар музыка сәнгате өлкәсендәге олы казанышлары өчен "Казан" милли мәдәният үзәгенең "Идел" концерт-филармония берләшмәсе җырчы-артисты **Сөңгатуллин Мирсәет Миңшәһит** улына "Татарстан Республикасының халык артисты" дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Мәдәниятне һәм әдәбиятны үстерүдәге уңышлары өчен, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре **Исмәгыйлев Нәҗип Фәйзрахман** улына **(Нәҗип Нәккашка)** "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# КАЗАН ГЕРБЫ—ТАТУЛЫК ТАМГАСЫ

732 елда куелган Күлтәгин мәңгеташында мондый сүзләр бар: *Түргәш каганда Мәкрәч тамгачы, Угызбилгә тамгасы калти.* Ягъни *Түргәш каганыннан Мәкрәч һәм Угызбилгә атлы пичәт саклаучылар килделәр.* Икенче бер борынгы документта: *бәк тамгасы әлгиңдә,* ягъни *хакимият пичәте кулыңда* диелгән. Шулай итеп, тамга сүзенең төп мәгънәсе пичәт (мөһер, нишан) булган.

Тамга сүзенең икенче мәгънәсе—билге. Һәр нәселнең үз тамгасы булган. Аны, гадәттә, сугыш коралларына, мал-мөлкәт әйберләренә һ.б. нәрсәләргә сукканнар. Бәк һәм патша нәселләренең тамгалары герб ролен үтәгән. Кайбер шундый тамгалар шәһәр яки дәүләт гербына әверелеп киткәннәр. Мисал өчен, мондый тамгалар хазар тәңкәләрендә Y, Болгар тәңкәләрендә A, Кыпчак (Алтын Урда) тәңкәләрендә Ħ рәвешендә сугылганнар.

Казанда көмеш тәңкәләр, ул болгар җирләренең үзгенә әверелгәннән соң, рәсми рәвештә Болгар (Болгар әл-Җәдид түгел!) исеме астында урда ханы Шадибәк тарафыннан 1400-1407 елларда сугыла башлый.

Тышлыкта урнаштырылган тамга тәүге мәртәбә Казанның беренче мөстәкыйль ханы Гаязетдин (идарә иткән еллары 1422-1445) тәңкәләрендә очрый башлый. Гаязетдиннең Казанда („Болгарда") сугылган 860 дирһәме саклаңган. Аларның кайберләренең сул ягында сугылган җире „Болгар" дип күрсәтелгән, ә кайберләренә тамга гына сугылган. Тамганың Казан-Болгарда соңрак идарә иткән Олы Мөхәммәт тәңкәләрендә дә сугылуы аның Казан тамгасына яки гербына әверелүе турында сөйли, чөнки Олы Мөхәммәт Алтын Урда ханы булып утырган чорда хәтта аның урдасында (станында) сугылган тәңкәләрдә дә мондый тамга юк.

Кырымда Гәрәйләр токымын башлап җибәргән Хаҗигәрәй Казан патшасы Гаязетдиннең туганы Дәүләтбирде нәселеннән булганга күрә, әлеге тамга Кырым ханнары ярлыкларына сугылган нишаннарда да сакланган.

Тамга кереше тартылган ук белән җәяне аңлата. Кереше тартылып, җәя атарга әзер булса да, угы күккә төзәлгән булганга, татулык, дуслык, тынычлык ниятен белдереп торган. Мәгълүм тарихчы М.Г.Худяков үзенең 1923 елда чыккан китабында: "В настоящее время национальным гербом казанских татар считается лук с натянутой тетивою и со стрелою обращенною вверх" дип яза. Казан тәңкәләрендә сугылган тамгаларга карап фикер йөрткәндә, укның өскәме, йә булмаса аска таба каратыпмы төзәлгәнен (анысы да бит татулык ниятен белдерә!) төгәл генә ачыклавы читен. Ләкин бернәрсә ачык—ук аска төзәлгәндә, җәянең тартылган керешен күрсәткән сызыкча беркадәр тәрене хәтерләтә. Бәлки шуңа күрәдер аны гадәттә (мәсәлән, нишаннарда) өскә таба каратып сурәтләгәннәр.

Тышлыкта бирелгән рәсемдәге зур тамганың талисман буларак муенга тагып йөртелгәнлеген укның каурыйлы башында җеп сыярлык итеп кенә калдырылган махсус тишеге күрсәтеп тора. Шунысы игътибарга лаек, талисман-тамга муенга ук башы аска каратылган хәлдә тагылган. Шунысы ачык: аны Казан патшасы Гаязетдин нәселеннән булган кеше тагып йөргәне шиксез. Тамга-амулет археология белән кызыксынучы Е.А.Беговатов тарафыннан Казаннан ерак булмаган бер Идел утравыннан 1997 елда табып алынган. (Тамганың һәм борынгы тәңкәнең үлчәмен ачык күз алдына китерү өчен аларның янәшәсендә бүгенге Татарстан гербы һәм хәзерге вак акча урнаштырылды).

Казанда сугылган дистәләгән мең көмеш һәм бакыр тәңкәләрдә урнаштырылган тамга—ул борынгы Казан тамгасы һәм, тарихи яктан караганда, аның бүгенге Казанның да татулыкка, тынычлыкка өндәүче матур бер гербы булырга тулы хакы бар.

**Әзһәр МӨХӘММӘДИ,**
*Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*тарих фәннәре докторы, профессор*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, техник фәннәр докторы Зәки Зәйнуллин.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Рәдиф ГАТАШ. **Гөлләр су сорый.** -Казан. Татарстан китап нәшрияты., 1998. - 256 бит. Тиражы—2000 данә.

Моннан утыз еллар элек (1966 елда) "Гөлләр су сорый" исемле беренче китабын чыгарган шагыйрьнең быел дөнья күргән сайланма лирика китабы да шулай аталган.

Күренекле шагыйрьнен бу китабына анын кырык елга якын иҗатыннан (1961—1998) иң яхшы дип тапкан үрнәкләр тупланган. Анда Р.Гаташның укучыга яхшы таныш яшьлек лирикасы—шигырь цикллары, җырлары һәм соңгы елларда шәрык поэзиясенә бәйле эзләнүләр җимеше—робагый, газәл жанрындагы шигырьләре дә урын алган. Китапка кереш сүзне Галимҗан Гыйльманов язган.




Роберт МИННУЛЛИН. **Уфа-Казан юллары.** -Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1998. -416 бит. Тиражы—3000 данә.

Танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Миннуллинның бу сайланма китабына төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре, дусларына, каләмдәшләренә, якташларына багышлап язылган котлаулары, эпиграммалары тупланган. Шагыйрь мәхәббәт турында, әниләр турында, тормыш мәгънәсе, Туган җир һәм халык язмышы өчен җаваплылык тоеп яза. Үзәктә—үз гомерләрен Татарстан һәм Башкортостан республикалары белән бәйләгән татар кешеләре, татар әдипләре язмышы. Кереш сүзне халык шагыйре Илдар Юзеев язган. Китапның редакторы—Г. Гыйльманов. Басма яхшы кәгазьдә, күп фотоиллюстрацияләр белән, заманча затлы итеп чыгарылган.

Индекс 73210



Зәки Зәйнуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)